# КАЗАН УТЛАРЫ

6
ИЮНЬ
1980

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Журналыбыз, В. И. Ленинның тууына 110, Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулу бәйрәмнәренә багышлап, очеркларга **«Вакыт һәм кешеләр»** дигән конкурс игълан иткән иде. Жюри, басылып чыккан һәм редакциядәге әсәрләрне карап, бүләкләрне түбәндәге авторларга бирергә карар кылды.

Беренче бүләк (150 сум) — **Изаил Зариповка:** «Уренгойның ак боланы» дигән очеркы өчен;

икенче бүләк (100 әр сум)—**Илдар Низамов** белән **Марсель Зариповка:** «Ул кабызган маяклар» һәм «Яңа эш — киң колач» очерклары өчен;

өченче бүләк (75 әр сум) — **Рәйсә Юсупова** белән **Мәгъсүм Гәрәевкә:** «Чәчәк бәйләме» һәм «Шамил батыр» очерклары өчен.

Конкурста катнашкан һәр авторга зур рәхмәтебезне белдерәбез һәм яңа иҗат уңышлары телибез.

**Жюри.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

6
ИЮНЬ
1980

## Бу санда

Г. УСМАНОВ. Мәңгелек бердәмлек . . . . . 3
Г. АХУНОВ. Йолдызлар калка. Повесть . . . . 9

ҺӘР ШАГЫЙРЬДӘН БЕР ШИГЫРЬ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Җомга көн, кич белән... Повесть 69

ЮБИЛЕЙГА — ВЕТЕРАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Ш. МАННУР. Сабыр төбе... Поэмадан өзек . . . 105
Х. ТУФАН. Төрле еллардан. Шигырьләр . . . . 110

Ф. ХӨСНИ. Берәү бик якын кебек... Хикәя . . 114
Бәйрәмгә — дуслар букеты . . . . . . . . 120

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ХӘСӘНОВ. Ай үсәсен көн үсеп . . . . . . 129
Күтәрелү һәм яңарыш еллары . . . . . . . 138

ПУБЛИЦИСТИКА

Я. АБДУЛЛИН. Рухи асылыбыз . . . . . . . 150

МӘСКӘҮ. 80 НЧЕ ЕЛ ОЛИМПИАДАСЫ

Ә. БУЛАТОВ. Ленин һәм физик культура . . . 156
Х. МОРТАЗИН. Батыр якташларыбыз . . . . . 159

НӘБИ ДӘҮЛИГӘ 70 ЯШЬ

С. МАННАПОВ. Язгы ташулар яктысы . . . . 165

ЖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВКА 60 ЯШЬ

Л. ИХСАНОВА. Зур бакчаның бер гөле . . . . 171

МАНСУР ХӘСӘНОВКА 50 ЯШЬ

Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме . . . . . . . 174

МӘРЗИЯ ФӘЙЗУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ

М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Солдат хатлары. Шигырьләр . 176

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

З. ГОМӘРОВА. Бер өйдән сигез кеше. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 180

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Үсештәге иҗат . . . . . . . 181
Г. РАМАЗАНОВ. Поэзиядә заман сулышы . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова (җаваплы секретарь), Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 27/II-1980 ел. Басарга кул куелды 23/V-1980 ел. ПФ 09019. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94.000 экз. Заказ У-117. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

**Г. И. Усманов,**
Татарстан АССР Министрлар Советы председателе

# МӘҢГЕЛЕК БЕРДӘМЛЕК

Партиянең ленинчыл милли политиканы— халыкларның тигезлеге һәм дуслыгы политикасын практик тормышка ашыруы — социализмның иң зур казанышларыннан берсе.

Л. И. Брежнев.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү турындагы В. И. Ленин имзасы куелган декрет игълан ителгәнгә—60 ел.

Бу данлы бәйрәм көннәрендә Совет Татарстаны хезмәт ияләре, барлык совет кешеләре кебек үк, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXV съезды карарлары белән рухланып яшиләр һәм эшлиләр. Табигый омтылыш, табигый күренеш.

Татарстан АССРның быелгы юбилее партиябезгә һәм Совет дәүләтенә нигез салучы В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу бәйрәменә туры килүе белән дә истәлекле. Чөнки Совет хөкүмәтенең Татарстан Автономияле республикасы төзү турындагы декретында юлбашчыбыз имзасы тора. Владимир Ильич Ленин республикабызның беренче адымнарын игътибар белән күзәткән, аякка басуына ярдәм иткән.

Менә 60 ел буена инде Совет Татарстаны, киләчәккә илтә торган мәһабәт магистраль буйлап алга омтылучы үзенчәлекле бер поездны хәтерләтеп, совет халыкларының бердәм семьясында алга бара.

Татар халкының хезмәт кешеләренең гасырлар буена килгән уй-хыялларын чагылдырган гүзәл риваятьләре күп. Ләкин аларның иң матурларыннан матуры да Совет елларында барлыкка килгән гаҗәеп үзгәрешләр белән тиңләшерлек түгел. Бу вакыт эчендә башка республикалар белән бертигез рәвештә, Татарстан АССР халыкларның тугандаш гаиләсендә иҗтимагый-политик, экономик һәм культура тормышының барлык өлкәләрендә бөек җиңүләр юлы үтте.

Революциягә кадәрге Казан губернасы ниндирәк йөзле булган соң? Авылга килсәң — чабаталар һәм сукалар ягы, шәһәргә барсаң — ярлы һөнәрчелек мастерскойлары дөньясы, кыскасы, кая гына күз ташлама, хәерчелек һәм ачлык төбәге. Руслар, татарлар, чувашлар, марилар һәм удмуртларның барысын да кертеп исәпләгәндә, бирәгәге һәр йөз кешенең 82 се укый-яза белмәгән. Губернада йогышлы авырулар, социаль-көнкүреш һәм башка авырулар хөкем сөргән. Үлүчеләр саны ил күләмендәге уртача саннан күбрәк, һәрбер 100 баланың 34е яше тулганчы ук үлеп китә торган була.

Ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру нәтиҗәсендә кайчандыр патша Россиясенең артта калган бер губернасы саналган Татарстан илебезнең куәтле индустрия базасына һәм нефть ягына, яхшы механикалаштырылган эре авыл хуҗалыгы

районына, фән һәм культура гөрләп чәчәк аткан үзәкләрнең берсенә әверелеп житте.

Милли республикаларның экономика һәм культура үсешендәге тигезсезлеген бетерү өчен аларның халык хуҗалыгы үсеше тизлеген гомумсоюз үсеш тизлегенә караганда югарырак булуын тәэмин иткән мондый зур адым ясау Коммунистлар партиясенең, аның Үзәк Комитетының зирәк политикасы белән генә мөмкин булды. Беренче бишьеллыклар һәм бигрәк тә социализм төзүнең шуннан соңгы чорында Татарстан индустриясенең көчле адымнары моның ачык мисалы булып санала.

1929 елдан 1940 елга кадәр СССРда промышленность житештерүе 534 процентка арткан булса, Татарстанда ул 852 процент тәшкил итте. Шунысы мөһим һәм үзенчәлекле: бу үсеш башлыча эре промышленность исәбенә барды. Ясалма каучук житештерү, кино тасмасы, авиация һәм башка күп кенә тармаклар шул елларда ук барлыкка килде инде. Җиңел һәм азык промышленносте дә кызу тизлектә үсеп китә. Бөек Ватан сугышы елларында приборлар төзү, медицина инструментлары, сәгатьләр, резина-техник әйберләр житештерү тармаклары барлыкка килә.

Совет Татарстанының алтмыш еллык тарихы — аның кискен рәвештә яңа үрләргә күтәрелүен чагылдыра. 1980 елда республикада промышленность житештерүе күләме 1913 елгы Казан губернасындагыга караганда — 750, ә 1940 елдагыдан 60 тапкыр артачак.

Хәзер Татарстан АССРда безнең заман производство тармакларының чынлыкта барысы да бар һәм ул индустриаль яктан нык үскән күп илләрдән калышмый бара. Биредә реактив пассажир самолетлары һәм вертолетлар эшләп чыгарыла, төрле-төрле промышленность җиһазлары, үлчәү приборлары житештерелә. Татарстанда эшләнгән продукция дөньяның 76 иленә чыгарыла.

Татарстан АССРга илебездәге нефть чыгару районнарының берсенә әверелү бәхете тиде.

Партиябезнең XXIV съезды наказы белән республикабыз язмышына илебездә өр-яңа автомобильләр эшләп чыгару бәхете дә эләкте. Съезд Директиваларындагы: «Татарстан АССРда йөк автомобильләре житештерү заводлары һәм аңа күрше районнарда арадаш предприятиеләр комплексы төзергә», — дигән юллар заманында зур рухлану белән каршы алынган иде.

Ул вакыттан соң нибары биш кенә ел үтте, ә КПССның чираттагы XXV съезды ачылуга Кызыл мәйданга Кама автомобильләренең беренче төркеме хезмәт рапорты белән килеп житкән иде инде. Бу ел ахырына Татарстан машина төзелешенең танылган байрак йөртүчесе — зур йөк автомобильләре житештерүнең Советлар Союзындагы иң эре комплексы илебезгә заманча эшләнгән 200 мең КамАЗ автомашинасы һәм 150 мең дизель двигателе ясап бирәчәк.

Кама ярларында барлыкка килгән бу яңа күренешләр Советлар иленең бәһа биреп бетергесез милли бер байлыгы ул. «Чаллы» дип аталган төзелеш мәйданына — КамАЗга салынган миллиардларча сум чыгымнар 1976 елдан үз хакын чыгара һәм халык хуҗалыгына менә дигән продукция бирә башлады. Хәзер КамАЗ маркалы автомашиналар илебезнең бөтен җирендә эшли: аларны БАМда да, чирәм җирләрдә, поляр тундрада, «Атоммаш»та, колхоз-совхозларда да очратасың. КамАЗ белән бергә ак таш кала, заманча төзелгән Чаллы шәһәре үсеп чыкты һәм халкының саны 300 меңлә чикне үтеп китте инде.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный Секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежневның комплексның беренче чиратын сафка бастыру уңае белән автозаводчылар коллективына котлау хатындагы: «Төзелеш масштаблары һәм темплары ягыннан Ватаныбыз һәм дөнья практикасында КамАЗга тиңдәшләр юк. Мин тирәннән ышанам: еллар үтәр, ләкин барлык совет кешеләре Камадагы хезмәт батырлыгын горурлык белән искә алырлар», — дигән сүзләрен бөтен илебез алкышлап каршылады.

Совет Татарстаны химия һәм нефть химиясе промышленностеның куәтле базасына әйләнде. Унынчы бишьеллык ахырына гомумсоюз күләмендә каучук житештерү, шиннар һәм полиэтилен эшләп чыгаруның үсеше башлыча шушы предприятиеләргә туры килә.

Безнең республикабыз — электр энергиясенә дә бай як. Бу бишьеллыкта, мәсәлән, аны эшләп чыгару үткән бишьеллык белән чагыштырганда 30 проценттан күбрәккә артачак.

Үзенең Россияне тоташ электрлаштыру турындагы гүзәл фикеренең чынга ашачагын күп дистә еллар аша күрәзәләү өчен В. И. Ленинга нинди зур зирәклек кирәк булган!

Бүгенге Татарстан — халык хуҗалыгының барлык тармакларын да иңләгән зур бер төзелеш мәйданы ул. Партия ихтыяры һәм республика хезмәт ияләренең фидакарь хезмәте белән, илебезнең башка республикаларының һәм өлкәләренең халыклары ярдәмендә, социалистик бердәмлек илләре катнашында яңадан-яңа промышленность индустриясе гигантлары, җиңел, азык һәм җирле промышленность предприятиеләре калкып чыга, яңа шәһәрләр һәм авыллар төзелә, элеккеләренең йөзе яхшырганнан яхшыра, матурайганнан матурая бара. Тугызынчы һәм унынчы бишьеллык елларында гына да республика халык хуҗалыгына 20 миллиард сумга якын, яки Совет властеның алдагы бөтен елларындагы белән чагыштырганда ике тапкыр диярлек артык капитал салынуны атау да күп нәрсә хакында сөйли.

Җыеп әйткәндә, Совет Татарстанының бүгенге экономикасы Россия Федерациясенең аерылгысыз өлеше булып үсә һәм илебезнең бердәм социаль-экономик комплексына керә.

Промышленностьтагы кебек үк республика экономикасының иң мөһим тармагы саналган авыл хуҗалыгы да искиткеч зур үзгәрешләр кичерде. Татарстан авыл хуҗалыгының үсеш тарихы берничә әһәмиятле чор белән билгеләнә:

1913 ел. Авыл җирендә бөтен Казан губернасы халкының 92 проценты яши. Уртача 5 крестьян хуҗалыгына 1 сука, өч хуҗалыкка бер сабан һәм ике хуҗалыкка бер тырма туры килә. Хуҗалыкларның өчтән ике өлеше генә атлы була.

1917 ел. Бөек Октябрь социалистик революциясе крестьяннарга беренче чиратта җир яулап бирде.

1923 ел. Совет хөкүмәтенең эчкерсез ярдәме белән авыл хуҗалыгы ныклап аякка баса башлады, сөрүлек җирләрнең 80 процентында чәчү үткәрелде.

1927 ел. Партиянең XV съезды таркау крестьян хуҗалыкларын эре социалистик җитештерү юлына күчерү юнәлешен билгеләде. Авыл хуҗалыгын үзгәртеп коруда машина-трактор станцияләре хәлиткеч, тамырдан борылыш ролен уйнады, аларны үсеп килүче промышленность авыл хуҗалыгы машиналары һәм кораллары белән тәэмин итеп торды. 1934 елның октябрена Татарстанда крестьян хуҗалыкларының 77 проценттан артыграгы кумәкләшкән иде инде. Авыл хуҗалыгындагы төп эшләрне үткәрүдә, колхоз һәм совхозларны ныгытуда бик зур уңышларга ирешкәне һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгәне өчен СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1934 елгы 3 январь Указы нигезендә Татарстан Ленин ордены белән бүләкләнде!

Икенче бишьеллык авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре өчен киеренке хезмәт еллары булды. Илебездә трактор, автомобиль һәм комбайн промышленносте ныгу нәтиҗәсендә республика шактый күп итеп авыл хуҗалыгы техникасы ала башлады, авыл җирендәге тормышның тәртибе, крестьянның холык-фигыле, психологиясе үзгәрде. 1940 елда Татарстан кырларында 9 меңләп трактор, 3 меңнән артык комбайн, шул санда ук автомашина эшләп йөри иде. Авыл хуҗалыгы механикалашкан тармакка әверелде.

Ләкин безнең шат, тыныч хезмәтебез рәхимсез сугыш белән бүленеп торырга мәҗбүр ителде. Сугыш халык хуҗалыгына, шул исәптән авыл хуҗалыгына да, иксезчиксез зыян китерде. Хәтәр кыен шартларда да колхоз һәм совхозлар үзләренең бәхәссез өстенлекләрен ышандырырлык итеп расладылар, кырыс сынауларны горур үтәләр, фронтны һәм тылны азык-төлек, ә промышленностьны чимал белән өзлексез тәэмин итеп тордылар. Сугыш елларында Татарстан хуҗалыклары илгә 154 миллион пот ашлык, 38 миллион пот бәрәңге белән яшелчә, 7 миллион пот ит һәм күп кенә башка продукция бирделәр.

Сугыштан соңгы чорда совет халкы партия җитәкчелегендә халык хуҗалыгын тиз арада аякка бастыра алды. Авыл хуҗалыгында җитештерүнең сугышка кадәрге дәрәҗәсе 1950 елда ук куып җителде.

Илебез коммунизмның матди-техник базасын төзү чорына аяк баскач, авыл ху-

җалыгы алдына яңа бурычлар куелды, ленинчыл аграр теорияне тагын да үстерү таләп ителде. Бу тарихи йөкләмә-бурычны КПСС Үзәк Комитетының март (1965 ел) Пленумы билгеләде. Ул партиянең хәзерге аграр политикасының нигезен тәшкил итеп тора. Коммунистик төзелештә авыл хуҗалыгының тоткан урынын һәм әһәмиятен яңача бәяләү, аны тиз арада үстерүнең төп мәсьәләләрен һәрьяклап нигезләү, колхозлар һәм совхозларның экономикасын һәм матди-техник базасын барлык чаралар белән ныгыту, авылның социаль алга барышын тизләтү шушы Пленумнан соң какшамас юнәлеш алды.

Ул Пленумнан соң үткән еллар аграр политика мәсьәләсендә партиянең тормышчан көчен тагын бер мәртәбә раслады. Сигезенче, тугызынчы һәм бигрәк тә унынчы бишьеллыклар чорында безнең республика авыл хуҗалыгының матди-техник базасы тәмам ныгыды, республикада авыл хуҗалыгын интенсив үстерү, фән-техника прогрессы казанышларын киң файдалану башланды.

Авыл хуҗалыгы хезмәте танымаслык булып үзгәрде. Хәзер һәрбер колхозчы һәм совхоз эшчесе төрле техника белән идарә итүгә катнаша. Республика кырларында һәм фермаларында 55 мең механизатор эшли. Алар кулында заманча машиналар, шул исәптән куәтле К-700 һәм Т-150 тракторлары, комбайннар, яңгыр яудыру җайланмалары, терлекчелек фермалары өчен машина комплекслары һәм җиһазлары бар. Машина белән сыер саву остасы, техник-оператор һәм диспетчер, электрик-көйләүче, кошчылык фабрикаларындагы автомат җайланмалар операторы кебек һөнәрләр авыл җирендә гадәти күренеш булып китте.

Боларның һәммәсе техника прогрессы турында гына түгел, ә бәлки авылдагы социаль үзгәрешләр турында да сөйли.

Авыл хуҗалыгына капитал салуларны арттыра бару бу тармакны үстерү турында зур кайгыртучанлыкка дәлил. Мәсәлән, тугызынчы бишьеллыкта республикабыз бу максатка 1 миллиард 600 миллион сум акча тотты, ә унынчы бишьеллыкта шулкадәр үк сумма дүрт елда ук үзләштерелде инде.

Химияләштерү һәм җирләрне мелиорацияләү зур үсеш алды. Авыл хуҗалыгы фәнен үстерүгә, авыл хуҗалыгына фән-техника прогрессын кертүгә, кадрлар әзерләүгә дә күп чыгым тотыла.

Комплекслы программаны тормышка ашыру, бөтен илебездәге кебек үк, Татарстан авыл хуҗалыгын да кискен алга җибәрде. Авыл хуҗалыгы тулай продукциясенең уртача еллык күләме тугызынчы бишьеллыкта 8,2 процентка, ә бу бишьеллыкның дүрт елында 9,2 процентка, авыл хуҗалыгында эшләүче һәр кешегә продукция җитештерү 8,8 процентка артты. Гадәттән тыш кыен табигать шартларында—1976—1979 елларда — бөртеклеләрнең уртача уңышы 1,3 центнерга артты. Яшелчәләрдән һәм башка культуралардан күбрәк, тотрыклырак уңыш алына башлады. Республика дәүләткә ашлыкны, шикәр чөгендере, яшелчәләр, ит, сөт һәм йомырканы узган бишьеллыкның шул ук чорындагыдан күбрәк сатты, шул ук вакытта терлекләрнең баш саны да арттырылды.

Товарлыклы йомырка җитештерү хәзер бөтенләе белән «Птицепром» тресты хуҗалыкларына тупланды, алар бу бишьеллыкның дүрт елында 1,8 миллиард йомырка һәм 45,5 мең тонна кош ите бирделәр. Хуҗалыкларны шикәр чөгендере, бәрәңге, яшелчәләр җитештерүгә специальләштерүдә зур эш алып барыла.

Хуҗалыкара һәм тармак кооперациясе авыл хезмәтчәннәренең тормыш дәрәҗәсенә, авылның социаль йөзенә шифалы йогынты ясый. Соңгы 12 елда колхозчылар һәм совхоз эшчеләре хезмәтенә түләү ике тапкыр артты. Хәзер барлык торак пунктлар электрлаштырылды, бөтен районнарда аларны үзгәртеп кору бара.

Хәзер яшәп килгән дүрт мең торак пунктының иң уңайлы урыннарда урнашкан, бай тарихы һәм традицияләре булган 1300 е үстереләчәк. Авыл төзелешенең төп юнәлеше колхозчы, совхоз эшчесе гаиләләрен өй янында бакчасы, абзарлары, гаражы булган уңайлы аерым йортлар белән тәэмин итүдән гыйбарәт булачак.

Авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген барлык чаралар белән күтәрүнең партия куйган бурычларын тормышка ашыру — халык хуҗалыгының бу мөһим тармагының алга таба тотрыклы үсүе өчен төп шарт булып кала.

Республикабыз тарихын кешеләр, замандашларыбыз язмышыннан да китаптан укыган кебек укып була. Патша Россиясенең 50 административ берәмлеге арасында

44 нче урында тора дип саналган һәм крайда колониаль политика үткәргән патша чиновниклары тарафыннан мәгариф кирәк-ярагына елга җан башына 12,5 тиен генә тотылып килгән якта хәзер югары һәм махсус урта белемле 326 меңләп белгеч эшли.

Хәзер Татарстанда укучылар саны 540 меңгә якын булган 2 336 мәктәп бар. Шулардан 683 е урта мәктәп. Йөздән артык һөнәр училищеларында 55 меңгә якын укучы укый. Училищелар 1941 елдан бирле 685 меңнән артык квалификацияле эшче хәзерләп чыгарды. Бу—хәзер республикада эшче кадрларның төп өлешен профтехбелем системасында укып чыккан кешеләр тәшкил итә дигән сүз.

СССР халыкларының яшь буынын туган телләрендә укытырга мөмкинлек алуы да культура өлкәсендәге ленинчыл милли политика тантанасы булды. Татарстанның барлык милли мәктәпләрендә, туган тел белән беррәттән, рус теле уңышлы укытыла. Совет дәүләте һәрвакыт, хәтта иң кыен елларда да халык мәгарифен үстерү турында тирәннән кайгыртты. Шуны әйтү дә җитә: безнең республикада гына да соңгы 10 елда мәгарифкә ике миллиард сумнан артыграк акча тотылды, 315 мең урынлы 500 дән артык типовой мәктәп сафка кертелде. Шул ук чорда мәктәпкәчә балалар учреждениеләре саны 600 гә, ә аларда тәрбияләнүчеләр саны ике тапкырга артты һәм ул 1980 елның 1 гыйнварена 200 мең балага җитте.

Югары һәм махсус урта белем бирү өлкәсендә бик зур уңышларга ирешелде. Хәзер республикадагы 12 югары уку йортында, дүрт институт филиалында һәм 57 техникумда 130 меңнән артык студент укый. Шуларның 45 проценты — татарлар. Һәр 10 мең кешегә туры килгән студентлар саны белән республикабыз Англия, Франция, Швейцария кебек нык үскән капиталистик илләрдән алда тора.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты —бездә югары белем бирүнең гөрләп үсүенә ачык мисал: ул 1979 ел азагында үзенең 175 еллыгын билгеләп үтте һәм фән үсешендәге зур уңышлары һәм халык хуҗалыгына югары квалификацияле белгечләр әзерләве өчен Ленин ордены белән бүләкләнде. Совет власте елларында университет 31 меңгә якын белгеч әзерләп чыгарды.

Бүген СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы институтларында, республиканың фәнни-тикшеренү институтларында һәм югары уку йортларында 17 мең фәнни хезмәткәр, СССР Фәннәр академиясенең өч член-корреспонденты, 450 дән артык фән докторы һәм 4 500 фән кандидаты эшли.

Бу саннар Татарстан АССРның мәгариф һәм фән өлкәсендәге зур казанышлары турында ышандырырлык итеп сөйли.

Сәнгатьнең барлык төрләре—революция алдыннан гына туган һәм социализм төзелеше дәвамында барлыкка килгәннәре дә, тамырлары белән ерак үткәнгә тоташканнары да яңача чәчәк атуга иреште.

Хәзер Татарстан язучылар оешмасы — РСФСРдагы иң зур оешмаларның берсе. Ул СССР Язучылар союзының 160 ка якын членын берләштерә. Совет әдәбиятында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил тирән эз калдырды. Аның иҗаты — каһарман, якты һәм зирәк, җәүһәр шигърият үрнәге, аның батырлыгы халыкара әһәмияте булган вакыйгага әверелде.

Быел Казанда «Зур Идел» зона сәнгать күргәзмәсе ачылды. Идел буе сәнгатенең бу смотры үз сафларында 70 кешене берләштерүче ТАССР Художниклар союзының соңгы еллардагы киеренке иҗади эзләнүләренә йомгак ясады.

Революциягә кадәр Казандагы бердәнбер музыка уку йортында татарлар булмаган. Хәзер исә республикада башлангыч, урта һәм югары музыка белеме бирүнең киң системасы — 50 дән артык балалар музыка мәктәбе, өч музыка училищесы, консерватория, педагогия һәм культура институтларында музыка-педагогика факультетлары бар.

Татарстанда композиторларның көчле коллективы эшли. «Шүрәле» балеты, «Җәлил» һәм «Алтынчәч» опералары СССРның Зур театрында, Ленинградтагы Киров исемендәге опера һәм балет театрында, Чехословакия, Болгария, Англия театрларында күрсәтелде һәм яңгырады.

Республикабыз хезмәт ияләрен рухи хәзинәләребезгә якынайту өчен гаять зур мөмкинлекләр бар. Бездә 9 профессиональ театр, цирк, 9 дәүләт музее, 2 560 клуб, 2 425 кино күрсәтү җайланмасы эшли, алар ел саен 55 миллион тамашачыга хезмәт

күрсәтә; 1 727 китапханә бар. Татарстан китап нәшрияты ел саен 8 миллионга якын гомуми тираж белән 350 дән артык исемдәге китап бастырып чыгара. Татарча 7 һәм рус телендә 4 журнал, шулай ук 6 республика газетасы (шулардан өчесе татар телендә) чыгарыла, кинохроника студиясе эшли.

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте совет кешеләренең сәламәтлеген ныгыту, аларның хезмәте һәм ялы өчен уңай шартлар булдыру турында даими кайгырта. Республикабызда сәламәтлек саклау, социаль тәэминат, физик культура һәм спорт үсеше шул хакта сөйли.

Тугызынчы бишьеллык һәм унынчы бишьеллыкның дүрт елында гына да Татарстан АССРда сәламәтлек саклауга бер миллиард сумнан артык акча тотылды. Дәвалау учреждениеләренә ел саен 400 дән артык яшь врач, мең ярым урта медицина персоналы җибәрелә. Бүген медицина учреждениеләрендә 10 мең врач эшли. Шушы вакыт эчендә 562 мең кешене пенсия белән тәэмин итү тагын да яхшырды. 1980 елдан башлап 146 мең колхозчының пенсияләре арттырылды.

Республика спортчылары Бөтенсоюз ярышларында, халыкара очрашуларда алдынгы урыннар яулап алалар.

Хезмәт ияләренең тормыш хәле елдан-ел яхшыра бара. 1970 елдан 1979 елга кадәр республикада эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең уртача айлык эш хакы 40 процентка арттырылды һәм быел 160 сум, ә промышленностьта 171 сум тәшкил итә. Пенсияләр, стипендияләр, пособиеләр арту һәм җәмәгать куллануы фондыннан файдалану исәбенә йөзләрчә мең кешенең доходлары артты.

Һаман үсә баручы торак фонды бик зур милли байлыгыбызны тәшкил итә. Соңгы ун елда гына да Татарстан АССР шәһәрләрендә һәм авылларында 1, 5 миллионга якын кеше өй туйлары үткәрде, бу 1960—1970 еллардагыдан бер ярым тапкыр артыграк. Тугызынчы һәм унынчы бишьеллыкларда торак-коммуналь хуҗалыкны үстерүгә, төзекләндерүгә һәм башка социаль, культура-көнкүреш объектлары төзүгә 3 миллиард сумга якын капитал салынды.

Шәһәрләр һәм эшчеләр поселоклары тиз үсә, соңгы 10 елда аларда яшәүчеләр саны 600 мең кешегә диярлек артты. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һәм башка шәһәрләр хәзерге социалистик типтагы зур шәһәрләргә әверелде. Республикабызның күптән түгел генә миллионлы шәһәргә әйләнгән башкаласы Казан нык яңарыш кичерә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе төрле милләт хезмәт иясенең дәүләт эшләре белән идарә итүенә, социалистик демократиянең чәчәк атуына киң юл ачты. Бу безнең республика мисалында да ачык күренеп тора. Татарстан АССР хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен СССР Верховный Советында 22 депутат, РСФСР Верховный Советында — 24, ТАССР Верховный Советында 250 депутат яклый. Шәһәр, район, поселок, авыл Советлары 24 милләт вәкиле булган 30 мең депутатны һәм 55 мең активистны берләштерә.

Бүген, 60 еллык иҗади эш юлына йомгак ясаганда, республика хезмәт ияләре горурлык белән әйтә алалар: Совет иле үсешенең барлык чорларында да алар социализм төзүчеләрнең алгы сафларында булдылар, республика байрагында балкыган Ватан бүләкләре — Ленин ордены, «Октябрь революциясе» һәм «Халыклар дуслыгы» орденнары шул хакта сөйли. Алар бүген дә КПССның XXV съездында билгеләнгән мәһабәт социаль-экономик программаны үтәүгә, илнең экономик һәм оборона куәтенә, коммунизм төзелешенә гаять зур өлеш кертәләр.

Республикабыз төзелүнең 60 еллыгын билгеләп, Татарстан хезмәт ияләре юлбашчыбыз истәлеге алдында зур хөрмәт белән баш ияләр, үзләренең бөтен казанышлары өчен партия һәм халыкның ныклы бердәмлегенә, Ленин партиясенең армый-талмый көндәлек эш алып баруына бурычлы икәнлекләрен тирәннән аңлыйлар. Ә безнең тыйнак халкыбыз бурычлы булып калуны яратмый һәм үз вәгъдәсенә турылыклы була белә. Аның яшәүчәнлеге шунда. Бердәм халыклар һәрвакыт яшь, көчле. Бердәмлектә—мәңгелек.

Гариф Ахунов

# ЙОЛДЫЗЛАР КАЛКА

ПОВЕСТЬ

## Беренче танышулар

Язучылар белән без университетта укыганның беренче елларында ук таныша башладык.

Сугыштан соңгы беренче елларда татар әдәбияты гөрләп үсеп китте. Зур-зур поэмалар, повестьлар язылды. Бүгенге татар совет әдәбиятының горурлыгы булган «Тукай», «Алтын йолдыз», «Онытылмас еллар», «Намус», «Язгы җилләр» әнә шул елларда иҗат ителделәр, «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыктылар.

Без, университет студентлары, язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубына йөри башладык. Анда әлеге романнар хакында кызып-кызып фикер алышалар, шигырь кичәләре үткәрәләр иде. Гомәр Бәшировны, Ибраһим Газины, Сибгат Хәкимне, Шәйхи Маннурны без мәктәп эскәмиясеннән үк укып үскән идек. Инде менә аларның трибунага чыгып сөйләүләрен күрү бәхетенә дә ирештек.

Минем үземне, мәсәлән, беренче мәртәбә Габдрахман Әпсәләмовны күрү бик дулкынландырды. Ул елларны аның «Алтын йолдыз» романын укымаган бер генә үсмер дә булмагандыр. Һәм без, ул чагында, иң яраткан язучың кем, дип сорасалар, ике дә уйлап тормастан, Габдрахман Әпсәләмов дип әйткән булыр идек.

«Алтын йолдыз» романының яшь геройлары безнең белән бергә яшиләр, күңелләрне сызып, авырттырып торалар — һәлак булганнарын әйтәм. Шунлыктан Габдрахман Әпсәләмов дигән язучыны күрү безнең күңелдә йөрткән бер хыялыбыз иде.

Шулай бер мәртәбә Тукай клубында утырган чакта, безнең яннан җил-җил атлап, ялан башлы, аксыл плащлы, уртачадан аз гына калкурак буйлы чандыр бер кеше узып киткәч, студентлар төркемендә: «Әпсәләмов!» дигән сүз ишетелеп калды. Ул арада инде әлеге җиңел гәүдәле кеше алгы рәткә үк барып утырган, янагына кулы белән таянып, ниндидер язуны укый, укый-укый да карандаш белән төзәтеп ба-

---

Дәвамы. Башы 5 нче санда.

ра иде. Юк, ялгышам, карандаш белән түгел, автомат ручка белән иде бугай. Мин аның кесәсеннән юан кара саплы ручканы чыгарганын, шундук икенче бер кесәсеннән кечерәк бер тартма алып, тартма эченнән уч яссылыгы гына кара чүпрәк алганын һәм автомат ручканың каләмен әнә шул чүпрәк белән бик пөхтә итеп сөрткәнен күрдем. Гапгади шушы бер хәрәкәт миңа бик көчле тәэсир итте, һәм мин аңа изге затка карагандай сихерләнеп карап тордым.

Трибунага чыгып сөйли башлагач, минем хәтеремә ин нык сеңеп калганы аның әдәбият дигән сүзне «әрәбият» дип сакаурак итеп әйтүе булды.

Мин «Совет әдәбияты» редакциясенә эшкә урнашкач, без көн саен диярлек очраша башладык. Габдрахман абый редколлегия члены иде, көн саен бер мәртәбә, кичкә таба, редакциягә кереп чыга торган иде. Ни бирсәң дә карышмый ала, бик төгәл укый, фикерен редакция кәгазенә язып китерә, олысына да, кечесенә дә бердәй тигез мөнәсәбәттә булып, «сез» дип дәшә торган иде.

Ибраһим Газига беренче мәртәбә укырга зур бер кулъязма илтүем шулай ук хәтердә калган. Нинди дер калын йөнтәс материалдан текКән бик зур зәңгәрсу халаттан, башына кызыл башлы сөлге урап куйган хәлдә, ул мине алма ашый-ашый каршылады. Шундук урындыкка утыртты. Мин тартынып кына утырдым, үземнең әле генә журналда эшли башлаган әдәби хезмәткәр икәнемне әйттем, менә сезгә, редколлегия членына, укыр өчен кулъязма китердем, дидем.

Кулъязманы ул кулына тотып, урталай ачты да иснәп карады.

— Фу! Тәмәке исе килә моннан! Син аны, Гариф энекәш, чыгышлый, чоландагы киштәгә куя кит әле. Бер атна торсын шунда, тәмәке исе беткәч, алып укырмын мин аны,— диде.

Мин аның ныклы характер иясе икәнен күрсәтә торган калку иягенә, калын пыялалы күзлегенә, кысыла төшкән иреннәренә, сөлге ураган зур башына сәерсенеп карап тордым да кайтып киттем.

«Язучы халкы да бер калыпка гына сугып куелмаган икән, бик төрле була икән»,— дигән уй туды күңелемдә.

Әнә шул уй, озак еллар язучылар белән аралашып яшәү һәм олкән әдипләребезнең әсәрләрен аңлы рәвештә өйрәнү аркасында, минем күңелдә тагын да ныгый төште.

## «Намус» романының сурәтләү чаралары

Университетта бишенче курста лекцияләр юк дип әйтерлек. Булса, атнасына өч сәгать буладыр, анда мин барып кайтам да журнал мәшәкатьләренә күмеләм.

Эшне мин иртәнге җидедә башлыйм. Иң әүвәл, әле беркем дә юк чагында, бер-ике сәгать гранка укыйм. Аннары тугызда, урамга чыгып, берәр ашханәдә тамак ялгап алам. Шуннан соң эшнең зурраклары китә: хатларны барлыйм, җавап язам, хикәя, повесть, романнарны редакциялим, редакцияләнгән кулъязмаларны машинкага тапшырам, техредактордан гранкаларны алып, авторларыннан укытам, яңа килгән кулъязмаларны редколлегия членнарына илтеп бирәм, әзер санны типографиягә төшерәм. Нигә бер кешегә шулкадәр дә күп эш дисезме? Без ул чагында 12 табаклы журналны нибары өч кеше: җаваплы редактор Гази ага Кашшаф, секретарь Булат Гыйззәтуллин һәм әдәби хезмәткәр — мин чыгарып бара идек. Хәзер «Казан утлары» журналының штатында 16 кеше, анда проза бүлеге, поэзия бүлеге, хатлар бүлеге, очерклар һәм публицистика бүлеге, әдәби тәнкыйть һәм башка бүлекләр бар. Бүлек саен диярлек әдәби хезмәткәр. Техник

редактор, ике корректор, баш редакторның урынбасары һәм җаваплы секретарь бар. Хәзер машинисткалар гына да икәү.

Безнең заманда Булат Гыйззәтуллин Язучылар союзының партоешма секретаре булып эшли, аның күбрәк вакыты әнә шул эшкә китә. Гази абый университетта укыта, китаплар яза, редакциягә сәгать икеләр тирәсендә генә килә иде. Миңа кулъязмалар килеп кергәннән башлап журнал булып чыгып киткәнче барлык-барлык эшне башкарырга, шулар өстәвенә әле журналны тарату эше белән дә шөгыльләнергә туры килә иде.

Боларны мин һич кенә дә зарланып әйтмим. Редакциядә эшләгән дәверемдә мин теләсә нинди эшне башкара алырлык, үз әсәрләремне иң кыен шартларда да яза алырлык, җәмәгать эшләреннән ни кушсалар, шуны үти алырлык хәлгә килдем. Үземдә корыч дисциплина, режимлы яшәү әмәле булдыра алдым.

Нәкъ шул елларны мин Муса Җәлил архивын өйрәндем, герой шагыйрьнең чамадан тыш күп эшләгән, күп язган булуы мине янә бер мәртәбә яшәү рәвешемнең дөрес икәненә ышандырды.

Бүген кайбер яшьләр җәмәгать эше куштыңмы, шундук каш җыералар, сөмсерләре коела. Минем аларга Муса Җәлил тормышы белән ныграк танышуны тәкъдим итәсем килә. Югарыда санаган бик күп редакция эшләре янына мин әле Язучылар союзы месткомында, проза һәм тәрҗемәчеләр секциясендә секретарьлык эшен дә алып бара идем. Нәкъ әнә шул чорда мин беркетмәләр, карарлар, мөрәҗәгать язарга өйрәндем. Соңыннан алар миңа бик тә кирәк булып чыктылар. Әйе, эш ифрат күп, вакыт бик аз, вакыт кысан, шуңа күрә йоклавын да редакциянең бер бүлмәсендә йокларга, тумбочкада мендәр тотарга мәҗбүр идем.

Ул еллар өчен мин Шәһидәгә әле дә рәхмәт укыйм: көнләшеп-мазар итеп, кирәккә-кирәкмәскә тикшереп, мине борчымады, минем булсынга йөрүемне белде, кичен җиделәр тирәсендә берәр сәгатькә генә кереп чыккан чакларда, сагынып, зерә дә үз итеп, чын туганнарча каршылый һәм туганнарча озатып кала иде.

Квартирага без Чернышевский урамының Гажур йортына кердек, дөресрәге, югарыда әйткән Советлар Союзы Герое Павел Яковлевич Гурьяновларда унбиш метрлы бер бүлмәдә өйдәш булып яшәдек. Мәхмүт Хөсәен ул елны хатыны белән башка чыкты. Яхъя Халитов тулай торакка күчеп китте.

Редакциядә башкарыла торган бик күп, бик мәшәкатьле эшләр белән бергә, мин әле университетның бишенче курсында укыйм, шул елны диплом эше язарга һәм дәүләт имтиханнары тапшырырга тиеш идем.

Баштарак мин, диплом эшен ничек язармын икән дип, куркып йөрдем. Редакциядә эшләвем, язучылар белән әледән-әле очрашып торуым, әтиебез урынына калган кеше, гаять дәрәҗәдә ягымлы, сабыр табигатьле Гази абый Кашшафның өзлексез булышлыгы аркасында, диплом эшен бары тик уку белән генә шөгыльләнгән сабакташларыма караганда алданрак, әйтергә мөмкин, хәтта беренче булып якладым.

1951 елны «Намус» һәм «Язгы җилләр» романнарына СССР дәүләт премиясе бирелде. Язучылар союзында шул уңайдан митинг булды. Бу романнарның даны белән бергә, татар әдәбиятының да даны ил буйлап яңгырады. «Намус»ка да, «Язгы җилләр»гә дә һәркайда ишек ачык, һәркайда яшел урам иде. Аларны илебез халыкларының күп кенә телләренә тәрҗемә итеп, бастырып чыгардылар. Аннары алар Европа илләренә чыгып китте. Бу ике роман хакында зур-зур мәкаләләр, фәнни хезмәтләр языла башлады. Миңа «Намус» романының сурәтләү чаралары хакында диплом язарга куштылар. Көчләп түгел, Мин аны үзем теләп алдым. Язучы Гомәр Бәширов романының теле,

гомумән, аның әдәби телгә булган мөнәсәбәте минем уйлаганнарыма, минем эстетик карашларыма ятышлы иде. Университетта чакта телчеләр төркемендә укуым да, бәлки, шуңа этәргәндер. Ул елны мин әдәби тәнкыйть белән дә шөгыльләнә башлаган идем.

«Намус»ның тулыландырылган өченче басмадагы зур калын китабын мин башта өч мәртәбә укып, карандаш белән сызып чыктым. Фикеремне язмаган, әсәрнең җөмләләрен төсле карандашлар белән билгеләмәгән бер генә бите дә калмагандыр.

Шуннан соң «Намус»ның телен квалификацияли башладым. «Квалификация» дигән авыр, татар теленә бигүк ятышып бетми торган сүзне бу урында шуңа кулланам, чөнки безгә ул чорда хезмәтебезне мөмкин кадәр фәнни итәргә, гыйльми терминнарны кыстырып язарга өйрәтәләр иде. Шул рәвешчә, мин «Намус» романындагы сүзләрне тартмаларга бүлеп тутырырга тотындым. Индивидуаль сөйләм, пейзаж теле, геройларга социаль характеристика, динамик вакыйга, тантаналы күренешләрдәге алымнар, әкият телен куллану, геройларның эчке кичерешләрен эчке монолог аша тасвирлау — минем тартмаларның иге-чиге юк иде. «Намус»ны шул рәвешле «сүтеп» чыккач, мин үземә фәнни җитәкче итеп билгеләнгән укытучым, филология фәннәре докторы Латыйф ага Җәләй янына килдем. Аның кәефсезрәк йөргән, муены кәкрәебрәк калган заманнары иде, Латыйф ага минем белән сөйләшергә кафедрага килмәде, туп-туры өенә чакырды. Киттем өенә. Галим йортыннан әллә ниләр күрергә өметләнеп барсам да, әллә ни күрә алмадым. Диван күрдем дә, өстәл күрдем, китап күрдем дә, шкаф күрдем. Безгә Җәләй аганың хатыны — аксыл чырайлы юаш апа чәй әзерләп китерде, майлап, ипиләп чәй эчтек. Сохари кимердек.

Латыйф ага, авырткан муенын тамырлары бүртеп торган кулы белән терәтеп, мин сөйләгәннәрне тыңлап утырды да минем картотекаларны күздән кичереп чыкты.

— Син брат Әүхәди,— дип башлады сүзен. «Әүхәди» аның һәммәбезгә әйтә торган яраткан сүзе иде. — Бик хәтәр купкансың бит әле. Мөгезне бәк зурдан чыгарырга келисең, шәй. Алай кирәгимәс. Башта син, брат Әүхәди, уйлап, бүрегең белән киңәш итеп кара: Гомәр хәзрәт, ягъни мәсәлән, элекке псевдонимы белән әйткәндә, Гомәр Разин ни өчен әсәрнең баш каһарманы иттереп Нәфисә киленне алган? Аннан ары килеп, ни өчен аңар каршы чулак Сәйфине, икенче төрле иттереп әйткәндә, кулак Сәйфине куйган? Нәфисәнең үз бригадасы кызларына «гөлкәйләрем» дип сөйләве Казан арты сөйләше генәме, әллә ул сүзнең бу чибәр яшь хатынны характерлый торган башка нагрузкасы, ягъни йөкләтмәсе дә бармы? Әйтик, чулак Сәйфи «дисвительни без алга китмәдек, иллә мәгәр артка да чигенмәдек» дибәйтеп әйткән сүзе белән безнең каршыга кем булып килеп баса? Бу очраклы хәлме, әллә бигүк очраклы түгелме? Гомәр Бәширов дигән хитрый абзаң аны берәр төрле, әйтик, социаль төсмерне бирү өчен кулланмаганмы? Ни өчен мин шундый конкрет, Шәйхи Маннур дигән шаирча әйткәндә, гәнгрит сораулар куям сиңа? Рәбига Афзаловна дигән бик тә хәтәр оста тел галиме сезгә сүзне контексттан аерып алып үрәтте. Ә мин сиңа, брат Әүхәди, сүзне контекст эчендә карарга кушам. Миңа синең сүзне ия дип, хәбәр дип, тәмамлык дип каравың кирәкми. Бир син миңа татар теленең җегәрен, көчен-гайрәтен бир! Менә булырсың тел галиме, менә булырсың — лингвист! Төшендеңме, брат Әүхәди?

— Төшендем, Җәләй ага, — дидем мин һәм, картотекалар тутырган папкамны күтәреп, өйгә кайтып киттем.

Шуннан соң мин өч-дүрт ай буена Латыйф ага күзенә күренмәдем. Аның мине формализмнан сакларга теләвен, әдәби телне эчтәлек белән форманың берлеге итеп карарга кушуын төшендем мин.

Мин үз алдыма менә нинди сораулар куйдым: хезмәттә, иптәшләренә мөнәсәбәттә һәм мәхәббәттә яңа карашлы, олы җанлы Нәфисәнең, әсәрнең беренче битләреннән үк укучының симпатиясен яулап алган Мәүлихә түтинең, укытучы Хәйдәрнең, райком секретаре Җәүдәт Мансуровның, авыр чакта «Чулпан» колхозы белән җитәкчелекне үз җилкәсенә алган Тимери картның һәм тагын башка бик күп уңай һәм тискәре геройларның без ышанырлык эчке халәтен автор нинди әдәби алымнар, нинди сурәтләү чаралары белән тудыра алган?

Латыйф ага без фәкыйрегезгә — «брат Әүхәдигә» сүзнең әсәрдәге мәгънә йөклатмәсен ничек тикшерергә кушса, гел шул юл белән бардык. Бу мине системасызлыктан коткарып кына калмады, бу мине үзем язачак әсәрләргә карата да саграк булырга, тел-сурәтләү чараларына таләпчәнрәк килергә өйрәтте.

«Аксыл зәңгәр күктән мул булып яз кояшының саргылт нуры коелган иртәдә, керфекләренә кадәр тузан кунган юка гәүдәле бер кыз белән яшүсмер кыз бала, җырлый-җырлый, бодай тазарткан» чакта, аларның бригадирлары, җыйнак кына киенгән яшь килен Нәфисә кырдан кайтып төшә.

— Я, нишлибез соң, гөлкәйләрем? Болай булгач, безнең бодай орлыгыбыз җитми бит,— ди ул.

Бу җөмләдәге «гөлкәйләрем» сүзе, «соң» ярдәмлеге, халык теленә кереп урнашкан «болай булгач» тәгъбире Нәфисәнең иптәшләренә эндәшүендәге ягымлылыкны, алар көченә ышану интонациясен бирәләр, Нәфисәнең бригада членнарына үз итеп, якын дусы итеп, ышаныч баглап каравын әйтеп торалар ич. Әлеге җөмләдән «бит» һәм «соң» ярдәмлеген, «гөлкәйләрем» дигән эндәш сүзне, «болай булгач» тәгъбирен, «бодай орлыгыбыз» дигәндәге бодай орлыгына үзеңнең газиз әйбереӊ итеп карауны билгерткән «быз» кушымчасын алып ташлау белән җөмлә дорфа бер эндәшкә әйләнеп кала һәм без белгән ягымлы, коллектив җанлы Нәфисә шундук юкка чыга.

— Я, нишлибез, безнең бодай орлыгы җитми?

«Бәлки, бу очраклы гына диалогтыр? Бәлки, мин арттырып җибәрәмдер? — дип уйладым мин. — Туктале, брат Әүхәди, тагын бер тикшереп кара әле син».

Бригада членнары җыелышып киңәшкән чакта, Карлыгач җитмәгән орлыкны үз араларыннан җыярга, көзгә хәтле әҗәткә биреп торырга әйткәч, Нәфисә болай ди:

«— Ишеттегезме, Карлыгач нәрсә ди? Үземнең дә шундый бер өметем бар иде, башта ук уйлап куйган идем, мондый асыл кешеләр белән беркайчан да хур булмабыз, дигән идем. Бу тикле дә дөрес чыгар икән! Әйдәгез, гөлкәйләрем, болай булгач, кайтыйк инде. Кайтыйк та, өйдәгеләр белән киңәшеп, уйлашып килик: кем күпме бодай әҗәткә биреп тора ала? Аннары Айсылу апа белән дә сөйләшик. Бәлки, ул әле теге кире бәндәне акылга утыртыр!»

Бу диалог минем алдагы уйларымның дөрес икәненә ышандырды. Чыннан да, ягымлылык, үз итеп сөйләшү, ышану интонациясен күрү биредә дә кыен түгел бит. Шуның өстәвенә, без сүзләрнең бер-берсенә бәйләнешеннән, тезелү тәртибеннән Нәфисәнең шушы мизгелдәге рухи халәтен дә тоябыз. Сүзләр биредә аның күңел күтәренкелеген, чыраена чыккан елмаюны әйтеп торалар.

Менә әле генә китерелгәннең капма-каршысы:

«...караңгы залдан Әпипәнең ал яулыгы калыкты, чөметтереп ала торган зәһәр сүзләре чәчрәп чыкты:

— Илдә булмаганны пешер, катын, дигәндәй, ни чыкмаса, шул Акбитнекеләрдән чыга! Безнең бригада имеш! Бакчи, менә мин дә синең бригада бит. Нигә минем сүзне җыелышка әйтмисең? Авырын-

жинелен белгән юк, уйлап караган юк, уптым илайһи чыгар да аудар. Һай, һай, һай, ташкулчим!»

Ачы, ярсулы тел, җәнҗалчы катыннар теле. Ә нинди динамика, нинди ярсынып ыргытылган утлы сүзләр! Бердән, Әпипәнең характерын тудырса, икенчедән, җыелыш кебек күңелсез нәрсәгә киеренкелек өсти.

Шушылардан соң, ягъни язучының персонажлар телен эчке бер сиземләү белән генә түгел, аңлы рәвештә, бик зур хезмәт куеп, тырышып яза икәнен ачыклагач, мин «чулак Сәйфи — кулак Сәйфи» теленә күчтем.

«...Инде бер төрле, барын бергә төйнәп әйткәндә, без нәрсә күрәбез? Без, иптәшләр, шуны күрәбез: дисвительни, түгел мирни врмедә генә, сугышның шундый куркынычлы и шундый, стал быт, авыр чагында да безнең «Чулпан»ыбыз мах бирмәде. Дисвительни ул алга китмәде, иллә мәгәр, әйтергә кирәк, артка да чигенмәде. Кәнишне сез әйтерсез инде, орлык җитми и шулай ук атлар да ябык дип әйтеп... Дисвительни, иптәшләр, орлык җитенкерәми, шулай ук атлар да көрдән түгел...»

Сәйфинең бөтен тормышы әллә нинди томан белән өртелгән. Сөйләгән чакта да ул ачык итеп сөйләми, кеше аңламаслык итеп бутап бетерә — наданлыгыннан түгел. Аңа үзенең эшкә аяк чалуын, вак җанлылыгын сүз чүбе астында күмеп калдырырга кирәк. Бу — икейөзле кеше, шкурник теле.

Диалогларның социаль характеристика бирә алырлык булуына, шул ук вакытта гаять тә халыкчанлыгына ничек ирешә алды икән соң язучы? Бу хакта мин авторның, Гомәр абыйның үзе белән киңәшмәкче булдым. Ләкин бер генә сорау белән бару уңайсызрак иде, аның язу үзенчәлекләрен үзем өчен бөтенләе белән ачыклап бетерергә теләдем.

Диалоглар төзүдәге тагын бер уңай моментка юлыктым мин «Намус» романында. Бу — геройларның тышкы хәрәкәте белән рухи халәтен, ягъни эчке дөньясын бергә кушып алып бара белү алымы.

Гомәр Бәшировка Хәдичә түтинең фронтта үлгән улын сагыну моментын бирергә кирәк. Мин, мәсәлән, тәҗрибәсез яшь автор мондый очракта «сагыну, юксыну», «үзәге өзелү» фигыльләрен куллаңыр идем. Тәҗрибәле, өлкән язучы алай итми, рухи халәтне ул башкачарак төзи.

Хәдичә түти, «кечкенә чагында баласының ялан башын сыйпаган сыман, йомшак кына итеп, пиджакның иңсәләрен сыйпады, бармак очы белән генә якасыннан бер мамык кисәге чеметеп алды. Гәрчә улының әйберләрен эче пошкан саен карый торган булса да, боларда ул белмәгән берни дә юклыгын белеп торса да, ниндидер бер өмит белән, сагаеп кына, бер генә бармагын тыгып, кесәләрен капшап карады. Карчыкның соргылт күзләре сагыш белән томаланды, моңсу уйлары рәхәт истәлекләр дөньясына алып киттеләр.

Әйе, бу костюмны Газиз киңәшмәдән киеп кайткан иде. Һай, күңелле дә чак иде, инде дә рәхәт заманалар иде!»

Мин бер нәрсәгә игътибар иттем: әлеге өзектә язучы башта Хәдичә карчыкның хәрәкәтләрен тасвирлый, аннары шул хәрәкәтләр аша карчыкның күңел кичерешләренә китереп туктата безне. «Пиджакның иңсәләрен сыйпау», «бармак очы белән генә бер мамык кисәген чеметеп алу» — болар бит безне, укучыларны, сиздермәстән генә моңсу халәткә әзерләү, болар бит Газиз дигән фронтовик егетнең, өстәвенә инде үлем хәбәре дә килгән улының ана күңеленә никадәрле дә якын икәнен, газиз икәнен әйтеп бирә торган детальләр. Тик шуннан соң гына: «Газиз бу костюмны киңәшмәдән киеп кайткан иде. Һай, күңелле дә чак иде, инде дә рәхәт заманалар иде» килә. Тышкы хәрәкәт белән күңел хәрәкәте бу урында табигый рәвештә берләшә һәм, әйтергә

тиешмен, язучы осталыгы үз дигәненә ирешә: безнең күңелләр, авырттырып-ачыттырып, Хәдичә түти күңеле белән кушыла.

Әнә тел дигәнебезнең нинди тылсымлы көче бар икән аның.

Язучының тел культурасы, телгә булган ихтирамы хикәяләү алымында тагын да күбрәк ачыла ала икән. Мин моны «Намус» романының сурәтләү чараларын тикшергәндә, тагын бер мәртәбә күрдем.

«...Яз көне иде, кинәт әллә нәрсә булды — өйдә елаша башладылар, ыгы-зыгы купты. Анасы, Нәфисәне җитәкләп, колхоз идарәсенә йөгерде».

Вакыйгага зур тизлек белән бара. Динамикалылык көчле, шуңа күрә автор җәенке метафоралар да, чагыштырулар да кулланмый, вакыйганың тизлегенә, сөйләгән хәлнең шомлылыгына фигыльләрне күп бирү, кыска җөмләләр куллану белән ирешә.

Романның гомуми агышы, әсәрнең архитектоникасына, вакыйгаларына карап, үзгәреп тора. Хәйдәрнең бала чагын тасвирлаган әкият алымы бик кызыклы. Дөньяны таң калдырып, җир җимертеп, беренче тракторлар кузгалган заман. Мөгезбай булып Мөгезбайның коты оча, этләр койрыкларын бот араларына кыстырып, кайсы кая күздән югалалар. Язучы күмәк хуҗалык төзелү елларының героикасын бирү өчен әнә шундый ышандыргыч матур алым тапкан.

Әйе, Гомәр Бәширов романның буеннан-буена бер алым белән генә сөйләп бармый. Тантаналы вакыйганы, геройларның шатлыклы минутларын сурәтләгәндә, җөмләләрдә дә тантаналылык сизелеп тора, метафоралар катлы-катлы, абстракт төшенчәләр күп, бар нәрсә җилкенеп, ярсып, тетрәп тора, сүзләр үзләре үк җырлап торалар.

«Кояш күтәрелә төште. Ялыктыргыч озын кышны уздырганнан соң, җир үзенең яшьлек бәйрәмен итәргә җыена, сагынып көткән җылы, иркәләүчән ягымлы кояш нурлары астында ул күзгә күренеп күперенгән кебек, аның иркенләп тын алуына хәтле ишетелгән кебек иде...

Атлар, туктап торган арада, борыннарын җиргә төртәләр, танауларын киереп туфракны исниләр дә, нидер хәтерләренә төшкәндәй, башларын күтәреп, әсәрләнә башлыйлар, күзләрен уйнатып, нәрсәнедер эзләгән сыман, зур тынгысызлык белән еракларга төбәләләр. Дәртләнеп һәм ашкынып, бөтен сыннарын тетрәтеп кешнәп җибәрәләр».

Биредә, бәлки, метафоралар бераз артып та киткәндер, әмма тантаналы халәтне, язгы тойгыларны бирү ягыннан бу сурәт мине бик тә дулкынландыра һәм алга таба иҗат иткән чагында минем үземә дә шундый алымнарны, шундый детальләрне эзләргә кирәк булыр дип уйлый башладым.

Романның үз эчендәге хәлләргә карап стильләштерә белүенә язучының тел өлкәсендәге җитезлеге, осталыгы, судагы балык кебек йөзүе дип карарга кирәктер.

Диплом эше мине күп нәрсәгә өйрәтте. Мин Гомәр Бәшировның әдәби әсәр теленә карата үз принциплары барлыгын күрдем. Ул халык иҗатындагы образларны, сурәтләү чараларын — көчле оптимистик рухны, яктыга, матурлыкка омтылуны, фәлсәфи тирәнлекне, шуларны чагылдырырга сәләтле тел чараларын үз эстетик максатына файдалана, әсәр теленә органик урнашкан идиоматик һәм фразеологик әйләнмәләр (кояш күзенә бодай тарату, җан көеге булу, аваз салу, хәерле белән, юл аягына, сүз озайту, керфекне какмау); тиешле урында гына, саклык белән генә, булган төсмерен тулысынча саклап файдаланган инверсияләр («җитте шундый вакыт, Нәфисәне Байтирәк егетләре берсеннән-берсе көнләшеп сөя башладылар», «җыелды зур

җыелышлар, китте колхоз саен зур киңәш»); халык иҗатындагы тулган ай, салават күпере, таң әтәчләре кебек традицион образларны файдалана, җырлар кертеп, әсәрнең аһәңлелеген, музыкальлеген көчәйтә, халык иҗатындагы сурәтләү чараларын максатына ярашлы булганда турыдан-туры ала, ярашлы булмаса, төзәтеп, үзгәртеп ала, тагын да үстерә, камилләштерә, халыкның тел иҗаты процессында потенциаль рәвештә сакланган хәзинәләрне ачып, халыкның үзенә кайтарып бирә. Кыскасы, Гомәр Бәширов үзенең «Намус» романында телнең халыкчан, йөгерек, үткен, кайвакыт салмак һәм тантаналы ага торган, образлы, сәнгатьчә бизәкле, тирән мәгънәле асыл бер тукымасын барлыкка китерә.

Диплом эше язган чагында, мин әнә шундый фикергә килдем. Редакциягә кергән әсәрләрнең телен шул югары таләпләрдән чыгып редакцияли, төзәтә башладым.

## Тәҗрибә

Язылып беткән диплом эшен Латыйф ага Җәләйгә илтеп күрсәттем. Ул аны үзлегеннән укырга риза булмады, минем кычкырып укуымны таләп итте.

Алтмыш битлек кулъязманы ике сәгать буе укыдым.

Җәләй ага, һичбер иренмичә, кайчагында сирәк тешләрен күрсәтеп көлә-көлә, кайчагында мактый-мактый тыңлады. Мин туктап торсам, «алга барабыз, брат Әүхәди!» — дип куя иде.

Мин профессорның гадилегеннән, мине чәй белән сыйлавыннан, тормыш турында ифрат та гади һәм кискен фикер йөртүеннән мөкиббән китеп, бу гади һәм ягымлы йортта рәхәт минутлар кичердем.

Карт минем диплом эшемнән канәгать булып калды. Тик әле моны якларга куйганга тикле авторның үзенә күрсәтеп, аның ризалыгын алырга кушты. Минем бар курыкканым олы кешеләр белән сөйләшү, аларга йомыш белән бару. Бер-ике көнне һаман сузып, һаман икеләнеп үткәрдем. Әмма бер атнадан диплом эшен якларга куярга кирәклеге әйтелгәч, Гомәр абыйга мөрәҗәгать итми булдыра алмадым.

Без редакциядә очраштык. Гомәр абый ифрат төз гәүдәле, басынкы-сабыр холыклы. Битенә матур гына булып вак шадра сибелгән. Дәү такыр башын кулы белән сыпыра-сыпыра, минем каршыда утыра. Илле яшьләрендәге бу агайның минем белән бик җайлап, ипле иттереп сөйләшүенә, хәлләремне сорашуына хәйран калып, дөньямны онытып утырам. Ул минем уңайсызлануымны аңлап, диплом эшен сорап ала, аны берничә мәртәбә кулында әйләндергәч, бик матур сары күн папкага салып, өенә алып кайтып китә. Мин аны, беренче хикәямне хөкем иткәндәге шикелле, сабырсызланып көтә башлыйм.

Гомәр абый вәгъдәле кеше булып чыкты: ике көннән китерермен дигән иде, китерде.

— Менә болай, энем Гарифҗан,— диде минем каршыма утырып,— якташ та бит әле син миңа, әйеме? Бу эш миндә әйбәт тәэсир калдырды бит. Куанып укыдым, кырыйларына тамгалар да сала бардым. Телгә карата талымлы кешеләр мине һәрвакыт шатландыра. Кем белә, бәлки, журналда чарлана торгач, синнән әйбәт кенә тәнкыйтьче дә чыгып куюы ихтимал бит әле, әйеме? Чыксыные, бирсен ие ходай. Әдәби әсәрнең тукымасын белеп, сизеп тикшерүчеләр бездә юк дәрәҗәсендә дип әйтерлек. Ийе, чынын әйтәм мин сиңа, ихлас күңелдән, син эшләгән эш матур тойгы калдырды. Кһм. Ийе, әйтик, беренче эшләгән эштәге кебек, синең хезмәтеңдә дә кайбер төгәлсезлекләр,

ышандырып ук житкермәгән урыннар бар. Хикмәт анда түгел, алары аның тәҗрибә белән килә торган нәрсәләр. Мин аларны карандаш очы белән генә төрткәләп куйдым. Хәзер үк төзәт дип әйтмим, минем дә ялгышуым мөмкин. Әдәбиятта категоричный булудан да куркынычрак бер нәрсә дә юк. Категоричный дигәннән, кем, Гарифҗан, кайбер төшләрдә син бик кистереп: «язучы ирешкән», «язучы камил тел тудырган» дигән кебегрәк билгеләмәләр җибәрәсең. Алай ук кирәкмәстер. Тел ул, Фатих Хөсни әйтмешли, бер дә төзәтүдән туймый. Андый чакта син, «минемчә», «минем аңлавымча» дигән сүзләрне дә куллан. Ул чагында ул, беләсеңме, тешкә йомшаграк, күңелгә ятышлырак була...

Гомәр абый минем күзләремә тутырып карады да уңайсызланып кына җемиеп куйды: акыл өйрәтүем күбрәккә китмәдеме, янәсе.

Ә мин аны тынларга әзер идем әле, минем аны бик тә тыңлыйсым килә иде. Ләкин безнең яшь аермабыз зур иде шул. ул миннән егерме биш яшькә олырак иде. Аңа инде илле ике яшь, миңа нибары егерме җиде генә, хәтта мин Тукай яшендә булсам да, үзебезнең кечкенә Өчиле белән Казаннан ары бүтән бер генә җирне дә күрмәгән булгангамы, үземне бик тә бала, бик тә тәҗрибәсез хис итә идем.

Шулай да мин Гомәр абыйга бер сорау бирерлек көч таптым үземдә.

— Сезгә «Намус» романын язарга берәр вакыйга этәргеч булдымы, әллә барысы да уйлап чыгарган дөньямы болар? — дидем.

Бу сорау миңа диплом эше өчен кирәк түгел, үземнең алдагы язу эшем өчен кирәк иде.

— Мин үзем уйлап чыгару ягында түгел. «Намус»ны язарга миңа Идел буендагы бер авылда күргән вакыйга этәргеч булды. Фронтта ирен югалткан хатынның елавы. Башта мин аңардан хикәя язмакчы идем, үсә-зурая торгач, ул әнә роман ук булып китте,— диде Гомәр абый. — Үзем яшәгән мөхит, күргән-белгән танышларым күз алдыма килде, яшьлегем, авыл буйлары күңелдә яңарды.

Әнә шул минуттан башлап без икебез дә яшь аермаларыбызны оныттык. Гомәр абыйның да кемгә булса да ышанычлы берәүгә романын ничек язганын, язган чакта нинди газаплар, кыенлыклар кичергәнен сөйлисе килә иде булса кирәк, ул миңа күңелендә йөрткән изге тойгыларын, уй-фикерләрен әйтеп бирде.

Романны ул бик озак язган икән. Ачлы-туклы торып диярлек язган. Кәримәттәй, Гомәр абыйның хатыны, аның шул чордагы күлмәк-ыштанын юып, үтүкләп, сандыкка салып куйган. Истәлеккә. Авыр чакларын онытмаска.

«Менә бит кешенең бәхете баскан, романы ил күләмендәге бүләккә лаек булган»,— дип уйлыйсың, бүләк алуы аның күп еллык хезмәтенең, мең газаплы авыр хезмәтенең җимешедер дип башыңа да китермисең, әгәр син язсаң, сиңа да бәхет кошы килеп кунса, син дә алырсың кебек. Бакчы, алай ансат кына килми икән бәхет дигәннәре!

Гомәр абый, ул көнне миңа ышанып, язу эшенә тотынган кешенең ниндидер даннар, мактаулар, күктән килеп төшкән бәхетләргә исәп тотмаска тиешлеген, йөрәгенә таянып эшләргә, еллар буе тир түгәргә кирәклеген аңлатып бирде. Вәгазь сөйләп түгел, үз тәҗрибәсен, «Намус»ны язу тәҗрибәсен сөйләп.

Ул миңа диплом эшемне хәзер үк якларга куярга ризалык бирсә дә, ашыкмадым, яклау көнен тагын бер айга кичектереп, язганнарымны өр-яңадан күчереп чыктым.

Кара тир түгү төшенчәсе минем күңелгә нык кереп утырган иде.

# ЯЗУЧЫЛАР АРАСЫНДА

## Гомер буе үзе булып калган кеше

Залда яп-якты утлар яна. Стенадан Тукай, Такташ, Шәриф Камал портретлары карап тора. Клубта алма төшәрлек тә урын калмаган. Эссе. Бөркү. Иөрү юллары студентлар, журналистлар, нәшрият хезмәткәрләре белән тулы. Кемдер тыгыз рәтләр арасыннан бердәнбер буш урынга керергә омтыла, аңа пышылдыйлар:

— Әй, эшем иясе, кая барасың, күрмисеңмени, сәхнәне каплыйсың?

Клуб — Матбугат йортының югары катында. Клуб — Габдулла Тукай исемендә. Болар барысы искиткеч, дулкынландыргыч. Клубта атна саен әдәби җомга оештырыла, клубка атна саен төркеме-төркеме белән язучылар килә. Тере язучылар, син инде аларны күрергә Казанбаш мәктәбеннән, Арча педучилищесыннан ук ашкынып яшәдең. Арча педучилищесына көнҗәлә чәчле Нәби Дәүли килгәч һәм аның тәнкыйтьче Гали Халит белән Арча урамнарын бер итеп сөйләшеп-бәхәсләшеп йөргәнен күргәч, төне буе йоклый алмый яткан идең.

Бүген язучылар синең алдыңнан төркемнәре белән узалар, трибунага чыгып, эссе һәм бөркү клубка кайнар сүзләрен сибәләр.

Менә бу Гали Халит, сине педучилищеда русча укыткан, синең беренче өйрәнчек хикәяңне тикшереп, киңәшләрен биргән Гали Халит әнә нинди зур романнарга теше үтәрлек кеше икән. «Онытылмас еллар» романының яхшысын яхшыга, яманын яманга аерды да куйды. Дөрес, син инде Казанбаш мәктәбендә яки Арча педагогия училищесында авызың белән кош тотып йөргән малай түгел, син үзең дә хәзер һәрбер әйткән сүз белән килешеп кенә тормыйсың, үзең укыган әсәрләр хакында синең үз фикерең бар, син аларны үз бизмәнеңә салып үлчи аласың, чөнки син Хәзинәләр утравында — университетта ил һәм дөнья җәүһәрләре белән таныштың, сине акыллы галимнәр нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен аңларга көне-төне өйрәттеләр.

Шулай да дөньяда сине шаккаттыра торган, сине сискәнеп китәргә мәҗбүр иткән нәрсәләр һаман да бар икән әле.

«Онытылмас еллар» хакында доклад сөйләнеп беткәч, син фикер әйтүчеләрне көтә башладың. Үзең малай килеш диярлек өзелеп яраткан Хәлимнең гел яхшы якларын гына күрүләрен теләдең. Бу ни хикмәт? Хәлимгә дә, «Онытылмас еллар» романына да тел тидерә алучылар бар икән бит. Яшькелт төстәге ярым хәрби кительле, йөз ел буена мичкәгә атланып йөргән төсле кәкре аяклы, өстәвенә шадрарак та битле бер абзый (бәрәкалла, Кави Нәҗми агай шушы икән!) трибуна янына чыгып, ярсынып-ярсынып сөйли башлады. Сүзләре аның түгәрәкләнеп ачылган авызыннан берәм-берәм түгел, ялкын тасмасыдай, тоташы белән чыгып торалар. Хәер, бу «ялкын тасмасын» син хәзер генә, язучылык тәҗрибәң ирешкән фантазия белән генә уйлап чыгардың бугай, ул чагында син, авыл малайлары кебек, гади генә итеп: «Самавар кебек кайнап сөйли бу», — дип уйлаган идең. Чыннан да, Кави агай кайнап, күбекләнеп сөйли, «Онытылмас еллар» романының авторын әллә ниткән гөнаһларда гаепли иде. Тыңлый торгач, аның нәрсә әйтергә теләве дә аңлашылган төсле булды. Бактың исә, романның авторы үзенең китабында, роман хәтле романда, татар милләтчеләрен фаш итмәгән. Хәлбуки, татар милләтчеләренең җирән-

геч образын халыкка күрсәтеп бирер өчен авторның көче дә, сәләте дә, мөмкинлеге дә, утлар чәчеп тора торган сатирик куәте дә бар икән. Ул аны эшләмәгән, ул сыйнфый сизгерлеген югалткан.

— Менә сиңа мә!— дип аһ иттек без.— Бетерделәр бит безнең «Онытылмас еллар»ны! Автор нәрсә дип әйтә инде монa каршы.

Төннәр йокламый әдәби геройлар белән хыялланып йөргән кешегә, без фәкыйрегезгә, бу ничек тәэсир иткәндер дип уйлыйсыз? Тәэсир бер генә: арттан килеп, миңгерәүләтерлек итеп, күсәк белән ордылар. Шулкадәр әйбәт китап та ярамагач, тагын нинди китап ярар соң?! Ай-һай-һай! Болай булгач, язучы булам дип ярсынып, әллә ниткән яшерен хыяллар белән йөрү кирәк микән соң?

Тагын кемнәрдер чыгып сөйләде, кемнәрдер бәхәсләште, кемнәрдер мактаган булды, аларның берсенә бер исебез китмәде. «Авторы ни әйтер икән?», «Аңа сүз бирерләрме икән?» дигән сораулар күңелне кымырҗытып, гел башта әйләнә башлады.

Кави Нәҗми агай белән күңелдән килешмәсәк тә, аның сүзләренә сабыйларча рәнҗесәк тә, ул да хаклы түгел микән, дигән уй да күңелдә, көйгән икмәк төсле, утырып тора иде әле. Аның «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» хикәясе «Бурап-бурап кар яуган кышкы төндә ул кайтты» дигән искиткеч моңлы, тирән мәгънәле беренче җөмләсе белән үк безнең хәтергә сеңеп калган иде. Аның «Яр буендагы учаклары», «Якты сукмагы», тагын башка байтак хикәя-повестьлары, бигрәк тә «Язгы җилләр» романы күңелдә иде. Ә менә бүген, әллә ниткән ятышсыз сүз әйтүе белән, Ибраһим Газига үтергеч гаеп ташлавы белән ул безне рәнҗетте.

Ни булыр дип көтә башладык. Ниһаять, без көткән минут җитте. Сөйлиселәр сөйләп, ярсынасылар ярсынып беткәч, «Онытылмас еллар»ның авторы Ибраһим Газига да сүз бирделәр.

Каяндыр, залның урта бер җиреннән күзлекле, озын буйлы бер кеше калыкты. Өйләренә кульъязма илтергә баргач, мин күргән юаш кешегә бер дә охшамаган иде ул. Халыкны аралап алга узды. Сәхнәгә ул басмачадан түгел, иданнән генә сикереп менде. Трибунага ике куллап чытырдатып ябышты, алга сөрлегә төште: күзлек пыялалары астыннан залга үткен күзләре төбәлде. Юка иреннәрен беркавым кысып, бер генә сүз дә дәшми торгач, безнең, башлап язучыларның, күңелләрен канат кактырырдай, кыска һәм усал берничә сүзен залга ташлады:

— Куркытма син мине, Кави! Татар милләтчеләрен фаш итү — синең эш. Татар крестьяннарының революциягә килүен язу — минем эш!

Башка бер генә сүз дә әйтмәде, ничек җилләнеп менгән булса, шулай җилләнеп төшеп тә китте.

Беренче тәэсир чын була, диләр. Ихтимал, бу дөрестер. Ибраһим Газиның холкындагы төп сыйфат — куркусыз принципиальлеге, әнә шул принципиаль фикерен өздереп, ярып кына әйтә белүе гомер буе сакланды. Мин аны егерме ел буена беләм. Егерме ел буена аның белән бергә эшләү дәверендә аның игелекле ярдәмен күрергә дә, минем иҗатым турындагы аяусыз усал сүзләрен ишетергә дә туры килде. Ул минем беренче китабымны чыгарттырмады. Юк, мин моңа рәнҗемим, киресенчә, шатланам, ул җыентыкка тупланган беренче хикәяләр бик зәгыйфь булганнар икән, мин аларны хәзерге җыентыкларыма керткәнем юк. Тагын шунысын да әйтим, ул мине беренче мәкаләмнән үк тәнкыйтьче дип таныды, хикәяче-прозаик итеп танымады. Бу аның шулай ук әдәбиятка булган зур таләбеннән, принципиальлегеннән килә торгандыр.

Шул принципиаль җирлектә ул әдәби әсәрләрне әнә күзеннән үткәреп барды. Татарстан китап нәшриятында Ибраһим Гази кулы

белән язылган берничә йөз эчке рецензия булырга тиеш, заманында, кулъязмалар актарганда, мин аларның берничәсен әдәби архивка да тапшырган идем, аларны, исән булган сурәттә, халыкка җиткерү әдәбият фәненә яңа бер өлеш булыр иде.

Принципиаль туры сүзен, мактавын яки кире кагуын, ул телдән әйтергә дә иренми иде.

Бервакыт, Октябрь бәйрәме алдыннан, без, Әнвәр Давыдов белән икебез, янәшә бүлмәләрдә эшләп утыра идек. Ял көне бу, өйдә язу шартлары юк. Давыдов Язучылар союзы бүлмәсендә, мин «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә язу язабыз. Шушы хәлне белеп торган Ибраһим абый, Язучылар союзына шалтыратып, Әнвәр Давыдовка аның Октябрьга багышлап шул көнне чыккан шигырен мактады. Давыдов миңа шуны ифрат та сөенеп кереп әйтте.

— Ә бит чын шигырьне шалтыравык шигырьдән аера белүчеләр бар, иптәшкәем. Прозаик әйтте, шагыйрь түгел, нәкъ менә — прозаик. Ничекләр итеп әйтте але... Мин сине, диде, чын шигырь язганың өчен мактыйм. Газетада басылган шигырьләр, бигрәк тә бәйрәмнәргә багышланган шигырьләр гадәттә дежурный-кәҗүнни булалар, диде. Синең бәйрәмгә багышланган шигырең сәнгатьнең барлык таләпләренә җавап бирә, диде. Бар әле, иптәшкәем, бетмәгән әле поэзияне аңлаучылар!

Әнә шулай сөендерә белә иде Ибраһим абый яшьләрне.

Яшь прозаиклардан ул Шамил Бикчурин белән бик кызысынды. Шамилдә аның ким дигәндә утыз хаты бар. Алар әдәбият мәсьәләләренә дә, әхлак мәсьәләләренә дә кагылалар. Аларны Шамил Казанга килгән саен горурланып сөйли, әмма ул аларны әле бастырып чыгармады диярлек. Бастырырга кирәк аларны. Ибраһим Газиның мирасын бүгеннән туплый башламасак, азактан соң булуы мөмкин.

Ибраһим абыйның икенче төп сыйфаты аның нечкә күңеллеге иде. Мин «Совет әдәбияты»на эшкә кергәннән һәм аңа, редколлегия члены на беренче кулъязманы илтеп биргәннән башлап ул мине ничектер үз итте. «Җен килеште» безнең.

Көне буе эшләп утырганнан соң Ибраһим абый кичкә таба бер җилләнеп керергә чыга. Аның җилләнеп керергә чыккан чагы кичке бишме-алтылармы тирәсендә була.

— Әйдә, тәмәке төтененнән туйгансыңдыр, һава суларга чыгыйк!— ди ул миңа. Чыгасыңмы, чыкмыйсыңмы, дип тормый, әнә шулай «категоричный» итеп әйтә. Мин аның энекәше, аңардан егерме яшьләргә яшьрәк кеше, өлкән язучының сүзен сөенеп кабул итәм.

Без «һава суларга» чыгабыз. Ул шуннан гыйбарәт: Ибраһим абый мине үргә, Чернышевский урамына алып менеп китә, Черек күл аркылы алып чыгып, Казанка елгасы буендагы тау башына китереп туктата. Шунда без утырышабыз. Ул кесәсеннән ак кәгазьгә төргән ике телем кара ипи чыгара, берсен миңа бирә, икенчесен үзе ашый башлый. Шулхәтле дә тәмле итеп, бер генә валчыгын да коймый ашый ул аны. Мин кара ипине андый ләззәт белән авыл кешеләре ашаганны гына күргәнем бар. Без, ипи ашый-ашый, елга өстенә, еректагы офык читенә карап, тау буенда озак кына утырабыз. Сөйләшмибез. Бу вакытта һәркем үз уен уйлый. Мин аңардан, кешеләрне елатырдай, сөенеп сикерергә яки моңсуланып күз яше түгәргә мәҗбүр итәрдәй әсәрне ничек язарга соң?! — дип сорарга ниятлим. Ләкин уңайсызланам. Сорамый калам. Ибраһим абыйның сүзне үзе башлап алып киткәнен көтәм.

Ул Бөек Ватан сугышы елларында фронт газетасында эшләгән чакларын, газетадагы каләмдәшләрен искә төшерә.

— Дөнья хикмәтле нәрсә икән ул, Гариф энекәш. Менә без Гадел Кутуй белән бергә фронтта йөрдек, газета чыгардык, беребезгә дә

пуля тимәде, беребезне дә мина ярчыгы яраламады, әмма язмышлар икебезнеке ике төрле булып чыкты. Кутуй, кайтырга санаулы айлар гына калгач, үпкәсенә салкын тидереп, фронт госпиталенә әләкте, шунда вафат булып калды, ә мин менә, синең белән ипи ашап, дөнья турында сөйләшеп, тау башында утырам. Әнә теге елга аръягындагы әрәмәләрне күзәтәм. Бу тау өстендә без Афзал Шамов белән дә утырырга яратабыз. Мин аңар әйтәм, син, Афзалетдин, мине татар зиратына күммәссең, анда юеш, минем аякта ревматизм, дим. Ул әйтә, юкны сөйләмә әле, Ибраһим, син миннән күп өлеш яшьрәк бит, ди. Юк, сөйлим дим мин аңа, син мине менә шушы тау башына күмдерерсең, мин шушыннан дөньяны карап ятырмын, дим...

Ибраһим абый бик оста сөйли, сузмыйча, азапламыйча сөйли, гомерендә дә телгә килмәслек мәзәк сүзләр китереп кыстыра. Сөйләшә торгач, ничектер үзеннән-үзе без әдәби мәсьәләләргә кереп китәбез. Ул миңа әйтә: син менә, яшь һәм башлап язучы, өметле каләм, ди, хәзер бит гәҗитләргә шулай язалар, ди, әйтик, халыкның урам тулып килгәнен син нинди алым белән сурәтләр идең? ди. Мин аптырабрак калам, мондый сорауның минем башыма килгәне юк. Мине әлегә газаплаган әйбер егетнең кайгыдан яки мәхәббәт хисләреннән башын югалтып йөрүен нинди чаралар белән бирү. Мин аның соравына җавап бирә алмыйм. Шуннан ул әйтә: «Горький бабаң әнә халыкның урамны тутырып килүен, аның **коймаларга бәрелә-бәрелә килүе** белән биргән»,— ди. Карале, дип таң калам мин, баксаң-күрсәң, нинди ансат, нинди гади икән. Әмма ул бөек гадилеккә ирешү өчен Максим Горький булырга кирәк шул. Әлеге сөйләшүдән мин әдәби әсәрнең бик төгәл детальләрдән торуын аңлыйм.

Ибраһим абый минем байтак әсәрләремне укыды, тик бер генә мәртәбә кулына каләм алып, бер җөмләне төзәтте. Минем бер хикәямдә: «Без барлы-юклы әйберләребезне машинага төяп китеп бардык»—, дигән җөмлә бар иде. «Төяү сүзе машинаның тулы булуын аңлата, — диде ул миңа, — ә барлы-юклы әйберне төяп булмый, машина төбенә салып кына була». Әлеге бер, әмма берәгәйле төзәтү минем хәтеремә гомергә сеңеп калды. Хәзер дә мин, кайбер детальләрне язган чакта, туктале, барлы-юклы әйберне машинага төяү килеп чыкмаганмы дип, кат-кат тикшерәм.

Миңа Ибраһим абый белән бергә проза секциясендә дә эшләргә туры килде. Бу — минем бәхетле елларым. Чөнки нәкъ менә шул вакытта 1951—1955 елларны мин проза секциясендә Фатих Хөсни, Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов кебек әдәбиятта үз юлларын, үз сукмакларын салган өлкән әдипләр белән аралашып яшәдем. Аларның повесть һәм романнарны сүтеп ташлаганнарын, образлы тел, ныклы сюжет-композиция таләп иткәннәрен күрдем. Ул чагында проза секциясенә Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри, Хатип Госман, Мөхәммәт Гайнуллин, Латыйф Җәләй кебек күренекле тәнкыйтьчеләр дә бик теләп йөри һәм бик теләп фикерләрен әйтәләр иде.

Тагын да әһәмиятлерәге, алар безгә, яшь һәм башлап язучыларга да, үз фикеребезне әйтергә кушалар, безнең фикерне бүлдерми тыңлыйлар һәм безнең белән тиң итеп бәхәсләшәләр, кайчагында хәтта «уртәшәләр дә» иде.

Рафаил Төхфәтуллин авыл тормышыннан повесть язып китерде. Аны бик теләп укыдык. Җыелдык фикер әйтергә. Ибраһим абый проза секциясенең җитәкчесе, мин — секретарь.

Башта, сабан туендагы кебек, безне — малайларны, — көрәштерәләр. Мин Рафаил язганнарны тоташы белән укып бара идем, аның әсәрләрендәге лирик җылылык, авылны яхшы белү миңа бик ошый иде.

— Төхфәтуллин шундый үтемле итеп яза, аның повестен укыган чагында аркалар чымырдап китә, — дип әйтеп ташладым мин утырышта.

Өстәл башында юка иреннәрен кысып, күзлеген ялтыратып утырган Ибраһим абый, халык сөйләп бетергәч, йомгак ясады һәм шул чагында бүтән беркем белән дә түгел, нәкъ менә минем белән үртәшергә исәпләде.

— Гариф энекәш әйтте, аркам чымырдап китә, диде, нишләп соң минем аркам бер дә чымырдамый?— Шуны әйткәч, ирен чите белән генә мыскыллы елмаеп, миңа карап алды. Пауза булып торган арада мин гомер буена килгән оялу-уңайсызлануымны җиңдем дә, мине үтергеч рәвештә мыскыллаган, мине әдәби әсәрне аңламый дип әйтергә теләгән аппонентыма әйтеп салдым:

— Сезнең арканы чымырдатыр өчен, беләсезме, Ибраһим абый, нишләргә кирәк?

— Нишләргә?— диде Ибраһим абый, елмаюын дәвам иттереп.

— Имән күсәк белән китереп сугарга кирәк.

Бүлмә тын калды. Кемдер «һи!» дип көлгән сыман өзек тавыш чыгарып куйды. Ибраһим абый дәшмәде, шуннан соң ул миңа тагын әле ай буе дәшмәде.

Ләкин ул моны педагогик чара итеп кенә эшләгән булса кирәк. Шуннан соң да әле ул минем күп кенә кулъязмаларымны укыды, китапларыма бәя бирде, Язучылар союзына үзе белән бергә эшләргә чакырып алды.

Әйе, ул ачу саклый торган үчлекле кеше түгел иде.

## Остазымның кайбер гадәтләре

Миңа Гази ага Кашшаф кул астында биш ел буе «Совет әдәбияты» журналында эшләргә туры килде.

Ул беркайчан да кул астындагыларга тавышын күтәрми, беркайчан да ачулана белми, аның, әйтик, сиңа хәтере калганын артык басынкыланып киткән булуыннан гына белергә була иде.

— Гази абый, нишлибез, журналда очерк юк бит? — дим мин.

— Юк икән, үзең яз,— ди ул миңа. Шаяртып түгел, чынлап әйтә.

Мин Арча районының Казаклар авылында балык күле бар икәнен ишетеп белә идем, шунда чыгып китәм, балык үрчегән күлләрне атна буе карап йөрим, балык үрчетүче галим-профессор Александр Владимирович Лукинны, балык күлләренең башлыгы Нигъмәтне эзләп табам, утыз битле очерк язып кайтам. Гази абый аны озаклап укый, аннары мине чакырып ала:

— Молодец, Гарифҗан, молодец, балам, әйбәт очерк язгансың. Мин әйтәм моны, балык тотуның тәмен белүче гомерлек һәвәскәр әйтә. Туктале, бер атна эчендә ничек итеп син, понимаешь, балыкларның исемнәрен, холыкларын, яшәү һәм үрчү рәвешләрен белеп бетерә алдың? Моны бит кимендә бер ел өйрәнергә кирәк.

— Ә мин нәкъ бер ел өйрәндем инде.

— Син аны ничек итеп бер ел өйрәндең соң, понимаешь, хәтерем ялгышмаса, чыгып киткәнеңә бер генә атна бит әле?

— Әйе, Гази абый. Бик дөрес: бер атна... Ләкин мин бит аңа тикле Виталий Закруткинның «Иөзмә станица» романын тәрҗемә иттем, тәрҗемә белән нәкъ бер ел азапландым, балыкчылардан Иделдәге барлык балыкның исемен берәмтекләп сорап чыктым.

— Алай булгач, син икеләтә молодец! Журналга тагын нәрсә җитми?

— Хикәя җитми, повесть җитми, роман җитми.

— Әйе, сугыштан соң каләм мастерлары роман-повестьларны бик күп итеп яздылар да, понимаешь, без менә икәү журналда эшли башлагач, коргаксыган мичкә кебек, язудан туктадылар.

— Нишлибез соң?

— Хикәя яз.

— Анысы булмас, Гази абый.

— Алайса, башкалардан яздыр. Хикәясез бит журнал чыга алмый, аңлыйсыңмы, чыга алмый. Табарга кирәк, понимаешь, хикәя.

— Ә тапмасак?

— Тапмасак, хикәя буласы урынны ак кәгазь итеп калдыр. Егерменче елларда андый гадәт бар иде. Берәрсе вәгъдә итеп тә вәгъдәсен үтәмәсә, газета уч төбе хәтле урынны буш калдыра һәм вәгъдәсез авторны укучыга фаш итә иде.

— Чынмы?

— Менә инде... Олы башым белән алдашып утырыйммыни, понимаешь...

— Әкәмәт, — дим мин, — шулай да хикәя каян табабыз, Гази абый?

Гази абый шаяртудан туктый, уйга калып утыра. Аннары өстәл яныннан кузгалып, протез аягын яннан селтәп ала-ала, бүлмәне бер урап килә.

— Ярый, журналны типографиягә тапшыр, хикәягә урын калдырып тор, журнал набордан килгәнче берәрсеннән хикәя килми калмас, гранка белән бергә төшерербез типографиягә,— ди тыныч кына.

Хикәя дигәнне без, әлбәттә, таптык. Унбиш көннән соң Кенәр авылында яшәгән Рафаил Төхфәтуллин бүгенге авыл тормышыннан «Таныш гөрелде» исемле 30 битле хикәя җибәрде. Әйбәт, чын хикәя иде, сәнгатьчә югарылыкта, җылы итеп язылган иде. Гази абый аны бастырып чыгарырга дип шундук кул куйды, ә Рафаилгә, иҗат уңышы белән котлап, телеграмма сукты.

Әйе, ул изге күңелле һәм ифрат дәрәҗәдә тыныч табигатьле иде. Аның шул тынычлыгы мине каударланудан, юкка-барга көенүдән коткарып калды. Тик мин аның бер генә нәрсәгә көенгәнен, вакыт-вакыт кына түгел, берничә ел рәттән көенгәнен беләм. Ул да булса — Муса Җәлил язмышы. Мин аның янында гел дә менә малае кебек кенә идем әле, шулай да ул мине үз күреп, Җәлил язмышы өчен борчылганын әйтә, журналга җыелган материалларны аның бүлмәсенә редакцияләп бетереп алып кергәч, бер читкә иләп кенә алып куя да:

— Ярар, мин аны дачага алып кайтып укып килермен,— дип әйтеп куя,— монда аны укырга барыбер ирек бирмәсләр.

Мин аның дымланып киткән күзләген салып, аның пыялаларын озаклап сөрткәнен карап утырам. Ул хәзер күптәнге дусты, бала чактан ук белгән ахирәте Муса турында сүз башлаячак.

Минем көткәнем аклана.

— Мусаның язмышы хәл ителми бит әле, Гарифҗан, — ди ул һәм авыр гына көрсенеп куя.

Шулай бервакыт икәүдән икәү генә утырып, мин редакцияләгәннәрне көне буе карап чыккач, ул миңа:

— Тагын бер өч елдан соңнан, балам, менә дигән редактор чыгачак, инде сине, ихтимал, проза бүлегенә дә әзерли башларга кирәк булыр, — диде.

— Ә нигә, проза бүлеге дигән бүлек бармыни безнең журналда?— дидем мин сәерсенебрәк.

— Булачак. Яңа елдан безнең проза, поэзия һәм тәнкыйть бүлегебез булачак. Үзебезнең машинисткабыз, корректорыбыз булачак.

— Каян килеп?

— Мин Үзәк Комитетта булдым. Ниһаять, безнең хатны караганнар, мине секретариатка чакырдылар.

Бу хәл мине кызыксындырды.

— Нәрсә диделәр соң? Гази абый? Редакциядә өч кенә кеше эшләүне нормаль хәл дип карамаганнардыр бит?

— Юк, нормаль хәл димәделәр. Сез просто герой, диделәр. Инде менә безгә иҗат эшенә генә дә җиде кешелек штат бирделәр. Без-без идек, без уникe кыз идек, үлә-үлә икәү калдык дип җырлыйлармы әле? Без өч бөртек кеше идек, инде менә тырыша торгач, җидәү булдык. Бу — зур җиңү, балакаем, әйдәле, буфетка керик әле, мин сине шуның өчен бер сыйлыйм әле...

Ул мине, ай-ваема карамый, буфетка алып керде. Өстәл янына утыртты. Шуннан соң портфеленнән ямь-яшел ике кыяр һәм бер шешә сөт чыгарды. Кыярларның берсен миңа сузды:

— Менә бу минем Идел буе бакчасыннан. Мирсәй Әмирнең дә, Әхмәт Исхакның да кыярлары үсмәгән әле. Беренче кыяр миндә. Шатлыктан сиңа алып килдем. Бәхетле малай икән Гарифҗан, мин әйтәм, беренче кыяр белән сыйлыйм әле үзен, дим. Тот, энекәш! Инде менә стаканнарга акны салыйк,— дип ул ике стакан тутырып сөт салды.— Тот әле, чүкеш әле,— диде,— күңелеңне киң тотсаң, нәкъ менә син уйлаган нәрсә исәбенә китә ул,— дип сабыр гына көлеп куйды.

Без, кара-каршы утырып, тамак ялгадык. Буфеттан чәй алып эчтек. Аның өчен түләргә дип мин никадәр генә тырышсам да, ул миннән акча түләтмәде.

— Син бүген минем кунак, екканчы үзем сыйлыйм мин сине бүген,— диде.

Шуннан соң атна буе редакциягә якты чырай белән, үзенә хас булмаганча, гел елмаеп килә торган булып китте. Миңа аның якты чырайлы булуын, теләбрәк сөйләшүен, хәтта мәзәкләр дә сөйләштергәләвен күрү күңелле иде.

Ул чакта мин аның нигә яктырып йөргәнен белмәдем. Олы кешедән сорарга батырчылыгым җитмәде.

Сигезме-тугызмы айдан соң мин аның холкындагы үзгәрешләргә берьюлы төшендем. Аның ул чакта Муса Җәлил язмышын кайгыртып йөргән көннәре булган икән. Сугыш елларыннан башлап аның дусты булып киткән Александр Фадеев, мәсьәлә озакламый ачыкланып бетә, дип вәгъдә биреп кайтарган булган икән.

Чыннан да, илле өченче ел башларында Муса Җәлил хакында ифрат сөенечле хәбәр алынды. Безнең редакциягә аны Гази абый үзе алып килде. Ул бүген, гадәтенчә, төштән соң, сәгать икедә генә килмәде, иртәнге уннарда ук килеп җитте. Йөрүе үк алмашынган, протезлы аягын ул озаклап яннан китереп салмый, селтәп-селтәп кенә килә, аның йөреш-торышыннан ук, аның көйрәп кабынган коңгырт күзләреннән үк бик тә мөһим бер хәл булганын күрү кыен түгел иде.

— Гарифҗан, балакаем... булды бу! — диде ул һәм аһылдап урындыкка килеп утырды. Өстен салырга да онытты.

— Менә, кара. Кара, балакаем!

Ул биргән «Литературная газета»ны ачып җибәрсәм, «Моабит зинданында язылган шигырьләр» ярылып ята.

— Котлыйм, Гази абый! — дидем.

— Котла, балакаем, котла, татар әдәбияты өстенә ыргытылачак тап алып ташланды, батырның исеме илгә кайтты. И матур көннәр булыр инде. Булыр, балакаем, шөкер, мин ул көннәргә тикле килеп җиттем... — диде һәм аның тавышы киселде, күзләрен яшь пәрдәсе каплады.

Менә шунда мин аның елаганын күрдем.

Озак та тормый ул Муса Җәлилнең көрәштәшләрен эзләргә, аның мирасын халыкка кайтару өчен илне гизәргә чыгып китте.

# Муса Җәлил архивы белән танышканда



Муса Җәлилнең Моабит зинданында язган шигырьләре «Литературная газета» битендә басылып чыкканнан соң, шагыйрьнең хатыны Әминә апа, өч зур чемодан күтәреп, Казанга килде.

Гази Кашшафка фронттан язган васыятендә Җәлил моңарчы иҗат иткән әсәрләренең 30—35 проценты гына басылып чыккан булуын әйтә, әсәрләре илнең төрле тарафларында чәчелеп яталар, ди. Әгәр фронтта үлә-нитә калса, Гази Кашшафтан ул шуларны җыюын, үзе кирәк дип тапканнарын бастырып чыгаруын үтенә.

Әминә апа алып килгән өч чемодан материал әнә шул васыятьтә әйтелгән зур эшнең башы иде.

Кулъязмаларны тәртипкә китерү, әйбәтләп теркәү һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына тапшырырлык итеп әзерләүне Гази абый миңа — үзенең университет шәкертенә йөкләде.

Иң элек, кулъязмаларга тотынганчы Әминә апаның үзен күргәч туган тәэсиремне әйтеп китәсем килә. Ире Мусаны фронтка озаткан чакта аңа күп булса утыз яшь булгандыр. Кызы Чулпан да бәләкәй була бит әле. Инде менә Җәлилдән башка яшәвенә унике ел узып киткән (Әминә апа архивны 1953 елның азакларында китерде).

Әминә апа — кырык яшьләрендәге зифа буйлы, нәфис ак битле, бераз моңсурак коңгырт күзле чибәр ханым — мине һәм минем белән бергә документларны рәтләшергә тотынган редакция егетләрен, бик тә үз итеп, якын күреп сөйләшә башлады. Тавышы аның йомшак, әйткән сүзе җанга ятышлы иде.

Чемоданнар белән без атна буе утырдык. Кул кисәге кадәрле һәрбер язу Әминә апа өчен җаннан да кадерле иде, күрәсең — ул аларны безгә иплəп кенә алып бирә, әз генә бөкләнгән урыны булса, сыйпап тигезли, ә без һәр документны, шагыйрьнең үзе белән күрешкәндәй, каушап һәм дулкынланып ала идек.

Энҗе тезеп барган кебек вак кына язуларда — шигырьләр, мәкаләләр, эш кәгазьләрендә, гомер узу белән инде саргайган документларда без Муса Җәлилнең көрәшче булып житлегү, фашистлар оясында, ерткыч бүреләргә бирешмәс, үлемгә баш имәс баһадир булып житешүен үз күзебез белән күрдек.

Ихлас күңелемнән әйтәм, әнә шул өч чемодан, Әминә апа күз карасы кебек саклаган чемоданнар, минем әдәбияттагы эшләү принцибымны да билгеләде булса кирәк.

...1925 елның 1 январенда Муса Җәлиловка корреспондентлык билеты бирелә. Билетның номеры 162. Ул «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» газеталарының һәм «Октябрь баласы» журналының үз хәбәрчесе. Мусага бу вакытта нибары 19 яшь әле.

Менә саргайган, бөкләнгән урыннары инде ертыла башлаган нке белешмә. Муса — комсомолның Оренбург губкомы инструкторы, губком аны комсомол эше белән районнарга, авылларга җибәрә.

Менә СССР халыклары Үзәк нәшрияты биргән 210 номерлы таныклык. 21 яшьлек Җәлил Мәскәүдә чыга торган «Кечкенә иптәшләр» журналының җаваплы редакторы.

Озак та үтми, ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт секциясе бюросына сайлана. Моны дәлилләүче документ — ВЛКСМ Үзәк Комитетының 8 нче пропускысы.

Безнең кулда 16 нчы мандат. Муса Җәлил 1927 елда ВЛКСМ работникларының Мәскәүдә үткәрелгән бөтен Союз киңәшмәсендә делегат булып катнаша.

Ниһаять, Җәлил Мәскәү дәүләт университетының әдәбият факультеты студенты (3145 нче студентлык билеты, март, 1930 ел). Универ-

ситетта укыган дәвердә дә ул җәмәгать эшләренә катнашудан туктамый, «Октябрь баласы», «Пионер», «Кечкенә иптәшләр» журналларын чыгару кебек җаваплы эшләрне башкарып килә.

Боларның барысына ничек өлгергән ул?

Безнең Муса Җәлил документларыннан алган тәэсиребез шундый зур, дулкынлануыбыз шундый көчле, без документларны барлаудан туктап торабыз, хисләребезне аз гына булса да тәртипкә китерергә телибез. Ял сәгатьләрендә Әминә апа безнең белән бик теләп сөйләшә, ул ире Мусаның берьюлы бик күп төрле эш башкара алуының сәбәпләрен сөйли, әкрен генә, ашыкмый гына сөйли, матур коңгырт күзләрен сагыш томаны урап ала. Ул бит аны күргән, ничәмедер ел аның белән бергә яшәгән.

— Муса бер үк көнне опера театрында булырга, Язучылар союзына барырга, мәкалә язарга, китабының гранкасын укып, аны типографиягә тапшырырга өлгерә иде. Ул бер генә минутын да әрәмгә үткәрми иде. Берьюлы күп төрле җәмәгать эшләрен җилкәсенә алу аны язу өчен идеал тыныч шартлар таләп итмәскә, гомумән дә аулак урын эзләмәскә өйрәтте. Аның күңеленә шигырь теләсә нинди җыелышта, киңәшмәдә, чаңгы шуганда килә. Чаңгы шууны, иптәшләре белән бергәләп прогулкаларга чыгуны ул үлеп ярата иде. Бөтен нәрсәсе аның ихлас, ышанып, инанып эшләгән эш иде. Минем үземнең, мәсәлән, поездга бер сәгать алдан килеп, көтеп тормасам, күңелем булмый, эчем поша, поезд мине калдырып китәр төсле тоела башлый. Муса поездга, кузгалыр алдыннан, баскычына сикереп менеп кенә китә торган иде.

— Организмы да нык булган, күрәсең?

— Әйе, нык иде, ул аны үзе чыныктырды.

— Авыру-чирләүнең дә нәрсә икәнен белми идеме?

— Юк, ялганлар хәлем юк, авыруның нәрсә икәнен белә иде Муса. Хәтта иркәләнеп авырый иде. Аз гына башы авыртамы, тамагы кызышканны сизәме, ул шундук урын өстенә менеп ята, үзен кызгандыра, температурасын үлчәттерә, зык куба торган иде. Ләкин ул бик сирәк авырый иде. Нык иде аның организмы...

Әминә апаның истәлек минутлары бетә. Без тагын эшкә керешәбез. Менә халыкара хәл турында сөйләр өчен Җәлиловны эшчеләр арасына җибәргән путевка, менә Ленин комсомолының егерме еллыгына карата Җәлил сөйләгән докладның тезислары, комсомол политмәктәпләре өчен татар телендә дәреслек чыгаруда аның катнашуы хакында белешмә.

Татар операсы Муса Җәлилнең якыннан катнашлыгы белән туа. Татар Дәүләт опера һәм балет театры оешуның беренче көненнән алып, Муса Җәлил анда әдәби бүлек мөдире. «Татар опера театры» дигән күләмле кулъязманы укыйбыз. Татар музыка культурасының опера театры булып үсеп житүгә кадәр булган юлын ача әдип. Архивта, кулъязмалар арасында әле беркайчан да матбугатта чыкмаган эчке рецензияләр, бәяләмәләр бар. Әхмәт Фәйзинең «Качкын», «Сафа», Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», Гадел Кутуйның «Бәхет», Әнәс Камалның «Туй», Мәхмүт Максудның «Кара йөзләр», Әхмәт Ерикәйнең «Бибисара» либреттоларына һәм башка әсәрләргә бәя бирелгән, аларны үстерү, камилләштерү юллары күрсәтелгән.

1934—1940 елларда, нибарысы биш-алты ел вакыт эчендә, Муса Җәлил иллегә якын тәнкыйть мәкаләсе, очерк, китапларга сүз башы язган. «Татар опера театры», «Совет драматургиясе яңа чорда», «Совет фольклорын җыйнарга чынлап керәшергә» кебек күләмле зур мәкаләләрендә, Габдулла Тукайга, Шәриф Камалга, Мәҗит Гафурига, Һади Такташка багышланган мәкаләләрендә проблематик мәсьәләләр күтәргән.

Күңелдә һаман бер сорау: ничек өлгергән?

Бу чорда бит ул әллә ничә шигырь җыентыгы бастыра, Мәскәүдә русча китап чыгара, музыкаль культурабызның алтын фондына кергән «Алтынчәч» драматик поэмасын, искиткеч халыкчан «Хат ташучы» поэмасын бастыра, дистәләгән җыр текстлары яза...

Әминә апа алып килгән өч чемодан кульязма һәм документтан без утыз папка әзерләдек. Җәлил тормышы безнең алдыбызга барлык киеренкелеге, зурлыгы белән килеп басты.

Без тормышларын бик җиңел генә уткәреп җибәрүчеләр, азактан «бушка узган гомер», «җилгә очкан көннәр» өчен үкенеп йөрүчеләрне беләбез. Муса Җәлил гомерен әрәмгә узган көннәр өчен үкенмәслек итеп үткәргән, ул гүяки аңа гомернең аз гына бирелгәнен сизгән, яшәп калырга, эшләп калырга ашыккан. Ул шагыйрьнең дәвер алдында, халык алдында җаваплылыгын беренче планга чыгарып куйган.

«Язучының бурычы — тирә-як чынлык турында дөресне язу. Без менә күбесенчә шул дөресне яза алмыйбыз. Ә дөресне язу өчен тирә-як чынлыкны тирән белергә, аның катлаулы процессларына төшенергә кирәк. Бу урында кайберәүләр «тормыш эчендә кайнарга кирәклек» белән генә чикләнәләр. Бу дөрес һәм иң мөһим шарт. Ләкин надан көенчә күпме кайнасаң да, аны тирән төшенеп булмый. Шуның өчен укырга кирәк. Партия, хөкүмәтнең бөтен карар, чараларыннан башлап, тарих, фәлсәфә, психология һәм башкаларга хәтле белергә кирәк. Бу безгә чынлыкны һәм кешеләрне белергә ярдәм итә».

Бу — декларация түгел. Җәлил иң әүвәл үзе өйрәнгән. Муса Җәлил архивында без «Алтынчәч» драматик поэмасының уннан артык вариантын күрдек. Кат-кат эшләгән шагыйрь. Шушы бер әсәрне язар өчен ул бик күп китап укыган. Алар арасында халык иҗаты үрнәкләре, халык этнографиясе, көнкүреш турындагы китаплар, сәхнә сәнгате, музыка теориясе бар. Алар арасында марксизм классиклары аерым урын алып тора.

Без табигый талантның гаять зур тырышлык һәм физик хезмәт белән кушылуын, иҗтимагый практика белән баетылуын, көннән-көн үсә, камилләшә баруын күрдек. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр — Муса Җәлил сугышка кадәр узган зур көрәш юлының ялкын булып кабынуы икәнен аңладык.

Муса Җәлилнең архивында, йөзләгән документ арасында, без шагыйрьнең бер шигыре басылган чакыру кәгазе күрдек.

Безнең илдә тиңсез хезмәт белән
Социализм иле төзелә.
Минем гомерем, кирәк бер таш булып,
Кереп ятсын шул йорт нигезенә,

— диелгән анда.

Бу — 277 сайлау округыннан Казан шәһәр Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән Муса Җәлил белән очрашу кичәсенең чакыру билеты.

«Социализм йорты нигезенә гомерем кирәкле таш булып керсен»,— дип әйтү өчен зур шагыйрь һәм аңлы көрәшче булу кирәк. Моны бары тик тарихи зарурилыктан туган олы шәхесләр генә әйтә ала.

Әминә апа өч чемоданга тутырып алып килгән язмалар һәм документларны — Муса Җәлил архивын институтка әзерләгән чакта без «Язучы нинди булырга тиеш» дигән мәңгелек соравыбызга җавап алдык.

Шул ук вакытта без язучының гомер юлдашы нинди булырга тиеш дигән сорауга да җавап алдык. Ул Әминә Җәлилова төсле булырга, иренең хатирәсен һәм мирасын күз карасыдай саклый белергә тиеш. Шуңа күрә халык аны гомер юлдашы дип атаган.

# Таулар иләндә егерме көн

...Мин редакция бүлмәсендә, кәгазьләргә күмелеп, эшләп утырам. Янымда гына карлыкканрак бер тавыш ишетәм:

— Гариф, башыңны күтәрче. Бер сөйләшеп алыйкчы, туганым.

Башымны күтәрәм. Каршымда таушалганрак костюмлы һәм ачык чырайлы Халик абый басып тора.

Халик Садри — безнең өчен әллә нинди томаннар белән өретелгән серле шәхес. Батрак, эшче, революция комиссары. Куйбышевны күргән, аның тәкъдиме белән 1917 елны коммунистлар партиясенә кергән. Бөек Октябрь революциясендә катнашкан. Гражданнар сугышы чорында Идел буенда партизан отрядлары оештырган. Татар һәм башкорт коммунистлары белән бергә, Кремльдә Ленин белән очрашкан.

Революциядән соң да байтак эшләр эшләгән ул. Казан «Спартак» комбинатының директоры булган. Уйлап табу, рационализаторлык тәкъдимнәре кертү белән озак вакытлар шөгыльләнгән, шул хакта китаплар язган. Бөек Ватан сугышы чорында батальон комиссары булган, хәрби полководец Чуйков кул астында эшләгән.

Бер уйласаң — гаҗәп зур шәхес. Ләкин... икенче карасаң, үзен тотуы гади бер авыл агаеныкы шикелле. Язучылар союзына гариза язса — аны торба итеп төрер, ул гына җитмәс, тегәрҗеп белән бәйләп кертер.

Без аның «Ил батырлары», «Безнең таң», «Тимерче малае», «Зиятдин балалары» дигән китапларын укып үстек. Ул китаплар безне аңа гашыйк иттерде, аны күрәсе килү, аның белән кара-каршы утырып сөйләшәсе килү теләген уятты.

Менә ул хәзер минем каршымда басып тора һәм:

— Гариф, энекәш, башыңны күтәрче, бер сөйләшеп алыйкчы...—ди.

Мин аягүрә торып басам. Халик абый елмая, елмаюы аның чын, ихлас.

— Тыңлыйм, Халик абый,—дим мин аңа ихтирам белән карап.

— Эш менә болай, энекәш: мин, әлбәттә, тәмәке тартуны ташладым. Картаймыш көнендә сиңа тәмәке тарту, пыскып утыру килешми,— диде миңа җиңгәгез. Димәк, мин тәмәкене ташладым. Син, туганым, миңа бер генә папирос бир инде, азаккы тартуым булыр...

Иртәгәсен ул тагын керә, тагын, сабый бала төсле уңайсызланып, миннән папирос сорый. Минем дә инде эшләп арган чагым була, без аның белән икебез бергә коридорга чыгып тәмәке тартабыз, тормышның юк-барын сөйләшәбез. Миңа янымда шундый да зур, бай биографияле, шул ук вакытта чамадан тыш беркатлы кешенең яшәве рәхәт. Ул сине кыен хәлгә куймый, тиң итеп сөйләшә, синең белән тәмәке тарта.

Ләкин ул бит хәзер дә кечкенә кеше түгел, безнең Язучылар союзы каршындагы Әдәби фондның директоры. Иҗат йортларына, санаторийларга путевканы ул бирә, балалары булган язучыларның балаларына Яңа елда чыршы бәйрәмнәре оештыра, әдипләрнең тормыш-көнкүрешен күзәтеп, барлап, кайгыртып яши.

Минем беренче мәртәбә Кавказга, таулар иленә баруым, Гагра шәһәрендә «Яшьлек яме» повестен язып ятуым да шул Халик абзый аркасында булды.

1953 елның апрель азакларында мин баш өстендә аның карлыкканрак тавышын ишеттем:

— Гариф, энекәш, башыңны күтәрче, бер сөйләшеп алыйкчы.

Мин «Совет әдәбияты» журналының типографиягә төшерәсе санын бик ашыгып укып утыра идем, тавышыннан Халик абзыйны танып, механик рәвештә аңар кесәмнән папирос чыгарып бирдем.

— Энем, Гариф, мин сиңа башыңны күтәр дип әйтәм.

Башымны күтәрсәм, ачык, якты чырай белән елмаеп, Халик абзый карап тора. Кулында папирос тартмасы. Ни житте генә түгел — «Казбек».

— Мин сиңа бурычымны түләргә кердем,—ди бу миңа, папиросын сузып. — Ал, рәхмәт, кыен чакларда коткарганың өчен.

— Сез нәрсә, Халик абый, булмаганны...

— Ал, энем, ал. Мин тәмәкене ташлый алмам, ахрысы, ныклап тартырга керештем. Курыкма, сиңа бүтән соранып кермәм, бурычымны түлим бүген. Аннары... минем сиңа бер изгелек эшләргә дә ниятем юк түгел.

— Нинди изгелек ул, Халик абый?

— Мин сиңа, Кавказга барып, язып ятарга тәкъдим итәм.

— Анысы ни дигән сүз?

— Син бит хәзер өметле яшь каләм саналасың. Журналда очеркыңны укыдым. Хикәяләрең дә газеталарда басыла. Әллә ничә мәкалә чыгардың. Менә шуларны исәпкә алып, аннары минем тәмәкече дустым икәнеңне дә истә тотып, мин сиңа Гаградагы иҗат йортына бер путевка тәкъдим итәм.

— Кайчанга?

— Май башына.

— Күпме тора?

— Бер мең дә биш йөз тәңкә.

— Минем бит аңар түләрлек акчам юк, Халик абый.

— Беренчедән, аның дүрт йөз тәңкәсенә скидка ясыйбыз, анысын Әдәби фонд үз өстенә ала. Аннары калганын мин аның бүген үк түлә дип әйтмим, бар, эшлә, ял ит, яз, кайткачыңнан, акча туплый төшкәч, көзен түләрсең.

Күңелдә искиткеч матур күренеш пәйда булды. Кавказ, без кечкенәдән ишетеп үскән Каф таулары. 24 көн буена беркемнән бәйле булмыйча, ашау һәм тору урынын кайгыртмыйча, гел язып кына яту. Зәпзәңгәр диңгез! Ә минем күңелдә инде сюжеты оешып житкән повесть бар, студентлар турында, үзебезнең Казан университеты тормышыннан. Анда барсам, язылачак бит ул, билләһи, язылачак...

— Мин үзем генә бараммы соң анда?

— Юк, икәү барасыз, Зәки Нури белән. Ул бик яхшы иптәш, үзеңне бер кайгысыз йөртеп алып кайтыр. Тәвәккәллә. Менә шушы тиле әйткәние дип әйтерсең, актыктан Халик абыеңа рәхмәт әйтерсең әле. Я, утырып бер тәмәке тартыйк та...

Кавказга бару минем өчен әйтеп бетергесез зур яңа дөнья булды. Беренчедән, анда Мәскәү аша барасы икән, ә минем Мәскәүне тәүге тапкыр күрүем иде. Көньякка барасы поездны көткән арада Зәки миңа Кызыл мәйданны күрсәтеп алып килде.

Кремльне бит мин мәктәп эскәмиясеннән башлап плакатларга ясап килдем. Ленин мавзолеен бит мин кече яшемнән башлап стена газеталарына үзем ясадым. Аларның төрле төсләр белән бизәлгән рәсемнәрен газета-журналлардан җыйдым, инде менә хәзер алар минем күз алдымда барлык зурлыклары, мәһабәтлекләре белән басып торалар...

Поезд безне Кавказга Курск вокзалы аркылы алып барды. Курск хакында, андагы Дуга сугышлары хакында мин Сибгат Хәкимнән ишеткән, аның шигырьләреннән укыган идем. Әнә шул көл өемендә яткан шәһәр яңабаштан күтәрелгән. Вокзал капкасын кантар-кантар ташлардан өйгәннәр, совет дәүләтенең көчлелеген, бернинди дошман алдында да җиңелмәслеген күрсәтү өчен юрамалый, демонстратив рәвештә, әнә шундый кантар-кантар ташлардан монумент өйгәннәр, дип уйладым мин.

Кавказ мине таулары белән таң калдырды. Янә дә мине диңгезнең чиксезлеге хәйран итте. Аларны мин башта көн саен, хат итеп, Казанга җибәреп тордым. Аннары, бераз эшкәртеп, «Яшьлек яме» повестендагы Таһир Юлдашев көндәлегенә керттем. Таһир образында, димәк, өлешчә минем үз биографиям дә бар.

Иң сөенечлесе шул булды, Кавказда 24 көн эчендә мин «Яшьлек яме»нең бер йөз егерме битен, ягъни нәкъ яртысын язып кайттым. Калган яртысын язар өчен тагын ике ел азапланырга туры килде. Журналда унар-уникешәр сәгатькә сузылган эш үз иҗатым белән шөгыльләнергә вакыт калдырмый диярлек иде.

Кавказга җибәргәне өчен мин Халик абыйга бик-бик рәхмәтле булып калдым. Бик озакка сузылган биш еллык студент дәвереннән соң мин кешечә ял итә алдым, рәхәтләнеп, туйганчы, күңел булганчы яза алдым. Мин берни хакында да кайгырмадым. Шәһидә алып биргән сап-сары төстәге, кыска җиңле ике күлмәгем бар иде минем, алмаш-тилмәш шуларны диңгез суында юып кия идем. Иҗат йортында эшләүче хуҗалык эшчеләре, грузин хатын-кызлары мине «сары үрдәк, сары үрдәк!» дип үчеклиләр иде.

Казанга мин нәкъ биш килога артып, түп-түгәрәк булып, ком гарәбедәй каралып, кояшта янып кайттым.

— Менә бит, бармыйм дип аптыраткан идең, килешкән бит Кавказ кояшы! — диде Халик абый.

«Яшьлек яме»н 1955 елны язып бетердем. Китабымның басылып чыккан беренче данәсен Халик абыйга бүләк итәрмен диган идем, ул минем китап чыкканчы көтеп тора алмады, 1955 елның март аенда вафат булды. Таза иде әле, алтмыш яшьлек юбилеен үткәргән чакта гел дә елмаеп, кояш кебек балкып утырган иде Тукай клубында.

Аңа, Әдәби фондта озак еллар эшләп тә, үзенә бер генә мәртәбә дә путевка алмаган кешегә, Кавказга бушлай путевка бирделәр. Китте безнең комиссар, сугыш ветераны, эшче-уйлап табучы Кавказга. Сау-сәламәт китте, көч-хәл белән кайтты.

Климат алыштыру килешмәгән, диделәр.

Килешмәсә дә килешмәгәндер, андый рәхәтләрне күргән кеше идемени Габделхалик Садретдинов!

Аның гәүдәсен Матбугат йорты каршысындагы Актерлар йортының аскы катына куйдылар. Кызыл материя белән уралган табутта ул күзләрен йомып ята, йоклап киткән төсле генә иде. Безне, яшь язучыларны, төнгелеккә аны сакларга куйдылар. Кемдер минем белән бергә саклашырга килергә тиеш иде (безнең халыкта мәетнең ялгызын гына калдыру гадәте юк, кем дә булса уяу булырга, янында саклап утырырга тиеш бит).

Төнге уникедә мин Халик абзыйны сакларга Актерлар йортының аскы катына килдем, минем белән саклашасы иптәш килмәде. Күрәсең, мин аны начар кеше дип хәтеремә беркеткәнмендер, аның кем икәнен хәзер әйтәсем килми.

Малай чагында, авылда, без мәет янында ялгыз калырга, төнлә зират яныннан ялгыз узарга, төн уртасында кара мунчага керергә яки чорма башына менәргә курка идек. Күрәсең, авылдагы җор телле кешеләрнең җен-пәриләр, әрвахлар хакында өзлексез сөйләгән шомлы сүзләре тәэсир итми калмагандыр. Мин үзем җиденче класска кадәр, комсомолга кергәнче, дини хорафатларга ышанып яшәдем.

Аннары ышанмый башладым. Төннәрен, күрше Көтек авылыннан Өчилегә кайтканда, ике коры елга чыгасы бар иде, тик әнә шулар гына мине бераз өркетә, чөнки аннан бүре килеп чыгуы мөмкин, сугыш елында авыл тирәсендәге урманнарда бүре бик күбәйгән, алар, кояш баеп житәр-житмәс авыл буйларындагы үләксә чокырына җыелышып, улаша башлыйлар иде.

Инде менә бүген...
Халик абзыйны мин төнге икегә кадәр япа-ялгызым саклап утырдым. Ул миңа үлгән кебек тоелмады. Менә генә күзен ачар да:
— Гариф, энекәш, каяле, башыңны күтәрче, бер тәмәке бир әле,— дип әйтер кебек кенә иде...
Сагынып сөйләрлек кеше иде Халик абзый.

## Поэзиядә яңа сулыш

Хәзер уйлыйм да, искә төшерәм дә, исем китә: булган да соң, мин әйтәм, кыю заманнар! Илле икенче елның, шуннан соң илле өченче елның поэтик йомгаклары хакында доклад ясадым. Ике ел рәттән бит ул, поэзия хакында!
Шул докладларым белән үземә бер көтү «дошман» җыйдым.
Минем белән исәнләшергә теләмәүчеләр күбәеп китте. Хәер, монда бер дә шаккатырлык түгел, чөнки ул заманда коры риторика бик күбәйгән, әдәбиятка конфликтсызлык заманасы килгән, шагыйрьләрне бер-берсеннән аеру кыен иде. Мин шуларны, кемнең кемлегенә карамый, әйтеп бирдем.
Ләкин бераз торгач аңладым, мин үземә дошманнар гына түгел, фикердәшләр дә җыйганмын икән. Аларның берсе — Әнвәр Давыдов, икенчесе — Шәрәф Мөдәррис булып чыкты.
Әнвәр Давыдов Казанга Куйбышев өлкәсе Камышлы авылыннан күчеп килде. Аңарчы ул фронт юлларын узган, сугыштан соң Камышлыда татарча чыга торган район газетасында редактор булып эшләгән. Төз гәүдәле, песи кебек йомшак басып, сыгылмалы итеп йөри, русчаны су кебек эчә, шигырьләрен сәхнәләрдән ут чәчрәтеп укый торган бу шагыйрь башлап язучы чорын да, яшь язучы чорын да узмады. Яңгыравыклы риториканы бәреп егып, тормышчан, уйланучан һәм яңача формалы шигырьләре, аннан да бигрәк ел саен иҗат иткән көчле поэмалары белән татар әдәбиятына өермәдәй килеп керде.
Беренче поэмаларын ул безгә Камышлыдан килеп укыды. Ул миннән, әйтик, алты яшькә олырак иде, әмма без икебезнең арада яшь аермасын сизми идек.
Казанга килеп төшкән чагында, аның торырга квартиры юк иде. Ул заманда квартирны хәзерге шикелле бик ашыгып бирмиләр иде әле.
Кави ага Нәҗмидән әллә ун, әллә унбиш мең акча бурычка алып торып, ул бер йортны арендовать итте, шул йортта биш-алты ел буена, казна фатиры алганчы яшәде, шунда балалар үстерде.
Ул йортка да, казна фатирына да аны мин, йөк машинасы табып, күчерешеп куйдым. Алдарак әйткәнемчә, без Матбугат йортында янәшә бүлмәләрдә көн күрәбез, ул — Язучылар союзында җаваплы секретарь, мин «Совет әдәбияты» журналында бүлек мөдире идем.
Әнвәр абый шаян-тапкыр сүзле, белемле, юмарт күңелле кеше, поэзия өчен яратылган кеше иде. Бүгенге бер буын яшь шагыйрьләр үзләренеке дип исәпләнгән ирекле поэзияне татар әдәбиятына сугыштан соң ул алып килде һәм үз артыннан байтак кына кешене ияртеп китә алды.
Әнвәр Давыдов төннең-төн буе шигырь укып чыга ала, һич кенә дә ялыкмый иде.
Ул табигатьне бик ярата, табигатьтән башка гомумән дә тора алмый иде бугай.
Ял көннәрендә ул мине Чернышевский урамындагы өйдәшләр булып яшәгән бер бүлмәле фатирыбыздан махсус кереп алып чыга,

өйдәгеләр минем чыгып югалуымнан куркып, ялгызымны гына җибәрмәсәләр, минем белән барасы кем бар — һәммәсен ияртеп алып чыга иде.

Казанда, табигать дигәннән, әллә кая бара алмыйсың. Без җәйләрен шәһәрнең Максим Горький исемендәге ял паркына, я инде, бик дәртләнеп китсәк, Идел аръягына чыгабыз.

Әнвәр абый, ял урынына килеп җитү белән, ботинкаларын салып ташлый, пиджагын агач ботагына элеп куя, чирәм өстенә без алып чыккан җәймәне җәябез дә ул шуңа чалкан сузыла, сәгатьләр буе, селкенми-нитми, зәңгәр күккә, ак болыт өемнәренә карап ята.

— Менә бит, болар, дус кеше, синең белән мин туганчы да булганнар: елгалар аккан, җилләр искән, күктән кояш карап торган һәм ак болытлар гел шулай бөдрәләнеп, күкнең зәңгәрлегенә контраст булып агылганнар. Без бу дөньядан китәрбез, алар һаман шулай калыр: кояш та, елгалар да, бөдрә болытлар да...

Дөнья бүген шундый аяз,
Шундый матур зәңгәрлек,
Күкнең читен кисеп алып,
Косынка итеп бәйләрлек!

— дип, ул күңеленә әлерәк кенә килгән шигырь юлларын укып китә.

Олы юлда машиналар
Ашыгалар, ашыгалар.
Ярканат-фонарь утлары
Әрле-бирле селкенәләр,
Коеларның сиртмәләре
Бер төшәләр, бер менәләр...

Шигырьне ул рәхәтләнеп, күзләрен йома төшеп укый. Аннары торып тезләрен кулы белән кочаклап, безнең яннан узып йөрүче кызларга озак кына карап утыра.

Мин аның ниндидер шаблон шигырь язганын яки тормышта бер калыпка сыеп яшәгән чагын белмим.

Вакыт-вакыт ул, такси чакыртып, Казанның аркылысын-буен йөреп чыга, үзе белән мине дә ала, яңа салына торган йортлар янына төшеп, сокланып карап тора, шофер чакырып алмый торып, баскан төшеннән кузгалмый иде.

Бервакыт көзен, ачы җилле суык төндә, ул мине «Совет әдәбияты» редакциясеннән алып чыгып китте.

— Кайтыйк әле безгә, — диде.

— Нәрсә белән кайтабыз соң, трамвай йөрми бит?— дидем мин аңа.

— Җәяү кайтабыз. Син ничә километр җәяү йөри аласың?

— Безнең авылдан Арча базарына унике чакрым. Мин анда көнен барып, көнен кайта ала торган идем.

— Ә Матбугат йортыннан Себер трактына күп булса биш километр булыр.

Без аның белән җәяү кайттык. Без кайтып кергәндә, сәгать төнге ике иде. Әнвәр абыйның хатыны Нина безгә ишек ачты:

— А-а, два холостяка... — диде дә, бүтән сөйләшеп тормастан, үз ягына кереп китте.

Ул безне кайдадыр «күңел ачып» йөргәннәр дип уйлады бугай.

Әнвәр абый мине үз бүлмәсенә алып керде. Чәй кайнатып китерде. Ризыклар тезеп чыкты.

— Гаепләмә, зәмзәм суы юк, куе чәй эчәрбез бүген һәм шигырь укырбыз, — диде.

Без төне буе шигырь укыдык. Күп укыды Әнвәр абый, басылган шигырьләрен түгел, басылмаганнарын укыды. Менә хәзер дә мин әле аларның байтагысының басылганын хәтерләмим. Шигырьләр дөнья

хакында, яшәеш хакында, хатын-кызлар һәм дуслар хакында, кеше гомеренең озынлыгы һәм кыскалыгы хакында иде.

Без төне буе шигырь дөньясында яшәдек. Мин иртән иртүк кайтып китмәкче идем, бәхетсезлегемдер — трамвай әле һаман йөри башламаган, кайдадыр аварияле юлны төзәтәләр иде. Иртәнге тугызга кадәр Әнвәр абыйларда утырып торырга туры килде.

Сәгать унда редакциягә килдем. Туп-туры. Шәһидә анда иде инде. Мин килеп керүгә Гази абый да килеп җитте һәм:

— Ни хәл, Шәһидә, кәефләр әйбәтме? — диде.

Шәһидә:

— Әйбәт түгел әле, Гази абый, Гарифҗан бүген өйгә кайтып кунмады, төне буе урамнан эзләп йөрдем, —диде һәм, бер мизгел иреннәрен мимылдатып торгач,— мин бит әле аның хатыны гына түгел, биш ел буе бергә укыган иптәше дә... — дип елап җибәрде.

И самими чаклар да бар иде соң!

— Ни булды, Гарифҗан?— диде Гази абый, хәвефләнеп.

Мин Әнвәр Давыдовларга барганымны, трамвай йөрмәү сәбәпле төнлә кайта алмаганымны әйттем.

Гази абый, баягы төсле үк тыныч тавыш белән, Шәһидәне юатып:

— Әнвәр начар егет түгел, ул бик әйбәт егет, ул бик әйбәт шагыйрь, аның белән йөргән кеше ким-хур булмас,— диде.

Тынычландыра белә дә иде соң киңәшкә килгәннәрне Гази абый! Әлбәттә, ул миңа да өлеш чыгарды.

— Ә син, яшь язучы, төнлә өеңдә кун. Гаиләңне борчуга салып йөрмә. Монысы соңгысы булсын,—диде.

— Мин бер начарлык та эшләмәдем бит, Гази абый. Шигырь тыңлау безнең заманда гаепмени соң?

— Якын кешеңне борчуга салгансың икән инде, син гаебең булмаса да гаепле, — диде Гази абый.

Әнвәр абый белән поэтик төн үткәргәннән соң, аның иҗаты белән кызыксынуым тагын да арта төште, һәм мин озакламый аның хакында «Совет әдәбияты» журналында мәкалә бастырып чыгардым. Миңа аның шигырьләрендәге ныклык, сүзләренең төгәллеге ошый иде, поэмаларының романтик биеклеккә күтәрелүен аның аеруча зур, принципиаль уңышы итеп күрсәттем.

Мәкаләне мин ашыкмыйча, күңелем кушканча яздым. Әмма Давыдов иҗатындагы мине борчыган тел кимчелекләрен күрсәтми калырга намусым кушмады.

Мәкаләне Гази абый журналга бик теләп алды һәм бастырып чыгарырга дип кул куйды.

Мәкаләне мин Давыдовның үзенә укымадым. Автор турында аның белән килешеп мәкалә язуны мин бигүк дөрес хәл дип санамыйм.

Ярый, хуш, өч-дүрт айдан журналның миңа кирәкле саны чыкты. Шуннан соң бер-икеме атнадан журналның шул санын кулына тотып, бик хәтәр дулкынланып, Әнвәр абый килеп керде.

— Их, дустым, дустым... — диде дә минем янга урындыкка килеп утырды.

— Нәрсә бар?— дидем мин аптырап.

— Менә укып кара әле шуны, аңларсың үзең.—диде Давыдов.

Ул миңа Камышлыдан, Һаҗәр апасыннан килгән хатны сузды. Хатта шундый юллар бар иде:

«И, энем Әнвәр, мин сиңа ничәмә-ничә мәртәбәләр әйттем, укы, дидем, белемеңне арттыр, дидем. Сүземне тыңламадың. Шуның аркасында энә нинди сүзләр ишетергә туры килә бит үзеңә. «Совет әдәбияты» журналында сине надан дип язганнар бит».

Мин кычкырып көлеп җибәрдем.

— Нәрсә көләсең? — диде Давыдов, кашларын җыерып. — Яза белми язсаң, шулай була ул.

Без аның белән икәүләп минем мәкаләне карап чыктык. Анда тел кытыршылыклары турында әйтелгән. «Болар Әнвәр Давыдовның юри эшләгән эше түгел, татар теленә саксыз каравыннан, тел наданлыгыннан килә», диелгән иде.

Давыдов миңа каш җыерып озак утыра алмады, журналны кулында селки-селки, үзе дә көлеп җибәрде.

— Күрдеңме авыл халкындагы ихласлыкны?! Ул син ни дип әйтсәң, шулай дип аңлый, шулай дип ышана. Син мине надан дигәнсең, апам надан дип аңлаган. Сиздеңме? «Тәнкыйтьче — әдәбиятның намусы» дип юкка гына әйтмиләр икән шул, моннан соң миңа карата үлчәбрәк әйт сүзеңне, яме, — диде. — Юкса, каш ясыйм дип күз чыгарып куярсың.

## Ил күләмендәге киңәшмә

1953 ел миңа бик күп яңалыклар китерде.

Шушы елны мин, бая әйткәнемчә, Кавказны күреп, повестемның яртысын язып кайттым. Нәкъ әнә шул елны, көзен, Язучылар союзы идарәсе мине Мәскәүгә, яшь тәнкыйтьчеләрнең Бөтенсоюз киңәшмәсенә җибәрде.

Бу эшне шулай ук минем беренче хикәямне «Үсү юлы» альманахында бастырып чыгарган кеше Газиз ага Иделле бик теләп эшләде. Дөресен әйткәндә, «Галләм сорау бирә» хикәясеннән соң мин өч ел буена хикәя бастырмадым, коридорда очраган чакларда Газиз абый, бик тә үз итеп, миңа: «Нәрсә син, егет, бер сорау бирдең дә туктадың?! Хикәя язмыйсыңмыни бүтән?!» — ди иде. Ул минем мәкаләләремне дә күзәтеп бара икән. Тоткан да Бөтенсоюз яшь тәнкыйтьчеләр киңәшмәсенә тәкъдим иткән.

«Совет әдәбияты» журналында минем диплом эшем — «Намус» романының сурәтләү чаралары» аерым мәкалә булып басылып чыккан иде. Шуны русчага тәрҗемә иттеләр. «Илле икенче елның поэтик йомгаклары»н, Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдов, Мәхмүт Хөсәен иҗатына карата язган мәкаләләремне тәрҗемә иттеләр.

Октябрь аенда без Мәскәүгә җыелдык. Мин Берта Яковлевна Брайнина семинарына эләктем, гомумән, киңәшмәгә илнең барлык якларыннан сиксән кеше — сиксән яшь тәнкыйтьче җыелган иде. Миңа иң ошаганы семинарлардагы фикер алышу тәртибе булды. Безнең мәкаләләрне тәҗрибәле өлкән тәнкыйтьчеләр үзләре генә укып калмый, безнең дә укуыбызны таләп итәләр, безне дә фикер алышуда катнаштыралар иде. Миңа калса, моның ике әйбәт ягы бар. Беренчедән, без әсәрләребез хакында олы тәнкыйтьчеләр әйткән фикерне сукыр килеш тыңламыйбыз, үзебез аңлаганнар белән алар сөйләгәнне чагыштырып карый алабыз. Икенчедән, без үзебез зур аудиториядә, олы кешеләр алдында чыгыш ясарга күнегәбез, каушау, югалып калу кебек кыен хәлләрдән котыла барабыз.

Мәскәү киңәшмәсендә минем хәтергә ике нәрсә бик нык сеңеп калды. Күренекле тәнкыйтьчеләрдән берсе — Анатолий Тарасенков безгә — яшьләргә әдәби тәнкыйтьнең нинди мавыктыргыч иҗат икәнен бик яхшы аңлатып бирде.

— Сугышка кадәрле мине тәнкыйтьче Семен Трегуб үзәк газета битендә тетеп салды, — диде ул. Газета шундый солидный иде — мин үземне яклап, авызымны да ача алмадым. Гаделе түгел иде тәнкыйтьче миңа карата, мин моңа рәнҗедем һәм әдәби тәнкыйтьтән ваз

кичәргә ният кылдым. Чыннан да, нәрсә мин, башыма тукмак ала-ала, кемнәрнендер сай әсәрләре өчен көрәшергә, әдәбият алга китсен дип чәрәшергә тиеш әле? Кимчелекләрен язып чыктыңмы, язучылар синең белән сөйләшми башлыйлар. Миңа гына кирәкме соң? Күчтем мин публицистикага. Менә, ичмасам, жаның тыныч. Илнең уңышларын язам, алдынгы кешеләрне матур төсләр белән сурәтлим. Берәү дә минем белән исәнләшмичә йөрми, берәү дә миңа каш җыерып карамый, китте минем эшләр җайга! Ләкин күңел риза түгел, әдәби тәнкыйтьтә эшләгән еллардагы кебек, рухи канәгатьләнү тапмыйм, дәртләнеп, ярсынып, ду килеп яшәмим. Кыскасы, түзмәдем, сугыштан соң тагын әдәби тәнкыйтькә әйләнеп кайттым. Әйтергә теләгәнем шул минем: яшьләр, сез бик авыр өлкәгә, әдәбиятның намусы булырга тиешле өлкәгә киләсез. Бу сезгә ифрат зур җаваплылык өсти. Мин сезнең әдәби тәнкыйтьче исеменә лаек булуыгызны телим.

Икенчесе Берта Яковлевна Брайнинаның семинарларны алып бару рәвеше, безгә карата ифрат зур ихтирам саклавы мине бик канатландырды.

Битен сары сипкел баскан, кулына эре сары гәрәбәдән тезеп ясалган беләзек киеп куйган, зәңгәр күзләре сизелер-сизелмәс көлемсерәп торган, алтмышлар тирәсендәге әби ишектән песи адымнары белән диярлек килеп керә, йомшак бәрхет тавыш белән исәнләшә, алдына кулъязмаларны тезеп чыга.

— Бүген кемнән башларга дип сөйләшкән идек әле? — ди ул.

— Ахуновтан, — диләр берничә кеше берьюлы.

— Ягез, Ахунов, миңа һәм иптәшләрегезгә аңлатып бирегез: сез ни өчен әдәби тәнкыйть өлкәсен сайлап алдыгыз?

— Мин берәр яңа китап чыкса — сөенәм.

— Бу — әйбәт фал. Я, шуннан?

— Сөенечемне үземдә генә калдырасым килми, башкаларга да сөйләп бирәсем килә.

— Бик яхшы. Тәнкыйтьченең беренче бурычы — әдәбиятны ярату. Бары тик гашыйк кешенең генә мәгъшукасының кимчелекләрен әйтергә хакы бар. Мин моны үтерим әле, мин моны кеше алдында усал сүзем белән хур итим әле дип тотынган кешене әдәби тәнкыйтькә, гомумән дә әдәбиятка якын да китермәскә кирәк. Кем әйткән әле, әдәбият бусагасыннан атлаганда, ишек төбендә аякларыгызны сөртеп керегез, дигән?

— Толстой!

— Чехов!

— Белинский!— дигән сүзләр ишетелә.

— Ярый, кем ул сүзләрне әйткәнне сез өйгә кайткач, иркенләп тагын бер карарсыз. Конкрет сөйләшүгә күчик. Сез, Ахунов, Казан университетын тәмамлагансыз икән, анкетагызда шулай дип язылган. Кайчан тәмамладыгыз?

— Узган ел.

— Яңа гына икән әле. Димәк, әле сездә: «Миннән дә күп белүче юк бу дөньяда», дигән тойгы исән?

Мин ут кебек кызарам, Берта Яковлевна елмаеп кына куя, семинарда катнашучылар дәррәү көлеп җибәрәләр.

Мин батырлыгымны җыям, ихтыярымны туплыйм да:

— Әйе, ул хис бар миндә,— дим.

— Бик яхшы, нәкъ менә шуны белү кирәк тә иде миңа, — ди Берта Яковлевна йомшак бәрхет тавышы белән. Ул моны җитди итеп әйтә.

Семинардагы яшьләр мин язганнарны «тетә» башлыйлар. Әсәрнең башта эчтәлеге ачылып җитмәгән, автор бәя бирергә ашыккан, шигырьдәге лириклыкны яки эпиклыкны башта ук күрсәтеп бирергә ки-

рәк, комплимент яудыру күбрәк түгелме икән «Намус» романына?.. Әнә шундый сүзләр, әнә шундый кимчелекләр. Эчтәлеккә карата әйтелгән кимчелекләрне мин игътибар белән тыңлыйм, телгә карата әйтелгәннәрне колак яныннан шудырып кына җибәрәм. Чөнки әлеге тикшерелә торган мәкаләләрнең теле мин язган тел түгел, ул тәрҗемә, өстәвенә әдәби тәрҗемә дә түгел, подстрочник, ягъни сүзгә-сүз, бер тиенгә бер тиен тәрҗемә.

Малайлар ярсынып туктыйлар. Семинар җитәкчеләренең сүзен көтәбез. «Знамя» журналыннан килгән бер ханым минем мәкаләләргә уңай бәя бирә: автор күзәтүчән, әдәби әсәрнең тукымасын тоя, фикерен анализдан соң әйтеп бирә. Өметле каләм. Илгә мондый тәнкыйтьчеләр кирәк, ди. Кимчелеге: татар әдәбиятын ил күләмендә ирешелгән уңышлар фонында тикшермәү, ди.

Мин аның соңгы фразасын чыкмаган мыек очыма чорнап куям, акыллы сүз әйтте бит әле бу ханым.

Тагын ике кеше, берсе «Дружба народов» журналыннан, берсе Әдәбият институтыннан минем мәкаләләрне бик җентекләп тикшерәләр. Нигездә уңай бәя бирәләр, начар гына тәрҗемә аркылы да авторның темпераменты, битараф булмавы сизелеп тора, диләр. Моңысы минем эчкә тагын да күбрәк җылы кертә.

Ниһаять, сүз Берта Яковлевна Брайнинага җитә. Ул йомгак ясарга тиеш. Мин, аның авызыннан чыккан һәр сүзне йотып алырдай булып, аңа төбәләм. Ул — күренекле тәнкыйтьче, «Константин Федин» дигән монографик китабы өчен СССР Дәүләт премиясе алган кеше. Әнә шул хәл безнең аңа карата булган ихтирамыбызны тагын да арттыра төшә. Димәк, ул әйтсә, хак әйтә инде.

— Мин Ахунов иҗатына өмет баглыйм һәм аның киләчәген зур итеп күрәм, — дип башлап китә Берта Яковлевна. — Без утырган бүлмәдә кинәт бик тын булып кала. Мине «теткән» яшьләр Берта Яковлевнага төбәләләр. Ә минем умыртка сөяге турысындамы, кайдадыр бер нәрсә сулкылдап бәрә башлый, йөрәк шашынып бугаз турысына менеп җитә. Мин көч-хәл белән тынычланам. Шундый зур киңәшмәдә шундый олы сүзләр әйтсеннәр әле сиңа!—Әйе, зур итеп күрәм мин аның киләчәген. Аңарда кыюлык бар, әдәбиятны ярату бар, үзенчә итеп язарга, фикерләрен яңача итеп әйтеп бирергә омтылу бар. Никтер минем аңар карата симпатиям уянды, ни хикмәттер, минем аның кимчелекләрен хәтта әйтәсем дә килми башлады. Сез, Ахунов, башка жанрларда да эшләмисезме?

— Нигә? Хикәяләр язгалыйм.

— Шулайдыр дигән идем аны. «Намус» романын сез тәнкыйтьче булудан бигрәк, хикәяче булып тикшерәсез. Мин моны начар дип әйтергә теләмим, мин моны мактыйм. Сез телнең җегәрен тоясыз, телгә карата дөрес фикерләр әйтәсез. Әмма сезнең монда, тәнкыйтьче буларак, җыйнап әйткән фикерегезне күрмим мин. «Намус»ны русчага беренче мәртәбә Надежда Чертова тәрҗемә иткән иде, ул китап татарчасыннан югарак булып чыккан. Бу нәрсә? «Намус» көпшәк булган дигән сүзме, әллә тәрҗемәче авторны кыркыганмы? Миңа калса, Гомәр Бәшировта, гомумән татар әдәбиятында бизәк ясау, купшы язарга омтылу кимчелеге бар. Аны бит без, тәнкыйтьчеләр, әйтеп бирергә тиеш. Юкса ул кимчелек артып, күпереп, әдәбиятның чиренә әйләнеп китүе ихтимал. Шуңа күрә мин сездән, иптәш Ахунов, таләпчәнлекне арттыруыгызны, критерийларны ил күләменнән чыгып куюыгызны сорар идем.

— Беләсезме, Берта Яковлевна, төрки телләре бит шатырдатып кысканны күтәрә алмый. Татар телендә дә шулай. Безнең тел — моңлы тел, бизәкле тел, — дим мин. — Бездә буш конструкцияне укучы бөтенләй дә кабул итми. Татар теле, хәтта прозада да җыр теле

булып кала. Тәрҗемәчеләр әнә шуны аңлаган сурәттә генә татар язучыларының яхшы әсәрләрен русчага бөтен матурлыгында бирә алачаклар.

Берта Яковлевна уйга калды, башын селеккәләде һәм минем белән бу хакта аерым сөйләшергә теләвен әйтте. Аннары ул:

— Тагын бер киңәшем, монысы бер Ахуновка гына түгел, барыгызга да кагыла: әсәргә мәкаләгезнең беренче юлыннан ук бәя бирә башламагыз. Иң әүвәл, мөмкин кадәр кыска итеп, әмәлен табып, әсәрнең эчтәлеге белән укучыны таныштырыгыз,—диде.

— Әсәрне инде укучы белсә дәме?

— Белсен. Әгәр сез башта әсәрнең үзен бирмәсәгез, буш урынга сөйлисез булып чыга, минә шуннан башлана да инде авторга комплимент яудырулар. Яки аны тиешсезгә тиргәүләр. Бу беркадәр Ахуновта да бар, әмма мин укыган башка мәкаләләр арасында, Ахунов ул яктан аерылыбрак тора. Ул эчтәлекне укучыга аңлатмый торып, бәя бирә башламый.

Без бүген тикшергән мәкаләләрнең авторы үзенең күзәтүләрен поэзия өлкәсендә дә, проза өлкәсендә дә алып бара. Мин моны, әлбәттә, авторның гаебе дип күрсәтергә теләмим, ләкин, шулай да бер өлкәне, әйтик, поэзияне, прозаны, яки драматургияне үзләренеке итеп алган тәнкыйтьчеләр, бер өлкәдә специальләшкән иптәшләр зуррак уңышка ирешәләр.

Соңгы сүзем итеп шуны әйтәм: мин бу семинарда катнашкан кешеләрне югалтырга теләмәс идем. Сез, Ахунов, язган яңа әсәрләрегезне миңа җибәреп торырга вәгъдә бирәсезме?

— Бирәм, — дидем мин. Ышанып әйттем.

Ләкин аңардан соң егерме биш елдан артык вакыт узды инде, мин Берта Яковлевнага бер мәкалә дә җибәрмәдем. Җибәрмәвемнең сәбәбе шул: әдәбиятта мин тәнкыйтьне төп жанрым итеп сайламадым. Проза мине бөтенләе белән йотып алды. Әмма яшь тәнкыйтьчеләрнең беренче Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашу эзсез калмады, миңа үз әсәрләремне язганда да, журналда ун ел буе эшләгән чакта да, татар совет әдәбияты хакында съездларда (үзебездә генә түгел, Мәскәүдә дә) докладлар сөйләгәндә, чыгышлар ясаганда да, бик нык ярдәм итте. Киңәшмәдән соң үземдә әдәби зәвык тәрбияләүне мин иң беренче бурычым итеп куйдым. Әдәби әсәрләргә бәя биргә аеруча җаваплы карый башладым.

Берта Яковлевна белән без аннан соң байтак очраштык. Ул һаман да шундый ук ягымлы, сипкел битле, кулына эре гәрәбәдән тезгән беләзек киеп йөри, милли әдәбиятлар үсеше белән өзлексез кызыксына.

## Юлдашлар

Әнвәр Давыдовның кордашы, аның кебек үк фронтовик, әмма иҗат эшенә аңардан да иртәрәк тотынган бер шагыйрь бар безнең татар әдәбиятында.

Аның исеме инде без мәктәптә укып йөргән елларда ук билгеле иде. Сугышка кадәр ул арадаш рифма белән шигырь язып танылды һәм унҗиде яшендә үк беренче китабын бастырып чыгарды.

Сугыш елларында аның «Тупчы Вәһап» поэмасы, окоп лирикасы басылып чыкты. Усалларның да усалы Гали Халит аның поэзиясенә карата иң яхшы, иң җылы сүзләрне әйтте.

Иҗаты белән дә, яшәү рәвеше белән дә беркемгә дә охшамаган ул кеше Шәрәф Мөдәррис иде. Талантлы шагыйрь, хикәяче, минә дигән очеркист, кайнар җанлы публицист, үз туган теленнән тыш русча, чу-

вашча, инглизчә, немецча, французча сөйләшә һәм шул телләрдән туры-дан-туры тәрҗемә итә белә торган әдип иде ул. Иа туры да сүзле кеше иде соң! И дә ихлас күңелле, нәрсәгә генә тотынса да җаны-тәне белән бирелеп эшләүче иде.

Трибунага менсә, башкалар кебек чәчне җайлап, артка сыпырып тормас, куе калын чәчләрен алга таба ишеп төшерер дә күңелдәгесен ишә башлар. Бунтарь йөрәк, тынгысыз йөрәк Шәрәф!

Республика газеталарында, журнал битләрендә аның әле фронтовик татарлар турында, әле хезмәт алдынгылары турында, әле илебезнең җиңүле адымнары турында очерклары, публицистик мәкаләләре басылып торды. Фельетоннар, дусларча шаржлар, пародияләр, сатирик хикәяләр язарга да бик оста иде ул.

Аның «Әбдүш Ялаяп» дигән хикәясе буенча кемдер бераү аны судка биргән иде. Актыктан «Комсомольская правда» газетасында «Яла ягучы үзен таныды» дигән фельетон басылып чыкты.

Рус әдәбиятында Сергей Орлов, Сергей Наровчатов, Михаил Луконинны, Михаил Львовны һәм тагын берничә шагыйрьне эченә алган фронтовик шагыйрьләр буыны бар. Аларның байтагысы дөнья куйды инде. Танкта янган Сергей Орлов та, кайнар җанлы Михаил Луконин да хәзер вафат. Безнең татар совет поэзиясендәге фронтовик шагыйрьләр буыны да сирәкләнеп калды. Гамир Насрый 43 яшендә, Шәрәф Мөдәррис 44 яшендә, Әнвәр Давыдов белән Зыя Мансур 49 яшендә, Гали Хуҗи 54 яшендә дөнья куйдылар.

Алар фронтта да, фронттан кайткач та шагыйрьләрчә яшәп, шагыйрьләрчә көрәшеп, авырлыкларны җиңеп, халыкка талантлы әсәрләр калдырып үлделәр. Аларның гомере, аларның иҗаты онытылмаска, халыкка җиткерелеп торырга тиеш.

Шәрәф Мөдәррисне мин, Әнвәр Давыдов кебек үк, якыннан белә идем, шуңа күрә аның иҗат портретына бер генә штрих булса да өстәлсен дип, бу китапка аның белән үткәргән бер сәяхәтем хакында язарга булдым.

1955 елның җәй аенда минем янга, «Совет әдәбияты» редакциясенә, Шәрәф Мөдәррис килеп керде.

— Эшлисенме, канәтым? — диде мишәрчәләп. Мишәр булса да, мишәрчә сөйләшми иде ул, бу юлы юри мишәрчәләп «канәтым» диде.— Эшлисең алайса? Эшлә, эшлә, ә мин сине тагын бер шәп эшкә димләргә дип кергән идем.

— Нинди эш ул, Шәрәф абый?

— Мин сине авылларга алып чыгып, бер-ике атна тузаныңны коеп кермә келим. Цыгасыңмы?

— Бик чыгар идем дә, минем бит әле баш кешем бар, Гази абый ни-әйтер бит?

— Эш аңа гына терәлсә, сүләшәбез аны. Әйдә, канәтым, керәбез икәү.

Ул мине җилтерәтеп Гази Кашшаф янына алып керде, ике генә сүз белән, ялынып-нитеп түгел, дорфа итеп тә түгел, әллә ничек кенә җаен китереп, йомышын әйтеп бирде.

Гази абый риза булды да куйды бит, әй.

— Түлке, кара аны, минем егетне ялгыш юлларга алып кереп китә күрмә, тупчы Ваһап!— дип елмаеп куйды Гази абый.

Безгә командировка кәгазе бирделәр, ул чактагы акча белән уч тутырып акча бирделәр һәм без, «кәҗә белән сарык, капчыкларга бүре башын салып», сәяхәткә чыгып киттек.

Китүебез Кукмара ягына булды. Поездга утыруга Шәрәф абый миңа төбәп карап алды да кесәсеннән ике төргәк акча чыгарды:

— Син безнең ике кешелек партизан отрядының интенданты булырсың. Менә сиңа — командировка акчасы, менә сиңа — Ләбибә

абыстаңа әйтми алган акча. Мин синнән азактан хисап-мазар сорап тормам, тамак тук, өс бөтен булса, борыннан чыккан тотен булса, шул житкән миңа, — диде. Ул бу хәтлесен ифрат та житди, хәтта караңгы чырай белән диярлек әйтте, аннары сирәк тешләрен күрсәтеп көлеп куйды: — Кыскасы шул, әгәр унбиш көн йөргәннән соң кайткан чакта юлга бер яртың булса, мин сине, канатым, интендант хезмәтен яхшы башкарып цыккан солдат дип исәпләрмен...

Юлда без сөйләшеп бардык. Чуваш халкының бөек шагыйре Константин Ивановтан тәржемә иткән «Нарспи»ны аның үз авызыннан ишетү кызык иде. Андагы вакыйгаларның мавыктыргыч булуына, шигырьнең җыр кебек агылып торуына мин әсәрне үзем укыган чакта да игътибар иткән идем. Шул поэманы аның миңа соңгы елларда тагын бер кабат, һичбер иренмичә, карап чыгуын, тәржемәне камилләштерүен күреп, Шәрәф Мөдәрриско ихтирамым арта төште. Бу ихтирамны аның поэманы яттан белүе тагын да арттырды...

Кукмарада без атна буе тордык. Өчме-дүртме колхозда булдык. Райком секретарьларын, колхоз председательләрен, бригадирларны, ферма мөдирләрен күреп сөйләштек, печәнчеләр янына болынга, көтүчеләр янына урманга бардык. Ул чорда колхоз председательләрендә җиңел машиналар юк иде әле, алар, зәңгәр төтен төчкертеп, мотоциклларда чабалар һәм, үзләренчә әйткәндә, шул «матайларына» безне дә утыртып йөриләр иде. Шәрәф абый «матайның» бишегенә утырырга теләми, күбесенчә мине утырта, ә үзе председательнең артындагы утыргычка сикереп менеп ала да чәчләрен җил иркенә куя иде.

Атна буена әнә шундый «матайларда» без басу юлларыннан ким дигәндә мең чакрым узганбыздыр. Кукмара ягында таулар күп, без ул тауларга җилдән җитез мөнеп китәбез, ул таулардан өермәләр уйнатып төшәбез, кыскасы — ирекле кошлардай, дөньяның астын өскә китереп йөрибез.

Каләмдәш иптәшләре аны талантлы диләр иде. Аның «Биш минут», «Яшел полоса», «Кызыл мәйдан», «Тупчы Ваһап» поэмаларын, окоп шигырьләрен мисалга китерәләр, аның туп-туры инглизчәдән Шекспир сонетларын, немецчадан Һейне шигырьләрен гаҗәп оста тәржемә итүен сокланып сөйлиләр иде. Ләкин аны берәү дә очерк остасы дип мактамый иде. Менә бу юлы мин аның очерк остасы икәнен дә күрдем.

Кукмара эшчәннәре турындагы очеркны без ике имза белән чыгарырга булып, материалны тигез бүлеп алдык. Иң әүвәл без аның исемен табарга, тик шуннан соң гына яза башларга тиеш идек.

— Исеме «Таудан тауга» булыр, —диде Шәрәф Мөдәррис. — Беренчедән, без физик рәвештә таудан тауга чабып йөрдек. Икенчедән, партия Үзәк Комитетының 1953 елгы сентябрь Пленумыннан соң колхоз авылында булган үзгәрешләрне без үз күзебез белән күрдек. Моны таудан тауга күтәрелү дип әйтү дөрес булыр шикелле. Син шуңа ризамы, канатым?

— Риза, бик әйбәт исем.— дидем мин.

Очеркны без, гостиницада утырып, ике көн яздык. Дөресрәге, үз өлешемә тигәнне мин ике көн яздым, Шәрәф абый үз өлешенә тигәнне ярты көндә язып ташлады да Кукмараны карарга, китап кибетләрен актарырга дип чыгып китте. Мин, әлбәттә, бер сүз дә әйтмәдем. Үземнән алты яшька олы кешегә, өстәвенә инде әдәбиятта исеме танылган кешегә сүз әйтү кыен иде. Тик борчыла башладым. Шул ярты көн эчендә ул унбиш битне яза алды микәнни? Язуын, бәлки, язгандыр да, ләкин бит әле сыйфат мәсьәләсе бар. Без бит газета репортажы язмыйбыз, без «Совет әдәбияты» журналына әдәби очерк язабыз. Гази ага Кашшаф бит безне кисәтеп чыгарды. Әдәби очерк алып кайтмасак, без редакциягә кайтып та кермәскә тиешле.

Шулай борчылып утырган чагында, кулына бер көчак китап күтәреп, бите-башы белән сөенеп, Шәрәф абый кайтып керде.

— Я, канатым, язып бетердеңме?— диде миңа.

— Юк әле, — дидем мин. — Алай тиз генә язылмый бит ул.

— Ялгышасың, дустым. Яхшы әйбер тиз языла, үзеннән-үзе языла, йә синең тәҗрибәң юк, йә очерк материалы күңелеңә сеңеп бетмәгән әле,— диде ул миңа.

— Соң бит әле сез дә, тәҗрибәле язучы да, язып бетермәдегез.

— Мин бетердем.

— Укып күрсәтегез.

Ул өстәл янына килеп утырды, җилләнеп өстәлдән кәгазьләрен алды һәм укый башлады. Мин шаккатып калдым. Очрашкан чакларда, председательләрдән, бригадирлардан, терлекчеләрдән мин сорашып-язып йөргәндә, фактларны, саннарны, кеше исемнәрен блокнотыма теркәп барган чакта, ул исе китмәгән сымаграк йөргән иде, карасана бер, ниндиләр итеп язган! Хисләре дә, табигать тә, кешеләр дә бик матур кереп утырган бит моның язмаларына.

— Туктале, Шәрәф абый, син ничек боларны хәтереңдә калдырдың да, ничек аларга үз сүзең таптың? — дидем мин.

— Фронттагы кебек эшләргә кирәк, канатым, — диде ул миңа.

— Ә фронттагы кебек ничек була?

— Бервакытны фронт газетасыннан безне, ике журналистны, алгы сызыктан кайткан кешеләрне күрергә, интервью алырга җибәрделәр. Бар булганы сәгать ярым вакыт бирделәр. Теләсә кемнән интервью алырга була, әлбәттә, сәгать ярымда да өлгереп була, әмма бит миңа татар сугышчыларыннан, минем иптәшкә казакъ сугышчыларыннан интервью алырга куштылар.

Киттек без эзләп. Минем иптәш ярты көн йөреп тә берни алып кайта алмады. Ә мин бер сәгать эчендә өч кешедән интервью алып кайттым.

— Хикмәте?

— Хикмәте шул. Киттем сорашырга: алгы сызыктан кайтканнар бармы?

— Бар, — диләр.

— Кайда алар?

— Кайсы йоклый, кайсы мунчада.

— Әһә, мин әйтәм, миңа иң кулае мунча. Барып кердем, буй-сыннарына бер күз сирпеп алуга, кайсы татар икәнен аңладым. Шундук сөйләшеп тә чыктым, язып та бирдем сөйләшүне. Газета редакторы шаккатты. Ә икенче иптәшем ярты көн йөреп тә казакъларны таба алмый кайтты. Менә шулай, канатым, яшь шул әле син, фронт шартларында эшләп караганың юк...

Без тагын бер көннән Киров өлкәсенә, халык телендә әйткәнчә, Нократ якларына чыгып киттек. Шөн авылына килдек. Нигә безнең монда килгәнне Шәрәф абый башта әйтмәде, сер саклады. Килеп төшкәч белдем, бу аның хатыны, язучы Ләбибә Ихсанованың туган-үскән җире икән. Ләбибәнең әниләре — укытучылар шушында яши, университет бетереп укытырга киткән Эдуард Касыймов та шушында яши икән.

Бу якларга килеп чыгуыбызга мин бик сөендем. Монда әллә нинткән кырыс матурлык бар. Төз чыршылар монда авыл уртасында һәм кырларда төркем-төркем булып үсә, саф сулы Вятка — төньяк гүзәле монда агып ята, табигать сокландыгыч матур иде.

Шөндә без өч көн тордык. Биредә Шәрәф абыйның тагын бер бик әйбәт сыйфаты ачылды. Ул иртән кулына чалгы тота да колхозчылар янына китеп бара. Алар белән бергә кукуруз чаба, алар белән рәхәтләнеп сөйләшә, аларның мәзәк сүзләрен тыңлый, ял минутларында

яңа шигырьләр укый, уртак табынга утырып ашый, алар аңардан, Шөн киявеннән бик тә канәгать иделәр.

Шул өч көн эчендә мин дә Шәрәф абый белән кукуруз чабарга йөрдем. Рәхәт чалгы селтәүләре! Рәхәт халык белән бергә күмәк табында утырып ашаулары! Сугышка кадәрге чорда, авылларда печән өсләрен нинди күңелле итеп каршы ала торганнар иде. Атларның йөгәннәренә, шлеяләренә җиз тәңкәләр тезеп чыгарлар иде. Дугаларны алма бизәкле итеп буятырлар иде. Аннары сиртмәле арбаның ике ягына тезелеп бер-берсенең җилкәләреннән алган егетләр, су буйларын яңгыратып тальян гармунга җырлый-җырлый, болын тугайларына китәрләр иде. Баш өстендә, кояшта чалгылар ялт-йолт ялтырар иде. Болын тулыр иде кызлар белән. Андый җырга, андый тамашага нинди кызның йөрәге түзсен ди!

Шәрәф абый, Шөн кешеләре белән кукуруз чабарга йөреп, миндә әнә шул үсмер чак истәлекләрен кузгатты.

Аннары без өчәүләп, Шәрәф абый, мин, Эдуард язын уйсу җиргә кереп калган Вятка култыгыннан балык тоттык. Тәтәлле җәтмә белән без ике-өч сәгать эчендә бер чиләк балык тотып кайттык.

Шәрәфнең әбисе белән бабасы һәм Венера исемле балдызы, балыктан уха пешереп һәм аны бик тәмләп кыздырып безгә бәйрәм ясадылар.

Иртәгесен без юлга чыктык.

Вагонда без бик күп итеп әдәбият турында сөйләштек. Шәрәф абый миңа «Биш минут» поэмасыннан, «Кызыл мәйдан»нан өзекләр укыды. «Тупчы Ваһап»ның ничек язылганын сөйләде.

Мин аның Икенче Белорус фронтының татар сугышчылары татар халкына шигырь белән язган коллектив хатның авторы икәнен белә идем. Ул хатның ничек язылу тарихын сорадым.

— Ничек язылды дисеңме? Мин аны, дустым, менә хәзер шушы җирдә атып үтерәм дип әйт, ничек язылганын әйтеп бирә алмыйм. Фронт ул шундый бер хикмәт, анда хис бер кабынып киттеме, пожар ялкыны кебек, бөтен кешене чолгап ала. Без, сугышчылар, дошманны кырып салу, җирләребезне азат итү уе белән шулхәтле дә кабынган идек, табигыйдыр ки, мин дә ул хистән читтә кала алмый идем. Мин аны көчәнеп язмадым, бер сулыштан яздым, сугышчан бурычны үтәгән чакта ничек ашкынып алга барасың, мин әнә шундый халәттә идем. Миңа аннары барлык фронтларда татарларның гел данлы эшләр эшләве, Илья Эренбургның татар сугышчылары хакында язган мәкаләсе тәэсир итте. Шулар барысы бергә җыелгач, мин дәртләнеп-канатланып ул хатны яздым. Аны фронтта татар сугышчыларына укыдылар, ул хат әле газеталарда басылмас борын ук меңнәрчә сугышчыны рухландырып йөрде...

Ул бик җитди итеп миңа карады:

— Әйдә, дустым, Мусалар, Фатихлар, кайтмый калган солдатлар рухына бераз тын гына утырыйк! —диде.

## Яшьлекнең яме нәрсәдә?

1955 елның башында мин, ниһаять, «Яшьлек яме»н язып бетердем. Бу минем күләмле беренче әсәрем иде. Студентлар тормышыннан Яшьлеккә шаулап яшәү хас. Кавказда мин сикерә-сикерә аккан тау елгаларын күреп кайткан идем. Шуңа күрә беренче юлларын язган чакта ук мин повестема исемне «Тау елгасы» дип кушарга уйладым. Шул исем белән яшьләр газетасында 1954 елда өзекләр дә бастырган идем. Әмма азактан әсәрнең исеме үзгәрде. Үзгәрүнең сәбәбе гади: Нурихан Фәттах, минем каләмдәш, миннән бер ел алдан университет

тәмамлаган кеше, ул исемнән кычкырып көлде. Ул да шул елларны «Сезненчә ничек?» дигән роман тәмамлаган иде. Аның да романы студентлар, җитмәсә Казан университеты студентлары тормышыннан иде. Ул чакта бездә юмор хисе, бер-беребезне үртәшү хисе бик көчле иде. Нурихан минем повестьның «Тау елгасы» дигән исемен «Тавык елгасы» дип атады. Ә бит бу — сай елга дигән сүз. Шуннан соң мин повестема карата яңа исем табарга тиеш булдым, шул хакта сабакташларыма әйтеп, конкурс ачтым. Бер коньяктан. Сабакташ һәм каләмдәш егетләр миңа күп төрле исемнәр әйтеп карадылар. Берсе дә ошамады. Миңа ошаганын, «Яшьлек яме» дигәнен шагыйрә Гөлшат Зәйнашева табып бирде, ул миннән коньяк таләп итмәде, бер тартма Мәскәү конфетына риза булды.

Язучылар арасында бер-береңнең әсәренә исем табышу гадәте бар. Әдип Маликовның балалар өчен язган бер поэмасына «Таңбатыр» дигән исемне, Сибгат Хәкимнең КамАЗ заводын төзүчеләр хакындагы поэмасына «Дәверләр капкасы» дигән исемне мин табып бирдем.

«Яшьлек яме» дигән исемнең минем күңелгә хуш килүенә сәбәп бер: ул әсәрнең эчтәлегенә тулысынча туры килә. Яшьлекнең яме нәрсәдә? Хыялланып яши белүдә. Яшьлектә кешенең матди байлыгы булмый, аның бердәнбер хәзинәсе — күңел байлыгы, намусы. Әнә шул намусны яшьтән үк саклый белсәң, хезмәтне үзеңә юлдаш итеп алсаң — бәхет синнән ерак йөрми. Мин шуны әйтергә теләдем.

Ләкин бит әле теләү бер нәрсә, шуны сәнгать чаралары белән, образлар аркылы ачып бирү бөтенләй икенче нәрсә. Әсәремне язучыларның проза секциясенә куйган идем, минем повестьны тетеп кенә салдылар.

Әйтелгән сүзләрнең һәммәсе, йөз проценты белән дөрес булгандыр дип уйламыйм. Сөйләүче дә хискә бирелүчән була, бәлки, алар да арттырып җибәргәннәрдер. Әмма мин үзем әнә шул «арттыру» дигән якка бик тә бирелүчән кеше икәнмен, фикер әйтүчеләргә чамадан тыш ачуым чыгып, повестьның кульязмасына борылып та карамаска, аны чүплеккә чыгарып атарга ният кылдым. Күңел төште.

Менә шунда миңа ярдәмгә Шәһидә килде.

— Мин бит синең хатының гына түгел, университетта бергә укыган, авыр чакларны бергә үткәргән сабакташың да әле, — диде ул. Бу аның үзенчә бик яратып, кат-кат әйткән сүзе булганга дәшмәдем.— Әгәр син шушы повестька кул селтәсәң, әйтәчәкләр, әй, ул да йөрде язучы булам дип! Баксаң-күрсәң, буш куык икән, ике авыз тәнкыйть сүзе ишеткәнгә, чыгымчы ат кебек, тәртәгә тибеп йөри, диячәкләр. Ул гынамы?! Синең үзеңдә үк үзеңә карата ышану тойгысы сүнәчәк. Ышанмау — ул беттем дигән сүз. Син бит дөньяда аннан да зуррак кыенлыкларны күргән кеше! Хәзергә син кульязмаңны куеп тор. Ял ит бераз. Аннары алырсың, әйткән сүзләрен, язып барган булсаң, аек акыл белән үз бизмәнеңә салып, үлчәп карарсың, кирәген алырсың, кирәк түгелен алмассың. Әсәргә бит алар түгел, син хуҗа, төзәтергә дә, төзәтмәскә дә синең генә хакың бар.

Бу сүзләр мине тәмам тынычландырды.

Ул арада, һава суларга чыккан чагында, Ибраһим ага Гази да Шәһидә әйткән үк сүзләрне куәтләде:

— Тәнкыйть ул — гөберле бака. Салкын ул, каһәр төшкересе! Чиркандыра. Аны тизрәк муеннан алып ташлыйсы, хатыныңның җиңенә күз яше түгеп, үзеңне кызгандырасы килә. Син, Гариф энекәш, әйбәтләп бер ял ит. Яшь кешегә повесть чаклы повесть язып чыгу уен эш түгел. Өстәвенә бит әле син көне-төне журналда эшләдең. Шул вакыт эчендә әллә ничә очерк, әллә ничә тәнкыйть мәкаләсе яздың бит әле син, докладлар ясадың. «Иөзмә станица» дигән роман да тәрҗемә иттең түгелме?

— Антон Макаренконың «Педагогик поэма»сын да тәрҗемә итеп утырам әле мин.

— Менәтерәк! Шулай булгач, синең бер дә язмышыңнан зарланырлыгың юк. Яшь тәнкыйтьчеләр киңәшмәсеннән дә олы сүз әйтеп кайтарганнар дип ишеттем. Сабыр бул, сабыр. Нервыларыңны урынына утырт та, яңадан бер мәртәбә үз эшеңә читтән карап, төзәтеп чык. И җүләр, синең яшеңдә без гүпчим дә яза белми идек әле, тел юк иде безнең, капшанып кына бара идек. Синең, шөкер, югары белемең бар, сиңа бары тик изгелек кенә теләп торучы без — абзаңнар бар. Тәртәгә тибеп йөрүеңне ташла, и давай җиң сызганып...

Вакытында, нәкъ кирәкле сәгатендә киңәш бирүчедән дә изгерәк кеше бармы икән?! Чыннан да, атна-ун көннән минем нервылар урынына утырды, мин салкын кан белән тәнкыйть фикерләрен карап чыгар хәлгә килдем һәм шуларның туксан процентын дөрес дип таптым.

Гази абыйдан ике айга үз исәбемә ял сорап алдым да, бер генә көнемне дә әрәм итмичә, повестьны өр-яңадан күчереп чыктым.

Ул елларда яшьләрне тәҗрибәле, өлкән язучыларга беркетү гадәте бар иде. Мине Мирсәй абый Әмиргә беркеткәннәр иде. «Агыйдел»еннән башлап барлык әсәрләрен укып барганга һәм язучы буларак бик ихтирам иткәнгә, аны мин үзем сораган идем. Мирсәй абый минем повестьның өр-яңадан күчереп, шуннан соң машинкада бик пөхтәләп бастырганын укып чыккач:

— Монда мин ярдәм итәр нәрсә күрмим, Гариф. Син инде ике аягыңа да баскансың. Телең табигый, вакыйгаларың ышандыргыч, тормышча, бик җылы язылган. Тирәнлек ягы... анысы — тәҗрибә белән килә торган нәрсә, болай булгач, озакламый тирәнлеге дә булыр,— диде.

Гази ага Кашшаф та хуплады минем әсәрне. Һәм ул 1955 елның азакларында «Совет әдәбияты» журналының 10—11—12 саннарында басылып та чыкты.

Повесть журналда басылып чыгу белән миңа яшьләрдән хат килә башлады. Татарлар илнең төрле тарафларында яшәгәнлектән, хатлар Казаннан гына түгел, республика районнарыннан гына түгел, Урта Азиядән дә, Уралдан да, башка урыннардан да киләләр иде. Мине аеруча дулкынландырганы Якутиядән килгән хат булды. Яшь кенә бер кызны медицина институтыннанмы, техникумнан соңмы Якутиягә җибәргәннәр. Врачлар аз, туксанышар-йөзәр чакрымга авырулар янына барырга туры килә икән кызыкайга. Бу моңар котөчкыч авыр тоелган, күңелен биздерә башлаган һәм ул, киредән Казанга кайтып китәргә ният кылып, әтисенә хат язган. Әтисе моңа җавап итеп минем «Яшьлек яме» басылган журналларны җибәргән. Кызый миңа повестем өчен рәхмәт әйтә, чөнки ул мине авырлыкларны җиңәргә өйрәтте, батыр холыклы булырга юл ачты, мин Якутиядә торып калдым, ди.

Укучылардан минем, башка каләмдәш иптәшләрем кебек үк, бик күп хатлар алганым бар. Әмма Якутиядән килгән төсле дә рухландыргыч хат алганымны хәтерләмим. Менә шул чагында мин әдәби әсәрләрнең кызык өчен генә, эчпошканнан гына языла торган нәрсә түгел, кешеләргә тормыш юлдашы булырдай нәрсә икәненә ышандым. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, язучылык эшенең ифрат та кирәкле, файдалы эш икәненә тулысынча ышандым. Шуннан соң бернинди тәнкыйть тә, кимчелекләремне зурайтып, купайтып әйтүләр дә мине куркытмады, язу эшеннән аера алмады.

Минем белән бергә әдәбиятка килгән талантлы шагыйрь һәм бик таләпчән редактор Хисам Камал, шушы повестьның китап булып чыккан чагындагы редакторы (ул нәшриятта эшли иде), әсәр инде жур-

налда басылып, уңай бәя алган булуга, авторга укучылардан күп кенә хатлар килүгә дә карамастан, повестьның бер олау кимчелеген тапты, таләпне бик зурдан куйды. Ул миннән әсәр геройларының эш-гамәлләрен аклап җиткерүне таләп итте. Бәхәсләшеп торырга урын юк, фикерләре төпле иде, повестьны тагын бер мәртәбә күчереп чыгарга, айлар буе җиң сызганып эшләргә туры килде. Зур күләмле әдәби әсәр язу чирканчыгын мин әнә шул «Яшьлек яме» повестенда алдым.

## Киңәшле дөнья

«Яшьлек яме»н язган чакта миңа ярдәм иткән тагын бер язучы булды. Ул — Хатип ага Госман. Дөресен әйткәндә, мин аны якыннан белми идем. Без университетта укыган елларны ул growth педининститутта эшләде, университетка бары тик 1951 елны гына, безгә китәргә бер ел кала гына килде. Мин аңа «Яшьлек яме»нең кулъязмасын бирдем. Ул ни әйтер икән дип көтә башладым. Әмма, икәүдән-икәү генә очрашып сөйләшә башлагач, мин кулъязманы онытгым. Хатип Госманның шәхес булуы, әдәбият турында зур каланчадан торып фикер йөртүе минем күңелемне билəп алды. Мин аңарда тау-тау булып әдәбият байлыгы, фикер байлыгы өелеп ятканны күрдем, аның әдәбиятка килү юлы да минем өчен бик тә гыйбрәтле булып тоелды.

Пермь өлкәсенең Сулмаш авылында тугыз балалы гаиләдә туган ул. Әтисе урта хәлле дип саналган. Крестьян эше генә ишле гаиләне туйдырып барырга җитмәгән, күрәсең — кыш көннәрендә Госман агай Бөредән Осоуга йөк ташыган. Беренче бөтендөнья сугышы чыгар алдыннан Казан белән Екатеринбург (хәзерге Свердловск) арасында чуен юл салу башлангач, әтисе кыр эшләреннән бушаган арада, олы уллары ияртеп, җир казырга йөргән. Госман агай русчаны иркен сөйләшкән, күрше рус авылларында дуслары булган, укый-яза белгән. Бу гаиләдә Тукай шигырьләрен укыганнар. Шигырь яратучылар гаиләсендә туып-үскән язучылардан мин гомер буе көнләшәм, аларны бәхетле язучылар дип саныйм. Алар беренче буын интеллигент түгел, икенче буын интеллигент. Аларга барысын да, тырышып-тырмашып, хәтта черәшеп диярлек яңа баштан башларга туры килми, алар әдәбиятка эстетик яктан әзерлекле кешеләр булып киләләр.

Бу җәһәттән Мәскәүдә 1953 елны үткәрелгән Бөтенсоюз яшь тәнкыйтьчеләр киңәшмәсе янә дә исемә төшә. Берта Яковлевна Брайнина семинар җитәкчесе булганнан соң, мин аның СССР дәүләт премиясе алган «Константин Федин» дигән китабын бик җентекләп укып чыктым. Константин Александрович Федин 1914 елны, 22 яшендә, немец телен камилләштерү өчен, Германиягә китә. Автобиографиясендә Федин болай дип яза: «Эти миңа җәйге айлар өчен, гадәттәге кырык сум урынына илле сум акча бирде — бу акча миңа Германиягә барырга һәм анда яшәргә мөмкинлек тудырды».

Кызыгам мин Константин Фединның 22 яшендә үк инде Европаны күрә башлавына, аның шуңа әтисе тарафыннан шартлар тудырылуына. Европага мин әле нибары 51 яшемдә генә чыга алдым. Анда да күңел офыкларымның киңәеп киткәнен, дөньяга карашымның ныгыганын сиздем. Миндә ике төрле җәмгыятьне чагыштырып карый алу мөмкинлеге туды. Социализм җәмгыяте тудырган мөмкинлекләрнең кадерен белеп җиткермәвебезне аңладым. Бу сәяхәт ник моннан утыз ел элек булмады икән, дип үкендем.

Федингә әйләнеп кайтыйк. Башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышы Фединны туган җиреннән еракта торгызып калдыра. Аны Германиядә гражданлык әсирлегендә Брест солыхы төзелгәнче тоталар.

Нюрнбергтагы шовинистик демонстрацияләрне күрү, сугыш башланган көнне башта Дрезденга сөрелеп, аннан Циттау шәһәренә кителүе, андагы тормышы, ниһаять, Россия гражданнарын 1918 елның азагына немец әсирләренә алмашу — бу вакыйгаларның барысы К. Фединның «Шәһәрләр һәм еллар» романында чагылыш табалар.

Милитаристик Германиядә әсир кеше хәлендә, хокуксыз-нисез, кечкенә бер шәһәрдә дүрт ел буе, тупас холыклы, мактанчык бюргерлар арасында яшәү Фединга буржуаз җәмгыятьнең рәхимсез якларын тулысынча ачып сала. Ул капитал хөкем сөргән илләрдә миллионлаган кешеләрнең кимсетелү-җәберләнүләргә дучар ителүен үз күзе белән күрә һәм империализмга карата күңелендә нәфрәт хисе уянуын тоеп кайта. Әнә шул хәл аның алга таба язылачак әсәрләренә ныклы нигез була.

Университетны бетергәндә, мин иҗатымны гомер буе тукландырып торырдай вакыйгалар ясый алырлык түгел идем әле. Ятимлегем дә, тормышны нульдән башлап җибәрүем дә, элек ала алмаган белемне гаять зур тырышлык исәбенә алырга омтылуым да — болар берсе дә миңа тормышымда, Федин чит илгә киткән кебек, кискен борылыш ясарга ирек бирмәделәр.

Ләкин мин, чын язучы булырга теләсәм, нидер эшләргә тиеш идем. Биш ел буе журналда утыру инде җиткән иде. Җиткән дип шуңа әйтәм, акыллы һәм гаять кешелекле әдип Гази ага Кашшаф кулы астында эшләп, мин матбугат кешесенә кирәкле беренче әзерлек чорын уздым — җаваплылыкка, кыюлыкка, үз-үземә читтән тәнкыйть күзе белән карый белергә, иптәшләрем белән хезмәттәшлек итәргә, теләсә нинди кара эштән, «вак» эштән баш тартмаска, иң кыен чакта да язудан туктамаска өйрәндем. Моның өчен мин Гази ага Кашшафка — укытучы-остазыма күңелемдә иң зур рәхмәт хисе саклап йөрим.

Ләкин миңа хәзер журнал редакциясеннән китәргә, бер көн кичекми китәргә кирәк иде. Юкса мин илдә барган зур тормыштан төшеп калачак идем.

Мин, әлбәттә, бу хакта иң беренче булып Гази абый белән сөйләшә алмый идем. Аңа тәҗрибәле редактор кирәк. Аның миннән, бәлки, аерыласы да килмәс. Шуңа күрә мин бу хакта Хатип абыйга сүз каттым.

Хатип абыйның гаҗәп бер гадәте бар: әйткән сүзгә ул шунда ук, турыдан-туры җавап бирмәс. Бик ерактан уратып җавап бирер. Кемдер берәү шаяртып: «Хатип Госман хәтта ашханәдә ашап утыруын да фәлсәфи нигезли ала»,—дигән иде.

Бу юлы да ул сүзне ерактан уратып башлады:

— Менә син мине тәнкыйтьче дип беләсең, галим дип беләсең, педагог дип беләсең. Ә бит мин әдәбиятка шигырь язып килдем. 1931 елны «Җырлар лирикасы» дигән шигырь китабы да бастырып чыгардым. Аннан соң мин бер-бер артлы өч җыентык — хикәя җыентыкларын чыгардым.

— «Иосыф» дигәнен, «Мин күккә күтәреләм» дигәннәрен минем дә укыганым бар. Сугыш вакытында язылган бердәнбер калын әсәр — «Ялкынлы йөрәк» тә сезнеке түгелме соң?

— Анысы да минеке. Рәхмәт искә алуың өчен. Ләкин шулай да мин үземнең төп жанрым итеп әдәбият белемен сайладым. Практик эшем итеп вузларда укытуны алдым.

— Татар әдәбиятын укытуны мы?

— Башта, пединститутта чакта мин чит ил әдәбиятын укыттым.

— Ник?

— Татар әдәбияты хакында җитди фәнни хезмәтләр язу өчен миңа дөнья әдәбиятын белергә, җирлек хәзерләргә кирәк иде. Менә шуннан соң гына мин Такташ поэзиясенә тотындым. Кандидатлык якладым. Исәбем докторлык хезмәтен әзерләү.

— Сер булмаса, әйтегез, нинди темага?

— «Социалистик революция һәм татар поэзиясе». Моның өчен мин төрки телләрендә иҗат ителгән поэзияне өйрәнәм.

Хатип абыйның минем белән, яшь бер егет белән шулай ачылып китеп сөйләшүенең серен мин аның сүзенең азагындарак, ягъни фәлсәфи өлешендә аңладым.

— Менә эшләр болайрак тора, чибәр егет, — диде ул, минем каршыма ук утырып. — Мин синең «Намус» романының сурәтләү чаралары хакындагы мәкаләңне укыдым. Толковый кеше буласыңны күреп шатландым. Инде менә беренче повестеңның кайбер өлешләрен укыдым, анысы да миндә өмет уятты. Җылылык бар синдә, күзәтү бар, аннары иң мөһиме — тел бар. Телнең хасиятләрен аңлый белү бар. Фәлсәфә җитми әле, гомумиләштерү җитми. Ә замана бит шуңа бара. Менә шушы абзый әйткән иде диярсең, халык аз гына тамагы туюо, өсте бөтәю, сугыш яраларын онгыта төшү белән китапка ташланачак. Әлбәттә, башта әдәби китапка, нәфис китапка. Аннары, күпмедер вакыттан соң, тарихи китаплар, тагын да арырак киткәч, фәлсәфи китаплар кызыксындыра башлаячак аны. Адәм баласы һәрвакыт үзенең чишмә башын эзли, ни өчен җир йөзендә яшәвен белергә тели. Мин озакламый борынгы әдәбиятыбызны актарырга тотынам, аның өчен үземдә җитәрлек нигез бар дип уйлыйм.

— Ә миңа нәрсә киңәш итәсез?

— Сиңамы? Икенең берсе — я фән юлын, ә нәфис әдәбиятны сайла. Икесе дә синең кулыңнан килә. Әгәр фән юлын сайлыйсың икән, син бүгеннән аспирантурага керергә тиеш, әгәр нәфис әдәбиятны сайлыйсың икән, бүгеннән син тормыш эченә чумарга тиеш. Сиңа инде журналда утыру ярамый, ул сине мүкләндерәчәк.

Мин матур әдәбият юлын сайладым һәм, бер елга административ ял сорап, Гази абыйга гариза язып бирдем.

Гази абый минем журналдан ычкыначагымны сизде, әлбәттә, ләкин минем аны шунда ук күнелсез хәлгә куярга теләмәвемне, аз гына булса да өмет калдыруымны да үзенчә матур итеп бәяләде.

— Ярый, Гарифҗан, мин сине өч ел эчендә журналист итәм дип сүз биргән идем. Син бездә биш елдан артык эшләдең. Дөньяның нәрсә икәнен дә, әдәбиятның нәрсә икәнен дә таныдың. Әгәр мин сине көчләп үзебездә калдырырга теләсәм, мин сиңа карата начарлык эшләгән булыр идем. Мөстәкыйль тормышка чыгарып җибәрәм мин сине. Кош баласын оясыннан очырам. Юлларың уң булсын, дөньяда сиңа хәерхаһ кеше Гази абзаң барлыгын юк-юкта исеңә төшер, яме.

## Сәяхәт

Университет бетергәннән соң биш ел буе кеше өстендә яшәү, язып утырырга ныклы бер урын булмау, шуларның барысы өстенә Матбугат йорты белән Казан урамнарыннан башканы күрмәү мине ялыктыра башлаган иде. Гел шулай барса, минем, язучы буларак, төпсез көймәгә утырып калуым да бик мөмкин иде.

Беркөнне Шәһидә миңа һич көтмәгәндә:

— Әйдә, Казагыстанга, я булмаса, Алтайга китәбез, — диде.

Кешегә әйтми генә җыена башладык. Яңа дөньялар күрәбез, китап өчен кызыклы кешеләр эзлибез, янәсе.

Ләкин Казагыстанга, бөтен ил шаулаган чирәм җирләргә күченеп китү мәсьәләсе ничек тиз кабынган булса, шулай тиз сүнеп тә китте. Минем иҗатымны күздән ычкындырмый күзәтеп торган Сибгат Хәким белән Гомәр Бәширов миңа әйттеләр, чирәм җирләргә күчеп китеп син

бер китап язарсың, аннары нишләрсең, диделәр. Мин уйга калдым. Чыннан да, туган туфрагымнан, халкымнан аерылгач, язарыма азык табармынмы? Юк, мин баштагы уемнан кире кайттым. Кайтуын кайттым, ләкин сәфәр чыгу, яңа җирләрне күрү дәрте күңелдә утырып калды.

Ул арада партия Үзәк Комитеты язучыларны халык белән тыгызрак бәйләнешкә керергә, ил тормышы белән яшәргә чакырды.

1955 елның январенда, СССР язучыларының III съездыннан соң, шагыйрь Шәйхи Маннур Татарстанның нефть районнарына чыгарга булган — үзе белән мине дә алмасынмы! Киттем. Шәйхи абый нефтьчеләргә совет әдәбияты турында, язучылар съезды турында сөйләп йөри, мин яшь язучы булып аның авторитетын күтәрешәм. Шәйхи абыйның өстендә соры каракүл якалы, энәдән-җептән генә чыккан кыйммәтле пальто, шундый ук соры каракүлдән тоташ итеп тектергән бүрек — кыяфәт министрларныкы! Рәхәт андый кеше канаты астына сыенуы. Хәтеремдә — бу пальто аны кайбер шаяртуларга да китергән иде.

«Казан—Уфа» поездында, безнең белән бер вагонда, күрше купеда гына драматург Абдулла Әхмәт, Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Ширияздан Сарымсаков, рәссам Әнәс Тумашев баралар иде. Абдулла абыйның «Серләр» спектакленә әзерләнгән заманнары иде бугай, ахрысы...

Төнлә купеда бик суык булгач, мин студент чактан соң алып кигән, инде чабулары кыршыла башлаган кыска пальтомны ябындым да йокладым.

Шәйхи абый ябынмады.

Төнлә мин аның, суыктан туңып, калач кебек бөгәрләнгәнен күрдем. Иртән ул дерелдәп, теше тешкә тими торды да, күрше купе ишегенә сөялеп:

— Бррр, туңдым, — диде.

— Пальтоңны ябынмадыңмыни? — диде Ширияздан абый.

— Ябынмадым шул, кызгандым. Яңа бит.

Абдулла Әхмәт бер күзен шар ачып, икенчесен кысып карады да:

— Дөрес, пәлтәң синең үзеңнән шәп! — дип көлеп җибәрде.

Без дә гөр килеп көлдек. Абдулла абыйның тормышта шундый усал шаярта торган гадәте бар иде. Ләкин ул аны әдәбиятта куллана белмәде. Кулланса — иҗаты тагын да үткенрәк булыр иде.

Нефть районнарында без ай буе йөрдек. Бөгелмәдә, Баулыда, Лениногорскида, Әлмәттә булдык. Алар әле ул чакта хәзерге төсле бәрәр йөз мең халкы булган калалар түгел, ул заманда бу якларда таш өемнәреннән, казылып ташланган траншеялардан, үкереп чирәм актаручы тракторлардан башка әллә ни юк иде. Почмак саен цемент ящигы, чат саен сумала кайнатучы кара казаннар күренә иде. Ләкин нәкъ менә шушылар мине җилкетеп җибәрде. Күпме хис, күпме яңа дөнья, күпме яңа кешеләр! Бу инде сиңа, туганкаем, Казандагы Матбугат йортының төтенле коридорлары түгел.

Нефть якларына үзем генә, иркенләп килергә дигән фикер күңелдә ныгый башлады. Ул фикернең тәмам ныгып җитүенә Бөгелмә кунак йортында очраган бер нефтьче егет тә сәбәп булды.

Шәйхи абый йоклый иде әле. Мин авылдан ук килгән гадәтем буенча, иртәнге биштә үк уяндым да, юлдашыма комачау итмәс өчен, кулыма китап алып, коридордагы диванга чыгып утырдым.

Зәңгәр майкалы, киң күкрәкле, ишелеп килгән аркан төсле таза беләкле, егерме биш яшьләр тирәсендәге бер баһадир егет, иңенә сөлге салып, юынып кайтып килә иде. Минем янга туктап:

— Сез язучымы? — диде.

Мин каушап, хәтта югалып калдым. Чөнки әле миңа беркайчан да андый сорау биргәннәре юк иде.

— Ә нигә? — дидем мин, ни әйтергә белмәгәч.

— Сезнең белән бергә килгән ак чәчле агай Шәйхи Маннур түгелме дип сорарга теләгән идем.

— Әйе, шул, Шәйхи Маннур. Ә сез аны каян беләсез?

— Китаптагы рәсеменнән таныдым. Мәктәптә чакта без аның «Гайжан бабай» поэмасын өйрәнә идек.

— Ә сез үзегез кем?

— Минме? Мин... бораулаучы. Мине Татарстан АССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр. Сайлаучылар белән очрашып йөрим менә.

Тере нефтьче белән беренче мәртәбә очрашуым минем әнә шулай булды. Бу егет — Әсгать Абдуллин — атаклы нефтьче икән, үзе тагын, җитмәсә, Сарманда, Баулыда, тагын кайлардадыр сабан туе батыры да булып калган икән. Соңыннан, Баулыга килгәч, без аның өендә кунакта да булдык. Ул безгә үзенең тормышыннан бик тә кызыклы хәлләрне сөйләде.

Бөгелмәдә, төнге бердә кайтып килгән чагында, аңа ике хулиган очрый. Башта, һәркайсыбызга мәгълүм алым — тәмәке сорыйлар. Әсгать тәмәке тартмый. Аһ, син әле тартмыйсыңмы, фәлән дә фәсмәтән, моны чишендермәкче булалар: сал пальтоңны, салага!

Сала пальтосын Әсгать, тоттыра кулларына теге ике хулиганның.

— Тагын нәрсәне салыйм?

— Пиджагыңны сал, — ди берсе, Әсгатьнең муенына пычак терәп.— Я, я, живо, синең белән уйнап сөйләшмиләр.

Әсгать моның пычаклы кулын әкрен генә этә дә, ике хулиганның берьюлы якаларыннан умырып тотып, маңгайга маңгай чакылдатып бәрә. Икесе ике якка авып китәләр. Аннарына килеп, аяк өсте баскач, сорый Әсгать:

— Ягез, батырлар, тагын нәрсәне салыйм?

Хулиган бит ул үзеннән курыкканнарны күргәндә генә батыр. Мәлҗерәп төшә болар, ялвара, гозерләнә. Кичер безне, шаярдык, диләр.

Әсгать әйтә:

— Сезнең шаяруларыгыз хезмәт иясе халкына кыйбатка төшә, атлагыз, хәшәрәтләр, сезнең белән икенче урында сөйләшерләр, — ди һәм милиция идарәсенә бик әйбәтләп илтеп тапшыра.

Минем «Хәзинә» романындагы бер үзе машинаны баткактан этеп чыгарган Арслан Гобәйдуллин образында әнә шул Бөгелмәдә танышкан сабан туе батыры Әсгать Абдуллин да бар. Арсланны мин өч кешедән алдым. Соңгы икесен мин беразданрак, Әлмәткә килеп төпләнгәч таптым, әмма нефть якларына күчеп килергә ымсындырган беренче нефтьче әнә шул Әсгать булды.

Акбуада чыгыш ясаган чакта миңа залдан бик яшь һәм сылу гәүдәле бер кыз күзен дә алмый карап утырды. Берничә мәртәбә күзләр очрашкач, мин башта уңайсызландым, азакка таба ничектер дулкынланып китеп, бер хикәямне аеруча дәртләнеп укыдым.

Миңа гомердә булмаганча озаклап кул чаптылар.

Чыгышлардагы дан-шөһрәтнең дүрттән өч өлешен гел үзенә күрәп ала торган Шәйхи абый, ул көнне мине мактап:

— Вәйт, энекәш, синең дә популярлык арта башлады, болай булса, шөкер, юл уңар безнең! — диде.

Икенче көнне китәргә кузгалдык. Автобуска утырырга торган чакта гына, кичә күзен шомырайтып утырган сылу кыз минем янга килеп җитмәсенме! Ул мине читкә чакырып алды да:

— Минем турыда стих сочинять итегез әле, — диде.

— Мин бит шигырь язмыйм... — дидем каушап.

— А-аа, мин уйладым поэт дип...— һәм ул иренен турсайтып читкә китеп барды.

Менә шул чакта инде мин ник шагыйрь булмавыма үкенеп бетә алмадым. Юлда барганда, сер итеп кенә, әлеге сөйләшүне Шәйхи абыйга сөйләгән идем, ул песнәк борынын җыерып тыңлап торды да рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Тиле, ярар диләр аны! Үзем язып биргән булыр идем. Яшьлек шул, тәҗрибәсезлек.

Нефть яклары белән беренче танышлыгым әнә шулай башланды минем һәм ул озакламый минем тормышымда һәм иҗатымда зур гына бер борылыш та тудырды.



## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

# БЕЗ ЯШИБЕЗ ӘЛМӘТТӘ

### Командировка

Әлмәт якларында Шәйхи ага Маннур белән бер йөреп кайткач һәм инде журнал редакциясеннән эштән дә киткәч, мин республиканың нефть районнары хакында ныклап уйлана башладым.

Казылып ташланган чокыр-траншеяларда, кыр уртасыннан узган гудрон юлларда һәм каядыр ашкынып чапкан металл баганаларда әле минем өчен ачылмаган серле бер дөнья торып калды. Әнә шул серләрне ачасы, тойгыларны кәгазьгә төшерәсе килә иде.

1956 елның октябрендә икенче мәртәбә Әлмәткә киттем.

Мине Бөгелмәдән Әлмәткә китергән җиңел машина урамда бил тиненнән пычракка төшеп батты. Командировкага чыгар алдыннан, газета хәбәрчесе Фазыл Мостафин киңәше белән, озын куңычлы резин итек сатып алган идем. Пычракны ерып кереп, шофер белән икебез һәм безгә ярдәмгә ашыккан өч гүәрдин егет машинаны этеп чыгардык та мин вакытлы баракка урнашкан гостиницага килеп егылдым.

Урамда яңгыр ява, коеп-коеп ява иде хәзер. Әлмәт кешеләре гостиница коридорларына ярты метр калынлыгындагы пычкы чүбе җәйгәннәр, чөнки йөрүчеләр итекләренә ияртеп алып кергән пычракны бетерерлек түгел иде.

Шыбырдап яуган көзге яңгыр астында моңаеп утырганда бүлмәгә плащтан, резин итектән Фазыл килеп керде. Без аның белән кайчан киләсен алдан сөйләшеп куйган идек.

Озын буйлы, таза гәүдәле, кешеләргә ярдәм итәргә атлыгып торган бу егет мине, ай-ваема карамый, өйләренә алып кайтып китте.

Казаннан күтәреп килгән чемодан минем кулыма да тимәде.

Өйдә безне чандыр гына гәүдәле, терекөмештәй тере бер хатын каршы алды. Монысы Фазылның хатыны Сания булып чыкты.

Алар торган йорт та такта барак иде. Гомумән, ул елларда Әлмәттә егерме елга исәп тотып салынган андый вакытлы бараклар күп иде. Әлмәткә илнең төрле якларыннан белгечләр, бораулаучылар, төзүчеләр килә, унлап, йөзләп кенә түгел, меңләп килә, аларга капитал йортлар салып өлгертү мөмкин түгел иде әле, күрәсең.

Сания — булдыклы, җитез хуҗабикә — безгә табын әзерләде. Фазылның өч балалы гаиләсендә, ут кебек кайнар итеп ягылган өендә бик иркенләп, төне буе сөйләшеп утырдык.

Фазыл белән Сания миңа:

— Гостиницада яшәүләре кыен булыр, үзебездә торырсың, — диделәр.

Ихлас күңелдән әйтүләре йөзләренә чыккан иде — каршы килмәдем. Аннары Фазылның, мин «Совет әдәбияты» журналында эшләгән чагында, безгә бер-ике очерк та алып килгәне бар, тик алар әле әдәби журнал очеркы түгел, газета репортажы иде, мин аларны Әлмәттә бергәләп, иркенләп карарга вәгъдә иткән идем. Димәк, мин аларда торсам, Фазылга күбрәк файда итә алам, шул фикергә килгәч, уңайсызлану хисемне җыйдем.

Мин бу юлы бер айга дип командировкага килгән идем. Әмма минем Әлмәттә яшәвем, Казанга кайта-килә йөреп, ел буена сузылды. Һәм мин шул вакыт эчендә гел Фазыл Мостафиннарда яшәп, аларның үзләре белән дә, балалары белән дә дуслашып беттем. Алты айлык Фәритне кулга алсаң, аякларын өзлексез селтәп, хәрәкәтләндереп торуы белән күңелгә әллә нинди рәхәтлекләр бирә торган иде.

Бу кунакчыл йорт ике нәрсәсе белән истә калды. Берсе — яшел абажурлы лампа. Ул төнге өчләргә, кайвакыт таңга кадәрле яна, Фазыл дус төне буе газетага мәкалә язып утыра торган иде. Кичке урамнан, яки төнге буровойдан кайткан чакларда әнә шул яшел ут күңелне сөендереп тора иде.

Икенчесе — әлеге дә баягы — бүлмәнең эсселеге. Без, әсәр язганда, бил тиңентен чишенеп утырабыз, ялангач тәнмән стена обое майланып, каралып бетте.

Фазылның чая хатыны Сания, усал телләнеп:

— Кара инде бу эшем нәләрен! Бер ел эчендә минем нинди әйбәт обоемны эштән чыгардылар бит, — дия иде.

Ни генә булмасын, ул көннәр гаҗәеп дулкынланулар, бәхәсләр, уртак сөенечләр белән узды. Фазыл мине нефть эшендә озак еллар эшләгән мастер Заһир ага Гарипов белән таныштырды. Әлмәткә килүемнең беренче эше итеп «Дружба народов» журналына ике табаклы очерк язып җибәрдем, Фазыл аны русчага тәрҗемә итте һәм ул, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңае белән, басылып та чыкты.

Шуның өстәвенә мин Фазылның очеркларын яңабаштан эшләттем. Аның тормыш материалы күп иде, әмма зур күләмле очеркның ул сюжетын оештырып җиткермәгән иде. Кызыклы сюжет эзләп, ул буровойларга чапты, әдәби очерк өчен кирәкле биографияләр эзләде һәм 1957 елны, бер-бер артлы, «Совет әдәбияты» журналында аның күләмле зур очерклары басылып, укучыларның да, язучыларның да игътибарын җәлеп итте.

Ниһаять, 1957 елны без, Фазыл белән икәүләп, «Җир куенында» дигән пьеса яздык. Бу әсәрнең язмышы шактый ук аяныччы булды, анысын соңыннанрак сөйләрмен.

Әлмәттә мин шагыйрь Әдип Маликов белән ныклап таныштым. Чәче ике якка уймакланыбрак кергән биек маңгайлы, ак йөзле бу яшь кеше басынкы табигатьле булуы белән күңелгә ошап куйды. Ул аз сөйләшә, шешмәгрәк кабаклы күзләре һәрвакыт җитди була иде. Ә йөргән чакта гәүдәсен аңардан да төзрәк тоткан, киемен искиткеч бер пөхтәлек белән кигән икенче бер кеше булса Гомәр абый Бәширов кына булгандыр. Мин Фазыл белән бергәләп аларда утырырга, мәҗлес-мазарда да катнашырга туры килгәләде. Әдипнең хатыны, сапсары чәчле, зәңгәр күзле, утыз яшьләрендәге ханым минем белән күрешкәндә:

— Шушымыни инде Ахунов? Беләм, беләм, «Яшьлек яме»гезне укыдым, — диде. Шуннан соң кухня ягына чыгып китте дә бүтән әйләнеп кермәде. Бу Саҗидә Сөләйманова булып чыкты, аның әле шигырь язганын ул чакта берәү дә белми иде.

Әлмәткә әледән-әле килә торгач, Әдип белән без шактый ук якынайдык. Ул «Татарстан яшьләре» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли, Әдәбият институтында читтән торып укый, соңгы елларда шигырь язудан аерылыбрак тора иде.

Танышкач, бер-беребезне якыннанрак белгәч, көннәрдән бер көнне ул мине үземне генә кунакка чакырды. Кунакка чакырды дип, кәгазьләр җибәреп, бер атна алдан әйтеп чакырмады, урам йөрергә, һава суларга чыккан җирдән үзләренә алып керде.

Хатыны өйдә юк иде.

Каяндыр, тумбочкаданмы, язу өстәле астыннанмы, ул бер шешә тартып чыгарды.

— Минә минем монда башлап куйган бер нәрсә бар иде...— дип, бер генә рюмкасы эчелгән шешәнең муенына бармагы белән сызып күрсәтте.

Аның кәефе шәп икәне күренеп тора, өйдә хатын-кыз-мазар юк, без икәүләп серләшеп алабыз, янәсе.

«Егет егетне падбадить итмәс!» — дип әйтергә ярата Шамил Бикчурин. Кыскасы — мин Әдипне «падбадить» итмәскә булдым.

Әдип закускага Урсал тау урманыннан үзе җыеп тозлаган гөмбә чыгарды, тозлы кыяр, кәбестә, каклаган балык, тагын нәрсәләрдер чыгарды.

Без сөйләшеп утыра башладык. Мин аның зәмзәм суын, кайбер җил яклы кешеләр кебек, башын артка ташлап эчмәвен, җай гына төшереп ашамлыкның төрлесеннән капкалап, сөйләшеп утырырга ратуын шәйләдем.

Утыра торгач, аның басынкылыгы бетте, теле ачылды, йөзе алсуланып китте. Ул миннән, озак еллар Казанда, язучылар арасында яшәгән кешедән, Казан хәлләрен сорашырга кереште.

Мин моның вакыт үткәрү өчен генә түгел икәнен аңладым. Чынлап та шулай булып чыкты. Әдипне Казандагы теләсә нинди хәл түгел, әдәбият хәлләре кызыксындыра иде, билгеле. Мин шунда аның янә дә шигырь дөньясына әйләнеп кайтуын аңладым.

Тагын бер атнадан ул миңа әлерәк кенә язып бетергән «Ташчы» исемле поэмасын укыды. Әсәр мине сөендерде, поэмадан саф җил искәндәй тоелды. Яңа шәһәрнең, яңа кешеләрнең рухын тотып алган иде Әдип. Язу алымы да муенныңны сындырырдай кыланчык алым түгел, гади алым иде.

Мин яңа әсәр туганга шатландым.

Әдип байтак вакыт сүзсез утырды. Мин аның хәлен аңладым. Дүрт-биш ел шигырь язмаган кешенең яңа әсәр укуы һәм шул әсәргә минем сөенгәнемне күрүе — аның өчен гадәти хәл түгел иде, ахрысы.

Шул көнне ул мине Әлмәткә бөтенләй күчеп килергә чакырды. Әлмәтнең киләчәге, зур эшләре турында, мин ышанмас дигәндәй, ярсынып сөйләде.

Берничә көннән мин Әдип оештырган әдәби түгәрәк утырышында катнаштым һәм Әлмәткә семья белән үк күченеп килергә кирәклегенә тәмам ышандым.

Әлмәт шәһәр советына, квартира сорап, гариза язып бирдем.

## «Тотса мәскәүләр якаң...»

1957 елның 21 мартында мине СССР Язучылар союзына член итеп алдылар. Членлыкка тәкъдим иткән Газиз ага Иделле, Гази ага Кашшаф һәм Гомәр ага Бәширов, идарә утырышында катнашкан Сибгат Хәким минем турыда гел уңай фикерләр генә әйткәч, Габдрахман абый Әпсәләмов түзмәде:

— Иртәрәк мактыйсыз. Яшьләрне бозмыйк. Чалбар төбе шомармаган, уч төбе кабармаган әле, — диде.

— Яшьләргә җылы сүз әйтүдән котларыбыз алына, — дип аңа каршы Шәйхи абый Маннур чәчрәп чыкты.

Мине Язучылар союзына бер тавыштан кабул иттеләр.

Әлмәт миңа бик сөенде. Фазыл Мостафин, мин килешкә, төнге сәгать бергә, табын әзерләп куйган иде. Таңга кадәр сөйләшеп утырдык. Иртәгәсен Әдипләргә бардык. Җиң сызганып, әдәби түгәрәк эшенә җигелдек.

Түгәрәкнең беренче яшь каләмнәре — Шамил Бикчурин, Илдар Әхсәнов, Клара Булатова, Энҗе Мөэминова, Мөдәррис Ибраһимов барысы да ашкынулы, ихлас күңелле, тормыш тарафыннан иркә-назны бик әллә ни күрмәгән яшьләр иде. Холыклары, әдәби әзерлекләре, тәҗрибәләре төрле-төрле булган бу яшьләрне өйрәтеп, Әдип белән миңа байтак кына чиләнергә туры килде.

Беренче эш итеп без түгәрәкнең утырышларын системалы рәвештә алып баруны, айга ике мәртәбә шәһәр газеталарында татарча һәм русча әдәби битләр чыгаруны куйдык.

Шамил Бикчуринның таш чыгаручылар турындагы очеркларын мин кат-кат төзәттердем, кулдан күчереп яздым. Үтә чыккан беркатлы, озын торыклы һәм салам чәчле бу егет үпкәләүне белми, әйткән сүзне тыңлый, кимчелекләрен гел төзәтә иде. Илдар Әхсәнов, бәләкәй, нык, уйчан йөзле, кара егет, эшчеләр турында бик чын шигырьләр яза башлады. Клара Булатова — ап-ак чырайлы, чандыр, «әртистләнә» белүче, феноменаль хәтерле кызый, беренче әдәби битләрне газета өчен әзерләгән чакта, шигырьләрне «кондициягә» китереп җиткерергә булышты.

Шушы елны без аена икешәр утырыш җыя, икешәр әдәби бит чыгара, кимендә бишәр мәртәбә нефтьчеләр алдында чыгыш ясый торган булдык.

Безгә шауларга, Әлмәттә нефть кенә түгел, җыр да барлыгын күрсәтергә кирәк иде.

Республиканың нәкъ шушы елны Мәскәүдә үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерләнүе дә безгә илһам өстәде.

1957 елның 25 маенда Әлмәттәге дуслар мине декадага озатып калдылар. Яшь-яшь килеш халкыбызның шундый зур бәйрәмендә катнаша алуымны мин үземә зур бәхет саныйм һәм бу бүлектә декадада катнашучыларның хисләрен түкми-чәчми бирергә телим.

1957 елны инде мин «Совет әдәбияты» журналында эшләмәсәм дә, элекке елларны бергә эшләвебезне истә тотып, журнал өчен декада материалларын оештыруны Гази абый миңа тапшырган иде. Мин ул чакта дүрт кешегә тукталдым. Берсе — Гази абый үзе, икенчесе — декаданы оештыручы төп кеше, ул чагында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председателе Гомәр Бәширов, өченчесе — Хисам Камалов, дүртенчесе — бу юлларның авторы.

Материаллар әзерләнде, журналда басылып чыкты. Мин шул материаллардан, бүгенге көн укучылары өчен кызыклы дип табылганын, безнең әдәби хәрәкәтебезнең үсешен билгели торганнарын укучылар карамагына тапшырам.

Гази Кашшаф. Безнең декаданың тарихы озын. Беренче тапкыр декадага әзерләнә башлаганда[1], Виль Ганиев, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Рафаил Төхфәтуллин кебек яшьләрне берни дә борчымаган да, дулкынландырмаган да. Алар әле ул вакытта «Такташ абый»ларының

---

[1] Беренче декада 1941 елны үткәрелергә тиеш була, сугыш аны өз...

шигырьләрен ятлап, колхоз авылының инеш буйларында каз куып йөргән малайлар. Ә хәзер... Мәскәүдә Язучылар союзы бинасының конференц-залында утырганда мин бу яшьләрнең йөзләрендә уйнаган төрле тойгыларны укырга тырыштым. Алар имтихан тоталар иде. Бер атна буена рус язучылары безнең әдәбият турында үзләренең фикерләрен сөйләделәр. Зал артык зур түгел, ләкин яңгырашы көчле. Безнең әдәбият дөньясының игътибары шушы залга юнәлгән шикелле, синең турыда әйтелгән сүзләрне колач җитмәс киң Ватаныбызның һәр почмагында ишетеп торалар кебек. Чыннан да, тезләрең калтырап тора икән, гаҗәп түгел. Бавырыңнан тотып, йөрәгеңне селкетә башлаганнар икән — йөзеңә нинди генә тимгелләр чыкмас. Ләкин молодец безнең яшьләр! Сынауны әйбәт уздылар, тез буыннары калтырауны сиздермәделәр.

**Мин язганнары.** Без Мәскәүгә җыр белән килеп кердек. Безне чәчәкләр белән каршы алдылар, меңләгән мәскәүлеләр җыелган киң мәйданда, микрофон алдына басып, язучы Фатих Хөсни әйтте:

— Безнең халыкта бик матур бер гадәт бар, без кунакка килгәндә ике куллап күрешәбез, бу, димәк, безнең йөрәкләребезне ачып салуыбыз була, бу, димәк, безнең күңелебезнең керсезлеге була, — диде.

Һәм бу чыннан да шулай иде.

Безнең сәнгать вәкилләребез Мәскәү тамашачысына, артык кәпрәймичә, шул ук вакытта артык мескенләнеп тә китмичә, тыйнак кына итеп, татар халкының нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәттеләр. Гади тамашачылардан башлап Партия Үзәк Комитетына чаклы безнең сәнгатебезгә, безнең культурабызга югары бәя бирде.

**Гази Кашшаф.** 1941 елда, декадага әзерләнеп йөргәндә, безнең арабызда Гадел Кутуй, Нур Баян, Абдулла Алиш, Муса Җәлил кебек тынгысыз, ярсу йөрәкле иптәшләребез бар иде. Ул вакытта Муса белән Кутуй нинди дәрт белән, нинди ашкыну белән әле Язучылар союзында, әле сәнгать эшләре идарәсендә, әле редакцияләрдә, әле театрларда эшләп йөриләр иде, һәр нәрсәгә аларның кулы җитә, һәр эшкә алар өлгерәләр иде. Бу декадага әзерләнүдә алар безнең арада була алмадылар. Ләкин алар декадада катнаштылар. Аларның әсәрләре килде, йөрәк җылысы килде. Алай гына да түгел, 1941 елда декадага олы фикерне эченә алган, халыкның тарихи хәрәкәтен тулы чагылдырган, якты әдәби образлар алып бару белән янып йөргән Муса Җәлил— бу декадага үзе үлемсез образ булып барды...

Декадага безнең якындагы дусларыбыздан — замандашларыбыздан тыш, элекке буын язучылар, хәтта борынгы буын язучылар да бардылар.

«Тукай, Ибраһимов, Такташ, Ф. Кәрим, Җәлил кебек сокландыргыч язучылар буш җирдә үсмәгәннәр икән, татар әдәбиятының бай традициясе, бай мирасы бар икән!» — диделәр безнең өлкән туганыбызның вәкилләре. Бу мираска ныграк игътибар итәргә кирәклеген, аның әһәмияте зурлыгын фикер алышулар да күрсәтте, китап күргәзмәсе дә әйтеп бирде.

**Хисам Камалов.** Татар поэзиясенең солдат җанлы, сугышчан, тормыш белән атлаучы, бай традициясе булган, республика чикләрен үтеп, бөтенсоюз мәйданына чыккан поэзия икәне әйтелде. Аннары безнең поэзия турында уйландыра торган, «тотса Мәскәүләр якаң...» өлеше дә булды...

Бездә хәзер ике төрле поэзия бар. Аның берсе, чыннан да, тормыш белән атлый торган һәм укучыларның мәхәббәтен яулаган тормышчан поэзия. Икенчесе: Толстой әйтмешли, поэзия поэзиясе, ягъни җырланганны җырлаучы, кабатлаучы поэзия. Бу поэзия тормышчан поэзия

тәненә талпан кебек ябышып яши. Болар барысы да фикергә, образга ябыклыктан килеп чыга торгандыр бәлки. Ябык малны аны талпан басучан була шул. Моңардан арынырга вакыттыр инде, егетләр.

**Гомәр Бәширов.** Юк, Мәскәүдә без алкышлар гына ишетмәдек. Мәскәү язучылары безгә дусларча туп-туры итеп кимчелекләребезне дә әйттеләр. Дөрес, без балалар әдәбиятының бик аксавын үзебез дә беләә, балалар өчен чын мәгънәсендә яхшы әсәрләр булмавы өчен борчылып, бу кимчелекне бетерү өчен кайбер чаралар да күрә идек. Әмма Язучылар союзында рус балалар әдәбиятының танылган язучылары Мусатов һәм башка иптәшләрнең чыгышы безгә балалар әдәбиятының артка калу сәбәпләрен тирәнрәк аңларга, аның сәбәпләре без уйлаганга караганда җитдирәк булуын төшенергә ярдәм итте. Безнең балалар өчен язылган күп кенә әсәрләребездә ясалмалылык бик көчле, алар күбесенчә тормышның үзеннән, реаль чынбарлыктан алынган вакыйга һәм хәлләргә нигезләнмәгәннәр, халыкның үз тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, шушы нигезгә салып язылмаганнар. Чын тормыш вакыйгасы урынына төрле ясалма ситуацияләр, «четрекле», «мажаралы» сыман нәрсәләр ярдәме белән боргычлап ясалган киеренкелекләр— безнең кайбер язучыларыбыз менә нәрсәләр белән мавыктылар...

Балалар әдәбиятының күтәрелеп китә алмавына тагын бер сәбәп итеп, зуррак тәҗрибәле өлкән язучыларның бу эшкә катнашмаулары, балалар өчен язуны берничә балалар язучысы өстенә йөкләп, шуның белән тынычланып калуны әйттеләр. Моныса да бик дөрес. Һәрхәлдә, бу турыда бик нык уйланасы, балалар әдәбиятындагы бу зур җитешсезлекне бетереп, яхшы әсәрләр иҗат итү юлында күп төрле чаралар күрәсе бар.

**Мин язганнары.** Мәскәү тамашачылары опера һәм балет сәнгате, драма һәм комедия сәнгате осталарының чын зәвык белән башкарган реалистик уеннарын сокланып карадылар, озак-озак алкышладылар. Әмма декаданың сәнгать өлеше профессиональ артистлар, сәнгать мастерлары уены белән генә чикләнгән булса, без үзебезнең сәнгатебезне бик бер яклы итеп, тар һәм чикләнгән итеп күрсәткән булыр идек. Юк, татар сәнгате үзенең аерым талантлары, ялгызак башкаручылары белән генә түгел, аеруча массовый сәнгате, массовый уеннары, җыр һәм бию ансамбле, үзешчән сәнгать коллективлары чыгышы белән истә калырлык булды.

**Гази Кашшаф.** Драматургияне алыйк. Сәхнәләрдән күрсәтелгән әсәрләр триумф белән бардылар. Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» исемле комедиясе Татар дәүләт академия театры тарафыннан гына да унбиш ел эчендә 1700 (мең җиде йөз!) тапкыр сәхнәгә менгән! Бу бит драматургның искиткеч таланты турында сөйли. Шулай да безнең Мәскәүгә алып барган сәхнә әсәрләребез арасында бүгенге көн төшеп калган иде. Соңгы елларда язылган яңа әсәрләр «сынауны» уза алмадылар, декада репертуарына кертелмәделәр. Без элекке еллар хисабына, кичәге осталык хисабына чыктык! Драматурглар бу хакта уйланмый калмаслар, билгеле.

**Гомәр Бәширов.** Ниһаять, без яңадан Казанда! Бик күп айлар хәзерләнеп, шактый ук дулкынланып, зарыгып көтеп алган ун көн узып та китте. Баргандагы кебек үк дулкынланып, әмма хәзер инде әдәбиятыбызның һәм сәнгатебезнең зурлыгына, аның көченә, әдип һәм шагыйрьләребезнең иҗат сәләтенә тагын да ныграк ышанган хәлдә, яңа көч, яңа иҗат дәрте белән илһамланып, яңадан үзебезнең Иделебез буена кайттык.

**Минем кайбер шәхси хисләр.** Инде ул көннәргә егерме елдан артык вакыт узганнан соң, мин менә декада чорындагы рәсемнәрне карап

утырам. Декадага мин фотоаппарат алып барган идем. Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеевне һәм Рафаил Төхфәтуллинны Мәскәү елгасы аркылы салынган чуен күпердә рәсемгә төшереп алганмын. Яшь кенә егетләр тартынып кына басып торалар. Әйбәт истәлек. Инде рәсемгә төшмәгәнен әйтсәм, шул: Рафаилнең авылда әллә ничә еллар киеп йөреп, каралып беткән бер салам эшләпәсе бар иде, без аны поезд тәрәзәсеннән очырып җибәрдек. Ул зур гына бер агач ботагына эленеп калды. Без, дәрте ташып торган яшь егетләр, татар әдәбияты классигы Шәриф Камалның бер хикәясен искә төшереп, рәхәтләнеп көлештек. Анда бит бер «недалекий» адәм әйтә: татарның мескен бүреген кадак белән айга кадаклап куярга кирәк. Алмый торгызырга кирәк. Аурупа күрсен, ди.

— Декададан, Мәскәү чаклы Мәскәүдән, без иске, каралган эшләпә белән кайтырга тиеш түгел! — дидек без.— Долой иске эшләпәләр! Давай безгә яңасын! Аурупа безнең Мәскәүдә имтихан тотып, яңарып кайтканны күрсен!

Аз сүзле, басынкы табигатьле Рафаил җил болгатып алып киткән иске эшләпәсенә моңсу гына карап калды, бер сүз дә әйтмәде. Күңеленнән ул Мәскәүдән соңгы иҗатынданиләр булачагы хакында уйлый иде булса кирәк...



## Төпләнү

1957 елның ноябренда миңа Әлмәттә квартир бирделәр. Фазыл Мостафин аны үзе сайлап алып, ишегенә йозак куйган, безгә кереп утырырга гына калган иде. Әби белән Шәһидәне һәм дүрт яшьлек улымны Фазылга ияртеп, поезд белән озаттым, ә үзем контейнерга төяп, әйберләрне җибәрергә калдым. Шәһидә уйламаганда күзсез кала язды. Аның беркайчан да чәч ясатканы юк иде, парикмахер хатыннар — каһәр суккырлары! — тегене чәчен бөдрәләтергә күндергәннәр бит. Боларны озатырга ике-өч сәгать вакыт калып бара — Шәһидәм юк та-юк, кайтмый да кайтмый.

Көтә-көтә көтек булгач, кайтып керде бу. Чәч юеш, бөдрә, сул күзе кып-кызыл, йодрык чаклы. Пар торбасы ычкынган да күзенә бәргән. Шуңа чаклы аның чәч бөдрәләткәне юк иде, шуннан соң да — шөкер! — бер генә мәртәбә дә бөдрәләтмәде.

Бу вак-төякне мин ни өчен язам?

Ул чорда без, Әлмәт яшьләре, гаять зур планнар белән, җиде кат күк артларында очып йөрибез, Фазыл белән икәүләп, Татар дәүләт академия театрына пьеса язып ятабыз (безнең пьеса моңарчы булган пьесаларны егып салырга тиеш!). Әдәби түгәрәкне гөр китерәбез. Кайбер кешеләребезне — Энҗене, Илдарны, Шамилне, Мөдәррис Ибраһимовны Казанга, яшь язучылар семинарына әзерләп йөрибез, әнә шул зур эшләр арасына тормыш үзенең вагы-төяге, чүп-чарлары белән дә килеп керә һәм безгә үзен онытмаска кушып тора иде.

Онытырга ярамый тормышны — юкса бездән язучы чыкмаячак!

Әлмәткә күчү белән минем ике табаклы хикәямне басмадылар. Югыйсә редактор Гази ага Кашшаф аны басарга дип, мин күченгән чакта ук, кул куйган иде инде. Мин күченүгә, Гази абый редакторлыктан китте. Аның урынына администраторлык эшен бик тә җиренә җиткереп үти торган, әмма әдәби әсәрләргә карата беркайчан да үз фикере булмаган Абдулла ага Гомәр килде. Шунлыктан миңа «Юллар чатында»ны бастырыр өчен бик озак азапланырга туры килде. Начар булганга басмадылар дип әйтер идең, нәкъ әнә шул хикәядән соң

мине Ибраһим Гази прозаик дип тә таныды, аңарчы әле ул мине тәвыйтьче дип кенә таныган иде.

Кыскасы, ни булса булды, мин Абдулла Гомәргә хикәямнең басылырга тиешлеген — бик зур нервы туздыру бәрабәренә — аңлатып бирә алдым, һәм ул басылып чыкты.

Анысы гына узган иде, «Юллар чатында» исеме белән тупланган хикәя-очерклар китабымны бастырмый азаплый башладылар. Монысы Татарстан китап нәшриятында булды. Нәшриятның баш редакторы урынбасары Габдрахман ага Минский карышты да калды: хикәя — әдәби әсәр, очерк әдәби әсәр түгел, ди. Мин аңар тегеләй дә, болай да аңлатып карыйм, Мәскәү нәшриятларында басылган «Хикәяләр һәм очерклар», «Повестьлар, хикәяләр, очерклар» дигән китапларны да китереп карыйм, юк, Габдрахман абый якын да килми.

— Мәскәү теләсә нишләсен, алар үзләре өчен үзләре җавап бирә. Без чыгармыйбыз, — дип һаман бер үк сүзне кабатлый.

Мин гаҗиз, мин ни дип әйтергә дә белмим. Үзе менә дигән очерклар язган, беренче кул публицист саналган кешенең очеркка каршы төшүе миңа аңлашылмый. Әмма мин, яшьлеккә хас бер үҗәтлек белән, китапны очерклардан башка чыгаруга риза булмыйм.

Китап ел буе нәшриятта ята. Минем сукыр бер тиен дә акчам калмый. Гаилә инде шактый, улыбыз бар, әби бар, шуның янына Шәһидә белән мине дә китереп куйсаң — дүрт җан бар. Беребез дә эшләми әле. Әлмәттә миңа да, Шәһидәгә дә үз профессиябез буенча эш табылмады. Безгә бер генә юл кала: яңадан Казанга әйләнеп кайту. Анысын эшлисе килми — хурлык, билләһи! Без 1958 елның җәендә яңа квартираны биклибез дә минем туганякларга — Арча районының кечкенә Өчиле авылына китеп барабыз. Мин, Казанга килеп, нәшрияттан вакытлыча, өйдә утырып эшләргә эш сорыйм. Мине редактор итеп билгелиләр. Өчилегә мин кулъязмалар ташыйм, аларны редакциялим, аларны типографиягә тапшырам, ә үземнең булачак китабым әле һаман нәшриятның өстәл тартмасында ята.

Ниһаять, минем сабырлыгым төкәнә. Мин үз китабымны да кайгырта башлыйм. Кайгыртмас идем, чөнки минем өчен берәү дә борчылмый.

Минем китапның редакторы итеп билгеләнгән Сания Сибгатуллина очеркларны хуплый, рецензент Газиз ага Иделле очеркларга хәтта хикәяләргә караганда да югарырак бәя биргән. «Мондый очеркларны без күптән көтә идек, болар тормыш сулышы алып килгән әсәрләр»,— дигән. Тик бер генә кеше каршы — Габдрахман ага Минский!

Газета битләрендә минем Әлмәткә, нефтьчеләр янына күчеп китүемне «зур батырлык» дип язалар, ә менә Әлмәттә язылган очерклар басылмый да басылмый.

Ниһаять, мин тыйнаклык саклап торуның мәгънәсез бер нәрсә икәнен аңладым. 1958 елның азагында, октябрьлар тирәсендә, нәшрият директоры Салих ага Вәлиди бүлмәсенә без өч кеше киңәшкә җыелдык: баш редактор урынбасары Габдрахман ага Минский, матур әдәбият редакциясе мөдире Сафа Сабиров һәм мин — бәхетсез автор. Киңәш гадәттә җай гына, акрын гына ага торган була, ә без бик шаулап сөйләштек, шуның нәтиҗәсе буларак, «Юллар чатында» китабы 1959 елны басылып чыкты.

Шул китапны бастырганнан соң минем гаиләм белән Әлмәттән китеп йөргәнем булмады. Мин ныгытып төпләндем.

Ләкин әле бу минем әдәби тормышымда каршылыклар булмаган дигән сүз түгел. 1959 елны Татар дәүләт академия театрында безнең Фазыл Мостафин белән икәү бергә язган «Җир куенында» исемле пьесабыз чамадан тыш зур каршылыкка очрады.

«Җир куенында» драмасының язылу һәм сәхнәгә куелу тарихын ин аерым сөйләп бирми булдыра алмыйм. Бу безнең беренче мәртәбә эхнә дөньясы белән якыннан танышуыбыз булды һәм ул минем үземә бик күп елларга чаклы сәхнәгә шикләнеп һәм куркып карау тойысы уятып калдырды.

Әлмәт якларында башланган зур эшләрне, нефтьчеләр дөньясын янача итеп язуны максат итеп куйган идек без. Фазыл белән икәү пьесаның геройларын ачыклап, аның сәхнәдә ничегрәк уйналачагын күз алдына китереп, төннәр буе хыялланып чыга идек.

Әсәрне язып бетергәч, драматург Сәет Кальметов киңәше белән Казанга киттек, режиссер Габдулла ага Юсуповны эзләп таптык, пьесаны аңа укыдык. Театр эшендә зур тәҗрибә җыйган, базык гәүдәле, төпле акыллы бу абзый безнең беренче эшебезне ошатты, безнең белән әсәрне бик теләп төзәтте, шуннан соң гына Язучылар союзының драматурглар секциясендә укырга кушты.

Секция дә якты йөз күрсәтте безгә. Тик ул утырышта берданбер кеше — Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Ширияздан ага Сарымсаков кына каршы чыкты.

— Бу әсәрне Әлмәттә куярга ярый, бездә куярга ярамый, — диде.

Театрларны олыга һәм кечегә бүлү безгә аңлашылмый иде һәм без Ширияздан агайга:

— Академияда укырга рөхсәт итәсезме? — дигән сорау бирдек.

Ул аптырап калды. Итмим дисә — уңайсыз, начар кеше булып, диктатор булып чыга, рөхсәт итте.

Барып укыдык. Урра кычкырып кабул иттеләр, шунда ук яшь режиссер, Мәскәүдә укып кайткан Празат Исәнбәтнең безнең әсәрне сәхнәгә куюын сорадылар.

Күңелләр канат какты безнең! Озак та тормый, Празат Исәнбәт белән Әнәс Тумашев Әлмәткә килделәр. Буровойларда, кульбудкаларда, урманнарда йөрдек. Празат нефтьчеләр белән сөйләште, Әнәс булачак спектакльнең эскизларын ясады, геройларның костюмнарын сызгалап барды.

Зур өметләр, баш әйләнгеч хыяллар белән без дә Казанга юл тоттык.

Театр администрациясе баш рольгә СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлиловны билгеләгәч, безнең йөрәк «жу-у» итте. Хәерлегә булса ярар иде, дидек. Куркуыбыз дөрес булган икән, Хәлил агабыз репетициягә килмәде, аны авырый, диделәр. Эш тукталды. «Начар бу, бик начар», — диде Празат борчылып. — Театр коллективын суытачак бу». Бер айдан соң баш рольгә икенче артистны билгеләделәр. Ләкин аның белән әле йөк урыныннан кузгалмады. Инде кабул итеп алынган, өйрәнергә керешкән пьесаны Ширияздан ага «төзәттерә» башлады. Төзәтәбез, төзәтми хәлебез юк, без, тәҗрибәсез драматурглар, ә ул тәҗрибәле режиссер... Әмма бу төзәтү бездә канәгатьлек хисе калдырмый, ник дисәң — пьесаның җылы урыннары китә, коры урыннары гына кала бара, пьеса гел өтелә бара. Ярый, хуш, «төзәтү дә» тәмамланды. Репетиция янә дә тергезелде. Ай буе азаплангач, әле соңгы пәрдәсе әзер булмаган көе, гадәти бер репетицияне Культура министрлыгы комиссиясе килеп карады һәм репетицияне туктатты. Сәбәбе? Сәбәбе гади: төзәтегез, камилләштерегез!

Мин ул чакта сәхнә белән тәмам шашкан идем, спектакльнең чыгуын төшләремдә күрәм, көннәремне хыялланып үткәрәм, бүтән бер нәрсә — ни очерк, ни хикәя язмыйм, повесть ише зур күләмле әсәр турында уйлаган да юк.

— Зинһар өчен,— дидем мин культура министры урынбасарына.— Без, авторлар, пьесаны эшләп бетерүгә каршы түгел, тик безнең бер үтенечебез бар: бу хакта хәзергә матбугатта бер генә сүз дә әйтмәсәгез иде.

— Ярар, әйтмәбез, — диде министр урынбасары.

Әмма — бу ни хикмәт?! — бер ай уздымы-юкмы, республика газетасында аның бер мәкаләсе басылып чыкты, ул нәкъ менә безнең әле куелып кына ята торган пьесаны начар яктан телгә алган иде. Аннары икенче, өченче, дүртенче, бишенче мәкаләләр дә озак көттермәде. Китте, мин синайтим, кар йомгагы тәгәрәп!

Просмотр дигәннәре бик күңелсез, бик сүлпән узды. Бу 1959 елның 18 апрелендә иде. Спектакль биш мәртәбә куелды да шуның белән туктатылды.

Бу чорда ике нәрсә минем хәтеремә сеңеп калды. Берсе — мин ихтирам итеп килгән Фатих ага Хөснинең сүзе.

Просмотрдан соң ул фикер алышуга калмады, театрдан чыгып барышлый, юл уңаенда гына:

— Кайбер пьесалар төкерек белән ябыштырылган була, ә бу — ачуым да килмәгәе! — төкерек белән дә ябыштырылмаган,— диде.

Икенчесе. Спектакльне чыгарыр алдыннан театр директорының хуҗалык эшләре буенча урынбасары безне мыскыллый торган хат язып җибәрде. «Пьесагыз художество эчтәлеге белән түбән дип табылды. Түбән бәягә риза булсагыз, чыгарабыз», — диелгән иде анда.

Мин, гарьлегемнән нишләргә белмичә, театрның яңа директоры Нәҗип ага Гайнуллинга һәм театрның башка ветераннарына озын бер хат яздым.

«Татар дәүләт академия театры җитәкчеләренә ачык хат.

Хөрмәтле Нәҗип абый!

Театр безнең пьесабызны ике ел буе азаплады. Һәм менә, ниһаять инде спектакль чыгар алдыннан, безне мыскыллый торган хат килде. Администратор иптәш Абдрахманов «Сезнең «Җир куенында» исемле пьесагыз драматургия һәм художество күзлегеннән карап түбән булганга күрә» дип бигүк татарча булмаган хат җибәргән.

Чынлыкта шулай идеме соң? Спектакльнең оешмавына без, авторлар гына, гаепле идекме?

Әсәрне без театрга көчләп такмадык. Язучылар союзында укылган чакта аңа Р. Ишморат, Н. Исәнбәт, Ш. Маннур, Х. Туфан һәм башка күренекле язучылар уңай бәя бирделәр. Театрда да ул бөтен коллективка укылып, шулай ук уңай бәя алды. Монысы бер. Икенчедән, театр администрациясе спектакльне әле нәүбәттәге бер репетиция вакытында, дүртенче пәрдәсе уйналмаган да килеш, Культура министрлыгы комиссиясенә күрсәтеп, аңлашылмау китереп чыгарды. Я, әйтегез инде, кайсы рәссамның язылып бетмәгән картинасын күргәзмәгә куеп, бәя алырга теләгәне бар?!

Ярый, тыйнаксызлык булмасын дип, без моңа да каршы килмәдек. Барлык гаепне үз өстебезгә алдык. Безнең үтенеч бер генә булды: хәзергә әсәр (һәм әдәби текст һәм спектакль) эшләнү, камилләшү процессында, шуна күрә бу хакта матбугатта сүз булмасын, дидек.

Һәр ике як безнең үтенечне дөрес дип тапты. Ләкин чынында нәрсә килеп чыкты? Вәгъдә биргәннән соң бер ай узар-узмас безнең пьесаны матбугатта тетеп салдылар.

Без, театрга биргән вәгъдәбезне үтәү йөзеннән, әсәрне нефтьчеләр коллективына кат-кат укып, камилләштереп йөргән чакта, «Советская Татария» газетасында Ян Винецкий мәкаләсе басылды: чи, эшләнмәгән һәм башкалар. Каян белгән Винецкий безнең әсәрнең чи икәнен? Укып караганмыни? Алай дисәң, ул татарча белми, пьесаның русча тәрҗемәсе юк. Димәк, чыганак бер генә: театр җитәкчеләре аңа ин-

тервью биргәннәр. Я, әйтегез, Нәҗип абый, кайсы ана инде карынындагы баласы турында: ул гарип, ул үләчәк дип сөйләп йөри? Бу нинди этикага сыя сон?!

Ниһаять, күптән түгел генә «Литература и жизнь» газетасында бастырган бер мәкаләсендә театр тәнкыйтьчесе Рауза Усманова ике яшь авторга юл уңаенда тибеп китүне олы бер мәртәбә итеп саный. Ул үзеннән алдарак язган иптәшләрдән дә уздырып җибәрә:

«Яшь авторлар таушалып беткән схема һәм алымнарның колы булып калганнар, безгә күптәннән билгеле булган, ашык-пошык кормаштырып куелган өйрәнчек пьесалардагы кебек, ясалма драматизм юлыннан киткәннәр...»

Нәрсәсе белән ясалма драматизмга корылган соң безнең пьеса? Бәлки бораулаучы Сәфәр Асылгәрәевнын юл өстенә зур таш булып яткан бюрократизмга каршы көрәшүе, үз бригадасында аек караш тәрбияләве, иптәш Усмановача, ясалма драматизм буладыр? Шушы көрәштә Сәфәрнең гомерен дә кызганмавы, прихватка эләккән буровой торбасын йөз атмосфера басымы белән тарттырып, һәлак булуы «ясалма драматизм» дип аталадыр? Ниһаять, халык арасыннан күтәрелеп тә халыкка каршы киткән Байназарның — бораулау конторасы директорының — эчке драмасы ясалма драматизм дип бәяләнәдер?

Укымыйча, әсәрне белмичә, яки укып та аның идеясен, эчке мәгънәсен, дәлилсез-нисез, юри бозып күрсәтергә азапланучы рецензентларның бәясе безне гаҗәпләндерми, театрның әнә шундый бәяләргә әйтеп бетергесез дәрәҗәдә битараф каравы безне чын мәгънәсендә гаҗәпләндерә.

Республиканың иң абруйлы, иң зур театры драматургия мәсьәләләренә, яшь авторлар белән эшләүгә шулай формаль карагач, якын араларда гына татар драматургиясенең алга таба үсеп китәчәгенә өмет булмаячак. Безне менә нәрсә борчый.

Без бүтән сезгә килмәбез...»

Хат язылган көнне җибәрелмәде. Икенче көнне дә, хәтта икенче атнаны да җибәрелмәде. Безне тыйнаксызлыкта гаепләрләр, безне барыбер аңламаслар, дигән уй күңелебезгә кереп утырды.

Хатны без Академия театры җитәкчеләренә җибәрмәдек.

Хат безнең архивта ятып калды. Инде менә язучы хезмәте турындагы бу повестьны язган чакта, материал актарып утырганда, ул күзгә чалынды. Мин аны кабат укып чыктым. Әдәбияттагы үз урының өчен азаккача көрәшмәүнең начар нәрсә икәнен күрсәтү өчен, гыйбрәтле бер сабак итеп, укучыларга тәкъдим итәм. Яшь язучы иҗат мәсьәләләрендә усал булырга, үз принципларын үткәрә белергә тиеш.

Безнең «Җир куенында» пьесасының күңелсез тарихы шуның белән бетте. Без Фазыл Мостафин белән принципиаль була белмәдек. Алай була белмәгәнебезгә үкенәбез. Тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллин берничә елдан соң, драматургиягә багышланган бер мәкаләсендә: «Г. Ахунов белән Ф. Мостафинның сәхнәгә менмәс борын егылып төшкән пьесасы» — дип безнең бик зур дан көткән әсәребезне бер селтәүдә кабергә салып куйды.

Мин шуннан соң гомер буена пьеса язмаска күңелемнән ант иттем. Әмма шул 1959 елда ук «Чулпы җыры» исемле пьеса язып, Әлмәттә куйдырдым. Әлмәт дәүләт театрының директоры, Томскидан күчеп килгән Фатих Утяев — ут борчасыдай үткен, тәбәнәк татар — үз кыюлыгы белән пьесаны куярга алды, тәҗрибәле өлкән режиссер Гали ага Ильясов бөтен дәртен салып әсәрне куйды. Ярады монысы— 160 мәртәбә уйналды. Халык яратып карады. Ике сугыш, ачы язмышлар үзенә тартты, күрәсең. Авылларга чыккан чагында, мине «Чулпы җыры»ның авторы итеп белә башладылар.

*Ахыры киләсе санда.*

## Нәби Дәүли

### Кызганыгыз йөрәкне!

Машинадан — төшеп калып,
Больницадан больницага
Мыштым гына инфаркт йөри...
Туктатыгыз, туктатыгыз!
Кеше әле озак еллар
Матур итеп яшәргә тели.

Кешегә кирәк — кеше ихтирамы,
Якты йөзләр һәм күзләрнең
Җылы карашы.
Сүзләрнең дә кирәк
Энҗе кебекләре — иң сафлары.
Аларны бит йөрәк аласы.

Йөрәк белә, йөрәк сизә
Чәчләр агарганын.
Барометр аннан калыша.
Йөрәк сыный —
    Күңел ныклыгын
    Намус бөеклеген
Йөрәк белән кешеләр табыша.

Йөрәк — компас,
Бер котыптан бер котыпка
    Магнитны сизә.
Йөрәк белән дуслар кавыша.
Телне белмәүчеләр,
Саңгыраулар, сукырлар да
Йөрәк белән сәлам алыша.

Хирурглар кайчак
Ул йөрәкне
Учларына алып салалар.
Пычак белән аны «телгәлиләр...»
Ә йөрәкләр исән калалар.

Кайгыларга чыдый,
Ачлыкларга түзә...

Гранит каты,
Граниттан каты ул йөрәк.
Кайвакытта әмма бер авыр сүз җитә,
Аны шартлатырга,
Динамиттан бәлки көчлерәк.

Йөрәк тибә, эшли көне-төне,
Кан куа ул армый-талмыйча.
Шул гынамы аның хезмәте?
Ул бит әле безне җирдә тота,
Җирдә йөретә...
Кызганыгыз,
Кызганыгыз, кешеләр, йөрәкне!

●

Кешеләргә шатлык ташыгыз,
Йөрәк белән, күңел белән, сүз белән.
Ташыгыз шатлык!
Беркайчан да, беркемгә дә
Шатлык ул булмый артык.

●

Икмәк булса табында,
Кемгә дә кысан түгел.
Чын дуслар җыелганда
Җитеп тора бер телем.

●

*Һава торышы турында әйтелгән*
*хәбәрләргә карата*

Болытлар килә,
Яшеннәр чатный —
Ут чыга.
Ә син,
Җир, чыда, чыда!
Ә син, кеше, тыңла, тыңла!
Табигатьнең бу
Бәлки сүзедер.
Бәлки кайгыны,
Бәлки шатлыкны
Алдан сизүдер.
Бу галәмәтне
Син аңлыйсыңмы?
Тавышны узып очканда,
Син артта калмыйсыңмы?

## Мөдәррис Әгъләмов

### Татарстаным

Шагыйрь дустым, сәяхәттән кайткач,
Әйткән иде, Татарстаным.
Картадагы синең сурәтеңнең
Чабып барган атка охшавын.

Ничек кенә әле чабасың син,
Томырылып, Татарстаным,
Ялларыңнан чытырдатып тотып
Синең белән мин дә очамын

Синең белән ул — без мәртәбәле,
Синең белән ул — без канатлы.
Бабаларым атларыннан егылып
Ничә тапкыр борын канатты...

Ярый әле, шундый заманнарда
Югалмаган күрү сәләте.
Егылганда авырткан җир була, —
Таныш нәрсә бу хәл, гадәти.

...Башка халыклар күк безне дә бит
Революция уяткан!
Без чабабыз,— еллар очкын булып
Очып кала безнең тояктан.

Без чабабыз еллар, чорлар аша,
Яңгыратып бөтен тарафны...
Иле белән кеше мәртәбәле.
Иле белән кеше канатлы.

## Фәнис Яруллин

### Мәңгелек мирас

Кайта-кайта укый торган
Бар минем бер китабым.
Кадерле, бик тә кадерле
Миңа һәр бите аның.

Ул китапта уелып калган
Бабамнарның имзасы.
Халкым сөялле кул белән
Язган аңа сүз башы.

Кара кан белән язылган
Кайбер битләре аның.
Күп сер саклый ул эчендә
Үзе кебек дөньяның.

Меңнәр язган бу китапны,
Меңнәр аны төзәткән.
Меңнәр аны матурлаган,
Меңнәр аны үзгәрткән.

Ул китапның битләренә
Имза салган Ленин да.
Күчкән ул зур мирас булып
Буыннардан буынга.

Иң кадерле, иң зур байлык
Булуын беләм аның.
Ул — минем азат, иркле
Җирем — Татарстаным.

## Рәдиф Гатауллин

### Йокы юк шагыйрьгә

— Нишлиләр алар?..
— Татарны строй аша куалар. Качкан өчен..

Толстой. «Балдан соң».

Китап, мин... Мин, китап... Толстой. «Балдан соң».
Төн, синме озын? Ник йокы качкан соң!
Белмим мин, бүген таң атармы?
Бик сәер төш кебек — бер аваз:
— Татарны... татарны!
Уемнан кичәме үткәннәр ачысы?
Халкымның түккән яшь, гамь, моңы, сагышы?
Бетәргә боерган патшалар әмере?
Тел, дин, җан коллыгы — тарихның җәбере?
«Татарга һәм эткә рөхсәт юк!» —
Авыздан китмиме шул чорлар әреме?
Юк! Халкым ирекле, ул азат, Ватанлы.
Артта ул канлы юл, еракта ул калды!
Тату, дус гаилә без — илдә Татарстанлы.

...Тик җирдә, дөньяда, бүгенге заманда
кемнәрдер кемнедер кыйныйлар һаман да.
Ак тәнле, сарымы, карамы —
кемнәрдер бүген дә яралы,
таяклар, чыбыклар сызгыра — кара әле!
Кыйныйлар негрны, индеец, ирландны...
Димәк ки, мине дә, димәк ки — татарны...

Дөньяның азмы әле царизмы, цезаре?
Кыйный ул һаман да, кыйната,
аркада чыбыркы уйната...
Юк, җанны кыйный ул, намусны яралый.
Пакь рухка, исемгә яга тап, яла ул!
Бүгенге «шпицрутен» — камил ул, яңа ул,
строй үтәли кемнәрдер уза гел,
сүз, гайбәт кыйный, күр, суга тел:
яшереп кемнеңдер тарихын, үткәнен
үч ала кемнәрдер!
Таяклап үткәрә илне ил!

Кем кабат ташлар соң бер набат, кем бүген?
Дөньяга дәшәр кем?
Кайда сез: Каласны яклаган Вольтер, кил?!
«Эндәшми калалмыйм» диюче Толстой?!
«Гаеплим!» — дип язган Золя, син?
Нәфрәтен әйтәлгән зыялы — Чехов? Кем?
Яклыймсыз хаклыкны? Кем белән сез бүген?!
Халыклар — дөньяда бер, игез,
тумыштан ирекле, дус, тигез —
мин шуңа ышанам. Шул уйда — коммунист!

Шуңа мин йокысыз, Толстой, «Балдан соң!»
Абсолют чынлыкка җитмичә,
дөньяда шундый чор килмичә,
йокы юк шагыйрьгә, тынгы юк.
Нәфрәтем шигырьгә ялгансын!
Җиңгәнче,
Фидельдәй, гамь төсе-сакалны без кырмыйк.
Таң аткач, көн килгәч? Күз күрер аннан соң.

Хәзергә — Толстой. «Балдан соң!»

## Мәхмүт Хөсәен

### Тоз турында баллада

*Революция солдаты, легендар чекист Николай Голубятников истәлегенә.*

Тоз кытлыгын кемнәр хәл итәр?
Тоз бөртеге — алтын бәясе.
Запас тозны урлый бандитлар —
Большевиклар белсен, янәсе.
«Талыйсыз, дип, илне ник алай?!»—
Эзләренә баса Николай.

Юлны кисә дошман шул чакта...
Берсен чекист сугып җибәрә.
Икенчесе, аны пычаклап,
Егып сала балчык идәнгә.
Юк, бирешми!.. Торып, яңадан
Мәлгуньнәрне тукмый каһарман.

Тагын тукмый — ул бит, постта бит,
Саркыса да каны ярадан...
Телгә килә кинәт пистолет —
Хаиннар үч ала аңардан.
«Хуш, Казаным!— ди ул.— Хуш, ярым!..
Үтәп үләм Ватан кушканын».

Батырлыгын аның ишетеп,
Дулкынлана Ильич Мәскәүдә.
Маяк итеп аны, тиң итеп,
Без сүз бирдек янып яшәргә.

Тормышы мул хәзер кешенең,
Тау-тау калка ак тоз комнары...
Гәүһәрдәй саф аның исемен
Горур йөртә Казан урамы.

## Энҗе Мөэминова

### Әлмәт

...Сөйли иден, эткәй, әкият итеп,
Безнең Әлмәт шәһәр булыр дип...

Автобуста шәһәр әйләнәм мин,
Кыңгыраулар чыңы күңелдә:
Кучер Вафа Әлмәт урамыннан
Ям чабадыр сыман бүген дә.
Күз алдыма килә, урам буйлап,
Шара сугып йөргән малайлар.
Чытыр арбасына лагун тагып,
Дегет эзләп йөргән агайлар.
Яшь баласын тартып, кыр түренә
Таңнан эшкә киткән әнием.
Ат дагалап, чалгы, төрән таптап,
Һөнәрчелек иткән әтием.
Кулдан суккан кирпеч өемнәре,
Алачык һәм күмер базлары;
Тар тыкрыклар буйлап тезелеп киткән
Чабата һәм чүлмәк базары...
Күз алдыма килә.
Базар беткәч, акча тапмаммы дип,
Йөргән чагым, чүп-чар актарып.
Күзгә төртсәң күренмәслек төндә
Лайга батып кайткан чакларым —
Күз алдыма килә...
Тукталышка җитәм. Уйларымның
Очы бүгенгегә ялгана:
Әткәм нигезеннән күтәрелгән
Европага мәшһүр калага!...

### Сәгатьләр

*Чистай сәгать заводы осталарына*

Манарада — сәгатьләр,
Стенада — сәгатьләр,
Сәгатьләр — өстәлдә, кулларда, кесәдә...
Сәгатьләр — космоста! Океан төбендә!
Вакытны саныйлар, кисәтә-кисәтә:
«Ва-кыт кит-ми...»
«Ва-кыт ки-тә...»
«Ва-кыт кайт-мый...»
«Ва-кыт ү-тә...»

## II

Көн килә сәгатьләп, төн җитә сәгатьләп,
Җан җаннан аерыла, бөреләр ачыла,
Таң ата билгеле сәгатьтә —
Кешеләр язмышны үлчиләр сәгатьләп:
«Кадерле сәгатьләр...»
«Каһәрле сәгатьләр...»
Кемнеңдер дөньяга сабые килгәндер,
Кемнәрдер, кайдандыр, кемнедер көтәдер.
Дөньяның күп гаме бәйләнгән сәгатькә:
Кемнәрдер киләдер, кемнәрдер китәдер —
«Хәерле сәгатьтә!»
«Хәерле сәгатьтә!..»
Кемдер юл башлаган, кемдер эш башлаган,
Кемнәрдер кемнедер югалткан, ташлаган.
Кемнеңдер суккандыр иң соңгы сәгате —
Сылтыйлар сәгатькә:
«Башланган булгандыр
Хәерсез сәгатьтә!..»
Бер минут кичегү, бер минут ашыгу —
Кемгәдер фаҗига, үкенеч, югалту!
Кемнедер битәрләү, кемгәдер күз яше,
Кемнедер файдасыз юату!—
Никадәр тегәллек сәгатьтә!

## Җыр

«Никахлашу йорты» каршында мин.
Бәхетлеләр белән очрашам.
Ак күгәрчен, кара карлыгачтай
Яшь парларны күздән озатам.

Аллы-гөлле машиналар белән
Шушы йортка яшьләр килгәндә,
Күңелемдә, алар өчен язар
Җыр дулкыны туып тибрәлә.

Яшь парларны котлап күтәрелгән
Бокалларның чыңы килгәндә,
Гаҗәп матур, моңлы бер көй булып
Җыр дулкыны миндә тибрәлә.

Гөл бәйләме тоткан Ак күгәрчен
Һәйкәл нигезенә иңгәндә,
Бар дөньяга яңгырарга теләп,
Җыр дулкыны миндә тибрәлә.

Гомеремнең бөтен сәхифәсен,
Тормышымның бөтен сукмагын
Бик җентекләп күздән кичереп мин
Шул туачак җырга тупладым.

## Горурлыгым

Кеше җирдә йорт-җир, нигез кора,
Тимәсен, дип, җилләр, салкыннар.
Зур илемдә минем өем, гаиләм —
Республикам, туган халкым бар.

Бу дөньяда мин бер ятим түгел,
Горурлыкка тулы хакым бар:
Тигезләргә мине тигез иткән
Республикам, туган халкым бар.

Ил йомышын кайда үтәсәм дә,
Сынатмаска дигән антым бар —
Балаларын күреп, сынап торган
Республикам, туган халкым бар.

Ямансулап калсам мин еракта,
Үзәгемә үтсә салкыннар,
Җылысына кайтып сыенырга
Республикам, туган халкым бар.

## Онытылмас җыр

*Мостафа Ногман истәлегенә*

Нурлы гомерең янып, илһамланып
Әйтер чакта шигъри сүзеңне,
Диңгезләргә чумган йолдыз кебек
Күңелләргә сызып өзелде.

«Бөек» исмен йөрткән әдипләр бар,
Үлмәс данга ия шагыйрьләр.
Ләкин җирдә син юклыгын тоеп
Өзгәләнә безнең бәгырьләр.

Мәхәббәтнең һәм дуслыкның үзенә
Лаек җырын бирдең чорга син.
Дуслыкка син үзең тугры идең,
Мәхәббәттә — үзең чын гашыйк.

Киләчлегең белән нурлы Казан
Синнән башка моңсу, ямансу,
Саф күңелле кеше, хисчән шагыйрь,
Күңелебездә безнең һаман син.

## Илем төренә тагын комачларга

Илем төренә тагын комачларга,
Бөек халкым көтә бәйрәмен,
Колачларын җәеп кояшларга,
Байрагына җыеп бар ямен,

Чыгар тиздән зур-зур мәйданнарга,
Шат авазга күмәр дөньяны.
Хезмәтендә ирешеп зур даннарга
Таң калдырыр бөтен җиһанны.

Хисап бирер бөек эшләреннән
Гасыр күрке булган алыплар.
Һәм кул болгар, сөенеп эчләреннән,
Җирдәге бар илләр, халыклар.

Шул төсеңә, илем, җан күнеккән,
Син югалтма шушы сыйфатны.
Шул киемнән бар син мәңгелеккә,
Шушы йөзең белән син затлы!

## Укучының күңел дәфтәренә

**Карел мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Теләсә нинди нарат та үз урманына шаулый.*
*Телең белән ашыкма, эшеңдә тиз була бел.*
*Бер саздагы җиләкне ике кат җыеп булмый.*
*Бәп-бәләкәй очкыннан зур-зур авыллар яна.*
*Ухасы бер җирдә кайнап, балыгы бер төштә пешә.*
*Яхшы башлап җибәрү — эшнең ярты уңышы.*
*Йөкнең авырмы икәнен җигелеп тарткач беләсең.*
*Мылтыгы зур, дарысы аз.*
*Кешене күзгә матур итәлми.*
*Яхшыны тиргә «бозылма» диеп, яманны тиргә төзәлсен өчен.*
*Кар өстендә чүп, чүплектә алтын күренмичә ятамый.*
*Йорты нарат урманында, ә үе — каенлыкта.*
*Сулыш өреп җил чыгарып булмый.*
*Елыйсың да, көләсең дә шул ук бер авыз белән.*

## Аяз Гыйләҗев

# ҖОМГА КӨН, КИЧ БЕЛӘН...

ПОВЕСТЬ

— Вальпараиса, Галапогос, Титикака, Куала-Лумпур — шәп яңгырый торган исемнәр, беләм! Әмма минем өчен Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк яңгырый! Кадерле булганга күрә шәбрәк!

*Авторның уз сүзләре.*

— Бу тарихны ишеткәч, мин ул әбинең болдырына утырып озак кына еладым..

Тәрәзәләре томаланган япа-ялгыз йорт. Башка корылмалар күптән ишелеп беткән. Үтә шомлы төн иде. Кап-караңгы булса да, череп укмашкан кара саламны әрсез җил иркенә бирмичә түбә өстенә рәт-рәт тезелешеп яткан нәп-нәзек каен бастырмалар ап-ак булып күренеп тора. Карчыкның бөек рухы белән саубуллашып китә башлагач, борылып карадым: сәҗдәгә чүккән өй дә, аның ак төшкән йомык тәрәзәләре дә юк иде, әнә шул, сабый бала беләге юанлыгы, иртә киселгән каен кәүсәләре генә мыштым гына, каядыр серле, без белмәгән мәңгелек елгасына таба йөзәләр төсле тоелды.

*Габдулла абый Юсупов сүзләре.*

— Уф, йөрәгем! димәс идем,
Янулары басылса!

*Татар халкының яраткан җыры.*

1



Өстән, тауга менеп карасаң, Ташлыяр елгасын кодрәт белән сызып куйганнар диярсең: нәкъ көнчыгыштан көнбатышка таба шактый җәенке төпле үзәнне урталайга телеп ага-ага да, Аксыргак авылына җитәрәк икеләнеп кала — бөргалана башлый, алай гынамы әле сиңа, ындыр артларына сырышып, куе кучкылланып үскән таллар арасына кергәч, беразга күздән югалып та тора. Авылның Түбән очына җиткәндә, Аксыргакның таудан бәреп чыккан биш чишмәсен дә үзенә алып, тагын ачыла Ташлыяр. Түбән очта нигәдер үксезләр, толлар һәм фәкыйрьрәк хуҗалыклар яши, ярдагы талларны кышлыкта утынга кисеп бетерәләр, елга ишәеп ачыла, киңәеп бер урында иркен сулыш ала — тугай ясый, аннан кинәт тарая, ярлары текәләнә, агымы тизләнә, ярга бәссаң аккан тавышы ишетелә башлый һәм ашыккан агым авылның Зәйгә чыга торган очында өч өйне аръякта калдырып кинәт көньякка юл ала.

Соңгы елларда Зәйдә ГРЭС салдылар — ул тирә-як авыллардан байтак чуар йөрәкләрне жыйды. Аннары Түбән Кама, Чаллы төзелешләре чоры башланды, гигант заводлар моңарчы йөрергә артык яратмаган, үз авылыннан кыз алып, үз авылына кыз биреп яшәгән Аксыргактан да бик күпләрне үзенә суырып алды, авыл уртасындагы дәрәжәле урыннарда да буш ихаталар ешайды, йорт хакы шалкан бәясенә төште. Ташлыяр аръягында «аерылганны аю ашар!» дип зарлана-зарлана, бигрәк тә кышкы бураннарда, көзге пычракларда курка-шүрли яшәп яткан ятим-ялпы хужалыклар да тиз-тиз авыл уртасында бушаган пужумнарга күченделәр, һәйбәт, заманча алты почмаклы, биек-биек йортлар салып куйдылар.

Зәй юлы өстендәге өч пужум байтак елларга иясез калды; андасанда тырпаеп калган усак баганалар череп ауды, баз урыннары ишелде; ишегалды, мунча урыннарын кычыткан, ак әрем һәм алабута басты. Нигез ташларында жәй буе кәлтә еланнар арка жылыттылар.

Яткын жирләрне үзләштерү шаукымы тар жирле Татарстан авылларыннан узган иде, шуңа күрә аръяктагы бу урынга кызыгучы да, күз салучы да табылмады, жир, мөгаең, шактый еллар шулай буш килеш ятыр да иде, колхозга яңа председатель килде.

Аксыргак авылының район читендә, чиккә урнашканын да искәртеп үтик, төньягында юаш таулар тезмәсе, тау өстендә кара урман, урман артында яңа район башлана, Аксыргакка беренче тапкыр читтән килгән председатель Жиһангир Сәфәргалин әнә шул күрше районнан, урман артында озын бау булып сузылган бер генә урамлы Тегәржеп авылыннан иде.

Ике авылны тау-урманнар гына аерып торса да, ике район колхозлары булгач, аларның арадашлыгы чамалы гына иде. Шуңа күрә Жиһангир Сәфәргалинне сагаеп, өнәмичәрәк каршыладылар, жыелыш азагында, арткы рәтләрдән: «Үз авылында эш беткәнмени аңа?!» «Нигә читтән кеше китереп йөртергә, чит чит була инде ул!» дигән ризасызлык тавышлары да ишетелгәләде.

Жиһангир Сәфәргалин читтән килгән булса да эшне чын хужаларча башлады. Председатель башкарырга тиешле бик күп мөһим эшләр рәтеннән ул иң әүвәл урам-тыкрыкларны рәткә керттерде, тракторларның эресен-вагын ел әйләнәсендә урамга керүдән катгый тыйды. Урам як коймаларын, өй түбәләрен тиешле тәртиптә тотуны таләп итә башлады. Ермакларны, вак-төяк мәкерле коры сызаларны күмдереп бик күп жирләргә агач утырттырды. Кушып, билгә таянып кына тормады, башлап үзе йөрде, урман хужалыкларына, питомникларга барды, агач орлыгын, үсентеләрне юллап үзе тапты; бер дә иренмичә агач чокырларының тирәнлеген, киңлеген вакчылланып кирәк сабы белән тикшереп йөрде, тамырлары имгәнмәсен өчен нәзек, зифа каеннарны бәби биләгән төсле генә күтәреп йөртүләрен үтенде, тәртип бозучыларга каршы шәфкатьсез дә була белде.

Яз саен «менә китәм, менә китәм!» дип авыл халкын куркытып дер калтырап утырган иске агач күперне жимереп, Аксыргак тарихында беренче буларак, Ташлыяр аша челтәр тимер култыксалы таш күпер койдырды. Югары очлар да, Түбән очлар да рәхәтләнеп тау ягындагы алачыкка, тау өстендәге урманга выж да выж үтеп йөри башладылар.

Каян жаен, сәрмәясен табып бетергәндер, күрше районнан да машина-машина бетон плитәләр килде, нефтьчеләр ул ни сораса шуны бирделәр, арматура, төрле диаметрдагы торбалар төягән дәү-дәү озын машиналар дөбер-дөбер тоташ килеп йөрделәр.

Алдагы елда Сәфәргалин зират коймасының баганаларын бетон белән алмаштырды, урам чатларына лампочкалар элдертте, лампоч-

калар кич саен янып тормаса, монтерга бик нык әләгә иде: «Ильич лампалары алар, исеңдә тот шуны!» дип кисәтә иде ул тыңлаусыз монтерларны.

Аксыргак яшьләрен сөендереп, күрше авылларны көнләштереп клуб, кибет, мәктәп тирәләрен асфальт белән каплатты.

Ни хикмәттер, моңа карап колхозның эше һич тә артка китмәде, Сәфәргалиннең «килгән-килмешәк» икәнлеге бөтенләй онытылды, аны яраттылар.

Җиһангирның иң соңгы мактаулы эше шул булды: Түбән очта, Ташлыяр кинәт кенә тарайган урында, елганы будырттты. Бер ел әзерләнделәр, икенче елда башкарып та чыктылар. «Казларга чумарлык, киленнәргә рәхәтләнеп кер чайкарлык, ә кайберәүләргә арык шавын тыңларлык булсын!» диде ул киңәшкә җыелган идарә членнарына.

Диде дә, моңлы күзләрен тутырып карап тынып калды. Бик зирәкләр дә аның тиз генә сул күкрәгенә кагылып алганын да, киңчә битеннән йөгереп узган аксыл-тонык шәүләне дә сизми калдылар.

Казлар су тулганны да көтмәделәр, «как-как-как!» дип, мең авызга куанышып буа өстенә кереп тулдылар. Башта сыеша алмыйча талашып, чукышып маташканнар иде, су җәелгән саен аларга урын киңәйде, казлар аерым-аерым ак утраулар булып куанышып йөзә башладылар.

Киленнәр дә озак көттермәде, шәрә балтырларын кызыктыргыч ялтыратып алар да төшеп җитте, бер-берсенә сәлам бирешә-бирешә, бәләкләре белән тукмап, кер юарга да керештеләр.

Арык шавының кемгә хаҗәт буласын ул чагында әле берәү дә уйлап карамады, Җиһангирның сүзен уен-көлке, мәзәк дип кенә кабул иткән кешеләр аны шунда ук оныттылар да.

Буа алдына тамаша карарга байтак кеше җыйналган иде.

«Баегач, мәңгелек итеп, тоташ бетоннан коярбыз буаны, — диде ул аларга карап. — Һәр буын авылга һәм колхозга үзеннән нидер яңалык өстәргә тиеш. Шунсыз авыл кешесе үзен колхозда бары тик кунак кына итеп тоячак! Берәүләр колхоз төзегән — урыннары тарихта. Берәүләр исә, манараларын кисеп ыргытып, мәчетне мәктәпкә әйләндергән, аларны да онытмыйбыз. Яхшы! Икенче бер буын агач келәтләр, ясле, балалар бакчасы, кардалар салган. Һәркемнең, һәр буынның сагынып сөйләрлек өлеше кергән. Беркем дә ата-бабалары кылганны механик рәвештә кабатлап кына яшәргә риза түгел, һәркем үз гомерен үзенчә уздырырга омтыла. Әгәр без һәр буынга шундый җаваплы эш йөкли алмыйбыз икән, яшьләребез авылда калмаячак. Яшьлеккә — сыналырлык эш кирәк. Әйдәгез, без яшеллек турында, урамнарыбызның һәм күңелләребезнең яктылыгы турында, җыеп әйткәндә, матурлык турында үз буыныбызга хас рәвешчә кайгыртыйк. Байлыгыбыз бар, алда авыл халкы тагын да байый төшәчәк. Байлык — кешенең холкын, фигылен бик тиз үзгәртүче куркыныч нәрсә дә ул! Әгәр без яшәргә өйрәнмәсәк, тук корсак колларына бик тиз әйләнәчәкбез. Революция өчен көрәштә корбан булган ата-бабаларыбыз гафу итәрме моны? Байгураларны, шәхси милек коллары — кулакларны себереп түккән агаларыбыз безне кичерерме? Гомергә кичермәс! Безнең буын байлыктан дошманлык, карунлык, мещанлык, күремсезлек түгел, нәкъ шуларның киресен — туганлык һәм матурлык тойгылары тәрбияләү юлын эзләп табарга тиеш. Байлыгыбыз яхшылыкка хезмәт итсен! Бүгенгә төп бурычыбыз шул. Байлыкка саклык аша барырга кирәк!»

Яңалыгы онытылып беткән председательнең бу сүзләрен яңа итеп,

сәерсенеп тыңладылар. Бер чакта да аның шулай озын итеп, кызыпкайнарланып сөйләгәне юк иде бугай.

Көрешүе идеме бу аның, хушлашуымы?!

Бусын әле җыелганнар аңлап бетермәделәр, сүз буа алдында гына әйтелсә дә, аңа гөрләтеп кул чаптылар.

Моннан байтак еллар элек, председатель булганда, аксыргаклыларны район сводкаларындагы иң актыккы сызыкка төшергән бер бәндә, «Сәфәргалин колхоз байлыгын вак-төяккә, гел кирәк булмаган нәрсәләргә исраф итә» дип, өч адреска анонимка әзерләп куйган Габдрахманов, буа буенда халыкка кушылып уч төбе авырткаңчы кул чапты да, ашыга-ашыга кайтып җитеп, хатларын ертып ташлады һәм гомердә булмаганны эшләде — күңеле нечкәреп, хатынын куенына алып тынычланып йоклады...

Болар белән генә тынмады Сәфәргалин, буа аръягында калган теге буш урындагы өй-баз чокырларын бульдозер белән тигезләтте, койма белән әйләндереп алып, бөтен кишәрлеккә каен аралаш яшь чыршы күчереп утырттырды. Бакча уртасында шәһәрдән килгән осталар гади генә, дүртпочмаклы мәрмәр һәйкәл койдылар. Һәйкәлгә дә гап-гади сүзләр язылды: «Сугышта һәлак булган авылдашлар! Без сезне онытмадык!»

Аннан һәлак булганнарның исемлеге рәт-рәт тезелде.

Бусына да кул куйдылар аксыргаклылар, Сәфәргалинне мактадылар, әмма аръяктагы бакчага, һәйкәлдән ерак та түгел урынга, тәрәзәләрен буа өстенә каратып авылның почта бүлекчәсен төшереп утырткач кына авылда бераз сүз кубып алды, монда инде фикерләр бердәм түгел иде. Аерата Югары очлар зарланды: «Безгә байтак җир йөрергә туры килә ич, авыл уртасында, мәктәп янында торса почтага ни була иде? Ни кирәк тагын бу тынмас җанга?!» диештеләр алар.

Мәгәр председательнең һәр хәрәкәтеннән мәгънә һәм тәм таба башлаган аксыргаклылар бу сүзләрне әйттеләр дә почтаның ераклыгына үзеннән-үзе күнектеләр. Почтаның авыл очында, буа янындагы бакчада булуы аларга ошый да башлады. «Рәхәтләнеп бер йөреп кайтасың ичмасам, кеше күрәсең, яңалыклар ишетәсең!»

Җиһангир Сәфәргалин кырык дүртенче яшенә чыккач, язгы кыр эшләре төгәлләнеп, сабан туена нәкъ бер атна калды дигәндә кинәт вафат булды. «Йөрәк» диде врачлар...

Аксыргаклылар «аһ!» иттеләр.

Үзе башлап йөреп, үзе беренче каеннарны утырткан яшь бакчага, Ватан сугышында һәлак булган батырларга атап куелган һәйкәл янына күмәргә теләп бик нык йөрсәләр дә, әтисе Җиһангирны монда калдырырга ризалык бирмәде. «Ниятегез изге, туганнар, бик аңлыйм, бик рәхмәт сезгә, улымны олыладыгыз, әмма Сәфәргалиннәрнең Тегәрҗеп авылында үз кадерле почмаклары бар, әби-бабалары шунда күмелгән. Вакытсыз китеп барган улымны да шунда җирләргә телим. Ичмасам, улларымның берсе булса да үз янымда булыр, өч абыйсы Европаның өч илендә ятып калды», диде.

Олы кешенең олы сүзенә ни димәк кирәк?!

Машина әрҗәсен кызыл комач белән тоташ урап кыйммәтле келәм җәйделәр, келәм өстенә кызыл белән чорналган табут куелды. Күрше тирә-яктан зур-зур кешеләр килде, район җитәкчеләре, председательләр берсе калмый Аксыргакка җыелды, һәйкәл алдында матәм митингасында кайгылы-тантаналы сүзләр әйтелде, антлар бирелде. Җиз трубаларын язгы кырлар, язгы көләч авыллар өстенә көлеп караган ак кояшта ялтыратып музыкантлар кайгы көйләрен туктаусыз уйнап тордылар...

Буа тавышын шул чагында беренче тапкыр аермачык ишетте Бибинур карчык. Музыка тавышын бүлергә теләп, кешеләрнең кайгыга уралып авырайган сүзләрен йотарга ашкынып, туктаусыз шаулый иде буа арыгы... Шул минуттан ул үзенең кылган гамәлләренең сәбәп-нигезен аңламас хәлгә килде: Тегәрҗеп авылына карап Җиһангир Сәфәргалинне соңгы юлына алып чыккан машинада, мәрхүмнең аяк очында, йомылып кына, орчык башы хәтле бәләкәй карчыкның бөршәеп утыруын берәү дә күрмәде, берәү дә аннан: «Кая барасың син? Анда сиңа ни калган тагын? Нишләп монда, аяк астындаураласың», дип гаҗәпләнеп сорамады. Күрмәүләре, күргәннәрнең кызыксынмавы өчен карчык аларга күңеленнән генә кат-кат рәхмәт укыды, исән калганнарның һәммәсенә озын гомер теләде.

Ничек аңлатыр иде сорасалар? Ни дип җавап табар иде?

Кеме соң аның Җиһангир?

Нигә Тегәрҗеп авылына кадәр үк озатырга уйлады аны Бибинур? Байтактан колхозның олы эшләреннән читләшкән карчыкның председатель белән арадашлыгы да чамалы гына иде түгелме? Урамда очраганда «Нихәл, әби? Тормышың көйлеме?» дип сорамыйча узмый иде узуын мәрхүм... Аңысы да күңел аклыгыннан гына иде ич аның!

Белә Бибинур, аңлый, председательнең эше бер өер тавык та чүпләп бетерерлек түгел, беркем Җиһангирның утырып торуын хәтерләмәс, гел хәрәкәттә, гел аяк өстендә иде, идарә утырышларында да ишекле-түрле йөреп торыр иде, бер генә мизгелгә тәрәзә каршына барып уйланып алыр иде дә, тагын кузгалып китәр иде. Ачык тәрәзәләрне, ярата иде мәрхүм, Бибинур карчыкның гаҗәпләнеп карап үткәне бар, көзнең соңгы көннәренә хәтле председатель кабинетының тәрәзәләре ябылмаган, сыланмаган булды.

Нигә утырды ул бу машинага?

Әнә ич, күпме кеше — председательгә аннан битәр мен якынраклар басу капкасы төбендә кайгы төене булып укмашып озатып калдылар. Рәхмәт, калучылар арасыннан да «бу исәр карчык дегет лагуны булып тагылып кая кадәр бара инде?» дип сорап калучылар күренмәде.

Машиналар аның хатирәсе булган таш күперне тавышсыз гына уздылар, гарип каз бәбкәләре кебек сөрлегешеп берәм-берәм тауга мендeләр. Алданрак меңгәннәре башкаларны көтеп торды. Тау башында җил иде, пешеп килгән башак исен сеңдергән җил Җиһангирны каплаган ак җәймәләрнең чите белән уйнады, аның бөдрәләнеп торган йомшак чәчләрен балавыздай сары битләренә сибеп-сибеп куйды. Тургайлар берөзлексез сайрап аларны озата бардылар.

Тау башына менеп туктагач ул ирексездән аска, Аксыргак авылының күз күнеккән чуар нокталарына һәм зур булып, җәйрәп яткан буага карады. Буа да аның хатирәсе иде...

Урманга кергәнче ул башын күтәреп тә карамады. Җил тынды, Җиһангирның йөзе күренмәс булгач, Бибинур беркемгә ишетелмәслек итеп сызгырып җил чакыра башлады...

Зират капкасы төбендә аларны кара болыт булып Җиһангирның авылдашлары каршылады. Капка төбенә җитәрәк ул да машинадан төшеп шул төркемгә кушылды.

Кемнәрдер көчле куллары белән табутны күтәреп алды, халык, савылып, мәһабәт тынлык саклап, эчкә керә башлады, Бибинур карчык, хатын-кыз буларак, әдәп саклап койманың бу ягында калды.

Тегәрҗеп зиратының күкне терәгән юан-юан тупылларын, эре-эре ботаклы, кабыклары түбырланып беткән наратларын читтән генә карап, «колһуалла»сын укып үткәне бар иде Бибинурның, менә бүген ят зират тирәли тилмереп, яшь коеп йөрергә язган икән...

Димәк, аның юлының соңы шушы. Дөньяның шушы тын ноктасында мәңге йоклаячак Җиһангир Сәфәргалин... Моннан соң аның ике кулын көч белән як-якка селтәп йөрүен беркем дә күрмәс, тап-таза тешләрен күрсәтеп башын чөеп көлеп җибәрүен беркем дә ишетә алмас. Исәннәр, исән чакта, аны хәтергә алырлар да җиргә яңа буын килер, алары онытырлар...

Җеназа башланды. Олысымак кыяфәтле, чибәр-чибәр киенгән кешеләр монда да сүзләрне сайлап кына сөйләделәр. Бибинур карчык ишеткәнен ишетте, ишетмәгәннәрне үз күңелендәге уйлар белән тутырып торды. Китап сүзләре сөйли белми иде ул, дин ягына килгәндә дә белгәне сай, бар очракка да шул бер үк әлхәм сүрәсе белән колһуалла ярап торды, сөенгәндә дә, көенгәндә дә алар таяныч булды. Тик бүген аның теле әллә нишләде, күңеленә моңарчы барлыгын да белмәгән гаҗәеп кадерле сүзләре килде: «Тар каберләрең киң булсын,— дип теләк теләде карчык, — исемең кешеләрнең якты күңеленнән мәңге онытылмасын. Кыямәт газапларын татыма, бар гөнаһларың кичерелсен, оҗмахлы бул! Чөнки син кешеләргә бары тик матурлык, аклык кына теләдең. Авыр туфрагың җиңел булсын! И илаһым! Тагы да газаплар җибәрмә аңа!» — дип кат-кат инәлде ул.

Ятим, япа-ялгыз карчык кем өчен еласын, байтактан күзеннән яшь чыкканы юк иде, бүген күз төпләре рәхәт кычытып дымланды, ул, әрвахлар тынлыгын бозарга базмыйча гына, кытыршы коймага маңгаен терәп, елый башлады, елый-елый җиргә чүкте, тезләнде, ачы тамчылар иреннәргә төшеп житте, карчык иреннәрен кысып-кысып тешләсә дә, авыз һаман кыйгаеп ачылды, аннан ярым ыңгырашу, ярым хушлашу авазлары дөньяга туктаусыз чыга тордылар. «Хуш, Җиһангир балам, хуш, асыл затым, хуш, нәнәм! Мәңгегә хуш!» дип байтак үрсәләнде Бибинур.

Ул исенә килеп зират тирәли урап чыкканда мәетне куйганнар, халык таралышкан, бая бергә килеп тыгылган машиналарның чуар-чуар эзләре генә чирәмдә кисешеп калган иде. Әнә, мәеткә соңгы сәламнәрен тапшырып, кулларын артка куеп, акрын гына атлап соңгы догачылар — картлар кайтып бара. Алар арасыннан бер генә кешене — кызыл сакаллы, кып-кызыл, яргаланган түгәрәк йөзле Вәли картны — Җиһангирның этисен генә таныды Бибинур. Аксыргаклылар байтактан киткән, ахрысы, юлда машиналар юк иде инде.

Аның аягы атламас булды, ул койма кырындагы җылы җиргә утырды, беләгенә сыгылып төште һәм беләкләренә капланып тагын озак кына елады. Күз яше кибеп бетмәгән икән аның, җанында җылы калган икән әле!

Тик нигә аны берәү дә күрмәде соң әле? Юлда булсын, монда булсын — беркем игътибарга алып тормады. Күренеп йөрсә эндәшмичә калмаслар иде! Шул чагында аның тәшвишләнгән күңеленә сәер бер фикер килде: бәлки ул үзе йөрмидер монда, күбәләк канаты кебек үтә күренмәле җаны гынаияреп килгәндер Тегәрҗепкә?! Әтәне анда, авылда калгандыр?

Шул уй күңеленә иңгәч, ул капыл гына урыныннан кузгалды, күлмәк итәгенә сырышкан әрсез үлән орлыкларын кагып та тормыйча, зират капкасыннан читкәрәк китеп, корырак урынны сайлады, коймага аркасын терәп утырды, арыган аякларын сузып җибәрде. Шактый вакыт узды бугай. Тик вакытның да әһәмияте юк иде инде Бибинур өчен, аның йомык күзләренә иплән кенә йокы инде. Йокыга китте дә төш күрде. Төшендә ул болында иртәнге томанда чабышып йөргән ак атларны күрде. Ак атларның сырты өстеннән туктаусыз күе томан агылды. «Нигә сезнең колыннарыгыз юк? Кайда сезнең колыннарыгыз?» — дип кычкырып сорады ул ак атлардан. Атлар җавап урынына кешнәделәр генә, арадан берсе Бибинур янына килеп аңлатып бирле;

«Бар безнең колыннарыбыз, бар. Тик алар бик еракта, еракта, Каф тау артында!» «Нигә алар Каф тау артында?» дип сорарга тели Бибинур карчык, ә иреннәре йомык, ачылмый... Авызын убырлы карчык пичәтләп киткән, имеш...

Ул тупырдаган тояк тавышына дертләп уянып китте, шактый вакыт кайда икәнен аңышмыйча башын селкеп утырды. Күлмәге аркасына жилкән кебек киерелгән житү чәчле малай жирән айгырга менеп алган да жилдерә генә! Якыннан гына чабып узса да, ул Бибинур карчыкны күрмәде бугай... Шул инде, яшьлекнең күзе үткен булса да, ул, гадәттә, үзе эзләгәнне генә күрә. Картлыкның күзе томанлы булса да, ул башкаларга кирәкне дә күрә белә. «Ат жиленнән суык алмасмы бу жилсәйне?» дип уйлады Бибинур, иңбашларын калтыратып. Малайның аны күрми үтүе баягы шиген арттырды: «Бармы әле мин бу дөньяда? Әллә жаным күбәләк булып кына Жиһангир артыннан очып килдеме?!»

Йокыдан уянгач та аңа суык булып китте, жир өстенә мыштым гына кичке дым йөгерде, тургай тавышлары тынды. Зират агачларындагы кошлар да шаулап туктадылар. Ул, торырга да иренеп, күлмәгенең тирән кесәсенә тыгылды һәм калтыранган кулы белән ике кап шырпы эзләп тапты. Берсе башланмаган да иде. Капны күзенә якынрак китереп сурәтенә карады: анда озын яллы, ап-ак ат колынын ияртеп каядыр чаба иде...

Ул тирә-якка күз йөгертеп ягарга әйбер эзли башлады, якында гына коры куралар, койма койганннан калган вак-вак йомычкалар күреп сөенде. Йомычкалар шылтырап торган коры иде. Әнә, сынган коп-коры чаңгы кисәге дә бар, утынга ярар, әйдә, дип уйлады ул.

Күрән, коры кура йолкып алып бер урынгарак өйде, такта-йомычкаларны иплән кенә шакмаклап тезде, чүгәләп ут тергезде. Утны һәм жылыны ярата ул. Ут куанычы иң элек тәнгә түгел, күзгә йөгерә торган була. Ут барында кеше бер чакта да ялгыз һәм мескен булмый. Аккан суга һәм янган утка карап кеше әллә никадәр тик кенә утыра ала.

Нәни генә учак Бибинурга ышанычлы иптәш булды. Тирә-якта караңгылык куерды, зират агачлары ботагына шомлы эңгер эленде. Берәм-берәм авыр, саллы йолдызлар кабынды. Ул урыныннан тормыйча гына учагына аз-маз йомычка өсти торды, күлмәк итәге белән аякларын төреп бик озак кыймшанмыйча утырды. Авыл ягыннан килгән аяк тавышларына сискәнеп калкынып куйды, көйгән кашы өстенә учын куеп, караңгылыкка текәлде.

Эндәшмәде, караңгылыктан сорау көтте.

— Кайсыгыз анда, әрвахларны куркытып ут яндыра? — диде карлыккан өлкән тавыш.

— Мин әле бу, — диде карчык юаш кына.

— Кем соң син? Нишләп монда утырасың?

— Мин идем, — дип кабатлады карчык, төшенке генә. — Тик утырам.

Килүче яктыга керде, Бибинур карчык йөрүчене Жиһангирның этиседер дип уйлаган иде, чыннан да, бу ул, Вәли карт иде. Ут яктысында аның кызыл сакалы тагын да жетерәк булып күренде.

— Күргән кешегә дә охшатам, танымыйм да бугай, — диде ул, учак ягына уйчан гына чүгәләп. — Кем соң син?

— Аксыргактан килгән идем мин, — диде карчык, караңгылыкка кулы белән изәп.

— Ә-ә, — дип сузды карт. — Машинада күрдем мин сине. Нишләп кайтып китмәдең соң алайса?

— Белмим, — диде Бибинур аптырап. — Машиналар киткән иде инде.

Вәли карт «җиңеләя башлаганмы әллә бу алла колы?» дип уйлады да, бик тиз ул уеннан кайтты, карчыкның бөтен кыяфәтеннән, бөтен тотышыннан кайгы кичерү бөркелеп тора иде.

— Әйдә, безгә кайтыйк, — диде ул, аны чын күңеленнән жәлләп.— Чәй эчәрсең, кунарсың. Минем улымны олылап килгәнсеңдер, рәхмәт сиңа.

— Кайтмыйм, — диде карчык, ап-ачык итеп. — Бүген сезнең кунак кертә торган көнегез түгел. Ничек чыдыйсыңдыр әле дә...

— Чыдамый нишлисең? — диде карт, кулындагы таяк очы белән утлы күмерләрне бер тирәгәрәк өеп. Ул җанына түзә алмыйча ишегалды тирәсенә чыккач зират ягына карады һәм имәнеп китте: бөтенләй көтелмәгән урында тычкан уты булып яктылык җемелди иде...

— Кем соң син Аксыргактан? Нәселең кем? Беләмме мин сине?

— Белмәссең дә инде. Безнең ир-атлар юк.

— Ирең кем иде соң?

— Ирем Габдуллаҗан атлы иде. Сугыштан кайтмады. Беләсеңме?

— Син теге игезек сыңарымы әллә? — дип сорады Вәли, азрак хәтерләп.

— Шул инде, шул. Атым Бибинур минем. Габдуллаҗан хатыны идем мин.

— Сезнең соң балалар да ишле генә түгел идеме?

— Ишле булмаса да бар иде... Өчәү иде. Хәзер таралыштылар. Ялгыз инде мин. Байтак гомер ялгыз.

— Сыңарың исәнме соң?

— Ул да исән. Җен ташы күк йөри.

Бибинур, зират янында җен исемен телгә алганына уңайсызланып, караңгыда оеп йокымсырый башлаган карт наратларга күтәрелеп карады. Беренче очрашкан кешесенә алай ачылып китми торган булса да, бу кешенең Җиһангирның әткәсе икәнен белгәнгә, тел яшереп торуны кирәк санамады ул.

— Күзләреңне күрмим, — диде карт бераздан.

— Нигә? — диде аптырап Бибинур.

— Күңелдәге — күздә диләр бит. Күзне күргәндә кеше белән сөйләшү җиңел.

— Ә сукырлар? — дип карышты карчык.

— Нәрсә сукырлар?

— Аларның күзен бирәү дә күрми бит.

— Аларның башка! Кем икәнлекләре чырайларына чыга аларның.

— Анысы шулай инде. Безнең авылның сукыр суфины хәтерлисеңдер әле?

— Хәтерләмичә...

— Кешегә борылса йөзе кояш күк балкып торыр иде бичараның. Гел елмаер, гел көлер иде... Зарлана белмәде. Шуңа күрә яраталар да иде кешеләр. Йөзгә житеп гүргә инде.

— Әйдә, кайтыйк, — диде карт, нык ук чакырып.

— Мин Аксыргакка кайтам, — диде карчык, бераз уйлагач.

— Төн бит! Куркырсың.

— Төн булса ни? Төнне яратам мин. Миңа кем тисен?

Икесе дә торып басты, икесе дә буйга тәбәнәк, ябык, какча иделәр.

— Хәзер берәр малайны табып китерәм, — диде Вәли. — Шоферны дим. Илтеп кайтыр.

— Төнлә машинага утырмыйм, — диде карчык, ашыгып-ашыгып.

— Ник?

— Акчаны чамасыз сорый алар.

— Гел утырмыйсыңмы?

— Утырганым юк.

— Егерме-утыз тиен жәл түгел инде, бирәсең!..
— Ә мин бирмим, — диде карчык киреләнеп.
— Ник? — дип кабатлап сорады Вәли һаман гаҗәпләнеп.
— Шоферның үз җилкәсенә утырып кайтмыйм ла мин!
«Характер бар бу карчыкта!» дип уйлады Вәли.
— Ул үзе дә утырып йөри. Машинаның теле булса ятим карчыктан акча сорап ятыр идеме, ә алар сорый!
— Мин илтеп кайтырга кушкач, сорамас.
— Олыны олы дип тормас.
— Кунган өчен акча сорамыйбыз, кайтыйк, — дип үгетләде һаман Вәли.
— Авылга кайтырга кирәк, — дип һаман карулашты Бибинур.
— Син кем белән торасың соң? — дип кызыксынды карт.
— Бер башым, — дип авыр гына көрсенде карчык. — Әллә кайчаннан бер үзем яшәп ятам.
Вәли «Балаларың кайда?» дип сорарга теләгән иде, ниятеннән кире кайтып:
— Алайса, куна калсаң да, сүз әйтүче булмас, — дип кенә куйды.
— Мич арасындагы чикерткәләр аптырар, — диде карчык тиз-тиз. — Кая китте безнең бу кортка, диярләр. Күрше-күлән әллә ни уйлар, югалтырлар.
— Чәй эчмичә барыбер җибәрмим.
Чәй эчәсе килә иде Бибинурның, баядан бирле авыз эче кибеп, иреннәре янып тора иде.
Бусына ул тиз ризалашты.
Зират капкасы яныннан узганда, ул тукталып Вәли картка карады.
— Улың янына кагылмадың...
Карт бераз дәшми торды.
— Озакламыйча үзем дә янына киләм, мәңгегә...
Бибинурның күзенә кинәт яшь килеп тыгылды.
— Барыбыз да үләчәк...
— Юк, минеке билгеле инде. Яздан бирле саулыкка туймыйм, тыным кысыла... Тик ул иртәрәк китеп барды. Бик иртә...
Вәли карт «тыным кысыла» дисә дә, шактый тибеш йөри икән, урыс капкалы, алты почмаклы өй янына тиз үк кайтып туктадылар. Хуҗа ишегалдына башта үзе керде, өй ишеген дә киереп үзе ачты:
— Менә, карчык, ут иясен алып кайттым, — диде.
Җиһангирның әнкәсе күз төпләре күгәргән, эре сөякле, олы гәүдәле карчык, өстән-өстән генә Бибинурга карап алды да, картының күз карашыннан аңлап, сүзсез генә табын әзерләргә тотынды. Өйдә кырма аяклы түгәрәк өстәл булса да, чәйне сәкегә әзерләделәр. Карчык ике читеннән сак кына чөметеп сәкегә кызыл ашъяулык җәйде, пыяла савыт белән май, агач капламыч белән бал китереп утыртты. Җиз самавар өстенә ак тастымал капланган булса да Бибинур таныды: Тула самавары! Тоткасы да, подносы да шул... Кайчандыр аларның да шундый ук самаварлары бар иде... «Тульский патронный завод. 1926 год», дип язылган... Самаварны күргәч аның хәле бетеп китте, чак кына сәкегә менә алды, аяк очын итәге белән төрә-төрә бер якка янтаебрак утырды. Чәйне Вәли карт ясады, карчыгы утырмады, бөкрәя төшеп тәрәзә янына барып басты да кемнедер көткән кебек урам якка текәлеп карап тора башлады.
Бибинур сәкедә ашаган чакларын онытып бетергән иде инде, җайсыз икән, ул эченнән генә: «Уллары укымышлы председатель иде, өй эчен ничек борынгыча тоткан», дип уйлады.
Берәр чынаяк чәй эчкән арада шулпа да җылынып өлгерде, бер утыргач анысыннан да баш тартып тормады Бибинур, ашыкмыйча

гына, ризыкны олылап, вак-вак кына йота-йота ашны да ялт иттереп куйды.

Ашап-эчеп, сәкедән ашъяулык киткәч кенә сүзгә керештеләр.

— Җиһангирым борынгыны бик ярата иде. Өйалдын күрмәдең әле син безнең, әкәмәт хәлләр бар анда, җылан мөгезе генә юк! Стенада тәрәшле тараклары, дага-кыңгыраулар, кутаз дисеңме, шлея шөлдерләре, калтырчалар, киндер сосалары, дугага кадәр бар! Ярма ташын әйткән дә юк. Аны да чыгарып ташлатмады... Шул иске-москыга һушы киткәне өчен хатыны да ташлап китте. Кала кызы иде килен. «Мин старьевщик татарга чыкмадым!» диде.

— Аның өчен генә түгел лә! — дип сүзгә катышты карчык, борылмыйча гына.

— Шуның өчен, әнкәсе, шуның өчен. Ярар, хәерлегә булсын. Менә, аллаһы боерса, Җиһангирның малаен үзебезгә алып кайтырбыз.

— Бирде ди сиңа.

— Бирер, — диде ышаныч белән Вәли карт. — Әле ныклап торып сорасак, бөтенләйгә бирер... Күзге каршыннан китмәгән нәмәстәгә бала нигә? Бала ул йөрәк җимеше. Карар дисеңме син аны? Котылганына сөенер генә.

— Синең үзеңне кем карар, шуны уйла.

— Малай кайтсамы?.. Терелеп китәм әле мин, күр дә тор.

— Улы да булган икән.

— Сигездә! Беренчене бетерде быел. Кая әле хаты? Шәп малай. Нәкъ әтисе инде, өзелгән дә төшкән. Акыллы. Биш яше тулып килә моның берзаман. Шуннан бер көнне әйтә бу, «әтки, минем күкәй суы, әчәсем килә», ди. Әтисе белән әнисе егылып көләләр малайдан. Нинди күкәй суы ул тагын? Ә мин шундук аңлап алдым, Җиһангир үзе дә дүрт-биш яшьләрендә гел чи күкәй эчә торган иде. Чыгып китте исә, ояга менми калмый иде, түше гел сап-сары булып кайта... Бүгенгедәй хәтеремдә, томырылып торган малай иде. Вакыты җиткәч, улының да күкәй эчәсе килгән, ибенә җайлап әйтә генә белмәгән. Менә бит ул ничек үз тамырың? Барыбер бер яктан тарта!

Вәли карчыгы артыгын кыстап тормады, кыска гына сорап куйды:

— Кунасыңмы?

— Кунмыйм, — диде Бибинур да сүзне өзеп. — Рәхмәт. Очыбыздан бер хатын каралырга бармакчы иде, булнискә. Шуның балаларын алып калырга сөйләшкән идем.

— Байтак җир бит.

— Булса ни? Җәяү йөреп күнеккән инде.

— Төн...

— Төн кайгылы кешегә иптәш кенә ул. Курыкмыйм.

Хуҗалар Бибинурны кыстамадылар. Вәли карт аны авыл башына хәтле озата килде.

— Улымны олылаганың өчен рәхмәт.

— Әйбәт кеше иде бит.

— Әйбәт кешеләр күп.

— Ул иң әйбәте иде.

— Үткән-сүткәндә безнең өйне чит итмә, кереп йөр.

— Керермен, — диде Бибинур чын күңеленнән.

Бик биектә тонык кына гөжләп самолет очып узды. Бибинурны сискәндереп бит алмаларына төнге күбәләкләр килеп бәрелде. Кайдадыр әтәч кычкырып алды.

Карттан аерылгач ук адымнарын кызулатты Бибинур. Мактанса да күңел түрендә курку бар иде. Куна калырга да була иде булуын, беркем дә больницага барырга җыенмый, монысын Бибинур чәй эчкәндә уйлап кына куйган иде. Кундың исә, чишенергә туры киләчәк. Чишенергә һич тә нияте юк иде аның. Өсте-башы чип-чиста анысы,

мунчага барып кына тора, керен дә тотмый. Әмма кеше алдында, кеше өендә ничек итеп чишенмәк кирәк!?

Хәзер шуларны уйлап тагын бер кат көрсенеп куйды...

Ул бара-бара итәген өскәрәк тартып күтәрде, күлмәк билен ыштан бөрмәсенә тутырды, болай атлау җиңелрәк иде.

Урманга кергәч аның шикләнүе артты, адымнары куерды. «Каһәр суккан оялчанлык, — дип сукранып уйлады ул. — Куныпі, иртән кайнар коймак ашап, җылы сөт эчеп киткәндә дә була иде!»

Бибинур карчыкның сыеры да, җылы сөте дә күптән юк, җиз самаварсыз калганына да әллә ни гомер, кунак булып кеше түрендә утырган чаклары да онытылган, аның үз йортына кунак кайтмаганга байтак еллар узган иде.

Яз явымлы иде быел, башка елларны сабан туена корып-кибә торган чокыр төбеннән сызылып кына су агып ята икән, аны-моны искәрмичә атлауга ике аягы да лычма су булды. Иелеп оекбашларын сыкканда ул якында гына эт өргән тавышлар ишетте. Этләр берничә иде, ахрысы, бер-берсен бүлә-бүлә, ярсып, абалап өрәләр. Ул чокырны йөгереп диярлек үтте, өскә менгәч аягына киеп тормады, салкын чыклы үлән өстеннән ялан аяк ләс-ләс чаба башлады.



## 3

Курка-шүрли барса да, җиде чакрым йөргән аякка арамыни, Бибинур таң яралганда авылга кайтып керде, аз-маз черем итеп алырга да өлгерде.

Ялгыз карчыкның йокысы күбәләк гомере генә, ятты да, торды да. Идәнендә чүп-мазар күренмәсә дә, себереп чыгарды, сыңар чиләген тотып суга төшеп менде. Элегрәк кәҗә асраган төз лапас астында баклаган утынын тота, шулар ишелеп төшкән икән, кереп аларны әйбәтләп өеп чыкты. Эшен бүлеп ике тапкыр кибет тирәсен урап килде. Ачмый гына бит Әсмәбикә уңмаган! Тыйнак кына кыз иде яшьлегендә, бригадирга кияүгә чыгып куйгач тәмам узынды, авызы тулы алтын теш, колагында да әллә ниләр елык-елык килә, үзе аркылыга-буйга җәелде, имәнгеч. Баскан урынында йоклап йөри!..

«Яңа эчке күлмәк белән яңа ыштан алырга кирәк», дип уйлады ул.

Бар иде аның, түшәм матчасына кыстырып куйган шыгырдап торган унтугыз тәңкәсе бар иде. Соңгы айның пенсиясе. Егерме тәңкә иде алганда, авызы явыз, тәмлегә кызыкты, бер тәңкәлек чуклы кәгазьле кәнфит алып кайтып суырып бетерде.

Унтугыз тәңкәнең кат-кат уйланган, үлчәнгән урыны бар, бик бар! Көзгә кадәр идән тактасының берсен алыштырырга кирәк — менә сынам, менә сынам дигәндәй сыгылып кына тора. Бер почмакта түбә саламы бик чергән — су үтә һәм шуңа өйнең һавасы дымлы, черек исе дә күңелне болгата. Бөтенләй үк алыштырып булмаса да түшәмне дә каратасы бар. Бик бар! Унтугыз тәңкәң җитәрме әле?..

Нишлисең, гомере буе колхозда эшләде дә бит, ат та карады, юл да чапты, барына җитеште, ир эшләмәгәнне башкарды, пенсиясен барыбер егерме тәңкә генә чыгардылар. Зарланып идарәгә барыр иде, гомере буе алачыкта тимер чүкегән Галикәйнең дә егерме тәңкә генә пенсиясе! Акча турында алар икәү очрашканда гына сүз алышалар.

— Әй, Бибинур, зарланма. Акча кешене боза! — ди Галикәй, ике җирдән сынык тешле авызын ерып. — Әнә, күрше авылда Минәч кордаш та пенсәгә чыкты. Алтмыш җидене ала! Чөнки аларда совхоз! Калхуз тимере йомшаграк булгандыр инде, валлаһи!

Галикәйгә авыз ерса да була, улы-килене янында, үзе дә тик ятмый, сунарга, балыкка йөри, бәхете бар, буш кул белән кайтмый. Иясез өйләрне ата, иш янына куш, тиресен үзе или, бүрек тегеп җибәрә, өй арасында да кулы ята: тегесен-монысын төзәтә. Заманга ярыйм дип телевизор, радиога да тотынып караган иде, бер кешенең кинескобын шартлатып, өч кешенең радиолампаларын тәмам яндырып бетергәч, даны чыкты, тиз үк ул кәсебен ташлады. Хәзер ул турыда искә алганны да яратмый. «Ябышырга куркам, яшь башыңнан үләрсең!» дип, Бибинурга гына әйтә.

Гомумән, аларның эч серләре сыя, Галикәй аңа зарланып та куя:

— И-и, Бибинур! Бүгенге пенсионерлар аерым чутта торырга тиешләр дә бит, һәммәсе исәпкә алынмый! Бүгенге картлар алар тарихи кешеләр — бар булган, тир түгеп җыйган малларын колхозга илтеп тапшырган батырлар. Хәзерге кешене малын тапшыртып кертеп карә син калхузга! Машинасын, матаен, икешәр сыерын, көтү-көтү сарыгын биреп кем керер иде икән? Без бит актык тавыкка кадәр илттек, кызганмадык!.. Хәзерге заман пенсионерлары шул батырлыкны эшләгән кешеләр ласа, — дип ярым көлеп, ярым шаяртып сөйләштерә.

Әллә ниләр уйлап чыгара бу Галикәй явыз! Аның белән бер авылда, бер чорда яшәсә дә, Бибинур алай уйлый белми, кая ул, башына чүбек тутырып куйганнармыни, иртән ни ашаганын да онытa хәзер!

Галикәй дә ялгыз, карчыгы дөнья куйды, тик нишлисең, парсызлар авылда бер алар гынамы?!

Җайлап сорасаң, Галикәй килеп идән тактасын алыштырып та куяр иде, акча да сорамас иде, тик беркемгә дә ялынып барырга яратмый Бибинур.

Ул, унтугыз тәңкәне матчага кыстырган җиреннән алып, учына кысты һәм — тагын кибеткә. Тыр да тыр бара, төн буе йокы күрмәгән димәссең. Ашыга, ус зур. Яңа эчке күлмәк алмый булмас! Арзанлы гына ситса алып бер-ике ыштан тегеп җибәргәндә дә ярар иде дә, җөй машинасы да байтактан юк инде Бибинурның... Самавар белән бер елны бетте.

Кеше юк чакны көтебрәк йөрсә дә, ул барып кергәндә кибеттә икеөч хатын-кыз бар иде. Икесе түзәрлек, сүз-йомыш сыя торган хатыннар, өченчесе, түше белән прилавкага ятып кибетче Әсмәбикәгә нидер сөйләп ялагайланып торучысы Бибинурның игез сыңары Зөһрәбану иде.

Бер дә күрәсе килми иде Бибинурның үз сыңарын!

Зөһрәбану да Бибинурны тансыкламаган, ахры, ул керүгә билен турайтты, ике күзеннән дә ут атты, юка иреннәрен бөрештереп «йөриләр шунда» дигән кебегрәк көлеп куйды. Кибетче Әсмәбикәнең коймак-коймак битләре уртасына урнашкан песи борын астындагы уймак авызы да елмайды: кибеттәгеләр мәзәк көтеп игезәкләргә текәлделәр, Ташлыяр кебек салмак кына аккан сүз өзелде.

Бибинур аларның ашардай карашларын бөтенләй күрмәде диярлек, очрашканда гел җәнҗал башлаучы Зөһрәбануга да ашыгып кына карап алды да, күзе шүрлектәге төргәге белән яткан кызыл комачка төште.

Шушы төргәктән алганнар бит инде Җиһангирның табутын чорнаган кызыл комачны! Шул кызыл белән машина әрҗәсен дә тоташтан ураганнар иде. Әйе, шушы... Хәзер шул төргәктән тагын кемдер кистереп алыр, бу юлы инде табут төрергә түгел, кирәк-яракка, берсе яулыкка дип кистереп алыр да, чит-читләрен каеп, башына бәйләр. Әйе, шул төргәк, шул!.. Егет-җилән кызыл яулыклы сылуга карап: «Һай, жаный, бигрәк килешә ал яулыгың!» дип мәдхия җырлар. Ә комач шул төргәктән, шуннан.

Әйе, кибеткә шулай кергәли Бибинур, әйтергә кирәк, еш та керә, яратып йөри. Ялгыз карчык тагын кая барсын?! Нинди юаныч тапсын? Кибет — авыл хатын-кызларының штабы ул, монда беркем белмәгәнне беләләр. Үз хәлеңне күршеңнән түгел, кибеткә барып сора, әйтеп үк бирерләр!

Гадәттә, кибеткә басынкы гына килеп керә торган иде ул, керә дә Әсмабикә белән бер-ике сүз алыша, «Чибәрләнгәнсең әле!» дип салпы якка бер-ике салам кыстыра, ашыкмый, өй борынча килгәнгә аның үзенә дә аз-маз яңа хәбәр ияргән була, хәл-әхвәл белешкәч аларны җыелганнарга түгеп аудара. Соңгы яңалыкларын кибеттәге хатыннар белән уртаклашкач тыңлый башлый, үзе дә нидер ишетә.

Шунысы кыен, кибеткә сүз сөйләр өчен генә йөреп булмый, абруеңны төшермәс өчен бик хаҗәт йомыш та эзләп табарга кирәк әле! Менә монысы аның өчен кыен мәсьәлә иде.

Ниләр генә кыланмый Бибинур мондый чакларда.

«Чәй кайтмадымы?» дип сорый, товарга кайчан барасын озаклап белешә, атнага бер-ике мәртәбә ул озак итеп, җентекләп күлмәклек сайлый.

Иң әүвәл кыйбатлырак тукымаларга тотына, крепдешиннарны ике куллап уып карый, бөкли, сыпырып тигезли, тәрәзәгә якынрак килеп кояшка куеп карый, исни, теше белән чытырдатып тешли. Тыныч кына күзәтеп торган Әсмабикә Бибинурның теш арасында кытырдавын ишетеп, товарын җәлли дә башлый: «Ертып та кара инде булмаса», дип куя.

«Алай димә син, Әсмабикә!» ди Бибинур һаман товарын сынап, «төрле яктан карарга кирәк аны!» Аннары тукыманы «төсе ошамый!» дип кире кайтара. Әсмабикә дә Бибинур карчыкның җаен белә, шүрлек арасыннан гаҗәеп шәп, яшел җирлеккә зәңгәр борчак чәчәкләре төшкән арзанлы гына ситсаны тартып чыгара. Карчыклар үлә инде андый күлмәклек өчен! Бибинурның күзләре кызыгып яна, шулай да бирешми: «Яшьләр өчен ич синең бу ситсың, Әсмабикә, мондыйны киеп чыксаң, тавыклар көләр! Чәчәксезе булсын иде аның, бер генә төслесе!»

Әсмабикә дә тәмам эт икән, карчыкны аяп тормый бит шунда, шүрлегенең әллә кай яшертен почмакларын актарып нәкъ карчык сораганны алдына китереп сала.

Бибинур карчыкның кыяфәте үзгәрә, аяклары тик кенә тормый башлый, ул ситсаны ике кулына сала да авырлыгын үлчәгән кебек озак кына селкеп тора. Бусын тешләми дә, исними дә, ситсының шәплеген күз белән дә аерырлык була.

Озак итеп, кулы арганчы тотып торганнан соң, ситсы почмагы белән яшьле күзләрен сөртеп төргәкне Әсмабикәгә кире кайтара.

«Әйбәтен әйбәт тә, мондый затлы малны кем тегә ала дисең хәзер? Бозып кына бирәчәкләр! Менә элек Гомәр хатыны Мөһәлилә тегә иде карчыкларга күлмәкне! Сылап кына куя иде менәтерәк... Күлмәк дигәнең канат төсле гел алга гына очыртырга тора иде үзеңне. Хәзер ни, карчыкларны мыскыл гына итеп җибәрәләр...»

Сүз җиңел генә Мөһәлиләгә, Мөһәлиләдән аның ире кылый Гомәргә, аның пакусны ике метр ярым алып печән чабуына, печәннән курмыларга, курмылардан салкын кышка, салкын кыштан аулак өйгә, аулак өйдән утырмага, утырмадан кунак кызларына, кунак кызларыннан җилдән ике бабай тапкан тәпән корсак Миңсылуга, Миңсылудан кендек әбисе Хәернисага, Хәернисадан аның ире самагунчы Бикбулатка, тагын әллә кемнәргә, тагын әллә нәрсәләргә күчә дә Бибинур онытылып тора, сүзгә мавыккан Әсмабикә, карчык кулыннан төргәкне ничек алганын, ничек кеше күзеннән яшереп салып куйганын сизми дә кала.

Бибинур кибеттә инде юк та кебек, йомышлары беткәннәр сүзнең азагын ялгап китәләр — кем Миңсылуны, кем утырмага килгән кызларны. Яңа килеп кергәннәр сүз агышына теләсә кай урыннан башлап катнаша, чөнки бөтен авыл, аның тарихы, кичәге-бүгенге хәлләр һәммәсенең күз алдында, һәммәсен беләләр, онытмыйлар, саклыйлар, буыннан-буынга тапшыра баралар. Бибинурның хәле юклыгын да, күлмәклек акчасы булмавын да бик шәп беләләр. Ситсыларны, киштәдәге башка вак-төякләрне бөртекләп карап бетергәннән соң, ул кибеткә кергән саен бер кап шырпы сатып ала. Шырпы алуның бер гаебе дә юк, аннары кибеттә ул бер чакта да өзелми, бәясе дә юнь — бер тиен генә, шуны ала Бибинур. Дөрес, мич арасында, моннан сигез ел элек килгән посылка тартмасында аның байтак шырпысы саклана, сакланса ни, хуҗалыкта утсыз яшәп булмый, мич арасында шырпы, корыда, — черми дә, дымланмый да, кайчан алып сызсаң да гөлт итеп кабына.

Күлмәгенең ямаулы, тирән кесәсендә аның һәрчак шырпысы булыр, шалтырап җанга тимәсен өчен ул икешәр капны берьюлы кулъяулыгы белән бәйләп йөртә, урамда очраганнарга кайчагында бирәр кабын бүләк итеп тә китә. «Миннән күрсеннәр яхшылыкны!» дип уйлый ул канәгатьлек белән.

Бүген ул ишек төбендә икеләнеп тормады, нияте нык, фикере нигезле иде. Кулында йомарланган унтугыз тәңкә! Бик күптәннән шул хәтле акча тотып кеше арасына чыкканы юк иде аның. Бик күп бит ул аңлаган кешегә! Аңа ниләр алырга мөмкин икәнен Бибинур карчыктан гына сорагыз. Унтугыз тәңкәгәме?.. Уһу, аңа күпме шикәр, ярма, сыек май алырга була!.. Шикәр комы сипкән дөге бәлешен үлеп ярата Бибинур. Үзе генә булгач бәлешне сандугач оясы хәтле генә итсә итә, әмма пешерә!.. Ризыкның бөртеген дә әрәм итми, сөяк-санагын ташларга җәлләп моннан дүрт ел элек микән, көзлектә, адашкан бер этне иялэштергән иде. Карабай иде аның исеме. Бер кыш, бер җәй тоташ ашатты, убыр урынына тыгына иде явыз, кышкы салкыннар шинеп, яз җиткәч, шомырт чәчәк атканда каядыр китеп югалды. Бибинур аптырап Галикәй янына барды:

— Карабай югалды әле, Галикәй, — диде ул борчылып.

— Күргәнем юк, — диде сунарчы карт.

Бибинур аңа ышанды, әмма эте табылмады...

— Әсмәбикә! Әсмәбикә, дим!

— Әү, Бибинур әби...

Зөһрәбану да, кибетче дә аның шырпы сораячагын әллә кайчаннан, Бибинур кибеткә аяк баскан минуттан ук белеп торалар, күзләрендә наян утлар бии, көләселәре килеп тамак төпләре кымырҗый.

Аларның күз карашыннан Бибинур икеләнебрәк калды, акчаның бик кирәк урыннары да бар, нишләргә? Бүген алмый калырга да ярамый теге комач төргәгеннән! Авыл зур бит, берәрсе керер дә, күз алдында кистереп алып чыгып та китәр, авыз ачып калырсың!

— Әсмәбикә! — Аның тавышы калтырады.

— Әү дим ич, әү! — Кибетче, көлүен чак тыеп, уймак авызын сөт өсте кебек ак кулы белән каплады, шырпы тутырган агач тартмага аяк очы белән кагылып үтте. Зөһрәбану таудан тәгәрәп төшкән иске чиләк кебек шылтырый ук башлады: «Хи-хи-хи, шырпы кирәк аңа!»

«Ничек көлә алалар шулай!» дип сызланды аның боек күңеле. «Кичә генә аны җирләдек ич. Ничек итеп көлмәк кирәк?!»

Хәзер аны туктату мөмкин түгел иде инде:

— Әсмәбикә, дим, сабан туе җитеп килә, ә мин һаман иске яулыгым белән йөрим.

Кибетченең песи борынга якын гына утырган майлы күзләре гадәттәгедән ныграк ачылды:

— Яулык?

— Яңа яулык бәйлисем килеп китте.

— Бар, Бибинур әби, яулыкның менә дигәннәре бар!

Кибетче шушы сүзләрне әйткәндә Бибинур горурланып Зөһрәбану ягына караган иде, сыңарыннан инде җилләр искән, кай арада кибеттән чыгып та шылган диген!

— Аклысын биримме, чуарынмы? — дип сорады Әсмәбикә.

— Юк, син миңа менә шушы кызыл комачтан бер яулыклык кис.

— Бибинур әби, килешерме соң? Кызылны яшьрәкләр бәйли. — Әсмәбикә хәзер көләргә дә, көлмәскә дә белми иде. — Менә бик әйбәт француз яулык, бәясе дә арзан. Үземә дип алып куйган идем, сиңа җәл түгел.

Яулык чыннан да күз явын алырлык, елкылдап тора иде, шулай да Бибинур баш селкеде:

— Син миңа шул комачны бир инде, — дип үтенде. — Шуны кис, Әсмәбикә.

Бибинур авылның башка карт-корысы сыман яшьләргә «улым, кызым» дип бер чакта да эндәшми, үзеннән яшьрәкләрнең һәммәсен исеме белән генә атап йөртә иде. Исемнәрен белмәсә: «Һай, атыңны онытып җибәрдем, кем әле син?» дип сүз башлый.

Әсмәбикә бик гаҗәпсенеп, тәэсирләнеп карчыкка яулыклык комач үлчәде, гадәтенчә, ситсыны чытырдатып тартып та китермәде, ул сораганнан мулрак кисте.

Бибинур карчык яулыкны ике кулы белән күкрәгенә кысып ишеккә җиткәндә, ул аны дәшеп туктатты:

— Бибинур әби!

— Әү, Әсмәбикә.

— Әллә минем янга кибеткә эшкә керәсеңме? Җыештыручы Камәр апа кулбашларым бик сызлый дип зарлана. Эше күп түгел, көнгә ике мәртәбә юып-себереп чыгарсаң шул житкән. Вак-төяк эшләрдә булышырсың анысы. Акчасы булыр иде дим! Нигә болай интегәсең!..

Бибинурны кадап-чәнчеп алса да, ул бүгенгә Әсмәбикәнең «интегәсең» сүзенә игътибар бирмәде, ишеккә үк килеп җитеп, шактый уйланып торды да:

— Юк, Әсмәбикә, эшкә кермим, — диде.

Әсмәбикә дә сүзен тиз генә куя торганнардан түгел — юкка гына авылның начальствосына — бригадирга кияүгә чыкмаган бит — һаман кыстады:

— Әле син болай үз көчеңдә, уңганлыгың дөньяга мәгълүм, бәлки, килерсең, ә? — дип кабатлады.

— Юк, — дип кистерде Бибинур карчык. — Эшкә керергә балалар кушмый.

— Балалар?! — Әсмәбикәнең җәя кебек нәзек кашлары маңгаена сикерде. — Шулар кушмыймы? Ә алар синең ни рәвешле тереклек итеп ятканыңны беләме? Синең интеккәнне күрәме алар?

— Юк, Әсмәбикә, үгетләмә. Балалар ишетеп калса, яхшы түгел. Аларны рәнҗетәсем килми... Беләләр димәктән, аларның үз көннәре, минем үз көнем...

Бибинур шулай диде дә, ашыгыч барасы җире бар кеше кебек, тиз-тиз атлап чыгып китте. Кибеттән шактый ерагайгач кына борылып карады, тирән итеп көрсенеп куйды.

## 4

Асылда ул бүген һичкая ашыкмый иде. Түбән очка да болай гына, өйрәнелгән көндәлек гадәт буенча гына төшеп бара. Көндәгегә карагайда адымнары гына авыррак. Онытылып җиргә текәлеп бара-бара да, башын күтәреп тирә-ягына сөзеп карый, кешеләр очрый калса, кау-

шаган йомшак тавыш белән сәлам биреп уза; сорасалар, җавап биреп тормый, адымын үзгәртми, атлый да атлый.

Тыкрыктан менеп килүче Галикәй күзенә чалынгач кына тыелып калды, туктап аны көтә башлады. Тыкрык читәне күләгәсендә аермачык күренеп киткән Галикәйне байтак көтте, ә теге яңадан күренмәде. Бибинурның чыраена салкын гына елмаю таралды, ул мәсьәләне шунда ук аңлап алды. Теге явыз балыкка төшкән икән дә берни каптыра алмаган, буш кул белән кайтып килә! Белә Бибинур, күп еллык тәҗрибәдән чыгып, бик яхшы белә, әгәр Галикәй бармак башы хәтле ташбаш эләктерсә дә, мыек чылгыйларын өскә урләтеп, урам уртасына ук чыга, очраган бер кешегә озаклап сәлам бирә, хатын-кыз янында тагын да озаграк юана. Сунардан, балыктан кайтучы ир-атлар хәзер, электә яудан кайткан батырлар кебек, юллары уң булса чибәр хатын-кыз яныннан тукталмыйча үтмиләр. Галикәй дә шулай: су алып кайтучы киленчәкләрне күрүгә ата каз кебек биеп үк атлый башлый, тамагы кипмәсә дә чиләкне кыйгайтып су эчә, мыекларын тәмләп сыпыра һәм сорашканнарын көтеп тора. Аның күз алмалары мутланып тәгәриләр, ирене мелт-мелт килә, озын муенын төрле якка боргалап бөтен авылның, бөтен урамның, бөтен кешеләрнең игътибарын үзенә генә җәлеп итәргә тырыша.

— Күрдеңме! — ди ул, җилкәсендәге брезент капчыкка суккалап.— Балыктан кайтып килеш! Менә-ә-ә мондыен каптырдым! Бу юлгысын күршеләргә вәгъдә иткән идем, әгәр дә мәгәр, аягың җиңел булып, икенче төшкәндә эреләре эләксә, күр дә тор, сиңа кертмичә калмыйм!..

Аннан китә сөйләп, китә сөйләп!

Балык турында сүз башланса, Казанның ата балыкчысы Яхъядан да арттырып җибәрә, билләһи!

Әгәр инде ялгышып кына олырак кызыл канат яки чуртан баласы эләксә Галикәй иртәдән кичкә кадәр урамда йөри.

Ә куян атып алса... Юк, куянның эзен күрсә дә җитә кала Галикәйгә, ул таудан чаңгы белән сызгыра-сызгыра авыл урамына хәтле очып төшә, кибеткә кереп ике чүлне кыстырып чыга, беренче очраган кешесен өенә кадәр алып кайтып сыйлый, чәй вә мәй янында озаклап-озаклап куянны ничек эзәрлекләвен, куян куам дип төлкегә юлыгуын сөйләп бирә.

Аның бу гадәтләрен улы белән килене яратып бетермиләр, аучылык маҗаралары еш кына өй арасындагы каты талаш, үпкәләш белән тәмам була.

Бүген Бибинурны күреп тыкрыктан чыкмыйча яшеренеп маташа, димәк, коры кул белән кайтып килә. Табыш, мал белән кайтсамы, уһу, туктатырсың син аны — хатын-кыз күзенә чәчрәп керергә генә тора!

Ә Бибинурның бу юлы аны күрәсе килә иде.

Кибеттән буш кул белән чыкмады бүген, кеше рәтеннән ул да яшәп ята, сабан туе алды икәнен онытмый, кулында өр-яңа комач яулык!..

Галикәй, карчыктан болай гына котыла алмаслыгын аңлагач, кыяктан артыннан чыкты да, туп-туры Бибинурга каршы китте — тизрәк һөҗүмгә күчәргә дә һушын алырга кирәк кортканың, балык-ау турында сүз кузгата торган булмасын: кармакларны, буп-буш брезент капчыкны күрмәсен Бибинур!

— Бибинур, — диде ул, мыек чылгыйларын йолыккалап. — Сине күрәсем бар иде!

— Нәрсәгә? — диде карчык, кулындагы яулыгын алай да, болай да күрсәткәләп.

— Бәй, сәгатем рәтләп йөрми дигән идең түгелме? Бүген үк кереп чыгам, хәзер үк, валлаһи. Керимме?

— Әйдә, ахирәт гамәлен чутлый торган нәрсә түгел әле, Бибинур

карчыкның калдык-постык гомерен санаучы сәгать кенә. Алга китсә ни дә, артка калса ни!

— Миңа ышанмыйсың син, булдыра алмас, дисең. Коеп бирәм! Акча да алмыйм, — диде Галикәй, карчыкның игътибарын мыекларына җәлеп итәргә тырышып.

Бибинур аның уң ягына да, сул ягына да чыга, карчык аның брезент капчыгы белән кызыксына дип уйлый Галикәй, Бибинурның исә аңа комач яулыгын гына күрсәтәсе килә. Җиһангирны озатып калган очтан кисеп алынган комач бит! Ә картның һаман үз сүзе:

— Бер чакны шулай районнан берәү килеп чыкты. Тимерче булып эшләгән чак. У, усал кеше! Сәгате йөрми башлаган тегенең, керде бу.

Бибинур үпкәләп китә үк башлады.

— Бибинур! — Галикәйнең тавышы бик сәер булып, нечкәреп яңгырады. — Бибинур, дим, сиңа әйтәсе сүзем бар.

— Әйт, — диде ул юаш кына.

— Бибинур, — дип кабатлады карт, хискә бирелеп. — Кич кырын өең яныннан уздым, утың күренмәде.

— Мин өйдә түгел идем, Галикәй.

— Аны озата бардыңмы?

Карчык сискәнеп китте, бераздан соң гына:

— Әйе, — дип раслады. Әле ярый, шуннан артыгын Галикәй сорашмады, әмма китәргә дә исәбе күренмәде, брезент капчыгының буш икәнен онытып, бер адым гына аңа якынрак килде.

— Сүзем бар сиңа!

Бибинурның колак яфраклары кызыша башлады.

— Әйтсәң әйт, интектермә.

— Кичә кереп тә чыкмакчы идем. Син дә ялгыз, мин дә шулай диярлек. Әнә, яңь-яшьләр дә егылып үлә, дим... Әллә бар гомер, әллә юк гомер, дигәндәй... Һәй, үзең дә беләсең инде!

— Син Шомбайның ни уйлап чыгарганын мин каян белим? — диде ул, сүзне җиңелгәрәк борырга теләп.

Галикәй чыдамады, әйтте дә салды:

— Сиңа күчеп килимме, Бибинур?

— Өйдәш булыпмы? Нигә миңа өйдәш?

— Өйдәш димим лә! — Галикәйнең кәефе кырылды. — Бөтенләйгә, дим, синең янга!

— Әй, Галикәй, Галикәй!

— Әллә көләсең инде миннән?

— Нигә көлим ди, юләр? Көлмим, бер дә көлмим. Мәгәр...

— Шулай булгач соң? — Галикәй тагын бер атлам аңа якынайды.

Авызы чак кына ерыла башлаган Бибинур кинәт җитдиләнде:

— Ә балалар? — диде ул. — Алар ни әйтер?!

— Минем балаларымы? Алар сөенәчәк кенә!

— Синекеләр димим, миңекеләр ни дияр?

— Ә-ә, синекелә-әр! — дип сузды Галикәй. — Алар синең ни хәлдә яшәп ятканыңны белә дисеңме?! Синең интегүләрне аңлыймы? Әнкәләреннән Каф тау артына качкан балаларны оныт син. Юк синең балаларың!

— Ник булмасын, бар.

Галикәйнең ачуы чын-чынлап кабарды, бер балык та каптыра алмавын онытып, буш брезент капчыгын кулына алып селки-селки, урам уртасыннан кайтып та китте. Бара-бара да, очраган бер кешегә: «Юк дим мин аңа, балалары юк аның!» дип кабатлый. Очраганнар аны сәерсенеп күз белән озатып калалар.

Бибинур карчыкка ныклап сүз салырга Галикәйнең әллә кайчан нияте өлгергән иде инде. Бер караганда тормышында моң юк та кебек: үз өендә, улы-килене белән яшәп ята. Тамагы тук, өсте бөтен дигәндәй,

ни җитмәгән инде карт кешегә? Тик көннәре узган саен ул күңеленә нидер җитеп бетмәвен тагын да ачыграк тоя бара. «Хатын!» дип иртән йокыдан торгач бер эндәшәсе килә аның. Өстәл янына утыргач, хуҗа икәнен сиздереп бер җикеренәсе килә. Төшлектә «ашың тозсыз яки кыркурак булган, чергән кул!» дип яратып кына талашып аласы килә! Ашның тозсызын да, кыркуын да пешергәли килене, җыр укытучысы булгач, аш-суга осталыгы чамалы, тик Галикәй дәшми, ни китерсәләр шуны йөз чытмыйча ашый, чөнки киленнең талканы коры... Һай, парлы яшәүләргә ни җитә, кичләрен мунча чабынып, чиста күлмәк-ыштан киеп кайтыр идең дә, караватта җәйрәп яткан тәмле исле карчыгыңа: «Кая, мине дә сыйдырасыңмы?» дип елмаеп бер әйтеп куяр идең! Әболай, кулыңда көч, тәнеңдә дәрт барында улың белән килененнең пышылдашканын тыңлап ят инде!..

Бибинурны да үлеп кызгана иде Галикәй, аның тормышын җиңеләйтәсе дә килә.

Нияте нык иде Галикәйнең, бер атуда ике куянны алырга, тик һич тә җае чыкмый, Бибинурга үтемле итеп сүз кушарга базмый йөри иде. Бүген дә менә, тыңлап та бетермәде, җил-җил килеп Түбән очка төшеп китте.

Галикәйнең сүзе аңа ошамады түгел, бик ошады. Күңеле әллә нишләп, кузгалып, җилкенеп алды аның. Галикәй шикелле ирләр көн саен тыкрык башына чыгып сине кәләшлеккә сорап тормый, бик абруйлы кешесе авылның, чип-чиста, әйбәт карт, елдан-ел авырлаша барган тормышның бик күп чуалчык мазалары, мәшәкатьләре аның янында онытылыр, яшәү күзгә күренеп җиңеләер иде. Ватык сәгать тә келткелт итеп йөреп китәр иде, тавык җименә комбикормны ул төшеп алыр иде, бәрәңге бакчасының да яртысын буш калдырмаслар иде.

Бигрәк тә каз асрыйсы килә иде Бибинурның! Каз бәлешен дә ярата, авыз суларын китерерлек итеп каклый да белә, электән каз асрап килгәнгә, түшәк-ястыклары бары тик күпереп торган каз мамыгыннан гына иде... Иде дибез, чөнки көннәрдән бер көнне җылы түшәксез дә, күпереп торган мендәрсез дә калды Бибинур, балалар кайткан җәй иде... Шуннан ары ике ел асрап карады, бер елында ана каз буп-буш күкәйләр өстендә утырган булып чыкты. Икенче көздә, яман чир чыгып, җиде бәбкәсе бер көндә тәгәрәп үлде. Мантымады карчык казлардан, аннан азык җиткерү авырлашты һәм казлар үзләреннән-үзләре юкка чыктылар. Авылда мул сулы буа буылгач ул тагын бер кат талпынып карады, председатель Җиһангирны урамда очратып аңа болай диде:

— Җиһангир председатель, пенсәдәге карчыкларга каз асрарга ярдәм итегез! Курмысын юнәтеп өйгә китереп торсагыз, байтак картлар каз асрар иде. Казның бәясе бит, ай-һай, үрдәктән чак кына зурларын базарда егермешәрдән саталар. Безнең халык казның кадерен белә. Бер каз — тәгәл бер айлык пенсә акчасы. Унны базарга алып чыктың исә, уч тутырып акча аласы! Безгә дә файда, илгә дә. Унны сатсаң, ике йөзне каерып аласың. Безнең төшкә дә кермәгән акча. Мәгәр казның җәфасы җитәрлек, әгәр азык тапсагыз, мәшәкатеннән курыкмас идек.

Җиһангир Сәфәргалин беренче һәм соңгы тапкыр аның аркасыннан какты:

— Уйлашырбыз, әби! Һичшиксез, уйлап карарбыз! — диде.

Ул Түбән очка төшеп җиткәнче Галикәй турында хөрмәт белән уйлады. Әйе, Галикәйнең күңеле якты, дип канәгатьләнеп уйлады ул. Аксыргактагы бик күп тол карчыклар арасыннан Бибинурны юкка сайламаган ич! Аның яхшылыгына, зирәклегенә ышанган. Ә карчыкларның берсе дә Галикәйдән баш тартмас иде, ирләре әллә кайчан сугыш кырларында үлеп калып, ир җылысына зарыгып ятучы карчык-корчык

әллә күпме әнә Аксыргакта! Көне-төне кыр эшенә чапканда, беләкләргә кан сауганчы утау утаганда, билләр кәкрәеп катканчы ашлык суккан да, салкын җилдә бөкшәеп ям чапканда аны-моны уйларга вакытлары калмый иде аларның. Язгы таңнарда сызланып, ыңгырашып бер уянырлар иде дә тормыш чоңгыллары аларны ел дәвамына йотар иде. Хәзер, картлыкта, кулдан эш киткәч, тол карчыкларга да уй төште: бәрәкәт, гомер узып бара түгелме соң? Картың белән чөкер-чөкер сөйләшеп, баллы куе чәй эчеп, арка кашышып яши торган соңгы чуак көннәр килеп җитте ләбаса! Һәм ир тәмен дә тоеп өлгермәгән, ирләренә хатын-кыз назының тулылыгын ачып бетерә алмаган, үзләре дә чып-чын хатын булып җитә алмаган әбиләрнең берише бизәнеп, колак алкалары тагып, беләзекләр киеп хушбуй исе таратып йөри башладылар. Тол картларга көн бетте, җебегәнрәк карчыкларның картларын кычкыртып алып та киттеләр. Барысы да булды Аксыргакта, барысы да.

Бик күп карчыкларның йөрәген җилкеткән Галикәй ул, бик күп әбиләрнең йокысын качырган егет-карт!

«Менә син агай, тапкан бер сүз, тота да «балалар» дип өзә дә куя!»

Балалары аны ташлап таралышканга һәм Аксыргакка бер дә кайтмаганнарына төгәл сигез ел узганын Галикәй санамаса да белә. Шуңа күрә ул Бибинурның баш тартуын аңламады... Хәтта рәнҗеде, эчтән генә гарьләнеп сүгенеп тә алды. «Әллә бик... мине кешегә чутламыймы... Әллә бик, бер сызгырсам... бише йөгереп килеп җитәр!»

Сигез ел элек Бибинурның балалары да кеше төсле, авылдашлары төсле сабан туена җыелдылар да бер дә кѳтмәгәндә эзләре суынды. Әниләрен чакырып хат язганнары да, кайтканнары да юк.

Бибинур бүген алар турында гадәтенчә озаклап уйлый алмады, балаларын яман як белән телгә алган Әсмәбикәгә дә, Галикәйгә дә ачуланмады, һаман элеккечә гаепне үзеннән эзләде.

Кай арада Түбән очка төшеп тә җитте әле ул! Нигә почта янына килде? Килде дә басты.

Болдыр ягы күләгә, рәхәт салкынча. Ишек янына ук китереп ялтыравыклы матай куйганнар. Шуның исе икән әле, фу, ят ис. Почта тәрәзәләре бары да ачык. Ишек тә ачык. Ишектән башларына әфлисун төсле тимер кәпәчләр кигән егет белән кыз чыктылар да Бибинур карчыкны таптардай булып янынңан үттеләр. Һәйкәл янында аз гына басып тордылар, аннан яшь каеннар арасына кереп беркемнән дә читенсенмичә үбешә башладылар.

Бибинур тезләрен кочаклап болдыр тактасына килеп утырды.

Көн матур.

Чебеннәр оча, почта йорты почмагында, бүрәнә тишеге эзләп куе шәмәхә төстә быжан выжылдый.

Бибинур карчык тагын буа шаулаганын ишетте. Күңелне моң белән тутырып, йөрәкне җирсетеп, үзе белән әллә кайларга чакырып шаулый иде Ташлыяр елгасы. Күз үзеннән-үзе һәйкәлгә тукталды. Анда язылган ирләрнең күбесе шушы ят егет кебек үк чибәр, зифа булганнар бит.

Ул хәзер генә аңлады: буа, почта һәм мәгърур һәйкәл сагынып өчен гаҗәеп бер урын икән ич. Каян барын да белеп яшәде икән Җиһангир Сәфәргалин? Телеграмм баганасына, хатларга багышлап күпме җырлар җырлаган татар халкы!

Телеграмм баганасын санысам калган икән,
Күз керфекләрем талганчы, карыйсым калган икән.

Талып кына калмады инде Бибинурның керфекләре, коелып бетте диярлек.

һәйкәлдә беренче булып аның Габдуллаҗанының исеме. «Буем бәләкәй булса да фамилиям иң алда йөри минем, сугышына да иң әүвәл барып керермен», дип шаярткан иде киткән чагында. Киткән чагында шаярта алды, әгәр кайткан булса ниләр сөйләмәс иде икән Габдуллаҗан!.. Тик ире турында да башка вакытлардагы кебек озын-озак итеп уйлый алмады Бибинур.

Ул бүген озак итеп бары бер кеше турында гына — Җиһангир турында гына уйлый ала иде. Әсмабикә, Галикәй белән сөйләшүләр, очрашулар, буа, почта, һәйкәл турында уйлар бөтенесе дә тыштан гына иде бүген, аның күңелен туктаусыз авыр уй кимереп торды: Җиһангир, Җиһангир, Җиһангир...

«Без — корыган ботаклар монда калганда яшьләр нигә китеп бара икән?» дип уйлады Бибинур һәм җавап эзләп тирә-ягына карады. Быжан һаман выжлый, буа һаман шаулый, Аксыргакның чиста күгенә сокланып каз канаты кебек ак болытлар акрын гына тирбәлеп йөзәләр. Егет белән кыз кычкырып-кычкырып көләләр, авызлары авызда, бармы аларга Бибинур карчык монда, юкмы, барыбер... Яши шул әле Бибинур, яши, әнә Җиһангир гына китеп барды. «Тыныч чакта яшьләрне нигә ала бу әҗәл?!»

Буа тавышын ул дөньядан Җиһангир киткәч кенә ишетте!

Оя табалмыйча бүрәнә почмакларына бәргәләнгән быжанны ул Җиһангир өчен генә кызганды бүген.

Күкне кыеп-кыеп, кисәкләргә бүлеп, җир кешеләренә бүләк итәргә ашкынган кара карлыгачларны ул бары тик Җиһангир булмаганга гына күрде...

Кинәт почта тәрәзәсеннән ул Галикәйнең исемен ишетте. Почта кызы, нәзек билле, тиктомалга да иренен турсайтып, сузыбрак сөйләшә торган Миңнегөл тәрәзә төбенә көзге куйган да, үзе шуңа карый, үзе телефон аша районга телеграммалар тапшыра. Әллә агачлыктагы егет белән кызны күзләве генәме?!

«Губаха... Әткәгез Галикәй бик авыр хәлдә ята, кайтып җитегез».

Ишетсә дә исе китмәде Бибинурның. Аксыргакның гадәтен белә, тагын онытылып уй йомгагын төйни башлады. Аның яшендә уй йомгагын сүтә башларга бик вакыт иде дә, дөньялыктагы эшләрне йомгаклап куярга кирәк иде дә, барып чыкмады, уйлары бер-бер артлы күңелендә төйнәлә тордылар.

Миңнегөлнең сузынкы тавышы тагын бакча ягына яңгырады: «Сахалин... Абыегыз Мидхәт бик авыр хәлдә ята, тизлек белән кайтып җитегез!»

Ашыгырга кушкан хәвефле телеграммаларны ваемсыз егет белән кыз да ишетте, ахрысы, алар, үбешүдән туктап, тимер кәпәчләрен кулларына тоттылар, тыңлый башладылар. Ә Миңнегөл һаман да һич исе китмәгән тавыш белән, диктант яздыргандагы төсле итеп, телеграммаларны районга бирә торды. «Яз, дим, яз! Тагын унҗиде телеграмма! Унҗиде генә. Иртәгә күбрәк булыр. Яз. Норильск. Солнечная урамы, Бикбулатовларга. Бабагыз бик авыр хәлдә, ашыгыч кайтып җитегез».

Егет белән кыз агач арасыннан тиз-тиз генә чыктылар да Миңнегөл алдында яткан телеграммаларга ябырылдылар. Исе дә китмәде Миңнегөлнең, укуы уку!

«Күктүбә. Таҗикстан. Сәгыйтовларга. Әниегез хәл эчендә ята. Кайтыгыз... Авыру фактын врач Мифтиев раслый. Мифтиев имзасын Миңнегөл Галиева дөресли».

Донбасс, Кузбасс, Чиләбе... Чирләр, үлемнәр, телеграммалар...

Егет белән кыз тәрәзәдән дә, әбидән дә, бер-береннән дә ерагаялар. Ниһаять, кыз телгә килде:

— Әби, чумамы әллә сездә? Эпидемияме? Халык шулай кырыламы?

Миңнегөл, болардан үч алган төсле, тагын да ваемсыз, тагын да җансыз суык тавыш белән хәвефле сүзләрне укый.

Бибинур карчык яшьләрнең шардай ачылган күзләренә карап чыдый алмыйча көлә башлады.

— Юк, юк... Чума түгел, сабан туе безнең авылда!

— Сабан туе? — Яшьләрнең күзе тәмам акайды.

— Әйе. Авылдашларның сабан туена кайтасы килә. Бик ераклардан кайталар.

— Ел да кайталармы?

— Кайтмыйча! Аксыргаклылар кайда яшәсәләр дә, кияүгә авылдашларга гына чыгалар, кәләш итеп тә авылдашларны гына сайлыйлар.

— Ничек бер-берсен табышалар соң алар?

— Сабан туена кайткач белешәләр, танышалар, вәгъдә бирешәләр. Өйләнеп, кияүгә чыгып та куялар. Ә сабан туе узасы көнне ел саен алыштырып торалар. Кайчан буласын көне килеп җитмичә беркем дә белә алмый. Быел да, бер атна калгач, өченче көн генә игълан иттеләр. Районнан хәбәр килә. Ә авылдашлар бик еракларга таралган. Безне шул бер сабан туе берләштереп тора да инде. Шунда туган-тумача, агай-эне очраша ала. Шунда кавыша. Билгеләмиләр бит шуның көнен ныгытып, июньнең икенче якшәмбесе, һич булмаса Татарстан бәйрәмендә дип ныгытып куйсалар кана да бит. Ә болай, күрәсезме, тыгызга килә. Ата-анаң үлем ягасында димәсәң Губахадан сине кем җибәрә? Губаха әнә кайда да, Сахалины кайда?! Ай-яй ерак, әле шөкер, самолет оча. Врач бирә инде, язуын да бирә, чирлиләр дип пичәт тә суга. Сукмый кара! Аксыргакта көнең бетә диган сүз. Шуны һич тә җайга сала алмыйлар...

Бибинур күтәрелеп карагач яшьләрнең байтактан үз янында түгелләген абайлады, алар тагын тәрәзәгә ябырылганнар.

— Казанны кайчан бирәсез? Сәгать үтте бит инде!

— Булыр, — диде Миңнегөл ышаныч белән. — Үбешә торыгыз. Минут узмас, сәгать тулмас, башкаланы бирербез!

Яшьләр кочаклашып агач арасына кереп югалырга да өлгермәде, Бибинур янына игезәк сыңары Зөһрәбану килеп басты.

— Хи-хи, — диде ул көлемсерәп.

— Нәрсә хи-хи?

— Тиле кызылга кызыгыр, ди. Тапкан яулыгын. Хи-хи.

— Тапканы үземә!

Зөһрәбану моның белән генә туктамады:

— Телеграмма сугарга төшкәнсеңдер әле! — дип үчекләште.

— Төшсәм ни, — диде Бибинур юаш кына.

— Әтә-тә, — дип куанды Зөһрәбану. — Әллә берәрсе кайтыр дип беләсеңме? Куеныңда җылан асрадың да хәзер кайтырлар дип өметләнәсеңме? Сабан туена чакырасыңмы?! Кайтмыйлар, бел!

Шул ук сүзләрне әйтә Зөһрәбану, Әсмәбикә белән Галикәй сүзләрен кабатлый, тик теле нинди зәһәр аның, нинди усал, күгелҗем каймаланган күзләреннән салкын ут бөркелә.

— Өметләнермен дә, чакырырмын да.

— Үләм, һай, адәм көлкесе.

— Көл, көл, әйдә.

— Мин көләм, син генә җылыйсың. Гомерең буе җыладың!

Башка кешеләр янында үзен яклый ала Бибинур, телгә-тешкә үткен булмаса да, алай ук җебеп акканнардан да түгел, шушы Зөһрәбану белән очрашканда гына әллә нишләп югалып кала, теле көрмәкләнә, зиһене томалана, әйтер сүзләре онытыла. Сүз урынына мәгънәсез авазлар теземе генә сузылып чыга башлый. Ике игезәк, бәләкәй генә ике

карчык, чукышырга торган этэчлэр күк берсе каршысына икенчесе басып кыдрачланалар.
Ашыгыч телеграммаларын онытып торып, аларны Миңнегөл күзәтә. Агач арасыннан ике тимер кәпәч тырпаеп бу якка карый.
Ә буа шаулый, һаман шаулый.
Аның шавын Бибинур гына ишетә кебек.
Игезәк балаларның рәсемнәрен газеталарда бастырып чыгаралар, куаналар. Карт игезәкләр турында гына берәү дә язмый. Картлыкта кешенең характеры төсенә чыга, чырае үз мәгънәсен ала шул.
Менә Бибинур белән Зөһрәбануны бер ата, бер ана балалары дип кем әйтер?! Бик җентекләп караганда гына аларда охшашлык төсмерен табарга мөмкин. Ә болай бөтенләй ят кешеләр сыман карашып торалар, ят кешеләр сыман әрепләшәләр.
Ниһаять, Казанны бирделәр, әфлисун башлар чабып почтага кереп китте, Миңнегөл телеграммаларын тапшырып бетерде, ике карчык — ике игезәк икесе дә ике якка карап болдырда утырып калдылар.

5

Бүген дүшәмбе генәме? Сабан туена кадәр әле күпме сулар агасы бар да, ничаклы уйлар уйлыйсы бар.
Әле Аксыргак авылына өстән генә карап торган зәңгәр тауларда сабан туе табиннары түрендә бәлеш, өчпочмак, тутырмалар булып утырасы симез-симез бүлтерек бәрәннәр чабып йөри. Сабан туе мунчаларын җылытасы сөяк-сөяк каен утыннары иренеп кенә кояшта кибеп ята.
Ә буа шаулый!.. «Төнлә килеп тыңлап торасы иде аның шавын, — дип уйлады Бибинур. — Төнлә аермачык ишетеләдер!»
Ул Зөһрәбанудан читкәрәк китер өчен бая яшьләр үбешеп торган чаукалыкка керде. Арырак ике-өч бәләкәй кыз, бер каен төбен өй иткәннәр дә, чүпрәк курчакларын таратып ташлаганнар. Нигә ияләнде әле бу бала-чага почта тирәсенә, дип уйлады Бибинур һәм соравына җавабын бик тиз тапты — әбиләре монда, шуңа уралалар. Һәйкәл янындагы артлы эскәмиядә татарча яулык ябынган өч-дүрт әби утыра икән. Элегрәк бездә, татарларда, сынга табыну гадәте юк иде, хәзер бар. Ватан сугышыннан соң ул дөньяви гадәт безгә дә керде. Зиратларны ныграк карый башладылар, юл тирәләренә агач утырталар, чокыр-чакырларны күмәргә тырышалар, авыл каберлекләрендә дә мәрмәр һәйкәлләр күренә, йолдызлар ай белән аралашып тып-тын гына утыралар. Һәйбәт гадәтләр!
Бүген дүшәмбе. Сабан туена әле атна бар. Рәчәйнең бөтен почмакларына авылның иң сөенечле бәйрәменә чакыру телеграммалары киткән, кемнәрдер юлда, Бибинур гына беркемне дә көтми, ул бәйрәм белән, кайтканнар шатлыгы белән, авыл сөенече белән яшәячәк.
Шуңа күрәдерме бәйрәмдә дә ул бүгенгесеннән бигрәк үткәннәр турында күбрәк уйлый. Дөресен генә әйткәндә, узган гомерендә дә бәйрәмнәрне аз күрде Бибинур, бик аз, тик бер чакта да зарланмады, шөкерана кылырлык сәбәпләр тапты, көр күңел белән яшәде.
Бер гаиләдә ничә кыз! Ата белән ана тилмереп малай көткәндә семьяга тагын кызлар — игезәкләр өстәлде. Бурасында җиде тычкан кимерерлек тә азыгы булмаган йортта тезелешеп җиде кыз үсә.
Бу турыда төпчек-игезәкләр уйлый белмәгән әле. Бала чакның бәхете — гамьсезлек. Зөһрәбану белән алар бик тату яшәделәр, бергә уйнадылар, бергә, башны-башка куеп чоланда сандык өстендә йокладылар. Тора-бара апалары кияүгә чыга башлады, җизниләр килде, бүләкләр килде, кодалар булды. Кодалар арасында хәлле генә кеше-

ләр дә бар иде. Нөркәйнең тегермәнче Хатип улына Сабира китте. Урта авылның күкәйче Нурмый төпчегенә Мәһирә чыкты. Хатип та, Нурмый да асылда төп Аксыргак кешеләре иде. Өченче кыз Мәһитап урак өстендә бума чире белән авырды да бәрәңге алган мәлдә дөнья куйды. Уртанчылар Кафия белән Рәхиләне зимагурлар Ситдыйк белән Камил кунакка кайткан җирдән читкә алып китте. Кафия да озакламый бәбәй тапканда вафат булды.

Кызлары матур иде Гыйлфанның. Аерата төпчек кызлары — игезәкләр сылу булып үсте. Берсенә-берсе ике тамчы су кебек ошамасалар да, уртак яклары да бар иде Бибинур белән Зөһрәбануның. Бибинур әтисе төсле зәп-зәңгәр күзле булса, Зөһрәбану чәчрәп торган кара күзле булу өстенә, чаярак та, кыюрак та иде. «Ай-һай, Гыйлфан абзый, күз тимәсен, бу кызың пешкән алма булып килә, унҗидесе дә тулмас моның, я урлап китәрләр, я ябышып чыгар!» дияләр иде күршеләре. Кызларының үз вакытында китә баруын күреп сөенеп, дага кебек кенә калдырган сөннәтле сакалын сыпырып, Гыйлфан күршеләр куанычына бик теләп кушыла иде:

— Шулай анысы, кем, һәр баланың бәхете үзе белән. Ходай бәхеттәүфыйктан аермасын! Биргәне булыр, кем, биргәне.

Үзләре белән булдымы бәхетләре, әллә төпчекләрнең бәхетен апалары алып киттеме, унҗидене дә тутырды Бибинур белән Зөһрәбану, унсигезне дә, егермегә дә җиттеләр. Тик кызлы йорт капкасына берәү дә ат бәйләмәде, яучылар да Гыйлфан йортын читләтеп уздылар. Авыл өчен бик сәер, хәтәр хәл иде бу. Ата-ана хафалана ук башлады, сабан туйларына читтән кайткан яшьләр күзен кызыктырырлык итеп төпчекләрне чук итеп киендерделәр, авырлык белән исәпләшеп тормадылар, егетле кунакларны ашка алдылар, нәзер итеп, корбан бәйрәме саен тояклы мал суйдылар, хәер-сәдакаларны кызганмадылар. Игезәкләрне көзлектә утырмага җибәреп кайтардылар, кеше аркылы ару егетле өйләргә сүз салдырып карадылар, әмма Бибинурга да, Зөһрәбануга да кияү табылмады. Әллә аларның игезәк булуын сәер иттеләр инде, әллә Мәһитапның авызыннан ак күбек килеп су юлында үлеп ятуы яшьләрне чиркандырды, буйга артык калку булмасалар да, төскә-биткә бик күркәм Гыйлфан агайның төпчекләре һаман ата йортында иделәр.

Авылда комсомол ячейкалары төзелеп, колхозлар калкып чыгып, замана да, кешеләр дә, мөнәсәбәтләр дә үзгәрә башлаган чак иде. Бибинурның кияүсезлегенә әллә ни исе китмәде, «язганы чыгар әле», дип көлеп кенә йөрде, Зөһрәбану исә бу хәлгә чыдый алмыйча көн-төн яна-көя иде. Бибинурны ваемсызлыкта гаепләп, алар, беренче мәртәбә, шул вакытта чәкәләшә-ызгыша башладылар.

Колхоз төзелде, колхоз ныгыды. Аксыргак авылында районда беренче буларак балалар бакчасы ачтылар, кемнән киткән исем булгандыр — аны «площадка» дип атап йөртә башладылар. Малайларга путяжкалы кыска чалбар, төймәсез ачык якалы күлмәк тегеп кигерттеләр. Кызлар билсез, чуар күлмәкләр киде. «Площадка»ны Соловкига куылган Мәсгут кулак ихатасына урнаштырдылар. Аш өе дә, таш эчле тирән кар базы да, балалар уйнарлык агач бакчасы да бар иде карун-кулакның.

Колхозның беренче рәисе Сабирҗан солдат бер көнне кәнсәләргә Бибинурны чакырып кертте.

— Кызым, — диде ул, Бибинурның аркасыннан сөеп. — Укый-язуың бар, бу да хәзер кирәкле күркәм сыйфат. Булганлыгыңны беләбез, кер син шул «Площадка» балаларын карарга! Мәктәп директорының хатыны Хәнифә апаң мөдир булыр, син аш-су пешерерсең, кер юарсың, идәнен-мазарын карарсың. Кыскасы, тырыш. Һәйбәт кенә эш хакы куярбыз, үкенмәссең. Ике оста кулыңа мең төрле һәйбәт эш булыр, йә, ризамы?

— Ә Зөһрәбану? — диде Бибинур эченнән куанса да белдермәскә тырышып.
— Зөһрәбану дисеңмё?
— Без гел бергә-бергә үстек. Эшкә дә бергә йөрибез.
— Беренчедән, «Площадка»да урын бер генә, — диде кызыбрак солдат Сабирҗан. — Икенчедән, тыңлап тор, сыңарың бик холыксыз синең.
Бибинур кызарынды: — Ул әйбәт, — дип, Зөһрәбануны яклады.
— Әйбәтен әйбәттер дә, йоклаганда, дим, иллә мәгәр сиңа аннан аерылырга кирәк.
— Нигә? — диде кыз, күзен тутырып карап.
— Кем аркасында кияүгә чыкмаганыңны беләсеңме соң син? Сукыр! Зөһрәбануны Зәһәрбану дип йөртәләр авылда. Даны бөтен Рәчәйгә таралган. Безнең халыкта пычак телле хатыннарны өнәмиләр, татарга аңа юаш хатын булсын. Болай да тормыш изгән аны, үз өендә дә хуҗа булып түрдә утыра алмаса, нинди тормыш ди ул?!
Бибинурның Зөһрәбану хакында бер дә кире уйлаганы юк иде, өйгә кайткач, игезәк сыңарының кыланышларын карап, уйланып торгач ул Сабирҗан солдат фикере белән килешә язды: төртмә иде Зөһрәбануның теле, кырку иде холкы, дөньяга нигәдер ачуланып туган иде кыз бала.
«Площадка»га мөдир итеп билгеләнгән юка, арык, җеп-җиңел Хәнифә апа итәге җиргә тиярлек юбкалар кия, мишәрчә каты итеп сөйләшә һәм авыл халкының исен китәреп нечкә бауга тагып «Марс» исемле бәләкәй этен ияртеп йөри иде. Аның ире, мәктәп директоры Игнат Белов асылда керәшен, булып, Хәнифә аны «Идрис» дип матурайтып әйтә иде. Ике метрга якын буйлы, калын, киң җилкәле, бер центнерлы Идрис Белов мәктәптә тәртипне бик каты куйса да, Хәнифә янына килсә җебеп, югалып кала торган ир иде. Аларның сөйләшүләрен мәзәк иткән Бибинур пырх-пырх көлеп рәхәтләнә торган иде. Бигрәк сәер сөйләшәләр иде алар, бер дә авылча түгел! «Матурым, син бүген төшке ашка кайтырсың микән?» дип сорый Хәнифә. «Тырышырмын», ди бер сүз белән генә Игнат-Идрис. «Чишмәдән су алып мен, кәбәм... Вакытың булса идәнне дә юып чыгар...» Суны алып менә Идрис, идәнен дә юа дип сөйлиләр.
Хәнифә кул астында Бибинур «площадка»да эшли башлады.
Тәртип бик гади һәм көн саен диярлек бер төрле иде: мөдир балаларга китап укый, алтын читле күзлегенең пыяласын ялтыратып бик куркыныч әкиятләр сөйли, балалар аның сүзенә караганда мишәр шивәсеннән егыла-егыла көләләр. Бибинур азык-төлек алып кайта, сучы Гарәпша белән талаша, бәрәңге әрчи, аш пешерә, балаларның керен юа. Идән юу, бәдрәфне тазарту, балаларның бит-кулын юу да аның өстендә. Тора-бара ул Идрис абыйсын җәлләп аларның керләрен дә уа-юа башлады. Хәнифә апасының бакчаны шаулатып «Бибинур, Бибинур!» дип кычкырганы иртәдән-кичкә кадәр яңгырап тора. Вакыты калса Бибинур балалар янына әкият тыңларга да керә. «Ак бүре», «Гөлнәзек» әкиятләрен яратып тыңлый, утыра торгач онытылып китә, аш өе ягыннан көйгән ис килә башлагач кына «Ай, аллам!» дип сикереп тора һәм җан-фәрманга казан янына чаба.
«Площадка»да эшли башлавын әти-әниләре бик яраттылар, «эше барның, ашы бар», дип уйлады әтисе: «тамагы тук, ашавы шунда уза», дип куанды әнкәсе. «Кызның бәхете бар икән», диделәр күршеләре. Зөһрәбану гына Бибинурның эшкә урнашуын яратмады, Хәнифәдән өйрәнеп кайткан сүзләрне өйдә сөйләвенә җене чыкты. Сыңарының ашсуга остара баруын күреп, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитте.
Әллә Сабирҗан солдатның (ерак булса да, кардәшләре ул аларның!) сүзе рас килә инде, «площадка»да чәчүгә төшәр алдыннан эшли

башлаган иде, сабан туе кичендә, Бибинурлардан өч кенә йорт аркылы яшәп яткан, аксыл, юка чәчле, тоз күзле, бик киң маңгайлы Мирзаһит аны кичке уеннан озата кайтты. Капкадан ерак та түгел эскәмиядә алар сабан туе таңын каршыладылар. Аксыргак халкы өчен бик зур мәгънәгә ия иде бу каршылау!

Зөһрәбануның тавышы зәһәр икәнлекне Бибинур беренче тапкыр аермачык шул таңда ишетте. Икесен дә сискәндереп урам як тәрәзәсе ачылды, таң этәчләренең сихри тавышын каплап, яшелле-зәңгәрле тавыш яңгырады. Башта Бибинур тавышны танымады, таныгач хәйран калды.

— Керә беләсеңме син, юкмы? Ыштансыз балаларыңны иртәгә мин барып карармынмы әллә?!

Сабан туе көнне Бибинурның ял иткәнен Зөһрәбану бик яхшы белә ләбаса, нигә шулай явызлана инде?

Мирзаһит та моңа игътибар итте:

— Ай-һай, апаң! — дип куйды.

— Безнең кайсыбыз ападыр әле, белүче юк, — дип йомшартты сүзне Бибинур.

— Мондый кызың булса — дип өстәде Мирзаһит. Моның белән ул Бибинурны гаҗәпләндерде: артык акыллы сүз иде бу өч өй аркылы гына яшәп яткан юаш егет өчен! Димәк, ул үз сүзен түгел, ишеткәнен сөйли! Сабирҗан солдат сүзен куалый! Димәк, авылда мондый сүз таралып та, ныгып та өлгергән икән!

Мирзаһит яңадан килмәс инде дип хафаланды Бибинур, ялгышты, егет бер генә түгел, күп тапкырлар килде. Көзге кырпак төшеп, юллар утыргач, авыл агайлары тегермәнгә, көзге ярминкәләргә, җыеннарга юл тоткач Аксыргакта аулак өйләр уза башлады. Шуларның берсендә «Авыллы» уйнаганда Мирзаһит Бибинурны караңгы өйалдына чакырып чыгарды, бит очыннан чут итеп үпте, бер кулы белән түшен капшап, калай савытта кершән, кәгазь савытта пудра бүләк итте. Җавап итеп Бибинур байтактан чигелсә дә, М. Ш. хәрефләре бүген генә өстәлгән кулъяулыгы бирде.

Арада четерекле бер нәрсә калды: Мирзаһит Бибинурдан ике яшькә кече иде. Башта кыенсынып йөрсә дә, «Булса соң? — дип уйлады кыз, — ике яшь зур аермамы әллә? Егет уңган, телгә беткән җилбәзәк түгел, моңарчы кызлар кулы тотканы юк, ипле. Үзем дә тормыш җаен беләм, рәхәт кенә, дус кына яши башлагач кем яшь аермасын карап торган?»

Сөя идеме ул Мирзаһитны? Монысына ачык кына итеп җавап бирә алмас иде, Мирзаһит та анысын сорап тормады. Бибинурның оялдында кулга тиеп киткән кайнар алмасы егетнең төшләренә кереп йөдәтә иде.

Сүз әйтеп, вәгъдәләр бирешеп араны ныгытмасалар да, егет белән кыз ул елның көзен җиткерә алмыйча зар булдылар. Ай-һай да көттереп килгән көз булыр икән!

Кыр эшләре тәмамланып килә диярлек, хәзер Мирзаһитның тел төбендә өйләнү, туй ясау булса, Бибинурның күңелендә дә шул иде. Авылда «кияү-кәләш» дигән исемнәре чыкты, ата-аналарга ишетелде, барысы да үз җае белән якынлашып килә иде.

Гыйлфан агай өендә «туй» дигән сүз яңгырауга Зөһрәбану, ашап утырган җиреннән кашыгын атып бәреп, чоланга чыгып китте һәм бала чагыннан якын күргән агач сандык өстенә капланып кычкә кадәр үкседе. «Нигә шулай бәхетсез?! Минем кай җирем аннан ким!» дип зарланды ул үз-үзенә.

Бибинур белән аларның аралары көннән-көн кискенләште. «Тизрәк житсен иде шул көн! Ярабби!» дип ялвара иде Бибинур туганы белән сүзгә килгән мизгелләрдә.

Мәктәптә укулар башланды, бу инде көз житте дигән хәбәр иде! Сөенде Бибинур! «Площадка»га йөргән олырак балалар киндер букчаларына каләм-дәфтәр тыгып беренче класска киттеләр.

Мәктәп биналарын аксыргаклылар куылган кулакларның йортларын сүтеп, күчереп салганнар иде. Бу эшне совет рәисе Габдуллажан Абдуллин дигән авылның иң актив кешесе башлап йөрде.

Гражданнар сугышыннан ук комсомолга кереп кайткан, соңыннан партиягә кереп, ячейка секретаре булып байтак вакытлар торган бу кеше берсеннән-берсе вак өч баласы, олы авызлы, ямьсез генә хатыны Гайшә белән уртача гына тереклек итеп ята иде. Шул көннәрдә Аксыргак авылын гына түгел, бөтен тирә-якны тетрәткән канлы вакыйга булып алды.

Күзгә явымлы, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы кич иңә. Гайшә иренең иске шинелен, бүреген киеп, комган тотып ишегалдына чыга, Лапас янына барып житүе була, кемдер арттан аның башына тимер кендек белән китереп суга... Хатын аһылдап кычкырып жибәрүгә, оручылардан берсе: «Ул түгел! Ул түгел!» дип акырып жибәрә. Габдуллажан балта күтәреп атылып чыкканда Гайшә жан биргән була инде...

Аны олылап жирләделәр. Ячейкадан кызыл әләм алып чыгып, аның таягына кара тасма бәйләделәр, женазасында башта речьләр сөйләделәр, явыз дошманга аяусыз булырга чакырдылар, иң актыктан гына кабер янына мулла бабайны чакырдылар...

Кечкенәләре Нәжипне моңарчы «площадка»га Гайшә алып килә иде. Югары очтан алырга да ул төшеп йөри иде. Гайшәне жирләгәннең икенче көнендә баланы бакчага Габдуллажан үзе алып төште. Бәрәңге әрчеп утырган жиреннән аны күреп Бибинур вакытсыз тол калган ир каршысына чыкты.

— Менә, китердем, — диде ир сабыр гына.

— Олылары ничек, Габдуллажан абый?

— Өйдә инде. Жылашып утыралар. Алары аңлый.

— Аларын да алып төшәрләр, Габдуллажан абый.

— Олыларын ничек тә карармын инде, менә бусын нишләтергә? Бер ялгызын калдырып чыгып китсәң, кызганыч. Бакча барында әйбәт иде дә, тиздән аны ябабыз бит. Карары алдан чыгарып куелды.

— Мужыт тиз генә япмаслар әле, ә?

— Ябарлар, Бибинур.

Габдуллажан бәләкәй улын күкрәгенә кысып-кысып сөйгән Бибинурдан бик озак күзен алалмыйча торды, бакча капкасы төбенә житкәч тә борылып карады, аларның күз карашлары очраштылар.

Бибинур ул көнне кичен Зәкиләрдә аулак өйдә Мирзаһит белән очрашырга тиеш иде, бармады. Егет ике-өч тапкыр аларның өй турыннан узып китте, өченчесендә гармунчы Гарифны да ияркән иде. Бибинурлар өй турына житкәч Мирзаһит, дустының иңенә кулын салып, бер генә жыр жырлады:

> Бүген төнлә төшләремдә:
> Карасу, кара урман.
> Шул карасу, кара урман
> Без аерылышырга булган.

Нигә алай дип жырлады Мирзаһит, үзе дә аңламады.

Ә Бибинурның күз алдыннан бөгәрләнеп беткән утыртма якалы сатин күлмәк кигән, ябык, бер тәүлектә бетәшеп каткан Габдуллажан китмәде. Мәет чыккан өйдә тәгәрәп калган өч сабый турында кат-кат уйланды.

Мирзаһитның жырлап узганын Зөһрәбану да ишетте.

— Әй, аулакка барам дигән идең түгелме? — дип кычкырды.

Бибинур аңа жавап кайтарып тормады.

Икенче көнне таң белән ул Габдуллажаннарга китте.

Аягына олтанлы көрән итек кигән, авызына юан махра капкан Габдуллаҗан, корымга, көлгә батып мичкә чуен белән бәрәңге куеп маташа иде. УяныП өлгергән олы кызы белән уртанчы малае (анысының ике борын тишегеннән дә катлы-катлы «кунак кызлары» карап тора) идәнгә түшләре белән ятып чирткиле уйныйлар. Нәҗип иске тун ябынып сәкедә йоклап ята иде. Сабыйның тун итәгеннән каерылып чыккан нәзек ботларын күреп ул елап җибәрә язды.

— Нәҗипне бакчага үзем алып барам, шуңа кердем, — диде ул аптырап карап торган Габдуллаҗанга. — Өйдә балалар, ә син тәмәке тартасың, Габдуллаҗан абый.

— Утыр безнең белән, Бибинур. Чәй эчәрсең.

— Рәхмәт, Габдуллаҗан абый, хәзер вакыт юк.

Малайны уятып кабыл-тибел генә киендерделәр. Гайшә белән ару гына яшәгән кебек булсалар да, Бибинур йортның шактый каралмаган икәнен, әйбер-кара, ризыкларның тарау, кадерсез ятуын, хуҗасызлыкны сизеп алды. Өйне быел юмаганнар да, ахрысы, түшәмнәр каралып каткан, почмакларда кат-кат пәрәвезләр асылынып тора, мич арасында, казан тирәсендә һич курыкмыйча тараканнар йөгерешеп йөри.

Улын киендергәнне Габдуллаҗан күз дә алмыйча карап торды.

— Рәхмәт инде, Бибинур, мәшәкатьләнәсең. Кичен баланы үзем керeп алырга тырышырмын.

— Ярый, — диде ризалашып Бибинур.

Җиде кызлы йортта чисталык мәсьәләсе бик каты куелган иде. Өйләренә аяк киеме кермәс, өйне яз саен кырып юып чыгарырлар иде, урын-җирләрне кагып, паласларны, түшәк-ястыкларны җилле-кояшлы көннәрдә киптереп кенә торырлар иде. Габдуллаҗаннардагы тәртипсезлек, пычрак Бибинурга бик авыр тәэсир итте.

Атнага якын шулай барды, иртән Нәҗипне Бибинур кереп ала, ә «площадка»дан малай әткәсе белән кайтып китә. Габдуллаҗан ир булса да һаман кайгысыннан айный алмый, кайсы көннәрне авызыннан тәмәке исе аралаш тәмсез ис тә килгәли, юл уңаенда кибеткә дә кагыла, ахры, андый чакларда кыюланып ул Бибинур янына кухняга да керә, эре-эре тамырлы кулларын ямаулы тезенә куеп утыра да иягеен калтыратып елап җибәрә:

— Минем өчен шәһит китте бит Гайшә. Мин дип белеп үтерделәр. Аның бер гөнаһысы юк иде бичараның.. Минем урынга кара кабергә ятты.

— Үтерүчеләрне тапмадылармы? — дип сорый Бибинур.

— Үзем табам мин аларны, үзем!

Кич белән, соң гына Бибинур Зәкиләргә аулак өйгә барды, шунда алар Мирзаһит белән очраштылар. «Авыллы» уйнаганда Мирзаһит, гадәтенчә, кызны өйалдына, аулакка дәшеп чыгарды.

— Нихәлләрең бар, Бибинур? — дип сорады.

— Нихәл дип, «площадка»ны ябалар. Менә әйберләрне барлап әзерлибез. Юасы, киптерәсе, чистартасы калды, һич вакыт юк.

— Тизрәк япсыннар иде, — дип куйды Мирзаһит гади генә.

— Нигә? — дип гаҗәпләнде Бибинур.

— Яратмыйм мин бала-чага чыр-чуын.

— Бәрәч, — дип куйды исе китеп Бибинур. — Нишләп?

— Белмим. Елыйлар алар, яман акыралар.

— Ә үз балаңны яратырсыңмы син, Мирзаһит? — Кыз кыюсыз гына аңа таба тартылып алды.

— Белмим. Ул турыда уйлаганым юк. Баласыз да яшәп булмыймыни?

Уйлап әйттеме моны Мирзаһит, уйламыйчарак ычкындырдымы, Бибинурның үзеннән читкәрәк тартылганын сизде, кочакларга теләде, кыз якын да килмәде.

— Кочаклатмыйсың да, — диде үпкәләп Мирзаһит. — Мин туй турында сөйләшергә дип килгән идем бүген.

Кыз дәшмәде, байтак тын торды, егет аны тагын кочагына алырга теләде. Бибинур бирешмәде:

— Куйчы, Мирзаһит, — дип этеп үк җибәрде.

— Бер үпкәннән үлмәс идең әле.

— Кирәкми, Мирзаһит, өйгә керик. Суык монда.

Кайтып яткач та Бибинурның аяклары тиз генә җылына алмады, ул егетнең сүзләрен кайта-кайта, кат-кат хәтереннән үткәрде, уйланды, мендәр почмагын тешләп, мыштым гына балавыз сыгып та алды.

Егетнең сүзләре аны сагайткан да, сискәндергән дә иде.

Иртәгә «площадка» ябыласы дигән көнне Габдуллаҗан Нәҗипне алырга килмәде, шактый озак көтте аны Бибинур, көн дә явымлы, аяк асты да пычрак булганга малайның үзен генә кайтарып җибәрергә яхшысынмады. Караңгылык куерып беткәч, малайны күкрәгенә кысып күтәрде дә, күлдәвекләрнең күзенә галушы белән баса-баса Югары очка менеп китте. Габдуллаҗанның җиргә үк салынган иске капкасын иңе белән этеп ачып ишегалдына керде, ишек ачык иде — өйгә үк үтте.

Үксезлекләре йөзенә чыккан кыз белән малай сап-салкын өйдә иске бишмәтләренә төренеп катык ашыйлар иде. Өстәлне пычратып бетергәннәр, идәнгә ипи валчыгы чәчелгән. Абзарда сыер мөгри, сарыклар кычкырыша иде.

— Әткәгез кайда?

— Кайтмады, — диде кыз, борынын тартып.

— Сыерыгыз сауганмы?

— Юк.

— Су эчерттегезме соң?

— Юк...

Бибинур, Нәҗипне чишендереп «үйный тор» диде дә, иң элек кече якны, чиләкләрне тикшереп чыкты. Юынтык суларны малларга чыгарып салды, аннан көянтә чиләк асып инешкә төшеп менде. Ташлыярның кара суына карап беравык уйланып та торды. Көзге төннең күзе юк, шулай да ул ишегалдында арлы-бирле йөри башлагач, күрше хатыны әрем тел Сәҗидә:

— Бәй, безнең очка килен төшкән икән бит! — дип кычкырды.

Сүз әйтеп тормады Бибинур, су җылытты, идәнне юып чыгарды, балаларның керен җыештырды, казан астыннан көл көрәп селте ясады, күлмәк-ыштаннарын чылатты. Чәй куеп, балаларны эчертте, йоклатга яткырды.

Габдуллаҗан районнан соң гына кайтты, филтәсе чак кына калыккан тоныкк лампаны, сап-сары өстәл тактасына терсәген терәп боегып утырган Бибинурны күргәч, ул куркып китте.

— Балаларга бер-бер хәл бармы әллә?

— Юк, юк, — дип, ашыгып күтәрелде кыз. — Чишен, Габдуллаҗан абый. Бәй, син манма су булгансың ич.

— Яңгыр астында кайттык. Шуңа соңга калынды да. Ат тарта алмый, мескен. Җәяүләдек.

Бибинур филтәне бераз гына калкытты, Габдуллаҗанга чишенергә булышты, күн итекләрен мичкә терәп куеп, дымлы аякчуларын мич төбенә таратты.

Өйнең эче генә түгел, төсе, исе дә үзгәргән иде. Өстәлдә ак ашъяулык белән капланган бәрәңге тора, чәй чынаяклары ялт иткән. Анда якынаерга базмады Габдуллаҗан, мич арасына барып коры чалбар киде, балак очларын оекбашы кунычларына тыгып ишек катындагы урындыкка утырды.

— Түргә уз, Габдуллаҗан абый, син бит хуҗа.

— Соңга калмыйсыңмы, Бибинур? Кайтырга курыкмыйсыңмы?

Габдуллаҗан кыяр-кыймас кына өстәл янына килеп утырды, бәрәңге капты, тамагына узмады, шулай, авызы бәрәңгеле килеш, көрсенеп алды.

— Менә ни уйладым әле мин, Габдуллаҗан абый. Әгәр син каршы килмәсәң, мин бөтенләйгә калам. Нәҗипне бик яраттым.

Габдуллаҗанның бәрәңгегә үрелгән агач кашыгы идәнгә шапылдап төште, күзеннән яшь сытылып чыкты, төк баскан очлы ияге дер-дер калтырарга кереште.

— Ничек? — диде ул көч-хәл белән.

— Балаларны ялгыз яшәтә алмыйсың, Габдуллаҗан абый! Өчәү бит! Әни кирәк аларга. Нәҗибе бигрәк берни белми, бәләкәй...

— Аларга әни булган кеше миңа хатын да буласы лабаса! — дип кычкырып җибәрде Габдуллаҗан.

— Анысы да булырмын. Әллә ышанмыйсыңмы?

— Син бит, син... Бибинур... кыз кеше! Өч бала өстенә карт ирга кияүгә чыгарга... башыңа тай типмәгән. Йөргән егетең бар, Мирзаһитны беләм.

— Мирзаһит табар, аңа кыз җитәрлек. Миңа балалар җәл.

— Балалар тилмерә анысы, — дип килеште Габдуллаҗан.

— Тик бер шартым бар, — дип әлдереп алды Бибинур.

— Мең шартыңны үтим, меңне! — диде сөенеченә буылып Габдуллаҗан.

Ул Бибинурның уйнап түгел, чынлап, чын күңеленнән сөйләшкәненә ышана башлаган иде.

— Мең үк җыелмас. Беренчедән, тәмәкеңне ташлыйсың, Габдуллаҗан абый. Бүгеннән үк. Аракы эчеп кайтмыйсың. Яратмыйм. Ил-күз алдында оят. Өченчедән, миңа авыр сүз әйтмисең. Без ишле үстек, мәгәр минем беркемнән дә авыр сүз ишеткәнем булмады. Җаным әрни авыр сүзгә... Әле су алып кайтканда ишеткән «килен» сүзенә дә абыныл ярты чиләк суымны түктем.

Габдуллаҗан бәрәңгесен хәзер генә йотты — бугазына төер утырган иде. Бибинур аңа чәй сонды, Габдуллаҗан ашыгып шапор-шопыр чүмерә дә башлады. Йөткергән тавышкамы чаршау артында балалар кыштырдады, әти кеше түзмәде, чәен куеп, алар янына барып килде, өчесенең дә җылы, татлы исле аякларын сөйде. Бибинур янына чыкканда аның күзләренә яшь килеп тыгылган иде.

— Ныклап уйладыңмы син, Бибинур?

— Ныклап, Габдуллаҗан абый. Балаларыңны күрсәм йөрәгем әрни.

— Ә атаңнар?

— Алар сүз әйтмәс.

— Авыл-күрше бар.

— Авыл-күрше гайбәтеннән куркып өч сабыйны ятим калдырыйкмы? Алар миңа күнегеп киләләр, мин аларга. Нәҗибе бигрәк матур!

Тагын тынлык урнашты, лампаның мае кими, филтәсе четер-четер тавыш чыгарып ала, мич арасында тараканнар кыштырдый.

— Балалар турында гына түгел, үзең турында да уйла, Бибинур. Тора алырсыңмы минем белән?

Габдуллаҗанның сүзе Бибинурга бик ошады, аның да керфекләре чыланды, җитен чәчәге төсле зәп-зәңгәр күзләренә рәхәт елмаю чыкты.

— Ә син... каршы түгелме, Габдуллаҗан абый?

— Эх, Бибинур, матурым. Бу инде бәхетнең ниндие, валлаһи дип әйтәм! Егет чакта да синдәй уңган, синдәй сылу кызларга сүз куша алмаган идем мин! Төшкә дә кермәгәнне... Менә бит... Минем ни...

Габдуллаҗан өстәлгә капланып ук төште һәм тешләрен кысып озак кына елады. «Еласын, хәсрәтен җиңеләйтсен! — дип уйлады Бибинур.— Аннан туктар... Туктагач онытыр. Дөнья үзенеке итәр!»

Алар икесе ике җиргә яттылар. Тәмәке, аракы исе килеп торган Габдуллаҗаннан читкә борылып ук ятты Бибинур.

Әткәсе дә түгел, әнкәсе дә түгел, ә эзләп Зөһрәбану килер дип төне буе тыңланып ятты. Алагаемга җил котырды, кар катыш яңгыр сибәләде, Габдуллаҗан ямьсез төш күреп бастырылып, кычкырып уянды.

— Габдуллаҗан абый, Габдуллаҗан абый дим. Әйләнеп ят, балаларны куркытасың.

— Әl..

Икенче көн, балалар уянуга, кайнар бәрәңге буын атып өстәлдә утыра иде, саплары сынып беткән чиста чынаякларга яңа сауган сөт салынган, юка, тигез телемнәр итеп ипи дә киселгән иде. Балалар комган шалтыратып идәнгә чәчрәтә-чәчрәтә мич арасында тиз-тиз генә юынып чыктылар да, өйләрендә ят кеше булуына сәерсенеп, күзләрен мөлдерәтеп өстәлнең бер ягына тезелештеләр.

— Менә, балалар, сезгә яңа әнкәй. Бибинур апагызны моннан соң әнкәй дип йөртә башларсыз, яме.

Олы кыз еламсырап алды, аңа ияреп бәләкәчләр ыңгырашты, Нәҗипнең генә исе китмәде, ыштансыз малай, олы агач кашык белән каерып алды да, бәрәңгене авызына да капты.

— Әйем, тәмсез, — дип акырды.

Кыз да бәрәңгене татып карады, йөзен бозып:

— Тоз гына! — дип өстәде.

Бибинур да капты, чыннан да бәрәңге шыр тоз иде.

Ул арада чалгы пәке белән кырынып чистарынган Габдуллаҗан да өстәл янына килеп утырды.

— Каяле, кая. Без дә авыз итеп карыйк. — Ул бәрәңгене мул итеп капты, авыз, күз тирәсендәге җыерчыклары нур белән тулды. — Әйбәт булган бу! Тәмле пешерәсең икән бәрәңгене, Бибинур. Дөрес, бер хатасы бар, тозы азрак. Тозы да җитенке булса, ашап туймаслык бәрәңге буласы икән.

Һәм ул, томраеп торган балалары күз алдында агач савыттан учына байтак кына тоз салды да, агач бадьянга тутырган бәрәңге өстенә сибеп тә чыкты, җылы сөт эчә-эчә рәхәтләнеп ашарга да тотынды. Бибинурның итәгенә күз яше тамды, бәрәңгегә кыяр-кыймас кына үрелде... Балалар да, әтиләре артыннан, бәрәңгегә тотындылар, озакламый агач табакның төбе шылтырый ук башлады.

Бәләкәй Нәҗипне күтәреп соңгы кат «площадка»га җитеп килгәндә, аңа очраган беренче кеше Мирзаһит булды. Йөзе кызарган, ак керфекләре еш-еш йомылып тора, ярсып атлаганы ерактан ук беленде.

— Бибинур, дөресме? — диде ул килеп җитәрәк.

Бибинур Нәҗипне җиргә бастырды, малай Мирзаһитның тавышыннан куркып еларга ук тотынды.

— Дөрес, Мирзаһит.

— Ә мин? — Егет бик нык җәберсенгән иде. — Миңа биргән вәгъдәң кайда?

— Вәгъдә үк бирешмәдек, Мирзаһит, ялгышма. Мәгәр өметем синдә иде. Син әйбәт егет, кече күңелле, күпме дус булып йөреп бер авыр сүз әйтмәдең. Синнән дә әйбәтне табачагым юк иде, Мирзаһит... Син үзеңә тиңне табарсың, әйеме?

— Габдуллаҗан абый олы ич сиңа! — диде Мирзаһит, һаман өметләнеп.

— Әйе, яшь түгел. Тик сабыйлар хакына, балаларын җәлләп чыктым мин аңа. Син ишеңне табарсың, ә ул балаларга ничек ана табар?..

— Кистең өметемне! Кеше арасында хур иттең! — диде юаш Мирзаһит йодрыгын йомарлап.

— Балалар, — дип кабатлады Бибинур. — Өчәү бит, өчәү! Аларның ни гаебе бар?!. Сабыйлар хакына чыктым мин аңа!

...һай, гомерләр, һай, гомерләр! Күк гөмбәзен иңләп аккан ак болытлар кебек эределәр дә беттеләр. Бәләкәй генә буйлы Аксыргак татары, ак керфекле юаш Мирзаһит Днепрны кичкәндә Герой исемен алды да, Чехословакия тауларында җан биреп, мәңгегә шунда ятып калды. Әйбәт егет иде, акыллы, берәү булса үчегеп, кинә саклап Бибинурның тормышына гел аркылы төшеп торыр иде, үчекмәде, кинә сакламады, Нәҗипне күкрәгенә кыскан Бибинурга «әйбәт яшә!» дип әйтеп калган иде, шуннан ары да гел яхшы мөнәсәбәттә булды, хәлен белешеп, ярдәмләшеп торды. Габдуллаҗан абыйсы белән дә дуслаша алды Мирзаһит!

Яраткандыр инде яратуын!

Яратмаслык кыз идеме соң Бибинур?!

Бибинур бакчада иртәнге эшләрен тиз-тиз бетерде дә, Хәнифә апасыннан рөхсәт сорап, әниләренә кайтып китте.

Нишләсеннәр, әткә-әнкәсе бер утырып еладылар да, сыкрана-сыкрана, хәер-фатихаларын бирделәр.

— Үзең теләп алган йөк, кәҗәләнеп таудан артка тәгәри башласа, матри, елап безгә кайтасы булма, — диде Гыйлфан абзый.

— Күрәсең булса, күркә талап үтерер, — дип сыкрады әнкәсе.

Зөһрәбану гына моны һичничек кабул итәргә теләмәде.

Әткә-әнкәсе белән сөйләшкәннән соң канатланып кына чыгып барганда, чоланнан үрелеп ул Бибинурның беләген чеметеп тотты.

— Әләй,— диде сискәнеп Бибинур.

— Авыртамы? — дип сорады Зөһрәбану.

— Ничек авыртмасын, шулай кансыз чеметкәч.

— Ә син бәгырьне чеметәсең. Җанны тырныйсың!

— Нишләгән әле мин? — диде Бибинур, авырткан тулы беләген уып.

— Җылан! Оятсыз! Җирбит! Челерке! — Зөһрәбану дөньядагы бар әшәке сүзне калдырмыйча тезде. — Нишләгән дип тора бит әле, карга. Шул җуләр картка, алдына куйганны да түкмичә ашый алмаган җебегәнгә чыкмасаң кияү бетәр идеме сиңа? Нәсел исемен чертеп йөрисең! Кияү чыкмас, коры калырмын дип белдеңме? Гыйшкың төшеп хатынын да син үтерткәнсеңдер әле. Мирзаһитың алмадымы, алмады! Авыз иттергән син аңа, түзмәгән. Шуңа алмады. Алдангач кем булса да ярар дидеңме?

Өйдәгеләр Зөһрәбануның тәмсез сүзләрен аермачык ишетеп торсалар да өялдына чыкмадылар, игезәкләр талашына катнашмадылар, алар Зөһрәбануны беләләр иде. Бибинур да беләм дип йөри иде, хәзер генә туганының кемлеген аермачык күрде. Зөһрәбануның ияге очлаеп алга чыкты, куллары тавык ботарлаган тилгән тырнаклары төсле тырпайдылар, кара күзләреннән карасу булып зәһәр акты, төкерекләре биткә килеп-килеп тиде, бөтен йомры гәүдәсе калтыранды, күкрәкләре туктаусыз тирбәнделәр.

«Бума чире башланмасын тагын», дип бик курыкты Бибинур... Апасының үлеме аның күз алдыннан китмәгән иде әле. «Тагын шул афәт кабатланса, мине генә миновать итәрләр!»

— Зөһрәбану туганым, — дип өзгәләнде Бибинур. — Балалар хакына эшләдем мин моны.

— Бала карарга карчык-корчык табар иде әле.

— Сабыйларга ана кирәк бит, ана!

— Синме аларга ана?

— Чыккач әни була белермен анысы.

— Кем икәнеңне алда күрербез! Борчак-борчак яшьләреңне коеп кайтыр көннәрең алда! Илаһым, рәнҗешем төшсен иде, бу дөньяда ук

җәзасын татысаң иде. Хасиятсез икәнсең! — дип карганды Зөһрәбану.

— Үзе абынган еламас, Зөһрәбану. Кайтмам.

Бакчага кире кайтып, җиңен сыдырып карагач Бибинур куркып китте: беләге бала учы хәтле бүлып күгәрә башлаган иде. Әгәр Габдуллаҗан күреп калса? Аның Мирзаһит белән очрашуын ишеттерсәләр? Яман уйласа, оятын яшерер өчен генә кияүгә чыккан дип белсә?!

Үз башына төшкәннәрне ансат кына бүтәннәргә сылап үтә торган гадәте юк иде Бибинурның, чирләсә дә, кәефе китсә дә ул үз күңеленә үзе бикләнеп, барын да үзе үткәреп җибәрер иде. Монысын да әйтмәде, Хәнифә апасының «өйдә ни әйттеләр?» дигән соравына көлеп җавап бирде: «Ризалаштылар!»

Телдә «ризалаштылар», ә Бибинурга бер-бер җайсызлык килә калса ни диярләр?!.

Ир, ир өстенә өч бала... Сәер генә озатып калган ата белән ана. Зөһрәбану әйткән сүзләрне, кара гайбәтне, пычрак яланы ишетмәделәрме әллә алар? Барын да ишетеп тордылар.

Габдуллаҗан тәмәкесен ташлады, аракыны да авызына алмады. Кибеткә эзе суынды, өйгә дә аракы кермәде.

Күрше-тирә хатыннарын җыеп өйне бик шәпләп юып чыгардылар. Түшәмне Бибинур үзе кырды. Өйгә ямь керде, тәрәзәләр яктырып, ачыкланып китте.

Габдуллаҗан белән һаман аерым йокладылар алар. Бибинур баштa көлемсерәп кенә йөргән иде, хәзер шигәя үк башлады: берәр ягын ошатмыймы ире аның? Шимбә көнне, мунча чабынып кайтканнан соң, самаварны екканчы чәй эчкәч, сөякләре эреп камыр булган балаларны тезеп йоклаткач Бибинур урынны гадәттәгедән киңрәк җәйде. Габдуллаҗан чиста күлмәк-ыштан киеп сәке йөзлегендә сабыр гына утырып торды.

Утны сүндергәч Бибинур ятырга ашыкмады.

— Габдуллаҗан абый, — диде ул. Һаман «абый» дип дәшә иде әле.

— Ни әйтәсең, акыллым?

— Миннән шикләнәсеңме әллә?

— Юк, шикләнмим.

— Алайса, ник яныма ятмыйсың?

Бибинур урынга менеп ятты, Габдуллаҗанның үлеп тәмәке тартасы килде, байтак таптанып торганнан соң гына хатыны янынарак килеп утырды.

— Гайшәмнән зарланмыйм, үзенчә ул да әйбәт хатын иде. Минем өчен җанын кыйдылар бичараның, бер гаепсезгә салкын гүргә тыктылар. Гомерем белән мин аңа бурычлы, моны онытсам, иманым аркылы килсен! Мәгәр синең белән өебезгә нур керде, Бибинур. Монысы да хак. Төнлә уянам да, уйлап ятам, ни өчен, каян килде бу бәхет миңа дим? Син пешергән тәмле ашлар, ризыклар — һәммәсе бик якын. Мәгәр мин бу бәхетнең озакка булуына ышанып бетмим. Ишетеп йөрим, гайбәтчеләр сүз тарата, Зөһрәбану гел яный... Китәрсең дә барырсың күк, Бибинур! Шулай икән, кыз килеш кит! Синең кызлык өлешеңә кул ягарга кыенсынам.

Өйдә беразга тып-тын булып алды, Габдуллаҗан Бибинурның, Бибинур Габдуллаҗанның тын алганына кадәр ишетеп торды. Бибинур юри эндәшми, ул караңгыда нур чәчеп елмаеп ята иде. Менә ул тезләрен кочып торып утырды. Габдуллаҗанның каен себеркесе исе килеп торган ябык, нык муенын кочып алды һәм тыелып кына көлә-көлә аны урынга аударды.

— Чү, иплэп... Балаларны уятасың, — диде каушап Габдуллаҗан.

Алар кысып кочаклашкан килеш онытылдылар...

Юк, гайбәтләргә урын калмасын, Бибинур саф кыз иде. Бөтен тәне, күңеле, уйлары саф иде аның. Габдуллаҗан тәҗрибәле кеше буларак — солдатта Украинада йөргән кеше, аз булса да яшь киленчәкләрнең каймагын ашаганы бар иде инде аның — моны башта ук сизгән иде, хәзер шуны ачык ук белгәч, Бибинурга хөрмәте дә, бурычы да чамасыз артты. Гөнаһсыз уй, гөнаһсыз тән алып кергән иде аның Бибинуры йортка!..

«Площадка»ны язга тиклем яптылар. Бибинур күбрәк йорт арасында уралды, колхоз эшенә чыгарга да өлгерде, балаларның өс-башын карады. Итек басучы керәшеннәр кертеп барысына да өр-яңадан итек бастырып алдылар. Кырынмыйча, чиста күлмәк кимичә Габдуллаҗан хәзер урамга да чыкмый, тазарып, тугаеп китте. Балаларның өс-башы бөтен, тамаклары тук — һәммәсе түгәрәк, тик Бибинурга «әнкәй» дип өзелеп әйтмиләр иде әле. Габдуллаҗан «ашыкма, Бибинур, әйтерләр, исең китмәсен!» — дип хатынын гел юатып килде. Моның сәбәбен ул үзе дә аңлата алмый иде. Бибинур сабыйларны үбеп кенә уята, көлеп кенә ашата, «улым, кызым» дип өзелеп кенә тора, тик алар өчесе тиң, бүреккә тутырган бүре балалары төслерәк, сөмсерләре коелып, аңа каш астыннан гына карап торалар иде. Моның сәбәбе дә бик тиз фаш булды.

Зөһрәбану да җиткән кыз булгач, Бибинур йорттан әллә ни әйбер алып чыкмады, күлмәк-күнчеген, сөлге-тастымал ише вак-төякне генә алды, үзенә әзерләгән бар нәрсәне туганына калдырды. Ләкин тормыш ни кирәген үзе сиздерде. Бер көнне ул төп йортка кайтты. Каз өмәләре шаулап узган тук һәм күңелле чак иде. Бер-ике мендәрлек каз мамыгы сорау иде аның исәбе. Зөһрәбану өйдә очрамаса ярар иде дип теләп барса да, алар туганы белән өялдыңда бәрелешә яздылар.

— Сиңа? Мендәр? — дип кабатлады ул зәһәр көлемсерәп. — Тиешен алып бардың бит инде.

— Үзебезгә ярый да, балаларга кирәк. Кыз үсеп китте, малайлар белән бер мендәрдә йоклый. Килешми дигән идем.

— Балаларга? — дип дәвам итте Зөһрәбану. — Кияүгә киткәнеңә кайчан гына, балаларга да өлгердеңмени инде? Камырын Мирзаһит кабартып җибәргән идеме әллә? Синең каткан камайларыңа бездә мендәр юк.

— Җитәр сиңа, — диде тәкате корып әнкәсе. — Татулыкка ни җитә?

— Син сора аннан, әнкәй. Балалары аңа кем дип дәшә икән? Әнкәй диләрме, әллә әйтмиләрме?! Бала күңеле сизгер ул, алар бу үләтнең Габдуллаҗан абыйның хатынын үтертеп иргә йортка кергәнен белмиләр дисеңме? Илдә булмаганны кыланды...

Менә кайда икән суның болгана торган башы! Әйтәм җирле Хәтимә бер көн пычрана-пычрана «Зөһрәбану апам бирде» дип кәнфит суырып утыра иде. Нәҗибе дә «Зөһрәбану апабыз әйбәт!» дип лыкылдаган булды бит.

Боларны күңеленнән кичерде дә, Бибинур:

— Минем сиңа ни начарлыгым тиде? — дип өзгәләнде. Зөһрәбануның ачуы бетмәгән иде әле, ул:

— Илдә булмаганны күрсәтеп бөтен нәсел-нәсәбебезне ямьсезләдең, яманатын чыгардың! Хәзер безнең йортка кем килсен дә, кем безнең капканы каксын?! Имансыз йорттан бөтенесе дә йөз чөерде! — дип елый-елый, каргый-каргый Бибинурны сүкте.

Хәтимәне быел мәктәпкә бирмәскәрәк торганнар иде, бер көнне икәүләшеп утырып киңәшкәннән соң кызны беренче класска илтергә булдылар. Атна уздымы икән, Хәтимә мәктәп китепханәсеннән «Үги кыз» исемле китап алып кайтты һәм сүзсез генә Бибинурга китереп тоттырды.

— Укы!..

Үги ананы бер чакта да яратмаганнар икән шул. Үги ана турында күпме әкиятләр тумаган! Үги ана — ялмавыз. Үги ана — аждаһа. Ни өчендер үги аналарга гел үги кызлар гына туры килә. Малай тапкан аналар таза, көчле булып, кыз әнкәләре дөньяны иртә куя микәнни соң?! Бибинурның үзенә өч үги. Тик аның әкиятләрдәге ялмавыз үги әни буласы килми, үги әни дигәнне ишетергә дә теләми. Үги ана турындагы әкиятне ул елый-елый, аны язган абыйларны каргый-каргый укыды. Бала котырта торган әкиятләрне нигә китапка басып чыгаралар икән дип уйлады.

— Син — ата, балаларга ныгытып аңлат. Һаман чит итсәләр миңа бик кыен! Әле алда гомер күп, хәзердән бөкмәсәң, үскән саен кыенрак булыр. Тудырган да ана, тәрбия иткән дә ана. Шуны яшьтән үк белсеннәр.

Яңадан бу турыда сүз кузгатмас булырлык итеп үтенде Бибинур. Һәм теләгенә дә иреште, ире ни чарасын тапкандыр, балаларны ничек үгетләгәндер, Хәтимә бер көнне мәктәптән кайтты да, озак кына аңа карап торгач:

— Әнкәй, — диде.

Авыз эчендә әвәләбрәк әйтте, «әнкәй» дигәне «әнки» булыбрак яңгырады. Ләкин Бибинур барыбер шат иде, ул Хәтимәне күкрәгенә кысып көлеп җибәрде, иярә килгән сандыгыннан ал тасма чыгарып, кызның чәчен икедән үрде, чук ясап куйды. Нәниләр дә апаларыннан күрмәкче шул көннән аны «әнки» дип йөртә башладылар. Габдуллаҗан гына:

— Нинди «әнки» ди ул тагын? Җәмки булып ишетелә. Авыз тутырып «әнкәй» дип әйтегез, — дигән зарын белдерде.

Бибинур моңысына да бик канәгать иде.

Тора-бара балалар яңа әниләрен яраттылар, Габдуллаҗан «уф» дип куйды, бишәүләшеп тату гына яши башладылар, бер генә як һаман китек кала бирде: Бибинурдан бәби юк иде.

Зөһрәбану моны да сүз итте.

— Мин каргадым сине! Туганы юлына аркылы төшкәне өчен кысыр калсын дидем. Ялваруым ходайга барып ирешге, гомергә кысыр син, мәңгегә!

Түзмәде Бибинур:

— Алдыйсың, явыз! Әллә ниләр кыландырсаң да сиңа кияү чыгачак түгел — аждаһа син! Күр дә тор, бәби алып кайтырмын, берне генә түгел, икене...

Алып кайтырга өлгермәде Бибинур, аһ өлгермәде, кырык беренче ел килеп җитте.

Кырык беренче ел! Кырык бернең июне! Егерменче гасырның иң дәһшәтле көннәреннән берсе. Күпме кешеләрнең язмышын айкап гашлап, шаукымы йөз елларга кадәр бара торган куркыныч ел!

Габдуллаҗанны да, Хәнифәнең Идрисен дә, Мирзаһитны да берьюлы алдылар.

Аксыргак авылы белән Ташлыяр елгасы бер көн эчендә ятим калды.

Өч баласын күкрәгенә кысып Бибинур да ятим калды. Хәтимә, шактый үк исәя башлаган кыз, кочагын җәеп аңа ташланды:

— Әнки!

— Я, балам, елама. Ил белән килгән кайгы ил белән китәр дә. Кояш кебек әйләнеп тә кайтырлар әле. Сау булсыннар!

Ишегалдында кызыл бозау чабып йөри. Капка төбендә казлар кангылдаша, ян бакчада чебиләр чемченәләр. Шушы муллыкка, шушы бәхеткә карап сөенешер кешесе юк иде Бибинурның.

Күңеле моң белән туп-тулы булса да, карыны буш иде аның. Ул өзелеп көткән бәби дә Габдуллаҗанның ирлеге белән сугышка китте.

Китте дә кайтмады...

Һай, ул көннәр, һай, ул гомерләр!

6

Почта машинасы тирәсендә ул көнне бик озак маташтылар. Шофер Илдар почтага кереп-чыгып йөрде, чыркылдатып кызларны чеметкәләде. Аннары газета-журналларны, хатларны, посылкаларны бушата башладылар. «Галим абыйларга ике посылка!» «Хәмәтләргә ничә җирдән хат!» «Монысында әллә җимеш инде, кызлар, иснәп кенә карагыз әле!» дигән соклану сүзләре туктаусыз шаулаган буа тавышын басып бакчада бик озак яңгырап торды.

Бибинур карчык та көтте. Бер кайтырга тиеш бит инде алар! Нәҗип белән Сабир кайтмаса да, Хәтимә белергә тиеш! Әле сабан туена ничә көн бар, әллә телеграмма сугасы инде? Чирләп ята, үләргә җыенды дип сугаргамы? Сугарсың, кайтырлар, ошатмаслар...

Почта кызлары гөр-гөр килеп сөйләшә, алар Бибинур карчыкны күрмәмешкә салышалар, ә үзләре аның ни көткәнен бик яхшы аңлыйлар.

Ә буа шаулый! Шаулый! Җиһангир Сәфәргалинне озаткандагы кебек үк моңсу шаулый.

Буа, почта, ялгыз һәйкәл...

Буа тавышы бер акрыная, бер көчәя. Бәлки Бибинурга гына шулай ишетеләдер ул, чөнки аның зиһене кайчагында томаланып куя, колаклары ишетмәс хәлгә килә. Ул, егылып китмәс өчен, чытырдатып күзләрен йома. Егылмый, турая, күзен ачканда буа тагын да ныграк шаулый башлый. Әллә кайларга чакырып шаулый ул. Хәер, әҗәл юлына төшеп яшәгән карчыкны кая чакырсын ди тагын!.. Каберстанга чакыра торгандыр, шуңа ямансудыр аның тавышы, шуңа моңлыдыр...

Тагын күпме утырган булыр иде Бибинур, буа өсләп каз куып килүче Зөһрәбануны абайлады да җилтерәп урыныннан купты һәм кызыл комачын күкрәгенә кысып тиз-тиз авыл урамына элдерде.

Сугыш беткән елны эти-әниләре бер-бер артлы дөнья куйдылар да, төп йортта Зөһрәбану ялгызы гына яшәп калды. Үлем-җитем вакытында үзе эш башлап йөрсә дә, шуннан бирле ул йортка аяк басканы юк Бибинурның. Авылның ике очында икәү тигез картайсалар да алар бер-берсенә йөрешмәделәр. Габдуллаҗанның кара кәгазе килгән көнне Бибинур янына кем генә хәл белешергә, кайгыны уртаклашырга кермәгәндер, Зөһрәбану гына юк иде. «Минем каргышым төште аңа!» дигән Зөһрәбану. Бусын ишеттерделәр.

Моннан соң ничек кермәк кирәк тә, ничек очрашмак кирәк?

7

Сишәмбе көн кичәгедән ягымлырак, ямьлерәк булып туды — сабан туена кергән атнада табигать шулай чуклы-бизәкле була инде ул. Игеннәр күзгә күренеп калка, буынга утыра, баш чыгара. Чәгендер, бәрәңге басуларының кара җире күренми башлый, тоташ яшел хәтфәгә әйләнә. Ул кошлар, ул кошлар, иртәнге шәфәкълән кичкә кадәр өзлексез сайрыйлар. Берсе туктаса, икенчесе көйләргә тотына. Капкалар җырлап кына ачыла, моржалардан хуш ис кенә тарала, яшь кызларның адымнары, сулышлары үзгәрә. Аксыргак кызлары диләр шул аларны!

Бибинур иртәдән тәрәзә каршысына, яктыгарак утырып, туып килгән көнгә башын ия-ия яулык читен бөкте. Араларын теп-тигез итеп, спайлап мережкалап бөкте. Сыпылып чыккан җебен дә әрәм итмәде. Шуның белән бер почмакка әйбәтләп, ике хәреф чикте: «С» белән «Ж»не. Каян башына килгәндер, шулай теләде. Чигешен беркем дә күрерлек итмәде, комачка кызыл төште дә эзсез югалды.

Яулыгын чөеп бәйләгәч озак кына тәрәзәгә карап утырды. Аннары Түбән очка төшәргә уйлады. Төп йортка кереп, Зөһрәбану белән бик әйбәтләп сөйләшәсе килде аның. Кунакка чакырыр иде дә... уңайсыз! Бөтен чәшкәсе дә калмады, чәйнек борыны да ага, самавар да юк. «Әткәй төсе» дип самавар белән җиз подносны Хәтимә алып китте. Әткәсе истәлеге итеп тотсын, Аксыргакны онытмасын дип сөенә-сөенә бирде Бибинур. Кадерләп тотсын, «Габдуллаҗан бабагызның истәлеге» дип балаларына әйтсен. Бибинур ялгыз, ул чәйнек чәен дә бик яратып эчә. Чәйнегенең борыны гына көйсезләнде. Галикәйгә әйтергә кирәк әле анысын. Һиндстан чәе генә кайтсын! Тик соңгы елларда чәйгә бик кинәндермиләр, халыкның да авызы бозылды — элек такта чәй кунак сые иде, хәзер салып кара такта чәйне — бала-чагасына хәтле «бу нинди чүп тутырдыгыз, тузаны авызга керә» дип мыркылдый башлый.

Шулай да Зөһрәбану белән очрашмыйча ярамый. Иң элек сәбәбен табарга кирәк. Әйе, сабан туй олы сәбәп. Сабан туйда элекке үпкәләүләр бәләкәйләнеп кала, кешеләр туганлаша, дуслаша, үткәннәрне кадерләп хәтергә ала, киләчәкне билгели. Ярый, шуны сәбәп итеп барып та кердең, ди. Аш чүмече белән маңгаеңа кундырып чыгарса ни диярсең? Имчәген чыгарып каргаган Зөһрәбану бит ул.

Булмады Зөһрәбануның бәхете! Тормышы гомергә җайлана алмады, майламаган арба тәгәрмәче төсле, тигез юлда да кылдый-былдый барды. Кырык бернең көзендә байтак эстоннар эвакуация белән күченеп килгән иде. Зөһрәбануларга ирле-хатынлы семья керттеләр. Кырык икедә, шомырт чәчәк аткан гүзәл мәлдә, госпитальдән ялга дип аларның бердәнбер уллары кайтып төште. Нечкә генә, колга кебек ябык, торна сыман озын ботлы, ак мыеклы лейтенант иде. Өйләнмәгән егет. Өйдә кеше юкта Зөһрәбануны кымтырыклый башламасынмы шул, юләр димә инде, тегесе бәләк белән чак кына яралы кулына кундырмаган егетнең...

Зөһрәбануны гаепләмәде Бибинур, тик шулай да нидер әйтәсе килә аңа, өйрәтәсе килә, хак яшәмәде! Теле бер чакта да авызына сыймады. Анысы да бар. Ә хак яшәп Бибинур үзе ни рәхәт күрде соң? Өч бала үстереп шул ук Зөһрәбану сыңары булып байгоштай яшәп ятмыймы? Уйлап карасаң, чынлап торып үлчәсәң, Бибинурның хәле Зөһрәбануныкына караганда күп яман, күп яман! Зөһрәбануның да бәхете булмады! Ир тамыры татымаган хатын-кыз бавырында ачы таш утыра, имеш. Шул таш ач талпан кебек ару күзәнәкләрне суырып зәһәрен канга чыгара, ди. Канга зәһәр чыкса яхшылык кылырга һич ирек бирми, кешенең холкы үзгәрә, гел яманлык эшләргә генә тартылып тора. Сәламәт тәндә генә сәламәт акыл! Дөньяның төрле почмагында кеше ашаучы арсланнар, юлбарыслар очрап тора. Тоткач, тикшереп карасалар, берсе дә сәламәт булмый тегеләрнең. Кеше ашаучы акулалар да гарип яки чирләшкә булалар. Ир тамырын үз вакытында татымау хатын-кыз өчен гариплек белән бер ул. Бавырына утырган ачы таш канга гел ризасызлык, явызлык чыгарып кына тора.

Чыраена карагач куркып китәрлек Зөһрәбануның ике бите — ике лимон. Бибинур мәшәкать чигеп яшәсә дә бите алай котсыз түгел, күзеннән зәңгәрлеге, ирененнән елмаю китмәде. Очрашканда һәркемгә күтәрелеп карый ала. Зөһрәбану кеше күзенә карамый, куркак явыз көчек кебек ашык-пошык өрә дә югала.

*Ахыры киләсе санда.*

Шәйхи Маннур

# САБЫР ТӨБЕ...

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

I

Әйе...
Патша җиңгән,
Халык башын игән,
Чал маңгае җиргә тигән.
Ирексезлек камап алган бөтен яктан.
Кол мәкален хәтта уйлап тапкан:
«Иелгән лә башны кылыч кисмәс...»
«Ялгыз җәяү — дәрья кичмәс...»

«Биш бил бишмәт», «мескен бүрек» киеп,
Аягына бәйләп чабатасын,
Аркылыга-буйга чыккан йөреп
Бөтен Рәсәй державасын.

Алтын түгел,
Эзләгән тик бакыр тиен,
Бакыр тиен бирә торган ипекиен.
Маңгаеннан тир таммаган
Җир калмаган!

Күпме җәбер, кимсетүләр,
Мыскыл итү, читсетүләр,
Изү, таптау — барын күргән,
Барына да дәшми түзгән...

Тик түгелгән күңеленнән моң-зар гына —
Михнәтеннән гаҗиз булган җырлар гына:
«Тауларыңа менсәм, һай, тау биек,
Түбәнеңә төшсәм, тамырлык.
Ниләр генә кылсам — ялгыз башым,
Бир, ходаем, бирче сабырлык...»

Нишләргә соң?
Ни кылырга?
Кая барып тотынырга?
Кай тарафка омтылырга?..

Күктә ай да, кояш та бар,
Тик якты юк,
Тик җылы юк,
Тик юлы юк,
Юл эзләргә һич хакы юк!
Эзли чыкса, каян соң ул юлдаш табар?..

Әмма күңел риза түгел!
Таш баскандай — тын алалмый, кымшаналмый,
Күпме яту мөмкин?
Сабыр җырын сузып кына,
Эчтән янып-сызып кына
Күпме гомер җан юату мөмкин?..

«Сабыр төбе — сары алтын», дисәләр дә;
«Сабырсызның юлы — капкын», дисәләр дә;
«Юк кылычың — юк йолучың», дисәләр дә;
«Көчле белән көрәшмә!» дип,
Әйбәт киңәш бирсәләр дә —
Кайчангача түзсен,
Кая куйсын җанын?
Бу кара төн күпме барачак?..
Сабыр савытлары тулган аның,
Ул түгелсә — дөнья яначак!

Тик яндырыр өчен утлар кайда?
Кай тарафка йөрмә,
Кемгә кермә —
Юк бер файда...
Һәркемнең дә күрәсе бер:
Тоткын, сөрген, богау, Себер...
Ак патшаның бу киң иле,
Бу чик белмәс җире,
Кай тарафка йөрмә —
Кабердәй тар бер дәү төрмә...

Татар, чуаш, башкорт, урыстан,
Тагын күпме, күпме халыктан
Тулган анда,
Тулган «ырыйстан»!..

II

Кара да гына урман төпләрендә
Качкыннарның уты бар, диләр.
Әллә шунда микән юлдаш төркем?—
Эзли аны дәрте бар ирләр.
Әллә шунда микән
Сүнде дигән өмет нуры?
Әллә шунда микән ирек юлы?
Эзли аны, эзли халык күңеле.
Урманнанмы, Уралданмы, даладанмы ул ут күренер?..
Сабыр савытлары тулган аның,
Түгелер ул, бер көн түгелер...

Ә бер төнне төндәй кара аргамакта
Уйлы башлар йоклый алмый яткан чакта,
Авылына кайтып кергән «Бәхти качкын»...
Таң алдыннан тагын кайдыр якка
Чыгып чапкан төнге чапкын...
Һәм иртәнге җепкен җилләр
Өйдән-өйгә хәбәр ташып йөргән
Тәрәз аша, ишек аша:
— Ишеттеңме? Әллә каян — Җаек яктан
Бөгәч патша чыккан, диләр,
Безнең ише мужик патша,
Мужик патша, мужик патша!..

Ак патшага каршы икән,
Нияте дә яхшы икән:
«Питербурга тиздән барып җитеп,
Тәхетендә өегүче әби патша затын
Җилгә җилпеп,
Баярларын, санатларын җиргә селкеп,
Азат итәм Эрәчәйнең бөтен халкын,
Барысына полный ирек! —
Шушы минем изге антым!»
Дип монафис тараткан ди...
Алпавытны астыра ди баганага,
Түрәләрне бастыра ди утлы табага,
Җир-суларны мужикларга өләшә ди,
Кем килсә дә бик шәфкатьле сөйләшә ди...

Бөтен Җаек казаклары купкан,
Урынбурны Бөгәч тупка тоткан.
Килә икән давыл булып, ташкын булып,
Патша чапкыннарын куып!
Бик күп рус та шул ук якка чыккан!
Кушылганнар аңа башкортлар да,
Күршедәге чуаш, мари, мукшылар да,
Типтәре дә, мишәре дә,
Тагын бик күп юксыллар да...

Ак патшага баш бирмичә,
Ирек эзләп,
Сөйгән яры кочагыннан чыгып качкан
Канкай улы Бәхтияр да,
Таң эченнән ак юл күзләп,
Мужик патшасына чапкан
Кул бирергә, «ал!» диярга,
Юлдаш булып баш иярга.

«Һай, ирек, ирек, ирек!
Ниләр генә биреп
Алырга сине?
Нинди генә көчләр белән
Шул кара төнне җиңеп,
Коткарып ла калырга илне?..»
Дип җырлаган егет юлында —
Сер яшергән урман куенында.

Мужик патша дусча аңа кулын биргән:
— Килсен халкың!
Татарга да полный ирек!— дигән.
Һәм Иделдә актарылган ташкын сыман,
Купкан халык
Ирек теләп ашкындуан!

Шул күп телле, чабаталы яулар,
Сәнәк һәм балталы яулар
Өфе, Казан, Оренбурны камап алган,
Генераллар һәм маршаллар
Башлык иткән полкларны
Тетеп салган!
Инде тиздән Идел кичеп — аргы юлга!
Мәскәү белән Петербурга!
Баярларны — баганага!
Түрәләрне — таганнарга!
Әнчек әби патшаның
Чәчен кыркытып,
Озатырга монастырьга!..
Шулай итеп мужик патша
Бар властьны алыр кулга!..

III

Матур булган бу хыяллар.
Батыр булган бу хыялга барган яулар.
«Эһ» тә итми,
Ярсу башны салган алар,—
Ярсу башлар азатлыкка сусаганнар!
Нәрсә бар соң иректән дә кыйбат?
Нәрсә бар соң иректән дә бөек?..
«Су сипмәгән гөлләр кебек,
Ирексезләр йөри янып-көеп...»

Ирек, ирек!
Ана сөте кебек татлы,
Язгы кояш кебек якты,
Ирекле баш —
Лачын коштай дәү канатлы!
Матур булган,
Изге булган бу хыяллар,
Ташлар түгел,
Сөйли моны легендалар:
Емельянны, Бәхтиярны, Салаватны
Җырга кушып
Ничә гасыр җырлый алар!...

IV

Әмма көчләр тигез түгел,
Бер дошманга сигез түгел,
Идел ташып җәелсә дә —
    диңгез түгел.

Ак патшаның туплары да, солдаты да
Саранчадай сансыз булган.
Генераллар, маршаллары кансыз булган,
Ирек явы — канга чумган...

Юл буйлары кара баганалар,
Башларында лачын ирләр чайкалалар:
Гыйбрәт алсын бу фетнәдән
Бар авыллар, бар калалар!
Әби патша көч-кодрәтен
Исләрендә тотсын алар!

Җиңелүнең кан-яшьләрен йотып,
Хыяллары көл булудан җанын йолкып,
Юлдашсыз да, яубашсыз да калып,
Баш иярга мәҗбүр булган тагын халык.
Йөз илле ел тагын биле тураймаган.
Сукыр ут та күренмәгән карурманнан.
Зар түгелгән ялгыз тарткан курайлардан:
«Очаем ла диеп өч талпындым
Болытлардан аша үтәргә.
Каерылган икән ак канатым —
Ничек кенә дөнья күтәргә».
Ничек кенә?..

Шул «ничек»не эзләгәндә,
Зар күңелләр түзмәгәндә,
Өр-яңа бер өн таралды бөтен илгә.
Тик ышану кыен әллә нигә...

Кышкы җилләр,
Түзмәс телләр
кабатлады:
— Патша төшкән!
— Патша төшкән!..
Тик күңелләр
Түрендә тиз таң атмады —
Күпме тапкыр көйгән халык канатлары!
Күпме тапкыр авызы пешкән!

Безгә шул чак Иван килде. —
Патша түгел, таныш Иван...
Домналарда чуен койган,
Җир астында күмер кыйган,
Патшасыннан, түрәсеннән, төрмәсеннән
Мең кат туйган,
Күкрәгенә ачу җыйган, ярсу җыйган,
Беләкләрен богау уйган
Иван килде,
Кулын бирде:
— Мин Ленинннан килдем!— диде...

## Хәсән Туфан

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

### Яңа ел табыны

Җилкәнен киргән кораб!
*Дәрдмәнд.*

И шигырь! Бәйрәм түрендә
Әйдә син дә — җәй канат:
— Тынычлык диңгезләренә
Юл яра безнең кораб!

Тынычлык өчен көрәшнең
Җимешен исәпкә ал:
Бусында безнең табынның
Корвалан иптәш тә бар!

Әйдә әйт, башны күтәр дә,
Әйдә яз, яз, яз, каләм:
— Ильич! Саф, ихлас күңелдән
Бәйрәмендә Октябрьның
Иң тәүдә сиңа сәлам!

1977

### Килер Казан

Урман-кырдан, ялдан кайтышларда
Тукайга да керә китик без:
Сәламнәрен гөлләр-чәчәкләрнең
Шагыйрьгә дә бирә китик без.

Балкып торсын шагыйрь тирәсендә
Ал-гөлләре илнең көн саен:
Белсен Дөнья — күрсен: Казан ничек
Хөрмәт итә үзенең Тукаен!

Чын шигырьгә сәлам китерә килү
Керсен иде бөек гадәткә,
Туган илнең тирән ихтирамын
Әверелдереп гөлгә-чәчәккә!..

Килер, килер — килер җәйләр буе,
Килер иртән, килер кичләрдә:
Килер Казан, сине үз итүен
Гөлләр аша тәкъдим итәргә!

1977

## Синьцзяннән

Быел да килде Казанга,
Быел да Җамал ханым [1],
Тапшырды бөек Тукайга
Меңнәрнең әманәтен.

Сәламнәр — әманәт алар
Меңнәрчә татарлардан:
Синьцзян, Мао илендә
Гүрләрдә калганнардан...

Иң җылы, милли сыйфат ул
Тукайны таваф кылу,[2]
Сәламе итеп халыкның
Һәйкәлгә гөлләр кую.

Быел да килеп Казанга
Җамалы Алматаның
Тапшырды бөек Тукайга
Меңнәрнең әманәтен.

1977

## Сер итеп кенә

Мин асылда — синдә тудым, Уфа...
Килеп менә Синең каршыңа,
Ике энем [3] бүген бу зал аша
Сәламемне сиңа тапшыра.

Синдә минем каләмдәшләр байтак
Һәм һәрберсе хөрмәт итәрлек:
Әйтик, «А»дан — Атнабайдан башлап,
Янбулатка барып җитәрлек!..

Бабичка хас юмористик нур бар
Атнабаең көләчлегендә.
Тактәшка хас нәфис төгәллек бар,
Тирәнлек бар шигъри телендә!..

Синең хәлне әмма — сизәм, энем:
— Үтә икән еллар... дисеңдер,
Иллеләрнең теге якларында
Ничек икән юллар?.. дисеңдер...

Тик сер итеп кенә әйтәм сиңа:
— Син, энекәш, һич тә каушама,
Иң тәүфыйклы, иң гөнаһсыз иҗат
Алтмышларга җиткәч башлана!..

1978

---

[1] Сүз Җамал Сәфәргалиева турында бара. Ул, Кытайдан күчеп, хәзер Алма-Атада тора.
[2] Таваф кылу — үлгән кешенең кабере[на] бару.
[3] Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин.

## Сихри сазың

*Исмәгыйль Һилаловка*

Без (Бабич, Җәлил вә Туфан) —
Синең чор шагыйрьләре
Һәм синең сихри сазыңның
Иң гадел шаһитләре.

1956

●

Яши торгач, тарыды баш
Искитәрлек заманга!..
Кем ышансын инде моңа:
Алтмыш, имеш, Җамалга! [1]

«Утыртмакчы» була бугай
Кемдер Казан каласын:
Җамалны ул — хет анфастан,
Хет профильдән карасын.

Безнең Җамал әле, җаным,
Кызлар кебек ләбаса!
Димәк, заман — я саташа,
Яки юри маташа.

Алтмыш дигән булып заман
Безнең житез Җамалны,
Озатмакчы була бугай,
Пенсиягә формальне?!

1967

## Кем бирде?

...Төренеп ятып түбә саламына
Бүре булып улый төнге җил.
Әнкәемнең кайнар кочагында
Васыятьләрен тыңлый идем мин...

Мин кояшка ялынам...
Ә ул чыкмый.
Аның өчен — минем моң нәрсә...
Син, Владимир Ильич, тыңлый-тыңлый
Безнең моңны шундый төннәрдә,
Йөрәгеңә җыеп халык зарын
Безнең Илне күреп узгансың,
Һәм миңа да бәхет яулап йөргән
Баһадирның берсе булгансың!

[1] Шигырь күренекле педагог, әдәбият белгече, галимә Җамал Вәлиевага багышланган.

Син икән ул — минем ишенең дә
Моңлы башын сыйпап китүче,
Саргаймаска тиеш бу малай да,
Корымаска тиеш диюче.

...Туганда мин әйбәт малай идем.
Мине
Моңаерга кем соң өйрәтте?..
Кем бирде соң?—
Кем бирде соң миңа шундый җанны,
Шул романтик, уйчан йөрәкне!?

Туганда мин әйбәт малай идем.
Кем өйрәтте,
Моңаерга мине
Кем өйрәтте?!

Кем өйрәтте,
Тын көнне дә
Үксеп елый торган
Камышларыммы?
Сай күлләрдә
Караешып беткән
Аккошларыммы?
Никрутларның
Төнге набат сыман яңгыраган
Сагышларымы?

Төннәр буе йокы күрми торган
Чишмәләрем, инешләрем әллә
Мине шулай моңлы итәләрме?
Моңаерга мине кем өйрәтте?!

1939

Фатих Хөсни

# БЕРӘҮ БИК ЯКЫН КЕБЕК...

хикәя



Унынчы классны бетереп чыгучыларның болай да баш әйләндергеч мәшәкатьле көннәрендә, кайсы уйлап тапкандыр, төрле профессия кешеләре белән очрашу кичәсе уздыруны билгеләгәннәр иде. Колхозның агрономы, зоотехнигы, медпункт мөдире, парторгы, бу колхозныкы яки бу төбәкнеке булмаса да, юлы туры килгәнлектән, аннан да бигрәк, үзе кызыксынып сорау сәбәпле, өлкә газетасының собкорын да кертеп, бөтенесе чакырылган иде. Хәтта районда ярыйсы гына спектакльләре белән дан казанган режиссерны да онытмаганнар, кыскасы, үз профессиясен мактап сүз әйтә алырдай кешеләр бөтенесе шунда иде. Әлбәттә, аудитория дә бар, быел унынчыны бетерүчеләрнең егете, кызы барысы да килгән, хәтта быел булмаса, киләсе елда бетерәчәк яшьләрнең дә кайберләре, арткарак булса да, кысылганнар. Һәм барысы да бәйрәмчә киенеп-ясанып килгән иде.

Шулай да сөйләшү алай тиз кызып китмәде. Әйтердәй фикерләре булса да, берсе дә чәчрәп чыгарга ашыкмый, берсеннән-берсе уңайсызланалар. Аннан да бигрәк, газета собкорының блокнотын өстәлгә үк чыгарып салып, язарга сусап карап торуын өнәмиләр: янәсе, әйтерсең уйлап җиткермичә берәр сүз, ә ул иртәгесен үк газета битендә басылып чыккан булыр.

Парторгның яхшы ук пафоска бирелеп әйткән кереш сүзеннән соң гына, анда да кыстатып-кыстатып кына, чыккаладылар. Арада иң кыюы газета собкоры булды.

— Без үз эшен яхшы белүче югары квалификацияле кадрлар авылга гына кирәк дип уйлыйбыз. Ю-у-ук, алар бөтен җирдә, бөтен халык хуҗалыгына кирәк. Ул кадрларны, беренче чиратта, әлбәттә, менә сезнең арадан, яхшы шартларда укып, урта белем алган, чыраегыздан ук күрлек бәрелеп торган, чәчәктәй киенешеп килгән менә сез яшь буыннан да көтмәсәк, я, әйтегез, без аларны тагы кайдан көтәргә тиеш булырбыз? — дип, үзен югары дәрәҗәдә тотарга тырышып башлады ул сүзен һәм соңыннан вакланыбрак киткәнлеген хәтта үзе дә сизми калды: — әйтик, мисал өчен менә безнең газета чы-

гару эшен алыйк. Бөтен шартлар тудырылган. Ундүрт катлы өр-яңа бина, кругом пыяла да бетон. Ике кешегә бер бүлмә. Ярыйсы гына зарплата, шуның өстенә эшләгән кеше гонорарын да ала. Кыскасы, яз да яз, газиз угълым, Тукай әйтмешли. Мәгәренки, безнең редакцияләрдә дә ташып тормый чын журналистика кадрлары. Атап әйткәндә, хәзергесе көндә безнең редакциягә ике литсотрудник, бер собкор, ике корректор җитми. Әгәр, әйтик, шул урыннарга журналистика факультетында махсус белем алып чыкканнан соң сез килеп утырсагыз, начар булыр идеме? Бер дә начар булмас иде. Онытмыйк, иптәшләр, гомуми бурычлар, ил һәм халык куйган бурычлар турында сүз бара.

Башкалар, ул чаклы кызып сөйли алмасалар да, үз профессияләренең кызыклы һәм кирәкле якларын «чәчәктәй киенешеп килгән» яшьләргә ничек тә төшендерергә тырышып әйттеләр сүзләрен. Бу колхозга узган ел гына авыл хуҗалыгы институтын бетереп килгән яшь зоотехник Кадыйр Сарманаев кына сүз әйтмәде. Күрәсең, үз эше, үз фермалары белән бәйләп ни дә булса әйтергә ул әлегә иртә дип исәпли, ә гомуми сүзләр болай да җитәрлек булдыга саный иде... Ә яшьләр, бигрәк тә арадан ике кыз, иде дус кыз, нәкъ әнә шул кыюсыз зоотехник егет әйткән сүзне көтәләр иде. Әллә ни шаккаттыргыч өндәү-димләү сүзе дә әйтәсен, ул ике кызның кешегә әйтеп булмый торган үз сәбәпләре бар: Халидәсенең сәбәбе — зоотехник егет аларда фатирда тора, кызның күңеленә егеттән, гәрчә егет үзе моны сизмәсә дә, җан эреткеч очкын чәчрәп төшкән, егет авызыннан чыккан һәр сүз аның өчен сүзләрнең дә сүзе кебек тоела иде. Ә Саимәсенең әнисе фермада сыер савучы, кызның уйлавынча: зоотехник егет, әгәр ферма эшенә кагылып нинди дә булса сүз ача калса, аның әнисе турында, ничек тә мактап, берәр җылы сүз әйтмәс иде микән?

Сораулар биргәләп тә, кыек атып туры тидерергә маташып та яшь зоотехниктан шома оратор ясап чыгара алмадылар, шулай да ул бу очрашуның чын мәгънәсен дөрес аңлап, берничә сүз әйтмичә калмады.

— Авылда туып, шунда үскән яшьләр утыра монда,— дип башлады ул, озын сөйләмәячәген алдан ук сиздерергә тырышып. — Аларны агитацияләп тору кирәк түгелдер дип уйлыйм. Әгәренки авылны яратсалар и аның бугаздан китереп тоткан хаҗәтләрен дөрес аңласалар, агитациясез дә авылныкы булырлар, безнеке булырлар. Әгәр аңламасалар, аларны авылныкы итүнең кемгә кирәге бар?

Бөтен сүзе шул булды яшь зоотехникның һәм аның кыска речь тегe ике кызны, ике дус кызны, Хәлидә белән Саимәне, әлбәттә, канәгатьләндермәде. Дөресрәге, тиешенчә канәгатьләндермәде.

*

Очрашу шактый озакка сузылды. Клубтан таралышканда сәгать төнге уннар чамасы иде. Җәй башына хас булганча җылы, йомшак һәм чак кына зәңгәр моңсулык белән тулган төн иде. Кырлардан, фермалардан кайтышы булганмы, зоотехник Кадыйр Сарманаев мотоциклы белән килеп туктаган икән, клубтан фатир хуҗасының кызына эндәшә чыкты:

— Күп агитация тыңлап арыган булсагыз, иярегез, Халидә, утыртып алкайтам.

— Без бит икәү,— дигән булды тегесе, әллә тыйнаклык саклап, әллә базарын күтәрергә теләүдән.

— Теккән белән Таккан, беләм мин синең Саимәдән аерылма-

ганыңны.— Һәм шунда ук өстисе итте: — Икегезгә дә урын табылыр, тирбәтеп кенә алып кайтырмын.

Шулай киң күңеллелек күрсәтеп сөйләшсә дә, минуты белән тырылдатып алып китәргә ашыкмады. Кызлар килеп туктагач та мотоциклын сөрткәләгән булып бераз көттерде.

— Бик тузанга баткан, мондый тузанлы матайга кызлар утырту килешмәс,— дигән булды хәйләкәрләнеп. Чын дөреслектә исә үе бүтәндә: клубтан таралучыларның аяк тавышлары басылганны көтә, кызлар ташый башлаган бу зоотехник егет, дип уйламасыннар, янәсе.

Менә ул әшен бетерде, утырырга да чабарга хәзер һәм, кызлар каршы килмәсә, бераз әйләнечрәктән чабарга иде.

— Рәхим итегез, кызлар. Кем ничек урнаша ала.— Шулай да өстәп әйтмичә кала алмады: — Халидә, малай, син үз кеше гаеп итмәссең, давай, бишеккә Саимәне утыртыйк, кунак кыз булып тирбәлеп кайтсын бер. Тем более, әнисе дә минем атаклы дояркам.

— Кеше дигәнең өнле! Әнисе өчен кызын тирбәтмәкче. Алайга китсә, мин бөтенләй дә утырмам.

Ләкин бу яшьлек кирелеге генә. Саимә егетнең әлеге тәкъдименә күңеленнән бик-бик шат, хәтта фатир хуҗасы кызыннан өстен куеп, йомшак урын әзерләп торудан чак кына борынын да күтәргән кебек күренә иде. Борынын ук күтәрмәсә дә, шулай да кабат әйттермәде, тәкъдим ителгән «бишек»кә иплән кенә менеп кунаклады. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, Халидә дигәне моны бик алай иple кабул итмәде. Белә Халидә, белә генә түгел, күңеленнән шулай саный: Саимә Халидәгә караганда чибәррәк. Ә ул, мотоцикл хуҗасы, Халидәләрдә фатир торучы зоотехник егет, мөгаен, шунлыктандыр, йомшак урынга Халидәне түгел, Саимәне утыртты. Хурланып үләрсең, әй!

— Утырсам, тик бер шарт белән,— диде Халидә, мотоциклның арткы иярәнә җиңел генә сикереп.— Синең үзеңә чытырдап ябышачакмын, Кадыйр абый. Юкса, минем башым әйләнә, очып төшеп калсам, җавап бирә алмыйча интегерсең.

Һәм болай куркытып кую белән генә чикләнмичә, шунда ук рульдәге Сарманаевны биленнән кочып та алды.

Киттеләр. Хәерле юл телик үзләренә. Әмма алдан өзеп әйтү кыен, хәерле булырмы икән юллары! Башта ук болай кырлы-мырлырак торгач. Җитмәсә, чөй өстенә тукмак, Халидәләр капкасы төбенә кайтып җиткәч (фактически: үз фатирына дигән сүз), Кадыйр абыйсы, Халидә күңелендә уйнаган каршылыклы хисләр белән чак кына да исәпләшмичә, ачык кына итеп әйтеп куймасынмы:

— Син кереп, өйгә ут ала тор, Халидә, мин бер очтан Саимәне дә өйләренә хәтле илтеп куйыйм.

Нәкъ әнә шулай диде, үз колаклары белән ишетте Халидә, һәм кызның каршылыклы хисләре отыры котырына төште: «Ярый ла, өенә илтеп кую белән генә чикләнсә... мондый матур төндә... Икәүдән-икәү генә калып соң... Үзем дә инде... шыр тиле түгел диген. Төшеп кал дигәнгә, ялт төшеп кал, имеш!»

Халидәнең шикләнүләре беркадәр дөрескә дә чыга язды, ләкин беркадәр генә. Саимәләр турыннан, хәтта өйгә сәлам дә бирмичә диярлек, зырылдап узып китте мотоцикл. Авыл башына җиткәч, хутын чак кына әкренәйтеп, кыздан сорады егет:

— Әллә тагы бер әйләнәбезме?

— Юк, әйләнмибез, Кадыйр абый,— диде кыз өзеп.— Мине капка төбебезгә кире кайтарып куй да, теләсәң, биш әйлән, каршылыгым юк.

Бу шундый ныклык һәм катгыйлек белән әйтелде ки, моннан соң егетнең тәвәккәллеге бары тик «хәерле төн, Саимә!» диярлек кенә калган иде. Анысы да әле рульдә утырган килеш кенә әйтелде. Ә бит мөмкин иде, шайтан алгырысы. Китапларда, мәхәббәт хикәяләрендә язылганча эшләргә дә мөмкин иде. Әйтик, мотоциклны бөтенләй истән үк чыгарып, капка төпләрендәге эскәмиядә бераз янәшә утырып торырга. Әгәр рөхсәт итсә, кызның кулын үз кулына алырга. Анысы да тик рөхсәт итсә генә. Унынчыны бетергән кыз, бөтенләй үк плансыз да түгелдер, уйлары-планнары белән кызыксынырга да мөмкин иде. Клубта яки рәсми очрашуларда гына сөйләшергә димәгән, ник монда, шушы зәңгәр төндә, икәүдән-икәү генә калып сөйләшмәскә: «Бер кая да алгысыма, матурым. Кал үзебезнең колхозда. Бергәләп, кулга-кул тотынышып эшләрбез, бергә тормыш корып җибәрербез. Син мине яратырсың, мин сине яратырмын, шуннан да зур тагын ни кирәк безгә?» диярга иде. Аннары, әгәр рөхсәт итсә, һич югы, каршы килмәсә, бит очыннан гына бер үбеп алырга иде. Бит очыннан гына, каршылык күрсәтмәсә генә... Мөмкин иде, мөмкин иде, каһәр. Ә менә берсе дә булмады. Әйтер сүзләре әйтелмичә күңелендә тагылып калды егетнең. Хәер, иртәгә дә аның иртәгесенә дә көн бар ич. Болай хәтта рәхәтрәк, күңелнең буш йөрүенә караганда, күңелнең әйтелмәгән матур сүзләр белән тулып йөрүе рәхәтрәк.

Истәлекле булды шулай озатышып йөрү. Беренчедән, Халидәдә дус кызы Саимәгә карата ниндидер алышыну сымак үзгәреш башланды. Юк, бу тел кузгатып әйтеп була торган үзгәреш түгел, моны табышмакка охшаган сәбәпсез салкынаю дип тә булмый. Ике дус кыз — юл төшкәндә элеккечә үк бер-берсенә керә-чыга йөриләр, сөйләшүләре дә, үзара серләшүләре дә була, ләкин теге төндәге озатышып йөрүләре турында нә берсе, нә икенчесе теш агартып сүз кузгатсын, әйтерсең, андый хәл бөтенләй булмаган. Аннары болай булды. Гадәттәгечә, бер көнне алар, икәү генә калып мединститут, имтихан бирү шартлары, имтиханда куелачак якынча сораулар белән танышып утырганда, Халидәсе аны-моны уйламыйча гына әйтеп куйды:

— Бик алай калтырап тормыйм, керә алмасам, барган юлыма киртә тотмаган, әйләнеп кайтып, колхозда эшләп калырга да күп алмам,— һәм ышанычлырак чыксын дигән төсле итеп өстәде: — әнә күпме чакырып, колакка тукып торалар колхозда калыгыз, дип.

Әлбәттә, Халидә моны уйлап тормыйча гына әйтте, ләкин Саимә уйламыйча булдыра алмады: тиктән генә чыккан сүз түгелдер бу, теге төнне зоотехник егетнең Саимәне ялгызын гына утыртып йөрткәне өчен ачуы чыгып әйтүе булгандыр... Күңелдәгесе бәреп чыккандыр.

Шундый буталчык уйлар белән иләсләнүе нәтиҗәсендәдер, бер көнне Саимә әнисе алдында болай дип сүз ачты:

— Әни, әгәр мин синең урында фермада эшләп калырга уйласам, син ничек карарсың? Әнә Халидә дә фермада калыргарак чамалап тора.

— Минем чиләнү генә җитмәгән, син дә башыңны сыер корсагы астына тыкмакчы икәнсең? — дип кабынып китте әнисе һәм, тавышын бераз йомшарта төшеп, җәберләнгән, өмете киселгән кешедәй, суза биреп өстәде: — Авызымнан өзеп, үзем киясене кимичә, шуның өчен укыттымы мин сине ун ел буена?

Әнисе дә әлбәттә, хаклы: Казанда врачлыкка укытып, бердәнбер кызының ак халатлы һәм халык алдында абруйлы врач булып ки-

түен бик-бик тели, яшьли иреннән калып, ялгызлыкның ни икәнлеген татыган булса да, кызының якты киләчәге өчен тагы биш-алты ел ялгыз яшәргә бик риза, бары тик кызы укысын, врач булып чыксын гына иде.

Бөтенесе аңлашыла, тик бер нәрсә генә аңлашылып җитми Саимәгә: нишләп соң әле ул соңгы көннәрдә үзен ничектер ялгыз сизә башлады. Дус кызы Халидә дә читләшә төште, бергә утырып хыяллар кору, институтка әзерләнүләр дә бетте диярлек. Халидәнең әлеге шул кыюсыз-тыйнак егет, узган ел гына авыл хуҗалыгы институтын бетереп кайткан яшь зоотехник Кадыйр абыйга күзе төшкәнлеген Саимә сизәме? Сизмиме соң! Бу турыда Халидә ничәмә-ничә тапкыр үзе дә ишарәләде. Якын кешесе итеп башына килгән уен әнисенә әйтеп караган иде, фикерен әнисе дә уртаклашмады. Җитмәсә тагы әлләкайчан онытылган бер җырның башлангыч куплеты исенә төшеп, хәтердә гел яңгырап тора:

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек,
Ялкынлаанган йөрәгемә
Бераү бик якын кебек.

Һич уйламаганда, һич көтмәгәндә аңлап булмый торган хәл: зоотехник егет бер көнне көпә-көндез аларның өенә, Саимәнең болай да буталып беткән уй-хисләрен тагын да буташтыра төшү өчен күктән иңгәндәй, рөхсәт сорамыйча гына килде дә керде.

Керде һәм сүзен дә тапты. Янәсе, Саимәнең әнисен, Сабирәттәйне күрергә керүе. Күзеннән, ышаныр-ышанмас әйткән сүзләреннән үк сизелеп тора: мәтәштерә. Ләкин «кемгә сөйлим серләремне?» дип озакка суза торганнардан түгел, бу яктан алганда, Саимәдән аерыла иде егет.

— Кергән-кергән, сиңа да әйтәсе сүзем бар, Саимә,— дип ялгап алып китте, беравык икеләнеп торганнан соң.— Нишләп әле син, кызый, мединститутка китәргә дигән уеңнан суындың? Беркөн әниеңнең ферма өендә, елар дәрәҗәгә җитеп, башкаларга зарланып торуын ишеттем.

— Нишләп дип... үзегез ич... Фермада калырга агитлап торасыз ич. Очрашулар үткәрәсез, кызыктырасыз.

— Алайса, бу юлы мин... Әйтәм икән, турысын әйтим: Сабирәттәйнең сүзен тыңлап, бу юлы мин икенче төрле агитация белән кердем. Син, кызый, алай төрлесен уйлап, әниеңне борчыма: медицина юлы белән китәргә дип бер уйлагансың икән, и шул юлдан китеп, барып чыгарыңа ышанасың икән, сәгать теледәй як-якка чайкалма. Вперед полным ходом, кыскасы.

— Ә менә шулай полный хут белән алга куганда... юлыңда, хыялны кузгатып, котыртып торучы бераү очраса? Һәм ул «бүтән бераү» онытыпь та, тотып та булмый торган җырга... күңелгә якын җырга* әверелсә, Кадыйр абый? Сез нинди киңәш бирер идегез, әгәр шулай була калса?

Оялчан диган идек, Кадыйр абыйсы искәртмәстән генә килеп кергәч, югалып калган сымак күренгән иде, карагыз әле сез бу Саимәне, әйтәм дисә, сүзен таба ала икән.

Әнисе белән дә, зоотехник егет белән сөйләшү дә ул хәтле читен булмаган икән, ә менә үзе белән үзе сөйләшү ерып чыккысыз карурман булып чыкты. Җәйнең җәй буе шул турыда баш ватты Саимә, әнисе белән дә берничә кабат сүз кузгатты. Бик йөдәтә башлагач, ахырында бер көнне тәмам җене чыгып Сабирәттәй әйтте кызына:

— Алай җиң сызганып бик сыер б... батасың килә икән, сүзем юк, бар, бер генә смена мине алыштырып тор, белерсең ферма эшенең төмен...

Кыскасы, башы катты кызның җәй буена. Әнисенең аны мединститутка җибәрәсе килә. Күз төшеп йөргән зоотехник егетнең шулай ук җибәрәсе килә. Тик менә Саимәнең үзенең генә китәсе килми. Аңа монда рәхәтрәк. Монда аның әнисе, монда туган авылы, ялан тәпи чапкан тыкрыклары, монда аның.... я хода, ни кадәр генә күз алдына китермәскә тырышса да, барыбер килә... монда мотоцикл бишегендә тирбәлеп чапкан айлы төннәр...

Хәлбуки, китәргә икән — китәргә кирәк. Медицина институтына икән — медицина институтына. Врач булып чыгарга икән, әлбәттә, врач булып чыгарга. Иң әһәмиятлесе, бу кирәклекне кыз үзе аңлый, бөтенесеннән дә ныграк, барыннан да ярсыбрак аңлый.

Шундый каршылыклы уй-хисләр белән күмелеп, алардан да бигрәк, китап-дәфтәрләр белән күмелеп, җәйге айларның үткәнен сизми дә калды кыз. Институтта имтиханнар башланыр көн дә җитте.

Җыйналу тиз һәм шау-шусыз булды. Гәрчә Сабирәттәйнең шауларга дәрте юк түгел — имтиханга китеп баруны ул инде кергәнгә саный иде. Ләкин Саимә әнисенең очынуын тиз басты.

— Кешегә-карага ишеттерәсе түгел, керә калсам, мактанырга аннан соң да өлгерерсең,— диде ул, каршы әйтергә урын калдырмаслык итеп.— Шуны да исеңнән чыгарма, әни, институтка керү син уйлаганча шаккатырдай эш түгел хәзер. Керәләр дә укып та чыгалар, эшлиләр дә.

Кыскасы, шауламаска булганнар иде, сөенечне ана кеше күңелендә саклый алмаганмы, хәбәр башка берәр җирдән тишелеп чыкканмы, автобус тукталышында әнисе белән әле елашып, әле үзара киңәш-табыш итешеп, шулай да, кеше күзенә бик ташланмаска тырышып көтеп торганда — беләсезме, мотоцикл уйнатып кем килеп чыкты? Инде аны Халидә миннән тартып алды дип уйлаган кешесе — Кадыйр абыйсы килеп чыкты.

— Абау, кайдан ишеткән бу? Әче таңнан күзеңне ертып болай чапмасаң,— дигән булды кыз, юри исе китмәгәнлек күрсәтергә тырышып. Дөресен әйткәндә, бу минутларда кызның телендә икенче сүз булырга тиеш кебек иде. Якынында гына әнисе тору комачаулады булса кирәк — бөтен җирдә дә итәгеңә әниең тагылып йөрү шарт түгел икән шул.

Кыз исе китмәгәндәйрәк күренгәч, егет тә тәкәллеф саклап торуны кирәк тапмады.

— Утыр бишеккә, беренче утыруың гына түгел,— диде кызга туп-туры карап.— Сабирәттәй үзебезнеке, шәт, рөхсәт итәрдер.

Кыска-кыска гына сүзләр әйтелде, күңелләре белән берсе икенчесен аңлагач, шул кыска сүзләр дә җитте тагын. Артык ялындырып тору булмады. Әйтелмәгәнен, мотоцикл газ биргәч, рульгә утыргач, егет өстәп әйтте:

— Балавыз сыкма, Сабирәттәй, мин синең бу тыңлаусыз кызыңны барасы җиренә момент үзем илтеп куям, институтын бетереп, «отлично» дипломы алуга, момент үзем барып апкайтачакмын. Әнә иртәнге кояш тыңлап тора, шаһит булсын.

Әлбәттә, очыныбрак әйтелде һәм, бәлки, бу аерылышу минутларында җитдирәк булганда да зарар итмәс иде. Ләкин нишләмәк кирәк, әйтеләсе сүз әйтелде, аны кире җыеп алып булмый. Хәзер безнең эш: ул сүзләрне чынга юрау. Әйе, шулай булсын, әйтелгәнчә барып та чыксын иде — бездән хәер-дога яшьләргә!

1979

# БӘЙРӘМГӘ — ДУСЛАР БУКЕТЫ

## Нормурад Нарзуллаев,
үзбәк шагыйре

### Татарстан кызлары

Чулпандай балкыйдыр күзләре,
Анардай[1] янадыр йөзләре,
Балдан да татлыдыр сүзләре
һәм чәк-чәк сузадыр үзләре.
Аңладым һәм күрдем мин бүген:
Дусларга ачадыр күңелен
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

Анабыз һавадан сорагыз,
Атабыз Адәмнән сорагыз,
Зәңгәрсу гөлләрдән сорагыз,
Иртәнге җилләрдән сорагыз,
һәммәсе ялгышмый әйтерләр:
— Гүзәлләр, назлылар, матурлар
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

КамАЗда зур эшләр барганда,
Галәмгә киң юллар салганда,
Мәхәббәт утында янганда,
һәрвакыт, һәр төштә, һаман да,
Кулларны тотышып кулларга,
Бәхеткә үзләре юл яра
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

Хисләре сүрелмәс ялкындыр,
Эш сөйгән куллары алтындыр,
Үзләре шиңмәс гөл кебекләр
Пар булсын иң тугры егетләр.
Аларга киная сакламас,
Бер биргән вәгъдәсен тапламас
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

---

[1] Анар — гранат.

Ятлыйлар Тукайның җырларын,
Тыңлыйлар Сәйдәшнең моңнарын,
Бишектән гашыйклар Җәлилгә.
Тавышы ишетелсен һәр илгә:
Үзләре җырлаган җырларда
Исемен илтәләр чорларга
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

Соклана аларга Илһамнар,
Мул хисле аксакал Туфаннар.
Ямь-яшел болыннар куенында,
Аерылмас дуслары туенда
Җыр итеп иң изге уйларын,
Яңгырата чал Идел буйларын
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

Дулкында акчарлак тирбәлә,
Сандугач җыр сузып җибәрә,
Тургайлар моң түгә һавада...
Мин — үзбәк — мең гашыйк
аларга!
Яратып аерылам сездән мин,
Хушлашып кулларым сузам мин,
Татарстан кызлары,
Татарстан кызлары.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәсе.

## Ташкентта Тукай урамы

Шәһәремдә якты, яшел бер урам бар, —
Кан тамыры кебек хәрәкәттә һаман.
Таңнан алып кайный анда моң дулкыны,
Шаулап-ярсып ага тормыш дәрья сыман.

Кулына алтын каләм тоткан шагыйрь халкы
Тоя монда гаҗәп бөек илһам көчен.
Авыр сулап гашыйк җаннар күтәрәләр
Шәраб тулы касәләрен дөнья өчен.

Шагыйранә булган халык мәхәббәте
Сыймый икән үлчәүләргә, бизмәннәргә.
Шигырьләре яши җанда — талант диген
Олуг асыл ташлар белән бизәлгәнгә.

Бу урамда бөек шагыйрь рухы яши,
«Нәваи»га килеп әнә ул тоташа.
Остаз белән шәкерт монда очрашалар,
Серләшәләр алар ерак чорлар аша.

«Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәбез, сез каласыз!»— дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә».

...Килде котсыз буран улап, күк күкрәде,
Күкрәкләрне яшен уты телгәләде.
Зилзиләдә тетрәнде җир — исән калдык,
Һәр ватандаш йөрәгендә — шигырьләре.

Каршылый ул мине һәр көн туганнарча.
Язганнарым тәэсирләнеп ул күзәтә.
Илһамчыбыз — аның күңел кошы — күктә,
Иң кадерле кунак үзе һәр үзбәккә.

Шагыйрь күңеле — мәңге шиңмәс гөл бакчасы,
Җырлары да гомере кебек — гүя кояш.
Йөрәккәен дөнья тыңлый, кушылып җырлый,
Ирек сөйгән шагыйрь безгә чын замандаш!

ФӘННУР САФИН тәрҗемәсе.

## Сергей Макаров,

рус шагыйре

### Искә төште

Мин Иделдә үстем. Бала чаклар
Әйләнделәр изге ядкарьгә.
Бүреләр дә әйбәт була иде
Без тыңлаган әкиятләрдә.

Истә әле, килде Җиңү көне...
Ятмадык без төнен йокларга.
Шуннан бирле кайгы кәгазьләре
Килмәс булды безнең йортларга.

Күк күкрәде, хәтерләтеп безгә
Дәһшәтләрен сугыш кырының.
Немец әсирләре җимерекләрдән
Чистарталар детдом урынын.

Истә әле, сайрады бер кошчык,
Шуны тыңлап яшьне киптердем.
Мин, бер сабый, немец әсиренә
Печенье һәм хәлвә китердем.

Алышырга түгел, кызганганга
Алып килдем ипи. Бөтенне.
Тезләнде дә немец, елый-елый,
Ни өчендер гафу үтенде.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Рәсүл Рза,

әзербайҗан халык шагыйре

### Теләгем

Теләгем:
агласа да күктә болытлар,
еламаса иде балалар —
әниле я әнисез сабыйлар.

Теләгем:
көн туса, чәчәкләр ачылсын....
Тик пулялар очмасын —
рәхимсез, төз атылган пулялар...

Теләгем:
салкында ишекләр ябылсын,
тик күзләр ачык, җан аек булсын,
иң кирәкле сүз әйтелми калмасын!

...Янгыннарның сүнсен барчасы,
сүнмәсен бары өметләр.
Өлгерсен бакчада тулышып, сутлы җимешләр,
йөрәкләрдән тик кан саркымасын!
Ботаклар бөгелсә дә алма күплектән,
оят, көчсезлектән
кешеләр имәсен башларын!
...Күз яшедәй саф болаклар булсын —
җирдә елга булып күз яше акмасын,
тезләнеп, кемнеңдер кулына
теләнгән кеше бакмасын...
Уяу булсын йолдызлар төнозын,
ә кеше йокласын, көч җыйсын
үзен көткән яхшы эшләр өчен.
Ышаныч белән ачсын ул
һәр иртәдә күзен.

...Булсын шатлыклар, бәхетләр күбрәк.
Иллərдән илләргә юл узсын. Ул — кирәк!

### Шигърият теле

Шундый бай шигърият теле!
Ул телдә син
теләсәң шатлыгың,
теләсәң кайгыңны җыр итеп яз.
Тик шигърият теле шундый серле:
җаһил кеше, йөз кат укысын —
барыбер берни аңламас!

## Болар — сары төстә

Тук бөртек тулы башаклар диңгезе.
Сабые гарип булган ана йөзе...
Кочагына көз алган агачлар...
Өлешен көчлеләр тартып алган ачлар.
Хәтта мәхәббәтне
таплый алган алтын — металл.
Тормыштан аерылган зәгыйфь хыял!
Саз кыллары ыңгырашканда
юлга төбәлеп арган күзләр.
Дөньяга баккан яшь нәркисләр.
Сугым сараена ваемсыз атлап керүче үгезләр...
Кешедә янып сүнгән күп өметләр!

## Ләкләк

Ахры, тарткандыр җылы як,
кышка калмады ләкләк.
Әмма яз бәйрәмен күрде:
аңа кайтып өлгерде.
Диңгез аръягы иленнән
сабыйларга ул быел да
күп бүләкләр китергән:
әкиятләр алып килгән
каты томшыклы ләкләк,
озын торыклы ләкләк!

Кайда гына китсәң дә, бел:
сине көтәр, ләкләгем,
бездә җылы ояң. Ләкин
моңсу булса әкиятең,
сабыйларга сөйләмә аны,
сөйли күрмә, ләкләгем!

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН** тәрҗемәләре.

# Сәявуш Сарханлы,

әзербайҗан шагыйре

## Ипи-тоз

*Иген игүче татар кардәшләремә*

Безнең әтиләр — кайнар йөрәкләр —
Бу йола өчен утка кергәннәр.
Ипи-тоз белән кеше тук булган,
Ипи-тоз белән антлар биргәннәр.

Бу йола сыный дусны, дошманны.
Ул һәрчак безнең тормыш юлдашы.
Ипи-тоз булса — йөрәк нык тибә,
Күкләргә тия горур ир башы.

Иген бөртеге эченә сыйган
Гомер тәүлегең: көзен, язын да...
Тик хәер итеп бирмә син икмәк,
Тик дус итеп бир татлы тозын да.

Тук басуларны күреп куанам, —
Чык булып куна анда ак томан.
Шул басулардан үткән чагында
Ак томан кебек сафлыкка чумам.

Бу — бөек басу, бу — бөек сафлык,
Сакла, кешелек, моны — юл башын!
Җир әйләнмидер кояш тирәли,
Ипи-тоз аның бөек юлдашы.

Алтын башаклы басу ягыннан
Илаһи бер шау, бер көй ишетелә.
Игеннәр шавы гел шулай мәңгә
Яшәүгә гимн-җыр булып килә.

Күңелең киң булса, табын түрендә
Түгәрәк йөзле икмәгең көлә.
Дуска ипи-тоз суза белгән ир
Дошманга кылыч күтәрә белә!

Ипи-тоз кадерен югалтсаң, шигырь,
Син туа күрмә, сүзләр янсыннар.
Синең тууны ватандашларым
Ипи-тоз белән каршы алсыннар!

**ГӘРӘЙ РӘХИМ** тәрҗемәсе.

## Ламар,

болгар шагыйре [1]

### Казан

Мин дә йөрдем Казан урамында
Һәм карадым шәһәр тирәсен.
Һәр адымда күңел күрә монда
Дуслар эшен, дуслар көрәшен.

---

[1] Болгария халык республикасының хезмәт герое, поэзия ветераны Ламар (Лалью Маринов) 1962 елда Казанда булып Татарстан әдипләре белән якыннан танышып-дуслашып киткән иде. Аккош күлендәге дачада без бергә тордык, экскурсия маршрутлары буйлап та мин йөрттем. Белоруссиядә халык шагыйре Янка Купаланың 70 еллыгы бәйрәмендә очрашкач, республикабызга кунакка Минск шәһәреннән аны мин алып кайттым — чөнки безнең «Шәһре Болгар» тарихы белән кызыксынуы көчле иде. (Тәрҗемәче искәрмәсе.)

Болытларга тия манаралар,
Суда уйный төзелеш нурлары,
Бизәл, Казан, һаман яңара бар! —
Дидер төсле дулкын җырлары,

Казан — бишек: шатлыгын да аның,
Хәсрәтен дә халык тирбәткән.
Күмелгән ул дәртле, татлы моңга,
Ә чыбылдык итеп — нур япкан.

Яңа портның биек краннары
Күккә гүя тиеп торалар.
Килә монда кораб кәрваннары —
Иркен сулап килеп керәләр.

Дуслар, дуслар! Тормыш диңгезенең
Юлларын сез кыю яргансыз,
Балкышын сез бәхет йолдызының
Йөрәкләргә тирән салгансыз.

Утларыңа, Казан, карыйм кат-кат,
Һәм әйтәм мин якты Казанда:
Син нур бирдең зур дуслыкны мактап,
Сине сөеп шигырь язарга.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе.

## Павел Любаев,

мордва шагыйре

### Күпер салыйк

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Туган илем,
Кеше синдә хуҗа булганга,
Туганлык һәм дуслык хисе аша
Күңелләргә шатлык тулганга.

Без бер тату семья. Җаннар шуңа
Бер-берсенә һәрчак тартыла.
Татармы син, русмы, я кыргызмы —
Әйдәгез, бер өстәл артына.

Кем килсә дә сиңа кунак булып,
Туган итеп сине китәрләр.
Кемгә генә килмә, үзеңне дә
Туган итеп кабул итәрләр.

Илемдәге кардәш-туганнарның
Йөрәгенә сал син күперләр.
Шул күпердән безнең якын дуслар
Йолдызларга кадәр үтерләр.

Шул күпердән — дуслык күпереннән
Юл салыйк без яңа дусларга.
Ныграк кыс син кулын дусларыңның —
Җылың күчсен кайнар учларга!

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Гатаулла Кармеев,

Саратов шагыйре

### Ике Кремль

Игезәкләр булып тоелалар:
Берсе белән кичә хушлаштым.
Бүген менә иртән Казанда мин
Икенчесе белән очраштым.

Безгә сөйләр өчен саклый алар
Ташларына тарих язганны.
Берсе аның Мәскәү каласында,
Икенчесе бизи Казанны.

Икесе дә шундый якын булып
Урын алган күңел түрендә.
Якын булулары гаҗәп түгел —
Икесе дә Рәсәй җирендә!

### Идел

Көннәр буе җанны талкып торган
Уйларымнан арыган чагымда, —
Шау-шулардан аерып, юлым сиңа
Алып килә мине тагын да.

Күзем төбәп зәңгәр киңлегеңә,
Сокланам мин сиңа, Иделем!
Сине улын һәрчак аңлый белгән
Ана белән тиңләр идем мин.

Атлап барыр юлым кайчагында
Упкын-таулар белән киселә.
Дулкыннарыңның бир мәгърур көчен,
Тирәнлегеңне бир хисемә.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәләре.

**Вячеслав Кузнецов,**
Ленинград шагыйре

•

Ташладым мин күкне.
Йолдызлар да
Тиеп тормый инде иңемә.
Текә-текә йолдыз юлларыннан
Кайтып төштем менә җиремә.

Тик шикләнмә.
Куркаклыктан түгел.
Ул чакларда, дөрес, яшь идем.
Күк законы миңа изге һаман,
Шул законнар белән яшимен.

Гел сагынып яшим күкрәүләрне,
Зәңгәр күкнең зәңгәр үрләрен.
Минем җанда
Аэродромнар гүли,
Мине чакрып елый төннәрен.

## Язмыш

Күздән кичер гомереңне,
Хатирәләргә күмел.
Көймәң ярда икән, булсын...
Ул әле бәла түгел!

Көймәң булгач, җиңел булсын,
Дулкыннар яралганы.
Ә давылда ышанычлы
Җилкәннең ямалганы.

Күп кичергән давыл белән
Ул күзгә-күз калуны.
Яралар ул — зур горурлык,
Кырыс чорлар кануны.

Көймәң ярда икән, димәк,
Өмет — көймә җанында.
Төшенә биек дулкыннар
Керә булыр аның да.

Дулкыннар көтә көймәне!
Дулкыннар — зур, иләмсез...
Җилкәнен киерсә көймәң,
Ул бит язмыш дигән сүз.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәләре.

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы,
профессор

# АЙ ҮСӘСЕН КӨН ҮСЕП...

Республикабызның 60 еллыгын тантана иткән бу көннәрдә А. М. Горький сүзләре искә төшә. 1930 елда, Татарстан АССР ның төзелүенә 10 ел тулу уңае белән җибәргән котлавында, ул болай дип язган иде: «...Татарларның республикасы үзенең ун еллыгын бәйрәм итә. Мин хезмәт халкының фидакарьлеге белән төзелә торган тарихның бу яшүсмере баһадир булып үсеп җитәчәгенә тирәнтен ышанам.

Аек акыллы, намуслы, хезмәт сөючән, йомшак күңелле һәм пөхтә, шул ук вакытта максатына ирешүдә тәвәккәл татар халкы турында бала чактан ук күргән-белгәннәрем бу ышанычның нигезе булып тора. Һәм ул Татарстан республикасының культура өлкәсендәге үсеш темплары белән дә ачык раслана» [1].

Октябрь кояшы астында тугандаш республикалар гаиләсендә үскән туган җиребез Татарстанны чыннан да «ай үсәсен көн үсеп» тиз арада гайрәтле ир, батыр йөрәкле көрәшче булып өлгергән баһадир белән чагыштыру бик урынлы. Экономикада булсын, халкыбызның тормыш-көнкүреше, мәгарифе, фән һәм культурасында булсын, — соңгы алты дистә ел эчендәге үсеш, үзгәреш чынлап та әкияти темплар белән барган, кайсы өлкәгә мөрәҗәгать итмә, иркенләп сөйләшерлек, горурлык белән искә алырлык казанышлар мөлдерәп тора. Шул җөмләдән татар совет әдәбияты бу үсеш-үзгәрешләрнең иң характерлы мисалларыннан берсе.

Милли сәнгатьнең башка тармакларыннан аермалы буларак, татар әдәбияты Бөек Октябрь революциясен шактый бай традицияләр белән каршы алды. Ул традицияләр кайнар, коры чүлдә дым эзләп бик тирән катламнарга киткән берән-сәрән, әмма ныклы, чыдам тамырларны хәтерләтә. Әдәби үсентеләр әнә шул рәвешле, күкрәп үсеп китәргә уңайлы шартлар булмау сәбәпле, халык рухы тирәнлекләреннән, аның өмет-хыялларыннан үзенә яшәү суты эзләп тамырлана килгән. Бары шушы гасыр башларында гына, Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә (1905 ел) һәм Бөек Октябрь революциясе җиңгәч кенә ул, классик рус һәм дөнья әдәбиятларыннан шифа алып, үзенә бер мөстәкыйль иҗат процессы буларак күкрәп үсеп китә.

Милли әдәбиятта критик реализм формалаша, традицияләргә чагыштырмача бай булган поэзия белән берррәттән проза, драматургия һәм әдәби тәнкыйть жанрлары да аякка баса. Тугандаш әдәбиятларның бердәм гаиләсендә лаеклы урын алып, социалистик реализм методын үзләштергән татар совет әдәбияты, ай үсәсен көн үсеп, яңадан-яңа биеклекләр яулый, уңышлар казана. Ниһаять, ул бүген мәһабәт, таза, нык бер имәнне хәтерләтә. Тукай, Әмирхан, Ибраһимов, Камаллар, Такташ, Җәлил, Кәримнәр ныклыгы, тазалыгы бар ул имәндә. Кәүсәсендә сырлар булыр. Тирән сырлар. Алары туган ил һәм халык белән бергә узылган авыр сынаулар, еллар һәм оллар истәлеге. Алар — азатлык һәм бәхет, социализм өчен көрәштә яуланган җиңүләр хатирәсе.

[1] Горький в Татарии. Казань. 1961, 122—123 битләр.

Мәһабәт агач дидек. Бәйрәм көннәрендә шул агачның республикабыз белән бергә соңгы алты дистә ел эчендәге үсеше күз алдына килә. Юбилейлар, түгәрәк даталар уңаена язылган мәкаләләрдә без шул тарихи юлны этапларга, чорларга бүлеп эзлекле рәвештә тикшерергә гадәтләнгәнбез. Бу юлы исә әдәбиятыбызның мәгълүм казанышлары турында язганнарны кабатламый гына, бүгенге әдәби процесс турындагы уйланулар һәм кайбер күзәтүләр белән уртаклашырга исәп. Чөнки бүгенге әдәбият —ул еллар буе тупланып килгән бай рухи мирасның турыдан-туры дәвамы һәм яңа шартларда формалашкан нәтиҗәсе дә. Татар әдәбиятының хәзерге торышында аның бигрәк тә Октябрь кояшы астында үткән юлы һәм шул данлы юлда ирешелгән казанышлары аермачык чагылыш таба.

Әдәбиятыбызның бүгенге халәте турында сүз чыктымы, иң элек, аның алгы сафында атлаучы тынгысыз аксакалларыбызны искә аласы килә. Әйтик, исем кушучысы Г. Тукай булган «Аң» журналында беренче шигырьләрен бастырган Н. Исәнбәтне, революция һәм яңа тормышның кайнар йөрәкле трибун-шагыйре, әдәбиятыбызда беренче булып даһи Ленинның үлмәс образын калку итеп сурәтләгән Һ. Такташның дусты Х. Туфанны, тәүге хикәяләре гражданнар сугышының утлы көрәш көннәрендә кызылармеец каләме белән язылган һәм 1919 елда «Эш» газетасында басылып чыккан А. Шамовны, иҗат эшчәнлеген егерменче еллар уртасында, олы әдип һәм остаз Г. Ибраһимовның тәнкыйть сүзен ишетеп, аның кайгыртучанлыгын тоеп башлаган М. Әмирне бүген дә арабызда күрү, аларның армый-талмый иҗат итүен тою үзе бер куаныч түгелмени!

Гражданнар сугышы чорында ук революциягә, Ватанга һәм халыкка бирелгәнлеккә зур сынау узган язучы Г. Бәширов, беренче әдәби әсәрләрен Бөек Октябрьның икенче еллыгына багышлаган драматург Р. Ишморат, тәнкыйть һәм әдәбият тарихы басуында озак еллар нәтиҗәле эшләп, күп чүмәләләр өйгән һәм олы-олы кибәннәр куйган М. Гайнуллиннарның тормыш һәм иҗат биографияләре татар совет әдәбиятының үткән юлын, үсеш этапларын калку чагылдырмыймыни?!

Җәлил, Кәрим һәм Кутуйлар белән бергә Бөек Ватан сугышы кырларына киткән Х. Госман, Ә. Еники, Ә. Исхак, Ш. Маннур, С. Хәким, Н. Дәүли, Н. Арсланов, М. Садри, А. Расих, З. Нури, Х. Камаловларның Татарстанның 60 еллык бәйрәмен иҗат уңышлары белән каршылавы шулай ук күңелдә бүгенге әдәбиятыбыз һәм әдипләребез өчен горурлык хисе тудыра. Гомумән, бүгенге татар әдәбиятының кайсы гына жанрын, кайсы гына тармагын алсак та, без анда, үзләреннән соң килүче берничә буын талантлы әдипләр белән бер сафта торып, ару-талуны белми иҗат иткән мөхтәрәм аксакалларыбызны — хезмәт һәм сугыш ветераннарын күрербез. Татар совет әдәбиятының беренче бураздаларын сызуга ук үзләреннән өлеш керткән, заман белән бергә өзлексез үсештә булган һәм әдәби процессны бертуктаусыз алга әйдәгән фидакарьләр турында сөйләгәндә күңелдә булган бар җылылык һәм хөрмәтне түкмичәчми җиткерәсе килә.

*

* *

Әдәбиятның авыр артиллериясе—проза хакындагы сүзне дә аксакал әдипләребез иҗатын искә алудан башламый мөмкин түгел. Әле утызынчы елларда ук «Сиваш» повесте, кырыгынчы еллар ахырында — илленче еллар башында «Намус» романы белән әдәбият сөючеләрнең кайнар мәхәббәтен яулап өлгергән Г. Бәширов соңгы ун-унбиш ел дәвамында «Туган ягым — яшел бишек» һәм «Җидегән чишмә» кебек күләмле әсәрләр тәмамлады. Бөек Ватан сугышы чорында колхозчыларның хезмәт героикасын масштаблы картиналарда тасвирлаган «Намус» романында автор шул чор өчен аеруча әһәмиятле булган мәсьәләләрне сәнгатьчә гомумиләштереп, зур осталык белән иҗат итү бәхетенә ирешкән. Шуңа күрә дә хезмәттәге батырлыгы, бетмәс-төкәнмәс оптимизмы һәм рухи сафлыгы белән аерылып торган Нәфисә әдәбиятыбызда сурәтләнгән гүзәл хатын-кыз образлары арасында бүген дә үзгә бер урынны били.

Җирнең, туган як табигатенең кадерен белергә өндәгән, аның киләчәге турында

олы кайгыртучанлык белән язылган «Җидегән чишмә» романы әдипнең талант чишмәсе бүген дә саекмау турында ачык сөйли.

М. Әмир иҗаты үзе генә дә татар совет әдәбиятының 60 ел эчендә ирешкән зур казанышларының ачык бер дәлиле. Халык язмышын, ил язмышын үзенеке дип кабул иткән бу өлкән прозаик, драматург һәм үзенчәлекле юморист «Агыйдел» повесте белән генә дә әдәбиятыбыз тарихында бер атау булып торырга лаеклы. Егерменче-утызынчы еллар комсомолларының яңа тормыш төзү өчен барган көрәштәге сүнмәс дәртен татар әдәбиятында шул дәрәҗәдә сәнгатьчә һәм тәэсирле итеп тасвирлаган бүтән проза әсәрен хәтерләү кыен. Әдипнең «Саф күңел» романы, «Миңлекамал» һәм «Тормыш җыры» пьесалары әдәбиятыбыз тарихында җуелмас урын алды һәм соңгы елларда язылган автобиографик повестьлары да игътибарга лаек. Чөнки өлкән әдипнең бай тормыш юлы һәрчак туган ил һәм республикабыз белән аерылгысыз бәйләнештә, ә иҗаты күп милләтле совет әдәбиятының магистраль юнәлешендә дәвам итте. Димәк, ул әсәрләр шәхси биографик язма гына түгел, аларда татар совет әдәбиятының үткән юлы чагылган.

Прозабыз аксакалларыннан «Йөзек кашы» повесте, «Җәяүле кеше сукмагы» һәм «Утызынчы еллар» романнары, башка күп кенә повесть һәм хикәяләр авторы Ф. Хәсни талантының озын гомерлелегенә сокланмый мөмкин түгел. Аның бетмәс-төкәнмәс оптимизм белән сугарылган мавыктыргыч һәм җор телле повесть, хикәя, публицистик чыгышларыннан башка да әдәбиятыбызның бүгенге барышын күз алдына китерү кыен. Г. Гобәй, Г. Галиев, Г. Минскийларның татар совет прозасы үсешенә керткән өлешен без шулай ук олы ихтирам белән искә алабыз. Соңгы елларда, каһарман-шагыйрь Муса Җәлил батырлыгы белән рухланып, шагыйрь Ш. Маннур да прозага мөрәҗәгать итте — күләмле «Муса» романын язды. Ул, берсүзсез, халкыбызның горурлыгы булган Җәлил образын тудыруда җитди адым саналырга тиешле әсәр.

А. Расих иҗаты исә елдан-ел яңа кырлары, үзенчәлекләре белән ачыла, тирәнәя бара. Барыннан да элек, бу әдипнең өзлексез эзләнүләре, тарихка мөрәҗәгать итәме, бүгенге чынбарлыгыбызгамы — һәрвакыт чорыбыз өчен аеруча әһәмиятле тема һәм проблемаларны кыю һәм принципиаль рәвештә күтәреп чыгарга сәләтле булуы куандыра. Татарлар арасында социализм идеяләрен пропагандалауда үз-үзен аямый көрәшкән ялкынлы революционер-ленинчы Хөсәен Ямашев образын калку рәвештә тасвирлаган роман үзе генә дә А. Расих иҗатының җитди казанышы булып тора. Әдипнең соңгы еллар тәнкыйтендә күп кенә бәхәсләргә нигез биргән «Ике буйдак» һәм «Сынау» романнары да бүгенге прозабызның игътибарга лаеклы үрнәкләре.

Әмирхан Еники иҗаты татар совет прозасы тарихында үзенчәлекле күренеш. Әдипнең беренче хикәяләре егерменче елларда Г. Ибраһимов редакцияләгән «Безнең юл» журналында дөнья күрә. Бу — гади бер факт. Әмма шул фактта бер мәгънә булуын да абайламый мөмкин түгел. Г. Ибраһимов, Ш. Камаллар прозасының мәгънәви һәм эмоциональ җегәрлеген, психологик анализ тирәнлеген һәм лирик рухын дәвам итүчеләрнең берсе Ә. Еники иҗат юлын әдәбиятыбыз классигының үзеннән фатиха алып башлаган икән. Бер карашка, аның әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләр алай артык зур да түгел, күзгә дә бәрелеп тормыйлар кебек, әйтик, Г. Ибраһимовның «Алмачуар»ыдай. Ләкин шул ук вакытта ул үзенә генә хас бер сиземләү һәм осталык белән, заман укучысының күңелен борчып торган җитди проблема күтәргән була. Бүген яңгырап та иртәгесен онытыла торганнардан түгел, кеше җанын, кеше рухын, гомумән, кешелекне мәңге тынгысызлык утында тоткан, бүген дә, иртәгә дә җитди уйлануларга чакырырга сәләтле проблема була ул. Менә ни өчен кырыгынчы елларда язылган «Бер генә сәгатькә», илленче еллардагы «Кем җырлады», алтмышынчы еллардагы «Матурлык» һәм әле соңгы вакытта гына дөнья күргән «Тынычлану» хикәяләре, төрле чорда иҗат ителүләренә дә карамастан, бер үк дәрәҗәдә сокландыргыч сәнгать әсәрләре буларак кабул ителә.

Өзлексез эзләнүләрдә һәм үсештә булган әдипнең бүгенге чынбарлыгыбыздан илһамланып, рух алып коммунистик җәмгыять төзүче замандашларының масштаблы образын иҗат итүдә тагын да зуррак уңышларга ирешүенә күңелдә ныклы ышаныч яши.

Сүз республикабызның олы бәйрәме көннәрендә бүгенге әдәбият һәм бүген дә

сафта булган әдипләребезнең татар совет әдәбияты үсешенә керткән өлеше турында дидек. Шулай да үзебез сайлаган шушы принциптан бер генә урында читләшеп алуны укучы гафу итәр әле. Чөнки бүгенге татар әдәбияты, бүгенге прозабыз турында сөйләшкәндә Габдрахман Әпсәләмов исемен зур ихтирам белән искә алу һичшиксез кирәк. Әле бер ел чамасы гына элек арабыздан киткән бу өлкән әдип үзенең иҗаты белән республикабыз чикләреннән үтеп, бөтен ил күләмендә танылган прозаик иде. Аның Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗмиләр башлаган юлдан барып, татар совет романын үстерүгә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур. «Алтын йолдыз», «Газинур», «Сүнмәс утлар», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр», «Күк күкрәр», «Яшел яр», «Агыла болыт» романнары һәркайсы прозабыз мәйданында җитди бер вакыйга буларак кабул ителде, һәм бүген татар совет прозасы үткән олы юлны ул әсәрләрдән башка күз алдына китерү һич мөмкин түгел. Г. Әпсәләмов романнарында һәрчак совет кешесенең иң күркәм сыйфатлары—туган илгә һәм халыкка бирелгәнлек, патриотизм, хезмәт батырлыгы калку рәвештә сурәтләнә килде. Аларда, кагыйдә буларак, батырлык, кешелеклелек, намус һәм тугрылык үзәккә куелды. Иҗатындагы бу юнәлеш язучының үз холкындагы тынгысызлыкка, хезмәт сөюгә, туган илгә һәм партиягә бирелгәнлеккә, интернациональлек һәм иҗтимагый активлыкка тоташкан иде.

Соңгы елларда күп милләтле совет әдәбиятында җитлеккән социалистик җәмгыять төзүче кеше — авыл һәм шәһәр хезмәтчәннәре, интеллигенция вәкилләре образларыннан тулы бер галерея тудырылды. Зур куаныч белән әйтергә мөмкин, моңа татар язучылары да мул өлеш кертәләр. Ил тоткасы — иген игүчеләр, шофер һәм предприятие җитәкчесе, слесарь һәм колхоз председателе, скважиналар бораулаучы, балта остасы, укытучы һәм врач, фән-техника революциясенең яңа офыкларын ачучы галим — боларның хезмәте, яшәү рәвеше һәм рухи омтылышлары заман укучысы өчен бер үк дәрәҗәдә якын һәм кызыклы. Бигрәк тә кара алтыны һәм бөек төзелешләре белән данлы Татарстан эшчеләре турында язылган әсәрләр ил күләмендә популярлык казандылар. Чишмә башы Ш. Камал һәм Г. Әпсәләмов кебек өлкән әдипләргә барып тоташкан производство темасының яңа тирәнлекләренә төшү эстафетасын аксакалларыбыздан соң килүче урта буын прозаиклар кабул итеп алды һәм, икеләнми әйтергә мөмкин, алар үзләренең остазлары алдында йөз кызартмады, бүгенге көн мәсьәләләрен заман таләпләренә җавап бирердәй сәнгатьле итеп сурәтләргә сәләтле икәнлекләрен исбат иттеләр. Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм Ш. Бикчуринның «Каты токым» әсәрләре шуның матур үрнәкләре. Татарстан нефтьчеләренең формалашу һәм үсеш юлын характерлы образларда эстетик гомумиләштереп күрсәткән бу ике роман, хаклы рәвештә, тәнкыйтьтә соңгы еллар татар прозасының җитди уңышы буларак бәяләнде. Һәм бер дә очраклы рәвештә түгел. Чөнки республикабыз хезмәт ияләренең тыныч тормыш шартларындагы батырлыгын һәм фидакарьлеген калку рәвештә тасвирлау бүгенге әдәбият алдында торган төп бурычларның берсе. Г. Ахуновның Лотфулла Дияровы, Ш. Бикчуринның Фазыл Зөбәеров образлары туган илебезнең эшчеләр сыйныфы турындагы карашларыбызны бермә-бер киңәйтә һәм тулыландыра икән, «Хәзинә» һәм «Каты токым» романнары В. Кожевников, В. Липатов, Г. Пенжикидзе, Ә. Мохтар, П. Загребельный, В. Бубнис кебек танылган прозаиклар әсәрләре арасында лаеклы урын алган икән — бу барыбызны да куандыра.

Бүгенге авыл тормышын, андагы җитди үзгәрешләрне, замандашыбызның бай рухи дөньясын киң чагылдырган проза әсәрләре арасында да аерым искә алырлык һәм уңай яктан билгеләп узарлык роман, повесть һәм хикәяләр бар. Мисал өчен шул ук Г. Ахуновның «Чикләвек төше» һәм В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» повестьларын гына алу да җитәр. Республикабыз авыл хуҗалыгы үсешен масштаблы образлар эволюциясе аша тасвирлаган бу әсәрләр талантлы урта буын прозаикларының иҗат мөмкинлекләре шактый зур икәнлекне искәртеп тора. Бу теманы күтәргән әсәрләр белән дә татар әдәбияты якын елларда киңрәк аудиторияләр яулар, бөтенсоюз аренасына кыюрак чыгар дип ышанырга кирәк.

Мораль-этик мәсьәләләр исә бигрәк тә А. Гыйләҗев әсәрләрендә киң яктыртыла. Өзлексез эзләнүләрдә һәм тынгысыз иҗатта булган бу әдип үзенең бурычын

кешеләрдә очраган тискәре гадәтләрне—эгоизм, кешелексезлек, бюрократлык, карьеризм сыйфатларын камчылауда күрә. Кагыйдә буларак, аның әсәрләрендә үзәккә куелган образ тискәре герой һәм ул сарказмлы үтә усал көлү белән фаш ителә, автор тарафыннан социалистик чынбарлыгыбызга чит күренеш буларак кире кагыла.

Мораль-этик мәсьәләләр вакытсыз арабыздан киткән художник Хәсән Сарьян әсәрләрендә, бигрәк тә аның «Бер ананың биш улы» повестенда да үзенчәлекле һәм тирән чагылыш тапты.

Бөек Ватан сугышы темасы СССР халыклары әдәбиятларында менә инде дүртенче дистә ел үзәк темаларның берсе буларак дәвам итә. һәм ул әле озын гомерле булып, килер буыннарга да сугыш афәтенең фаҗигаләре, совет халкының фронтта һәм тылда күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары турында озак еллар буе сөйләп торыр. Фронтовик әдипләр белән бергә бу темага һәм ул чор вакыйгаларына бер төркем урта буын язучылар да даими рәвештә мөрәҗәгать итеп киләләр. М. Мәһдиев исеме исә алар арасында аерым игътибарга лаек. Язучының «Без кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», «Кеше китә — җыры кала» повестьлары илебез халыкларының, конкрет алганда татар халкының, тылдагы хезмәт героикасын һәм ныклыгын югары художестволы чаралар белән чагылдыра. Образлы йөгерек тел һәм халкыбызның үзенә хас җорлык белән язылган бу әсәрләр соңгы еллар прозасының югары үрнәкләре булып саналырга лаек.

Прозадагы эзләнүләр, табыш һәм уңышларыбыз турындагы сүзне йомгаклар алдыннан аның үсешенә Җ. Тәрҗеманов, Н. Фәттах, Р. Төхфәтуллин, Ә. Баянов, М. Зарипов, М. Хәбибуллин, Б. Камалов, Э. Касыймов, Ш. Рәкыйпов кебек тагын күп кенә үзенчәлекле каләм осталары керткән зур өлешне дә билгеләп үтү тиеш.

*

* *

Татар әдәбияты дигәч тә күз алдына килгән, Тукае, Такташы, Җәлиле булган поэзиябез юбилейга нәрсә белән килә соң?

Бу сорауга җавап биргәнче шуны әйтергә кирәк: татар поэзиясе беркайчан да урман, тау итәгенә посып йокымсыраган тыныч күлне хәтерләтмәде, Идел һәм Камага койган дистәләрчә инеш һәм елгалар кебек ургылып, шаулап, челтерәп бервөзлексез агуында булды ул.

Иҗат юлын Бөек Октябрь таңында ук башлаган шагыйрь Хәсән Туфан бүгенге татар совет поэзиясенең һичшиксез иң өлкән һәм күренекле вәкиле. Шигърият көче, туган илгә һәм халкына, табигать һәм кешеләргә булган хисләре кайнарлыгы һәм самимилеге белән ул бүгенге шагыйрьләребезнең күбесенә остаз дияргә мөмкин. Х. Туфан тормыш һәм иҗат юлында нинди генә каршылыкларга очрамасын, бервакытта да туган иленә һәм халкына булган тирән ышанычын югалтмады, иҗатының башыннан ахырынача туган илгә бирелгәнлек, патриотизм һәм гуманизм идеяләрен җырлап туймады. Аның югары гражданлык идеяләре белән сугарылган лирикасы шигъриятнең бетмәс-төкәнмәс рухи байлыкка ия бер могҗиза булуын аермачык раслап тора. Халык авыз иҗатына, татар шигыренең озак еллар дәвамында тупланып килгән традицияләренә нигезләнгән бу иҗат елдан-ел киңәя һәм тирәнәя барып, рус, Көнбатыш һәм Көнчыгыш поэзияләреннән үрнәк алып өзлексез үсештә, камиллеккә ирешү юлында булды. Шагыйрьнең эчтәлек һәм шигъри форма өстендәге тынгысыз эзләнүләре, җитди табышлары һичшиксез махсус өйрәнүгә лаек.

Әдәбиятыбызның Тукайлардан килеп үсә, камилләшә барган шигъри традицияләрен бүгенге шартларда дәвам итүчеләрнең берсе, үзенең поэтик көче һәм иҗтимагый сиземләве белән заман сулышын нечкә тоючы, ил һәм дөнья күләмендә барган бөек үзгәрешләрнең фәлсәфәсен, тарихи мәгънәсен шигъри образлар аркылы чагылдыра килгән әсәрләре белән партия, халык таләпләренә сизгер һәм оператив шагыйрь, әлбәттә, —С. Хәким. Беренче карашка, иҗаты да аның үзедәй сабыр һәм тыйнак кебек. Әмма ныклап баксаң, шул сабырлык, тыйнаклык артында нинди колач, фәлсәфи тирәнлек, күпме яну, гражданлык ашкынуы бар... Ул чын мәгънәсендә патриот һәм интернационалист шагыйрь. Иҗатының кайсы гына чорына мөрәҗәгать итмә,

анда совет патриотизмы һәм халыклар дуслыгы идеяләре белән сугарылган әсәрләр өстенлек итә. Даһи Ленинның үлмәс образы, республикабыз биографиясенә бәйләнешле тарихи вакыйгалар белән рухланып, ул язган шигырь һәм поэмалар лениниананың матур сәхифәсен тәшкил иттеләр. Шагыйрьнең Г. Тукайга багышланган поэмалары исә, бер яктан, Тукай турындагы әдәби әсәрләрнең гүзәл үрнәге булса, икенчедән, жанр күзлегеннән дә камиллекләре белән сокландыралар. С. Хәким олы шагыйрь исемен иҗтимагый актив һәм югары әхлаклы шәхес, чын гражданин булуы белән тыгыз бәйләгән. Ару-талу белмәс җәмәгать эшлеклесе һәм әдәбиятка килүче яшь талантларның якын остазы ул.

Шагыйрьләр берән-сәрән генә туса, әдәбият һәм шигърият ничектер артык бер төрле, ярлы һәм кызыксыз булыр иде. Бәхеткә каршы, җәмгыятебездә иҗат эше өчен зарур булган барлык объектив шартлар да тудырылган. Ә халык исә талантларны, үзенчәлекле җырчыларны аз бирми. Һәркайсының үз моңы, үз җыры булган өлкән һәм урта буын шагыйрьләрне искә алганда күңелне шул хактагы уйлар били. Ш. Маннур, Н. Арсланов, Н. Дәүли, М. Садри, З. Нури, Г. Афзал, Г. Латыйп, Х. Камалов, Р. Гәрәй — саный калсаң байтак алар һәм, шунысы куанычлы, һәркайсының бай тормыш һәм иҗат биографиясе, димәк, замандашларына әйтер сүзе бар.

Поэзиябезгә Бөек Ватан сугышыннан соң берничә буын талантлар килде. Шулар арасында әдәбият мәйданында аеруча ат уйнатырга өлгергәннәре һәм бүгенге татар шигъриятендә иҗатлары белән кабатланмас урын алганнары да бар. Әйтик, Ш. Галиевнең балалар поэзиясендәге уңышлары аерым игътибарга лаек. Бу өлкәдә Г. Тукай, А. Алиш, Б. Рәхмәт традицияләрен дәвам итеп, ул балаларыбызның С. Маршак, К. Чуковский, А. Барто, С. Михалков кебек яратып укый торган үз әдипләре булып китте. Ш. Галиевнең сатирик әсәрләре һәм юмор хисенә бай лирикасы да поэзиябезнең җитди казанышы.

Ш. Галиев күбрәк юмор һәм сатираны үз иткән булса, И. Юзеев, барыннан да элек, тормыш матурлыгына, замандашларыбызның гүзәллегенә сокланып туймый җырлаган лирик. Аның мәхәббәт һәм тугрылык, рухи камиллек һәм сафлыкны раслаган шигырьләре халык җырларыдай йөгерек һәм җиңел агышы белән дә аерылып торалар. Шулай ук И. Юзеевның менә инде күпме еллар дәвамында поэма жанрында аеруча актив эшләп килгән шагыйрь булуын да әйтергә кирәк. Аның «Таныш моңнар», «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар», «Мәхәббәт китабы» поэмалары әдәбиятыбызның лиро-эпик жанры үсешенә һәм форма, һәм эчтәлек җәһәтеннән зур өлеш кертте. Р. Кутуй поэзиясе дә яңадан-яңа яклары белән әдәби җәмәгатьчелек фикерен үзенә җәлеп итә килә.

Алтмышынчы еллар башында поэзиябезгә үзенчәлекле язу манералары булган бер төркем яшь шагыйрьләр килеп кергән иде. Алар алып килгән яңалык һәм кайбер урынсыз мавыгулар хакында тәнкыйтьтә сүз шактый дәвам итте. Шулай да бүгенге татар поэзиясендә Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Ф. Яруллин, Р. Мингалимов, Р. Әхмәтҗанов, Р. Гатауллин кебек талантлы шагыйрьләрнең үзенчәлекле урын алуын инкарь итү дөрес булмас дип уйлыйм. Алар, әдәбиятыбызның мул традицияләренә тугрылыклы булган хәлдә, бүгенге дөнья һәм, барыннан да элек, рус совет поэзиясе үрнәкләренә игътибарлы. Шагыйрьләребез шигърият дөньясында барган эзләнү һәм яңалыкларга битараф түгел икән, моңарга, минемчә, ниндидер мөгез чыгару дип түгел, ә табигый иҗат процессы итеп карарга гадәтләнү кирәк. Мисал өчен, Р. Фәйзуллинның фәлсәфи лирикасы, Р. Харисның «Рәссам» поэмасы һәм күп кенә шигырьләре бу шагыйрьләрнең киләчәк иҗатына һәм әдәбияттагы урынына тагы да зуррак өмет багларга нигез бирә.

*

* *

Шушы гасыр башында, 1905 нче ел революциясе нәтиҗәсендә генә формалашу мөмкинлеге алган милли театр сәнгатебез, шулай ук республика белән бергә үсеп, туган илебезнең төрле почмакларында яшәүче тамашачыларның олы мәхәббәтен яулап өлгерде. Бу казанышны, әлбәттә, театрларыбызның төп репертуарын тәшкил иткән драма әсәрләре — татар совет драматургларының иҗат җимешләреннән башка

күз алдына китерү мөмкин түгел. Г. Камал, М. Фәйзи, Т. Гыйззәт, Ф. Бурнаш һәм К. Тинчуриннар үзләренең классик әсәрләре белән бергә киләчәккә үтә. Аларның чордашлары Н. Исәнбәт һәм Р. Ишморат исә, тамашачыларга яңа әсәрләрен әледән-әле тәкъдим итә килеп, көннәрдә очкын, йөрәктә җегәр җитәрлек әле дигәндәй, зур иҗат планнары белән янып яшиләр.

Х. Вахит пьесалары менә инде ничә еллар татар сәхнәсеннән төшми уйналып килә, тугандаш республикаларның театрларында куела.

Шулай да бер ара сәхнә әдәбияты жанрында, торгынлык дип әйтергәме, нинди-дер сүлпәнлек булып алды. Илленче еллар һәм алтмышынчы елларның беренче яртысында иде бу хәл. Ә бүген, татар драматургиясе республиканың олы бәйрәменә зур әзерлек һәм җитди уңышлар белән килә — моны һич икеләнми горурлык хисе белән расларга мөмкин.

Хәзерге драматургларыбыз арасында иң активы һәм нәтиҗәле эшләүчесе, һич-шиксез, Туфан Миңнуллин. Бер дистә еллар чамасы гына элек Т. Миңнуллин исеме өметле яшь драматург һәм юморист булудан тыш артык әллә ни сөйләми иде кебек әле. Бүген сәхнә әдәбиятыбызның торышы, республикабыз театрлары репертуары ин-де аның әсәрләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Драматургның «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ир-егетләр», «Канкай углы Бәхтияр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Дуслар җыелган җирдә» кебек пьесалары тамашачыларыбызның күңелен һәм ихлас мәхәб-бәтен яулады.

Ару-талуны белми иҗат иткән, өзлексез эзләнүләр кичергән талантлы һәр әдип-нең, һәр драматургның иҗатында, әгәр шулай әйтергә яраса, аеруча бәхетле язмыш-лы бер әсәр була. Әйтик, М. Фәйзидә ул «Галиябану» булса, К. Тинчуринда «Зәңгәр шәл»дер. Т. Миңнуллин өчен андый әсәрнең «Әлдермештән Әлмәндәр» булуы бик ихтимал. Дөньяга һәм тормышка бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт белән сугарылган тирән фәлсәфи эчтәлекле бу оптимистик пьеса укыган саен, караган саен бер яңа кыры бе-лән ачыла бара. «Зәңгәр шәл» һәм «Галиябану» кебек үк һичкайчан ялыктырмый, туйдырмый. Уңышлы әсәрләре арасында да һәр авторның аеруча бәхетле әсәре була дидек. Т. Миңнуллин исә безгә андый әсәрләрнең берәү генә түгел, ә берничә бу-лырга мөмкин икәнлеген дә исбат итәр әле.

Драматургиябездәге хәрәкәтне, соңгы елларда бу жанрның сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелүен бер Т. Миңнуллин иҗаты гына билгеләми, әлбәттә. Ш. Хөсә-еновның «Зөбәйдә адәм баласы» һәм «Әни килде», И. Юзеевның «Бәхетемнән узып барышлый», А. Гыйләҗев, Д. Вәлиев, Ю. Әминов, Р. Батуллин һәм башка авторлар-ның театрларыбыз репертуарында булган пьесалары бүгенге сәхнә әдәбиятыбызны шактый баета һәм тулыландыра. Театрларда бер төркем талантлы яшь драматурглар-ның аяк тавышлары көннән-көн ачыграк ишетелүе дә милли драматургиянең киләчәк үсешенә ныклы ышаныч бирә.

...Без хәзерге татар совет әдәбиятының төп жанрларына кыскача тукталдык. Әмма юбилей мәкаләсе рамкаларында гына бүгенге әдәби хәрәкәтне бөтен тулылыгы һәм катлаулылыгы, үзенчәлекләре белән тулы күрсәтү мөмкин түгел.

Хәзерге әдәби процессны шартлы рәвештә зур симфоник оркестр белән ча-гыштырып булыр иде. Анда сүз сәнгатенең һәр төре һәм жанрының үз урыны, үз вазифасы бар, ул оркестрның матур яңгырашына төрле буын, төрле талант, төрле стиль язучыларының өлеше кергән. Без бу урында әдәби иҗат эшендә, хәзерге әдә-бият үсешендә хатын-кыз язучыларның актив катнашуын куану белән күрсәтеп үтәр идек.

Татар хатын-кызлары элек-электән ислам кануннарының тарлыгын аңлап, әдә-бият һәм сәнгатькә зур омтылыш белән яшәгәннәр. Ләкин ул омтылышлар, кагыйдә буларак, чыңга аша алмый килгән. Әдәбиятта булсын, сәнгатьтә булсын хатын-кызла-рыбыз арасыннан соңгы алтмыш ел эчендә чын мәгънәсендә йолдыз булып балкыган талантлар үсеп чыкты. Бүгенге әдәби процесста да язучы хатын-кызларыбызның күңел җылылыгы, мораль-этик сафлыгы, тотнаклыгы белән өртелгән нәфис бер агым бар. Ләбибә Ихсанова, Гөлшат Зәйнашева, Саҗидә Сөләйманова, Әминә Бикчәнтәева, Мәрзия Фәйзуллина, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова һәм башкаларның иҗаты әдәбиятыбызга үзенчәлекле бер бизәк булып тора, аның диапазонын киңәйтә.

*
* *

Республикабыздагы әдәби процесс турында, Татарстан әдәбиятының казанышлары хакында сүз барганда татар әдипләребез белән «тел вә ләгать алмашып» дигәндәй кулга кул тотынып иҗат итүче рус язучылары иҗатына да аерым тукталып үтми мөмкин түгел. Татар әдәбияты элек-электән бөек рус әдәбиятыннан, аның тормышчан һәм халыкчан традицияләреннән үрнәк алып үсте. Совет чорында бу бәйләнеш билгеле бер дәрәҗәдә, республикабызда яшәүче рус һәм башка милләт язучылары белән үзара аралашу нәтиҗәсендә аерым бер матур төс алды. С. Радзиевская, Т. Журавлев, К. Лебедев, Г. Паушкин һәм башка язучыларның әсәрләре Татарстан читләреннән еракта да республикабыздагы әдәби процессның үзенчәлеге, уңыш һәм казанышлары хакында дәлилле сөйли. Һәм бу уңайдан, үз чиратында, татар әдәбиятының да якташларыбыз—рус язучылары иҗатына игелекле тәэсире булуын да билгеләп узарга мөмкин.

Бүгенге күп милләтле совет әдәбиятын, тугандаш әдәбиятлар арасындагы көннән-көн үсә, ныгый барган әдәби багланышларны тәрҗемә һәм тәрҗемәчеләр иҗатыннан башка күз алдына китерү дә кыен. Тәрҗемә әсәрләре әдәбиятыбызның тематик һәм идея-эстетик офыгын киңәйтә, дөнья әдәбиятларында барган эзләнүләр һәм прогрессив әдәби күренешләрне милли әдәбиятның үз казанышларына китереп куша. Шул уңайдан соңгы елларда үсеп чыккан бертөркем талантлы тәрҗемәчеләребезнең нәтиҗәле хезмәтен аерым бер канәгатьләнү белән искә аласы килә. Р. Даутов, Я. Халитов, К. Миңлебаев, Т. Нурмөхәммәтов кебек тәрҗемә осталары үзләренең фидакарь хезмәтләре белән әдәбият сөючеләрнең һәм әдәби җәмәгатьчелекнең олы ихтирамын яулады. Шунда ук күп кенә танылган язучыларыбызның да тәрҗемә эшенә керткән өлеше зур булуны билгеләп узмый мөмкин түгел. Ә инде татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен бөтенсоюз укучысына тәкъдим итү өлкәсендә армый-талмый хезмәт иткән рус язучыларының исемлеге елдан-ел арта, байый баруы безне аеруча куандырырга тиеш.

*
* *

Әдәбиятның пульсын билгеләп торган тәнкыйтьнең әдәби хәрәкәттә һәм рухи тормышыбыздагы роле көннән-көн үсә, арта бара. Аның соңгы еллардагы барышы турыдан-туры КПСС Үзәк Комитетының 1972 елда кабул ителгән «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары белән бәйле. Әлеге карарның җитди әһәмияткә ия булуын искә алып, партия өлкә комитеты, аның культура бүлеге һәм Татарстан Язучылар союзы идарәсе дә әдәбият-сәнгать тәнкыйте үсеше хакында даими рәвештә кайгыртып тора. Республикабыз газета-журнал редакцияләрендә (бигрәк тә «Казан утлары» һәм «Социалистик Татарстан» да), Татарстан китап нәшриятында бу мәсьәләгә игътибар бермә-бер үсте.

Нәтиҗәләр күз алдында: соңгы елларда әдәби тәнкыйть теоретик базасын шактый тирәнәйтте, һәм идея, һәм эстетик анализда сизелерлек дәрәҗәдә алга китте, ныгыды. Аның оперативлылыгын арттыру юнәлешендә дә чаралар күрелә. Жанр һәм форма төрлелеге күзгә күренеп арта бара. Тәнкыйтьчеләребез әдәби күренешләрне тормыш вакыйгалары белән бәйләнештә өйрәнеп, иҗтимагый һәм рухи яшәешебезнең яңадан-яңа проблемаларына үтеп керәләр.

Социалистик реализм иҗат методының методологиясе һәм поэтикасын, эчтәлек һәм форма, художество осталыгы мәсьәләләрен тикшергән төпле теоретик тәнкыйтьнең әһәмияте хәзер аеруча зур. Моңарга, аерым алганда, партия Үзәк Комитеты карарында да махсус игътибар ителгән иде. Шул күзлектән М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин, Н. Юзеев, Й. Нигъмәтуллина кебек фән докторларының һәм өлкән тәнкыйтьчеләр Х. Хәйри, Б. Гыйззәт, Р. Бикмөхәммәтовларның эшчәнлеге аерым билгеләп узуга лаек. Ә инде тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләренә дә җитди игътибар белән бергә, үзләренең бурычын күбрәк агымдагы әдәби процессны анализлауда, аңарга юнәлеш бирүдә күргән Т. Галиуллин, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, А. Әх-

мәдуллин, Ф. Мусин, Ф. Әгъзәмов кебек авторларның иҗади уңышларын күрү икеләтә куанычлы. Чөнки алар алдында әле әдәбият-сәнгать дөньясы буйлап үтәсе озынерак юл ята. Теоретик хәзерлекле, партиягә, халыкка һәм әдәбиятка хезмәт итү эшен тормыш максаты итеп алган бу тәнкыйтьчеләр ул юлны киләчәктә тагы да активрак һәм фидакарь иҗат белән үтәрләр дип ышанасы килә.

*

* *

Әдәбиятыбызның бүгенге барышында аерым жанрларның торышы хакында уйланганда, аңлы рәвештә, яшь әдипләр турындагы сүзне кичектереп килдек. һәм очраклы рәвештә генә түгел. Чөнки әдәбиятка әле беренче адымнарын ясаучы заман яшьләре иҗатлары белән дә, иҗтимагый активлыклары һәм тынгысыз эзләнүләре белән дә аерым игътибарга лаеклылар. Бүгенге әдәби процессны, әдәбиятыбыздагы яңа сыйфат үзенчәлекләрен аларның әсәрләреннән башка анализлау тулы булмас иде. Шул ук вакытта яшь талантларның әдәбиятыбызның бүгенгесе генә түгел, беренче нәүбәттә, аның киләчәге, булачак өметләре икәнлеген дә онытырга ярамас.

Әдәби алмашның соңгы еллардагы активлыгын һәм иҗади уңышларын, әлбәттә, 1976 елның октябрендә КПСС Үзәк Комитеты кабул иткән «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карар һәм шул олы кайгырту нигезендә республикабызда үткәрелгән һәм үткәрелә торган махсус чаралардан чыгып аңлату дөрес булыр. Инде, табигый рәвештә, сорау туа: әдәбиятыбызның киләчәккә өмете булган талантлы яшьләре дигәндә, иң элек, кемнәрне күздә тотабыз соң? Шагыйрьләрдән Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, Н. Измайлова, драматург һәм прозаик Ә. Гаффар, тәнкыйтьчеләрдән Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиевләрнең иҗаты әдәби җәмәгатьчелекнең генә түгел, киң масса укучы игътибарын да инде җәлеп итте булса кирәк. Алар белән кулга-кул тотышып дигәндәй, янәшә баручы башка авторларның да киләчәктә талантларының яңа, якты яклары белән ачылып китүенә ышанасы килә. Гомумән, сүз яшь көчләр турында, аларның өметле киләчәге турында бара икән, без һәр чак һәм һәр урында олы кайгыртучанлык, зур ышаныч һәм җитди таләпчәнлектән чыгып эш итәргә тиешбез. Уйлавымча, әле яшьләр алдында күтәрелмәгән чирәм байтак. Алар үз-үзләрен аямый иҗат итәргә, Тукай, Такташ, Җәлилләрдән үрнәк алып, олы максатлар белән янып — Ватан һәм халык белән бергә зур тормыш юлы узарга, замандашларыбызның героик образын тудырып киләчәккә алып барырга тиешләр. Бу — җиңел юл булмас. Чын шагыйрьләр, олы әдипләр иҗатларында һичкайчан әзер сукмаклардан узмаган. Моңа мисал эзләп ерак китәсе түгел, илебез халыклары әдәбиятларына, татар әдәбияты үткән юлга күз төшерү генә дә җитәр. Тукай, Ибраһимов, Такташ, Җәлил, Кәрим, Туфан, Әмир, Хәким, Г. Ахунов — болар һәммәсе үрнәк алырлык шәхесләр. Иҗат кешесе бөтен әдәбият өчен, әдәби процесс өчен янып яшәгән, аны оештыручы һәм җитәкләүче ялкынлы шәхес, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе дә булырга тиеш — әйтик, шул ук Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, М. Җәлил, И. Гази, Г. Кашшафлар кебек. Бүгенге өлкән һәм урта буын язучыларыбыз арасында да бу күзлектән караганда үрнәк булып торырдай мисаллар аз түгел. Олы идеаллар белән рухланып яшәргә, ялкынланып иҗат итәргә — әдип өчен, чын шагыйрь, прозаик, драматург һәм тәнкыйтьче өчен заман таләбе әнә шундый.

*

* *

Туган илебез хезмәт ияләре КПССның XXVI съездын данлы җиңүләр белән каршыларга хәзерләнәләр. Төзелүе турындагы декретка В. И. Ленин үзе кул куйган Татарстан республикасына 60 яшь. Героик хезмәт, күтәренке рух, киләчәккә ышаныч тантана итә. Шундый тантана көннәрендә татар совет әдәбияты үткән юлның да Ватаныбызга һәм халкыбызга тиң олы, данлы булуына куанмый мөмкин түгел. Ә аның киләчәге тагын да яктырак һәм олырак булуга күңелләрдә нык ышаныч яши.

# КҮТӘРЕЛҮ
# һӘМ ЯҢАРЫШ ЕЛЛАРЫ

**Республикабызның 60 еллык олы бәйрәме уңае белән, редакция бер төркем әдипләргә мөрәҗәгать итеп, аларның анкетадагы өч сорауга җавап бирүләрен үтенде. Сораулар түбәндәгедән гыйбарәт:**

**1. Республикабыз Татарстанга 60 ел тулган көннәрдә без — язучылар — татар халкының, аерым алганда, милли әдәбиятыбызның шушы дәвер эчендә ирешкән уңышларын куаныч һәм горурлану белән тагы бер кат күз алдыннан уздырабыз. Шул еллар эчендә булып узган һәм үзегезне аеруча дулкынландырган берәр мөһим вакыйга яисә очрашу турында истәлекләр белән уртаклашсагыз иде.**

**2. Җитмешенче еллар татар совет әдәбияты өчен актив эзләнүләр, җитди табышлар чоры булды. Ул сезне иң элек нинди сыйфат үзенчәлекләре белән куандырды һәм кайсы яклары белән канәгатьләндерми!**

**3. Сиксәненче елларда совет әдәбиятының һәм, аерым алганда, сез үз иткән жанрның үсеш тенденцияләре нидән гыйбарәт булыр дип уйлыйсыз!**

**Редакциягә килгән җавапларның бер өлешен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.**

## Мирсәй Әмир:

1929 елның җәй азагында Казаннан зур бер төркем язучы һәм театр-музыка сәнгате өлкәсеннән берничә кеше, бергәләп, көньяк республикаларга экскурсия оештырдылар. Ул вакытта бер Татарстан өчен генә түгел, Союз күләмендә әһәмияткә ия булган зур яңалык иде бу. «Известия» газетасы аны «зур интернациональ пролетариат бәйрәме» дип атады һәм: «Бу экскурсия СССР халыклары арасында хуҗалык, культура якынлашуы эшендә яңа сәхифә ача», — дип язды.

Яшь-яшь башым белән, әле язучы булып тиешенчә танылырга да өлгермәгән көемә, миңа шул экскурсия составына эләгү бәхете насыйп булды. Тау-тау дулкыннарда чайкалу авыруыннан башларыбыз әйләнә-әйләнә, күңелләребез үйный-үйный, укшый-укшый булса да, Каспий өстендә йөзү барыбыз өчен дә диярлек куанычлы яңалык. Иделдән — диңгезгә, җыйнак кына Татарстаннан — зур Советлар Союзы киңлекләренә чыгу бәхете иде бу. Моңарчы әкият кебек хыял дөньясында гына булган диңгезләрдә йөзү: мәңге ак түбәләре болытлар аша чыгып киткән биек-биек «Кафтау» артларына барып җитү; Дагстан, Әзербәйҗан, Аҗарстан, Грузия, Кырым, Украина җирләрен күрү; социалистик төзелешнең әлегә Казанда күренмәгән, ә Баку, Харьков кебек шәһәрләрдә гөрләп үсеп барган уңышларын үз күзләребез белән күрү, ниһаять, Мәскәү, Максим Горький белән очрашу — бары да искиткеч яңалык иде безгә, әйтеп бетермәслек шатлык иде.

Шәхсән минем өчен бу сәяхәтнең аеруча әһәмиятле ягы шул булды: пароход салоннарында, тимер юл вагоннарында, һәр шәһәрнең иң шәп кунак йортларында, Кырым курортларында, Кара диңгез пляжларында, нефть манаралары дөньясында, эшче бистәләрдә, завод-фабрика цехларында, һәркайсы үз телендә иҗат итүче каләмдәш дусларыбыз белән очрашулар белән узган ул көннәрдә мин үз Казанымның атаклы кешеләрен дә якыннан күрдем. Кәрим Тинчурин, Шәриф Камал, Һади Такташ, Салих Сәйдәшев, Галимҗан Нигъмәти кебек ул чакта әле минем өчен буй җит-

мәслек югарылыкта торган данлы кешеләр белән көне-төне бергә булу, аларның иҗат җимешләрен генә түгел, үзләренең көндәлек тормышта нинди кеше икәнлекләрен якыннан күреп, тоеп тору — теләргә җөрьәт итмәслек зур бәхет иде.

Ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат гомеремдә миңа бик күп мәгънәле очрашуларда булырга, тарихи әһәмияткә ия булган истәлекле вакыйгаларда катнашырга туры килде. Зур дөньяга чыгу юлында беренче адымнарымнан булгангамы, беренче сорауга җавап урнында шул экскурсияне искә төшердем.

**Икенче.** Әйе, җитмешенче еллар — әдәбиятыбыз өчен, аеруча проза җанрында, актив эзләнүләр, җитди табышлар чоры булды. Хәтердә калганнарын гына күңелдән кичергәндә дә бу чор эчендә илледән артык роман һәм повестьлар дөнья күрде. Шулардан әдәби тәнкыйть һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан яхшы кабул ителеп, әдәбият киштәбездә ышанычлы урын алганнары да өч дистәгә тула торгандыр. Аз түгел! Өлкән буынга алмашка килеп, инде әдәби хәрәкәтнең төбенә җигелгән урта буын язучылар һәм аларга ялганып килүче яшьләр электән килгән әйбәт традицияләрне — гражданлык активлыгы, патриотлык, гуманизм сыйфатларын дәвам иттереп, аларны бүгенге көнгә хас яңа сыйфатлар белән үстерәләр. Рухи азатлык, чорыбызга хас катлаулы каршылыкларны ачуда кыюлык, кешеләребез арасындагы мөнәсәбәтләрдә интеллигентлык, вакыйгаларга бәя бирүдә фәннилек, тарихилык, фәлсәфилек — соңгы елларда язылган әсәрләрнең уңышлыларына хас булган өстенлекләр аларның әнә шул үзенчәлекләренә бәйләнгән. Шундый әһәмиятле үзенчәлекләре, алларына куелган проблемаларны хәл итүдә тормышчан булулары авторларга иҗатларында оригиналь булырга, һәркайсына үз стилен табарга ярдәм итәләр.

Заман белән бергә атлап баручы өлкән буын әдипләрдән Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Атилла Расих, Әмирхан Еники, Газиз Иделлеләр иҗат иткән әсәрләрнең оригинальлекләрен әйтеп торасы түгел. Иҗатлары белән бүгенге әдәби хәрәкәтебезнең алдынгы сафында баручы чәчмәчеләрдән Гариф Ахуновнымы алып карыйк, Мөхәммәт Мәһдиевнеме; Әхсән Баян, Аяз Гыйләҗев, Миргазыян Юныс, Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова, Диләрә Зөбәеровaларнымы; Шамил Бикчурин, Вакыйф Нуруллин, Әдип Маликов, Барлас Камал, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Хәниф Хәйруллин, Гәрәй Рәхим, Җәмит Рәхимовларнымы — һәр кайсының үз тавышы, үз стиле, үз теле. Әдәби иҗат эшендә авторның оригинальлеге — бу бик зур эш. Үз әдәбиятының патриоты булган һәркем өчен зур куаныч.

Күңелне борчый торган кимчелек? Әдәби сыйфатлары ягыннан ярыйсы эшләнгән кайбер әсәрләрнең «Саргаймагыз, каштаннар!» (Г. Рәхим), «Төлке тоту кыен түгел» (Ә. Баянов) кебек реализм принципларыннан беркадәр тайпылулары түгел; кайбер әсәрләрнең тиешенчә эшләнеп җитмәгән хәлдә, иң югары таләпләрдән чыгып редакцияләнмәгән килеш «Дулкыннар ни сөйли?» (А. Вергазов), «Сәмум җиле» (Г. Кашапов) кебек матбугатка чыгулары да түгел, шундый әсәрләр уңае белән җитди тәнкыйть сүзе җитәрлек булмавы күңелне борчый. Гомумән, кимчелекле яклары белән тәнкыйтькә мохтаҗ әсәрләргә карата гына түгел, күп вакытта һәркем тарафыннан әйбәт бәя алган әсәрләргә карата да тәнкыйтебез тиешле югарылыкка күтәрелеп җитә алмый. Мәсәлән, «Табу һәм югалту» (М. Юныс) турында берничә тәнкыйть мәкаләсе чыкты. Автор өчен дә, әдәбиятыбыз өчен дә уңыш дип, дөрес бәя бирделәр. Ләкин аның төп көче нәрсәдә икәнен ачып бетерүче булмады. Язучы, тормышыбызга фәнни-техник революция китергән уңай яңалыкларның зур булуын күрсәтү белән бергә, аларның кайбер уйландыра торган яклары барлыгын да искә төшерә. Ягъни, ул табышлар белән бергә, тормышыбызда үзебез өчен бик кадерле булган нәрсәләрне — табигый байлыкларыбызны, буыннан буынга килгән яхшы традицияләребезне, кирәкле мораль сыйфатларыбызны да өлешчә югалтмыйбызмы? Беркадәр бәхәсле булса да, укучы алдына куелуы бик урынлы булган бу сорауларны тәнкыйть күрергә һәм аларга җавап бирергә тиеш иде.

Шушы мәсьәләгә ялганып, өченче сорауга җавабым да килеп чыга. Алда безнең прозабыз гражданлык хисләре белән тагын да ныграк сугарылсын, әсәрләребездә социаль проблемаларга нигезләнгән темаларны күтәрүгә тагын да ныграк әһәмият бирелсен иде. Әдәби тәнкыйтебез дә, редакцияләр эше дә прозабыздагы уңышларга тиң булсын, барысы бергәләп тагын да югарырак сәнгать биеклекләренә күтәрелсеннәр иде.

# Фатих Хөсни:

Бөек Октябрь революциясеннән соңгы чор, аерым алганда, Татарстан республикасы игълан ителгәннән соң үткән алтмыш еллык дәвер, тулаем җыеп әйткәндә, әлбәттә, күтәрелеш һәм янарыш еллары булды. Бу күтәрелешне туры сызык буенча, бер дә бөгелешләр һәм хаталар ясамыйча гына барган хәрәкәт дип күз алдына китерү дөрес булмас иде. Киң җәмәгатьчелек хәрәкәте, социаль алга барыш бервакытта да һәм бер халыкта да туры сызык буенча гына була алмый. Шуның өчен ул социаль хәрәкәт дип атала да, чөнки анда берьюлы күбәүләр, бик күбәүләр, халыкның төрле катлаулары мәйданга ташлана һәм алар һәрберсе үзенекен — үзенчә уйлавын, фикер йөртешен, теләк-идеалларын алып килә һәм бу төрлелек тормышның алга барышында үзенең күпмедер дәрәҗәдә чагылышын күрсәтми кала алмый. Ләкин бер хакыйкать бик ачык: мондый аерым чагылышлар гына тормышның, гомуми прогрессның алга барышын туктата да, бөтенләй кире якка бора да алмый. Әле шушы без алган чорда да, политикада булсын, экономик һәм мәгънәви үсешебездәме, нинди генә чарпалышлар, бөгү һәм бөгелешләр, үтә «суллашып» киртә сикерергә маташулар һәм, узганны сагынып, артка каерулар булмады дип әйтә алабыз? Ләкин тарихның революцион логикасын туктату яки кирегә бору булмады.

Минем революциям үзенчә килде. Авылда, хосусый милекчелек шартларында туып-үскән һәм шул шартларда дөньяга карашымның беренче «кирпечләре» салынган мин — крестьянның революцияне аңлавы һәм кабул итүе бик чикләнгән рамкаларда гына иде. Кайдадыр кала җирендә эшчеләр белән фабрикантлар, солдатлар белән патша офицерлары арасында тартышлар бара, шарт та шорт мылтыктан атышалар, ур-ра кычкыралар, күкрәккә кызыл чүпрәкләр тагып йөриләр. Я алла, үзләренчә шуның кызыгын табалар икән, кычкыра бирсеннәр, тага бирсеннәр кызыл чүпрәк. Миңа кагылмый. Минем урыным авылда, безнең авылда хәзергә андый галәмәтләр юк, безнең үз иманабызга тигән җиребез бар, без шуны сукалап чәчәбез, шул иманабызда үскән арыш, солыны үз кулларыбыз белән урабыз, сугабыз. Калганы кайдадыр, ындыр артында, кала җирендә...

Юк, ындыр артында гына булып калмады шул! Илдә купкан гомуми шау-шу, революциядән соң кузгалган яңарыш хәрәкәте, халык арасына керергә омтылу, ындыр киртәсенең аргы ягына сикереп чыгарга теләү, укырга-белем алырга дәртләнү, мине дә, хәтта үз җиренә берегеп каткан мин крестьян тумасын да, җилкендерә куйды...

Әти, әни үлгән, абый һәм туганым җиңги белән әллә ни борчак пешми... Шулай бер көнне мин дә, тәвәккәлләп, аркама котомка асып, кала якларына чыгып киттем.

Дөресен әйтим, «таш кала» мине әллә ни башымнан сыйпап каршы алмады. Укырга керүен кердем, ләкин түбән классларның гына берсенә. Бу класстагыларны әлегә интернатка алмыйлар иде. Ә кайдадыр яшәргә, ипи ашарга кирәк. Шуннан башланды минем авылдашларда кунып йөрүләр, ул чагындагы мәктәп директорыбыз Вакыйф Зыя абый артыннан тагылып Наркомпроска чабулар. Ияреп түгел, нәкъ менә тагылып. Чабуына ук ябышып та түгел — ул чаклысы ук рөхсәт ителми, шул ук вакытта «Дәү абыйны» күздән дә ычкындырмыйча.

Бу әрсезлек шулай да ярдәм итте. Октябрь бәйрәме алдыннан, шул зур тантанага туры китереп эшләнгәндер инде, элекке Әхмәт бай йортында, Кабан күле буенда ике катлы тимер баскычлы шәп өйдә интернат ачылды. Бик тә тырышып елап йөрүебезне искә алдылар булса кирәк, ике малайга, Казан артыннан килгән Габделхак Гобәев дигән малайга һәм мин елакка, аерым бер «җәннәт капкасы» ачып, безне дә интернатка алдылар. Беравыктан әле өскә кара шинель, аякка ботинка да бирәчәкләр, имеш. Бүлмәләр җылы, залыбызда Әхмәт байлардан калган, идәннән түшәмгә сузылган зур көзге, ур-р-ра кычкырырга менә кайчан килде безнең чират — «ур-р-ра! Яшәсен совет власы!» Минем революциям менә шулай килде.

Тырыша-тырмаша бер-ике ел укыганнан соң, миңа яңа канатлар кунды, мин очына ук башладым. Инде өлкән классларның берсендә, инде кызларга күз төшә башлады, инде күңелдә җыр дәрте кузгалды һәм мин — казна ботинкасындагы буй жит-

кән күсәк — авылдан отып килгән халык җырларының азактагы ике юлын «сәвит-чә»гә әйләндереп, шигырьләр яза башладым. Шундый «шигырьләр»нең берсе «Яшь ленинчы» газетасында басылып та чыкты — чабата хәтле итеп «Фатих Хәснетдинов» дигән имзамны куеп. Соңыннан белдем, каешлана төшкән кала малайлары төшендерделәр, әле шул хәтле зур имза, имза өстенә тагы, барып сорасаң, гонорар дигән нәрсәсе дә чыгачак, имеш. Менә бусына инде икенче «ур-р-ра!» Менә бусы минем өчен икенче революция булды.

Уку, шәһәр тормышы, төрле кеше белән аралашу, шул җөмләдән, исемле зур язучылар тирәсендә кыршылу, тулаем алганда, минем күз алдындагы офыкларны киңәйтте, миндә гражданлык тойгысы арта барды, әкренләп булса да баш та үсә, акыл да керә төште кебек. Ләкин бер үк вакытта мин авыл тузанында аунап калыпланган көләч бала чагымны югалттым. Бу, әлбәттә, сизгер күңелле авыл баласы өчен барыбер түгел иде. Соңыннан, язучы булып киткәч тә, барыбер булмады, ялганга телем бармый, хәзер дә барыбер түгел.

Парадоксаль хәл: үзем, язучы булып, әдәбиятка илле елдан артык гомеремне бирсәм дә, бу очракта әдәбият турында җәелеп сөйлисем килми. Чөнки әдәбият турында сөйләүләр — мактанып та, көенеп тә — күп булды һәм булып тора. Бәлки, шул «сыйдан» махмырлаганмындыр...

Әдәбиятыбыз дөрес курс белән бара, елдан-ел яшь каләмнәр килә, өсте-өстенә китаплар чыгарабыз. Ләкин моның да хәвефләндерә торган бер ягы бар шикелле: шул китаплар чыгару белән үтә дә берьяклы мавыгып, без, язучылар, укучылар турында кайгыртуны оныт[ы]п җибәрмибезме? Сүз дә юк, татар язучысының аудиториясе киңәйде, ул русча да басыла, башка халыклар телендә дә чыга. Ләкин татар язучысының үз укучысы — татар укучысы кимемәсен иде. Менә бу хәл безне, әлбәттә, уйландырырга тиеш.

Тагы бер каршылыклы күренеш. Темалар киңәйде, төрләнде, язучы барысын да кочарга, иңләргә тели. Күп язабыз, озын язабыз, ләкин бу очракта да бөтенләй үк югалтусыз түгел: соңгы елларда әдәби телебез үзенең нәфислеген, милли колоритын кимета бара. Бу бигрәк тә яшь каләмнәрдә нык сизелә. Димәк, безгә бу юнәлештә дә эшләргә кирәк. Бәйрәмнәр — киенү-ясану, кунак-кунак уйнау, үзара мактанышу өчен генә түгел, бәйрәмнәр — сафларыбызны барлау, адымнарыбызны тигезләү, җырларыбызны көррәк тавыш белән күтәребрәк алу өчен дә килә.

## Сибгат Хәким:

1. Әдәбиятта бер талант ялтырап килеп чыкса да вакыйгага әйләнә. Әгәр ул талантлар бөтен бер буын булып килсә? Шулай, әлегрәк төшкән фоторәсем кирәк булды, актарындым. Фотога аерым аз төшәм. Менә Бөек Ватан сугышыннан соң төшкән күмәк рәсем. Шәүкәт Галиев, бер рәттә Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Рәшит Гәрәй, Гамил Афзал. Яшьләр, ябыклар, чандырлар. Малайлык чыгып бетмәгән. Еллар аларның йөзләренә әле горурлану, масаю, тәкәбберләнү буяуларын салмаган. Гади, гөнаһсыз йөзләр. Әле бар да алда. Кем ничек атлап кереп китәр? Кем ничек үзен табар? Күңелләрдә бары беренче китаплар җылысы. Мин бу фотога кимендә чирек гасыр ераклыктан торып карыйм. Хәзер инде бар да ачык — бу шагыйрьләрнең һәркайсының егермеләп шигырь җыентыгы, сайланмалары бар. Бу авторларның һәркайсы турында мин җае чыккан саен фикер әйткәнмен, язганмын. Поэзия дөньясына бергә керделәр, бер чорда формалаштылар. Иң кызыгы шунда, аларның берсе дә төшеп калмады, татар совет поэзиясендә үз урыннарын алдылар. Шәүкәт Галиев балалар әдәбиятының иң күренекле вәкиле булып калды. И. Юзеев шигырьләрендә, поэмаларында һәм драма әсәрләрендә романтик хис белән янып яшәүче шагыйрь икәнлегенә тәмам ышандырды. Хисам Камалов поэзия белән проза жанрында җигелеп эшли. Ике жанрда да — Хисам үзе, үз биографиясе, үз моңсулыгы, үз чынлыгы. Гамил Афзал татар поэзиясенә үзенә генә хас лирик моң өстәде. Кайвакыт аерып алып карыйм. Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр, Фатих Кәримнәр, Әхмәт Фәйзиләр янында әгәр ул булмаса? Юк, ул кирәк. Ул иҗат иткән юмористик ши-

гырьләрсез, ил, ватан турындагы лирик уйлануларсыз поэзиягә нәрсәдер җитмәс иде. Поэзияне төрле юнәлештәге талантлар баета.

Дулкын өстенә дулкын. Буын арты буын, фото, шул фотолар арасында тагын берсе. Анысы да күмәк. Бу ике фото арасында ун-унбиш еллар... Фәйзуллиннар буыны. Рәсемдә Рәдиф Гатауллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхимнәр... Боларны бик тыныч, бик тыйнак дип булмый инде. Болар шигырьдә экспериментлар ясап, укучылар арасында бәхәсләр оештырып, хәтта өлкән буын шагыйрьләрне дә шул бәхәсләргә тартып, поэзиягә дәгъва белән килгән шагыйрьләр. Моннан бирле ун-унбиш ел вакыт узган. Бу шагыйрьләрнең иҗат йөзләре дә минем өчен хәзер шактый ачык. Боларының да шигырь җыентыклары татар һәм рус телләрендә чыгып килә. Тәнкыйть тә алар турында үз сүзен әйтте инде. Нык буын, эшли торган буын, бәхәссез. Бу шагыйрьләрнең иҗатыннан чыгып мин үзем өчен бер нәтиҗә ясыйм: поэзиянең мәйданы зур, поэзия мәйданы күп төрле талантларны сыйдыра. Поэзия тере организм, хәрәкәттәге организм. Ул заман сулышы белән яши. Заман рухы, заман ритмы — аның җаны. Бәхәсләрдән курыкмаска кирәк. Төрле буын шагыйрьләре белән аралашкан еллар шуңа өйрәтә.

Ике рәсем, ике буын. Болардан тыш? Болардан тыш аерым-аерым үз юллары белән килеп чыгып, поэзия ташкынына кушылып киткәннәр дә аз түгел. Саҗидә Сөләйманова, Әхсән Баянов кебек шагыйрьләрнең үзенчәлеген бернинди күмәк рәсемнәр дә юкка чыгара алмаячак. Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмовларга карата да шулай. Шулай бер чорда, бер парта арасыннан күтәрелеп, иҗади ярыш уты кабызган тагы бер буынны күрәсе килә әле. Килерләр, Такташ әйтмешли, аяк тавышларын ишетәм.

2. Поэзияне генә түгел, үзебезнең проза әсәрләрен дә укып барырга тырышам һәм башка әдәбиятлар белән дә чагыштырырга яратам. Беренче фикерем, талантларга бай безнең әдәбият. Кайсы жанрга чыксаң да чумып укырлык әсәрләр бар. Зур, өлгергән әдәбият. Соңгы вакытта укып чыккан «Кеше китә, җыры кала» әсәре үзе генә дә миндә дөнья чаклы фикер уятты. Үз ягым кешеләрен яхшы беләм дип йөри идем. Аз беләм икән. Мин белмәгән кешеләр бик күп икән. Рухи дөньялары искиткеч бай, матур, олы йөрәкле, зур җанлы кешеләр минем туган ягымда язып бетергесез икән. Яраттым, сагындым мин ул кешеләрне. Проза һәм поэзиядә шигърият, җанлы тел, кешеләр рухын ачкан тел якын минем өчен. Казан артының тагын бер почмагын ачтым үзем өчен. Дөресрәге, Мөхәммәт Мәһдиев ачты. Мин ул тудырган образларга сокланып яшим. Сагынам мин ул кешеләрне. Яхшы әсәрдән җылы кала, нindидер сагыну хисе кала күңелдә. Фикерем конкретрак булсын өчен бер генә әсәргә тукталдым. «Кеше китә, җыры кала» дан алдарак мин Әмирхан Еникинең «Тынычлану» хикәясен укып та тирән сагыш кичергән идем. Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход», Распутинның «Соңгы срок», «Яшә һәм онытма» кебек әсәрләрен укыганнан соң иманым тагын да ныгый төште: кеше рухы, кеше кичерешләре, кеше психологиясе, язучы таланты, язучы осталыгы — әсәрне чын сәнгать әсәре иткән төп сыйфатлар кайсы чорда да шулар икән. Безнең әдәбият кайсы яклары белән канәгатьләндерми дигән сорауга мин хәзер икенче төрлерәк җавап эзлим. Аңа яхшы тәрҗемә җитми.

3. Сиксәненче еллар өчен генә хас аерым үсеш тенденцияләре туар дип уйламыйм.

## Гомәр Бәширов:

Бу еллар эчендә республикабыз хуҗалык өлкәсендә булсын, мәдәнияте үсеше ягыннан булсын яңа баскычларга күтәрелде. Әдәбият, сәнгать өлкәсендәге уңышларыбыз да кечкенә түгел. Алар мине аеруча куандыра. Хәзер безнең бөтен Советлар Союзына, хәтта чит илләргә танылган талантлы композиторларыбыз, мәшһүр җырчыларыбыз бар. Татар җыр һәм бию ансамбленең Африка илләрендә зур уңыш белән чыгыш ясавы ифрат та куандыра.

Элекке еллар белән чагыштырганда безнең татар әдәбияты бик үсте, баеды, халык арасында абруе да артты. Без моны горурлык белән әйтә алабыз. Бу уңыш-

ларга үзеңнең дә азмы-күпме өлеш кертүең бу шатлыклы бәйрәм көннәрендә күңелне аеруча күтәреп җибәрә. «Намус» романы, «Туган ягым — яшел бишек» повестьлары бәхетле әсәрләр булып чыктылар. Бу ике китап рус телендә генә дә миллионнан артык тираж белән күп мәртәбәләр үзәк нәшриятларда басылып таралды. «Намус» романы, моннан тыш, барлык Европа һәм кайбер Азия илләре телләренә тәрҗемә ителде. «Туган ягым — яшел бишек» повесте белорусчага, венгерчага тәрҗемә ителә. Бу әсәрне монгол язучылары да үз телләренә тәрҗемә итәләр дип ишетәм. Шулай ук башка әдип һәм шагыйрьләребез әсәрләренең дә бөтен ил күләмендә танылуы, кайбер чит телләргә тәрҗемә ителүе татар әдәбиятының зур үсешен күрсәтә.

Соңгы елларда әдәбиятка дөньяны заманча аңлаучы, халык рухи халәтенең шактый ук катлаулы якларын әсәрләрендә үзенчәлекле итеп чагылдырырга омтылучы талантлы яшьләр өстәлде. Без, өлкән буын, аларга зур өметләр баглыйбыз. Чөнки әдәбиятның киләчәге яшь буынның халык алдында үз вазифасын ничек аңлавына, нинди идеяләр белән рухланып иҗат итүенә, нинди юнәлеш алуына бәйләнгән.

Сүз дә юк, хәзер әдәби әсәрләр күп языла, китаплар күп чыга. Алар тема ягыннан да төрлеләр. Ләкин шулардан әдәбиятның алтын фондына кереп калырлык ничә генә әсәр табылыр икән! Нигә шулай? Китаплар ник кыска гомерле булып туалар, чыгалар да бераздан ук онытылалар, аларны бер карап чыкканнан соң яңадан укыйсы килми?.. Бик тә уйландыра, борчый торган хәл бит бу.

Минемчә, соңгы елларда чыккан әсәрләрнең байтагысына фикер тирәнлеге, мәгънә тыгызлыгы җитми. Андый әсәрләрдә, күбесенчә, хәл һәм вакыйгаларның тышкы күренешләренә генә игътибар ителә, кеше эшчәнлегенең күзгә күренеп торган тышкы бизәкләре генә бирелә дә, аның рухи дөньясы ачылмыйча күләгәдә кала. Матур әдәбиятның төп вазифасы кеше рухын тасвирлау, аның иң кыйммәтле, иң затлы кешелек сыйфатларын эчке яктан нурландырып күрсәтү ләбаса! Укучыларыбыз бездән әнә шуны көтәләр.

Бу кимчелекләр, минемчә, бер үк вакытта әдәби әсәрнең тел байлыгына, аның сәнгатьчә эшләнешенә, образлы тасвир итүгә игътибар җитмәү белән дә бәйләнгән. Соңгы елларда әдип һәм шагыйрьләребезнең байтагысы ниндидер стандартлашкан тел белән яза торган булып киттеләр. Кайбер язучының телен һәм язу алымын икенчесенеккеннән һич тә аерып булмый башлады. Укыйсың, укыйсың, көтелмәгән чагыштырулар да, тапкыр охшатулар да куандырып җибәрми, усал репликалар да сискәндерми, телнең нәфислеге дә соклындырмый. Әйтерсең, кешенең күңел түренә үтеп керә торган тылсымлы көч — телнең иң кадерле «мамыгы» коелган да шырпылары гына тырпаеп калган. Минемчә, бу язучының талымсызлыгыннан, үзенә зур таләпләр куймыйча, аз-маз белән канәгать булып, әдәбиятта күптән үк әйләнештә йөргән, шунлыктан тәэсир көчен югалткан әзер сүзләр, әзер төшенчәләр белән чикләнүеннән килә. Шул ук вакытта халык телендә нинди генә җәүһәрләр сакланмый, анда безне нинди тансык сүзләр, тапкыр гыйбарәләр, моңарчы күренми яткан нинди генә образлы шигъри байлык көтми!

Киләчәктә шул чиксез байлыктан күбрәк, остарак файдаланырга кирәк иде бит. Без әсәрләребезне тыгыз мәгънәле фикерләр белән баетуга, тел чарлауга, сүз сайлауга, кыскасы, күңелләргә үтеп керердәй итеп оста язарга күбрәк көч салсак иде. Тырышсаң, телдән могҗиза тудырып була бит!

## Гариф Ахунов:

1. «Ардуан батыр» повестенда мин якташыбыз Мирсәет Ардуановның, Березники каласын һәм Березники химия комбинатын салучы ударникның, Ленин ордены кавалерының, беренче Совет Конституциясен кабул иткән съездда катнашуын чиксез бер соклану белән язган идем. Озак та узмый, минем үземә СССРның яңа Конституциясен кабул иткән СССР Верховный Советы сессиясендә катнашу бәхете насыйп булды. Республикабызның 60 еллыгын бәйрәм иткән чакта, мин моны гомер юлымдагы иң истәлекле вакыйга дип саныйм.

2. Җитмешенче елларда драматургиябез яңа бер сикереш ясады. Сәхнәне тутырган кәсепчеләр төшеп калып, аксакалларыбыз янына чын мәгънәсендә талантлы эшлекле яшьләр килде. Драматург Туфан Миңнуллинга һәм аның коллегаларына РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Моны соңгы ун елда илебез сәхнәләрендә чынлап торып юл алган татар совет драматургиясенең җитди уңышы, илебез тарафыннан танылуы дип карарга кирәк.

Җитмешенче елларда әдәбиятка әзерлекле, талантлы яшьләрнең килүе барлык жанрларда да артты. Бу — бик тә куандыргыч күренеш.

Инде безне борчыган мәсьәләләргә килгәндә, роман һәм повестьларыбызда эпик колач, масштаблылык кимеде. Интим-лирик повестьлар никадәрле генә җылы, тәэсирле язылган булмасыннар, алар зурлыклары, тормышны иңләп алулары белән эпик прозадан калышалар. Җитмешенче еллар прозасында уңай герой зур итеп, бөтен буйга куела алмады.

3. Сиксәненче еллар әдәбиятында, бигрәк тә поэзиядә, яңа ачышлар булыр, форма камиллеге килер, шарада-табышмаклар сәерсенү объекты булып кына калыр дип ышанам. Сиксәненче еллар татар прозасын дөнья күләменә чыгарыр, тәнкыйтьчеләр әсәрнең кысасын түгел, тукымасын тикшерә башларлар, сәнгатьчәлеккә аеруча игътибар итәрләр, моны нигездә яшь тәнкыйтьчеләр эшләр, әдәбиятта документальлек тагын да арта төшәр, татар әдәбияты нигезендә эшләнгән нәфис фильмнар күбәер дип өметләнәм. Тагын да зуррак өметем шунда, җитмешенче елларда канат чыгарган яшьләребез сиксәненче елларда әйдәүче көчкә әйләнерләр, әдәбият йөгеннән төпкә җигелеп тарта башларлар. Бу исә татар әдәбиятына киңрәк сулыш өстәр.

## Сажидә Сөләйманова:

Бер төркем татар һәм башкорт язучылары белән миңа Гарәбстан илләренә сәфәр кыларга туры килгән иде. Борынгы әкиятләр буенча бала чактан күңелне алгысытып торган дөньяга сәяхәтнең тәэсире никадәр көчле булуы турында әйтәсе дә юк. Совет халкы гаиләсендә татарның урыны, культурасы, уку йортлары, әдәбияты турында гарәп җәмәгатьчелегенең ихлас кызыксынуы безне шактый кыюландырып, үстереп җибәрде. Гарәп дәүләтләренең башкалалары Дамаск һәм Бәйруттагы дусларыбыз безне Совет илчелеге каршында оешкан культура үзәгенә очрашу кичәләренә чакырдылар. Һәр ике клубта Совет иленең дуслары җыелган иде. Баян Гыйззәт татар әдәбияты, аның үткәне, хәзергесе, борынгы әсәрләребезгә гарәп язмаларының йогынтысы турында бәйнә-бәйнә сөйләп, тыңлаучыларның игътибарын берьюлы җәлеп итте. Драматург Ибраһим Абдуллинның илһамлы чыгышыннан Урал тавы итәгендә искиткеч байлыклары, шигырь һәм җырлары белән дан алган матур дөнья — Башкортстан республикасы барлыгын белделәр. «Белделәр» дигән сүзне кулланам, чөнки язучылар сөйләгәндә гарәпләрнең йөзләрендә могҗиза күргәндәй гаҗәпләнү һәм соклану чагыла иде. Арабызда бердәнбер шагыйрь буларак, мин шигырь сөйләдем. Татарча һәм русча. Русча шигырьне культура үзәгенең тәрҗемәчесе гарәпчәгә тәрҗемә итеп аңлатты.

Бу вакыйгаларга байтак вакыт узды. Бәйсезлек өчен, тынычлык өчен көрәшүче Сирия һәм Ливан халкының язмышлары бөтен кешелекне борчый. Газета, радио, телевизорлар ул илләрдәге канлы вакыйгалар турында сөйләүдән тынып тормыйлар. Дини әкиятләр буенча Адәм һәм Һава йөзендә кешелек дөньясы башланып киткән җир, кеше хыялында борынгы оҗмах булган яклар...

Гарәпләрнең безгә ни өчен сокланып карауларын мин соңрак аңладым. Алар безне үз язмышын үз кулына алган халык вәкилләре итеп, шул батыр халыкның язучылары итеп кабул иткәннәр. Ул көннәрне уйлыйм да, гарәп дәүләтләренең ике башкаласында шигырь сөйләүче мин түгелдер сыман тоела. Бөек тарихлы халык вәкиле булмасам, мин алар өчен кем? Татар язучысының чит ил башкалаларында чыгыш ясавы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Моннан гайре мин үзем өчен тагын бер әйбер ачтым. Гарәпләр Муса Җәлилне яхшы беләләр. Бая телгә алган

тәрҗемәче Тарикъ шагыйрь дә икән. Җәлил шигырьләрен тәрҗемә иткән, берсен культура үзәге клубында укып та күрсәтте. Бөтен бер милләтнең дөньяга таныш булуы кайчакта бер шагыйрь исеменә бәйле. Җәлил — безнең шундый горурлыгыбыз! Ватанга мәхәббәт һәм дошманга нәфрәтнең иң тетрәндергеч минутларын ул «Моабит дәфтәрләре»ндә мәңгеләштергән. Дөньяга иң кирәкле нәрсә — җирдә тынычлык урнашсын өчен ул башын салган. Укучыга шагыйрь шуның белән кадерле.

Шагыйрь шигырьдә тулаем янсын өчен чорның кайнап торуы, кискен тарихи борылышлар зарур дибез. Заманадан ташламалар өмет итәбез. Кеше җанына тирәнрәк үтеп керү ягыннан, әлбәттә, җитмешенче елларда татар поэзиясе шактый уңышлар казанды. Шагыйрь йөрәгендә ялкын аз дип тә әйтеп булмый. Мәхәббәт утында дөрләү, нәфрәт утында көю... Матурлыкны, мәхәббәтне җырлау да укучы җанын сафландыруда соңгы чиратта тормый.

Заман чалымнары — галәмгә очыш, җир язмышы турында борчылулар соңгы еллар поэзиясендә байтак урын алса да, җыеп әйткәндә, шагыйрьгә укучы җанын тетрәндерердәй активлык җитми. Берәр шагыйрь турында фикер йөрткәндә безнең арада «аның үз Мокамае бармы?» дигән төшенчә йөри. Мәктәп елларыннан ятланып, берничә буынның теленнән төшмәгән һәм беркемне дә битараф калдырмаган әсәр турында сүз бара. Һади Такташның бу шигыре фаҗигале бер шәхес язмышы турында, шул ук вакытта ул җиңеп баручы катлаулы яңа тормыш турында. Авторның шул вакыйгалар эчендә кайнап яшәве шигырьнең һәр юлыннан бөркелеп тора. Үтә шәхси һәм көрәшчән. Бүген кайсыбызның үз «Мокамае» бар? Һәр көн булып торган искиткеч яңалыкларга, җанга тынгылык бирмәгән катлаулы проблемаларга безнең заман аеруча бай бит!

Сиксәненче елларга аяк бастык, яңа гасыр башына якынаябыз. Кеше һәм дөнья, йолдызлар һәм Җир шары турында уйлануларга яңа мөмкинлекләр туа. Уйлануларның үз җирлегендә төгәл адресы, төбәлгән кешесе булуын теләргә кала. Кеше җаны өчен көрәш кискенләшә барачак. Бу көрәштә һәр заман шагыйрьләре алгы сафта була киләләр.

## Ренат Харис:

1. Әдәбият вакыйгаларсыз булмый. Әдәбиятта иң зур вакыйга, минемчә, — я талантлы яңа язучы мәйданга килү, я талантлы яңа әсәр туу. Талант төшенчәсенә мин ике очракта да әдәби осталыктан да бигрәк иҗтимагый көчкә ия булган сыйфат итеп карыйм. Соңгы елларда татар совет әдәбиятына сәләтле яшьләр шактый күп килде. Араларында талантлылары да байтак. Алар әдәби процессыбызга сизелерлек йогынты ясыйлар. Моны күрмәскә дә (тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр, сезгә әйтүем), моңа куанмаска да мөмкин түгел. Әйтик, Мансур Вәлиев, Равил Кукушкин, Салих Маннапов, Әмир Мәхмүдов, Ринат Мөхәммәдиевләрнең тәнкыйть мәкаләләре белән исәпләшү барыбыз өчен дә табигый хәлгә әверелеп бара шикелле. Бүгенге, бигрәк тә киләчәктәге әдәби тәнкыйтьне, бу исемнәрдән башка күз алдына китерү кыен. Аларны тәнкыйть мәкаләләре язучылар итеп кенә түгел, ә әдәби шәхесләр, культура эшлеклеләре булып җитлегүләрен тизрәк күрәсе килә.

Драматургиябез дә матур-матур вакыйгаларга бай булды — соңгы дүрт-биш ел эчендә генә дә театрларыбыз сәхнәсендә Әхәт Гаффар, Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин, Ризван Хәмид пьесалары спектакльләргә әверелделәр. Алар һәр көн саен республикабызның меңләгән хезмәт ияләре — тамашачылар белән күзгә-күз калып сөйләшәләр, кеше күңелен гүзәллеккә, рухи камиллеккә омтылу хисе белән сугаралар.

Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Әхмәт Гадел, Зиннур Мансуров, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин, минемчә, әдәбиятыбызның гомуми букетына әлегә артык җитеп булмаган, әмма үзенчәлекле, кызыклы төс бирә торган шагыйрьләр. Аларның шигырьләрендә әлегә эзләнү эзләре күренә, ә артык эзләр, сызыклар һәм штрихлар әсәрне тоныклыйталар. Роберт Миңнуллин һәм Фәннур Сафинның җыр өлкәсендә

эшләүләре аларның иҗтимагый активлыкларын тагы да үстереп җибәрә — җырның офыгы киңрәк, хисе үткенрәк. Авыз тутырып Разил Вәлиев иҗатының бер кыры турында әйтәсе килә — аның шигырьләренә бәйле рәвештә эстрада җыры жанрына яңа төсмер — заман төсмере — өстәлде.

Прозада мине шатландырган вакыйга — Фаил Шәфигуллинның юмор-сатира өлкәсендәге уңышлы эшчәнлеге.

2. Җитмешенче еллар татар совет әдәбияты өчен, чыннан да, җитди эзләнүләр чоры булды. Минемчә, эзләнүләрнең юнәлеше күбрәк әдәби осталыкны үстерү, камилләштерү юнәлешендәрәк барды. Безнең әсәрләребез күләм ягыннан җыйнаклана төштеләр, ә художестволы информация микъдары аларда кимемәде, киресенчә, артты гына. Ә менә драматургиябез, миңа калса, укышларга да иреште — заман аһәңе белән сугарылган, олы гуманистик идеяләр белән өртелгән совет драматургиясендә яңалык булган образлар — бөек оптимист, «бетмәс-төкәнмәс» Әлмәндәр (Туфан Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы), шәхси мәнфәгатен халык, дәүләт мәнфәгатенә табигый куша белгән Саттаров (Диас Вәлиевнең «Тормыш бүләк итәм» пьесасы) дөньяга килделәр һәм халык мәхәббәтен казандылар.

Прозадан мин тормыш проблемаларын заманча, заманга тиң олы итеп гәүдәләндергән, халкыбызның кылган эшләренә тиң гүзәл образлар көтәм, ә драматургиядә — әйткәнемә өстәп, кәтелмәгән, шаккатырырлык, хәтта парадоксаль, ләкин реалистик нигезгә корылган форма табышлары. Драматургиягә бераз «көнкүрешлелек» («бытовизм») тузаны куна башлады шикелле.

3. Дөресен генә әйткәндә, әдәбиятның, шул исәптән татар совет әдәбиятының, үсеш тенденцияләре, гомумән алганда күптән билгеле — аларның нигезендә социалистик реализм методы таләпләре.

КПСС Үзәк Комитетының соңгы елларда кабул ителгән «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы, «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы тарихи карарлары әдәбият алдына олы бурычлар куйды.

Язучылар алдагы елларда әхлак тәрбиясе, патриотик тәрбия проблемаларын алга сөргән әсәрләр язуга тагы да ныграк игътибар бирерләр дигән өмет бар. Бу өмет әдәбиятыбызның барлык жанрларына да бер дәрәҗәдә кагыла.

Ә шигърияттә, минемчә, лиризм арта төшәр — фәнни-техник революциянең шаулап барышы кеше күңеленең тыныч тынлыкка сусавын көчәйтә генә.

## Әхәт Гаффар:

Ярсу чабышкы шикелле ашкынып, Татарстан АССР алтмышынчы Сабан туена килеп керде.

Тып-тып баса алмачуар,
дагасы корыч булса.
Яшәрбез дә, эшләрбез дә
дөньясы тыныч булса.

Бүгенге мәҗлесебезнең дә табын җырыдыр бу. Шушы җырны җырласа да, безнең әти-әниләр дөньялар хәвефле, сугышлы булса да эшләгән, яшәгән. Олы юлның маягы сыман, артта дәверләр торып калган. Тынычлык һәм иминлек мизгелләре тузан булып җилләргә очкан, сугыш һәм кан кою гасырлары агымсулар булып ташыган. Күпме кешеләр үзләре туган җир зиратына күмелмәгән!.. Аларны зиярат кылырга теләсәк, безгә, һичшиксез, кәрәш кырларына бару шарт.

Ә безнең яшәвебез алмачуары заманаларның сират күперләрен кичә-кичә киләчәккә оча.

Акбүз ат атлап килә,
юлларны таптап килә.

Иң авыр чакта кешене
өмете саклап килә.

Өмете. Шул өмет чаткысы, утлы тиендәй, бер гасыр ябалдашыннан икенче гасыр ябалдашына сикерә-сикерә килгән дә бүген илдәге алтмышынчы Сабан туеның түрендә утыра. Арттә — данлы өермәләр, артта — утлы көрәш учаклары...

Шәмнәре янган була,
Кайчагында безгә дөнья
елмаеп алган була.

Шәм генәме?! Татарстанның кайсы гына тарафына караш атма — төп-төз нефть манаралары. Кайсыбер урында аларга иске мәчет манарасы, җил тегермененең сулган гәүдәсе янәшә диярлек. Һәр авылда Сәмәркандның бер почмагын хәтерләткән силос манаралары... Без икмәкне кешедән сорап ашамыйбыз! Әйе, безгә дөнья елмаерлык.

Безнең милләт — моңлы халык. Моңлана белгән кеше генә — кеше, җырлый, җырлана белгән ил генә — ил. Ә без җырны һәрчак алдан башлаганбыз. Ирек, хакыйкать өчен көрәшләрнең кайсысына гына әйләнеп карама — җиңүләрнең яшел болыннарында безнең алмачуарлар утлап ял итә.

Әдәбиятыбыз Алмачуары да — көрәшче юргасы.

Урман кисәм, урман кисәм,
кала агач төпләре.
Киләчәк ямьле булсын дип,
хәтерлибез үткәнне.

Хәтерлибез генә түгел, һәрчак истә тотабыз. Үткән — безнең әдәбиятның канында, аңында.

Ишетәсезме?

— Кемнәр? — дигән кайтаваз килә.

Күрәсезме? Алтмышынчы Сабан туебызның алтын әдәбият мәйданына толпар атлар килеп керде. Таныйсызмы? Мыеклысы — Галимҗан абый, зәңгәр күзлесе — Такташ, балкып торган йөзлесе — Кутуй, сынап караганы — Кәрим, гайрәтлесе — Җәлил, тыйнагы — Исәнбәт, какчасы — Туфан, аз сүзлесе — Хәким. Әнә Таҗи Гыйззәт, Тинчурин, Әмир, Бәширов, Хөсни, Ибраһим Гази, Еники агайлар. Маңгайларындагы тирләрен сөртә-сөртә толпарларының дагаларын карыйлар... Шикләнмәгез лә! Барып җитәрсез! Йөзенче, меңенче Сабан туйларыбызга да барып җитәрсез. Бәлки әле үзегезгә Ахуновларның Идел кызларын, Миңнуллинарның Әлмәндәрләрен, Гыйләҗевләрнең җиргә гашыйк бер кешесен, Юзеевләрнең Миләүшәләрен, Шәүкәт Галиевләрнең нарасыйларын, Бикчуриннарның иң каты токымнардан да ныграк егетләрен, Мәһдиевнең кырык беренче ел балаларын, Харисов белән Фәйзуллиннарның көрәшчеләрен, Зөлфәт белән Әгъләмовларның яралы йөрәкләрен дә алып китәрсез?

Үз халкыңның киләчәген,
үткәнен, бүгенгесен,
кайгысының, шатлыгының
зурлыгын белер өчен
еракка китеп кара син,
еракка китеп кара...

Ераккарак китеп карыйм да... халкыбызның рухи хәзинәсе, күңел кошы — әдәбияты салынган бөек кәрванның менә шушы әйдәүчеләрен карашым белән узып, егерме җиде яшьлек кәрван башы Тукайга:

— Исәнме, бабай! — дип эндәшәм. Таный. Үзенә кадәрге Кол Галине, Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Укмасый, Мәрҗани, Насыйриларны таныган шикелле үк, үзеннән соң килгән һәм х а л ы к дигән иман белән яза торган, язачак бүгенге, ки-

ләчәк язучыларның һәммәсен таный. Безнең кәрван башыбыз — бөтен милләтебезнең өмет җепләре йомгагын үз йөрәге иткән Тукаебызга иман тоткан һәркемне егерме җиде яшьлек Мәңгелек егет һәрчак таныр!

Бүгенге мәҗлесебезгә кемне үткәрергә диеп уйланса, Тукай үз кулларына Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»н, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н, Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур»ын, Әбрар Кәримуллинның «Татар китабы»н тоткан һәм күңелендә халык җырлары булган һәркемне кочаклап каршы алыр иде. Чөнки Тукай үз халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген, хәсрәтенең, бәхетенең зурлыгын белер өчен барыбыздан да ераккарак китеп караган лабаса!

Ә алтмыш еллык дәвердә милли әдәбиятыбыз ирешкән уңышларны куанып һәм горурлану белән тагын бер кат күз алдыннан уздырганда Тукайның әдәби кәрванындагы һәркем иҗатына, халык тарихына, аның киләчәгенә якынрак килеп карыйсы килә. Бу хакта илебез яшь язучыларының VI Бөтенсоюз киңәшмәсендә уйланып утырганым бар. Бу хакта һәр яңа хикәям, повестем, пьесамда уйланам... Якынрак! Ватаныбыз һәм социалистик илләр халыклары белән тугандашлыкның үзәгенә якынрак, тынычлык өчен көрәшнең иң алгы сызыгына якынрак! Киләчәккә юл бары тик шушындый якынлык аша гына — безнең йөрәкләребезнең кыл уртасы аша үтә. Әдәбиятыбызның уртак бер жанры бар — ул да булса көрәш дигән жанр. Сиксәненче елларда шушы жанр безнең һәр сүз толпарының йөрәге булып типсен иде! Чөнки безнең халык дагага карамый, йөраккә карый. Көрәш утын без Тукайның Ватан һәм халык өчен көеп янган йөрәгеннән, Җәлилнең бөтен дөньяны яңгыраткан җырыннан әҗәткә алдык. Көрәш — безнең киләчәккә гозеребез.

Халкыбызның йөрәгендә алтмышынчы Сабан туе тибә. Беренчесенә кадәр меңнәре булган. Алтмышынчысыннан соң ничәү?

Юрамыйк: җиңүләребез әйтер. Язучының коралы — сүз. Ташка язсак, сүзебез мәңгелек. Ә мәңгелекне акыллы халык бирәү дип тә, меңәү дип тә санамый — ул мәңгелек кенә. Мәңгелек безнең сусаганда эчә торган бер йотым суыбыз ул. Мәңгелек — язучы каләме очындагы бер тамчы кара...

Тик шагыйрьгә кара китерегез
Һәм кулына каләм бирегез!

## Мөдәррис Әгъләмов:

Мин сугыштан соң дөньяга килгән буын вәкиле. Димәк, 10—13 ел гомерне сабыйлыкка калдырсак, республикабызның 60 еллык тарихының 20 елы гына без олы вакыйгаларны кабул итә алырлык чорга туры килә. Бу егерме ел эчендә минем өчен нинди истәлекле, тормышыма, шагыйрь буларак формалашуыма тәэсир иткән нинди гыйбрәтле вакыйгалар булды? Алар минем өчен өчәү.

**Беренчесе:** Җәлилнең илгә кайтуы. Сугыштан соңгы күтәренке атмосфера.

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Мин — малайга Җәлилнең кайтуы төнлә кояш чыгуы кебек бер могҗиза булды. Шуңа күрәдер дә «Вәхшәт», «Җырларым», «Чишмә белән сандугач» шигырьләрен сәхнәләрдән укып халыкны җылатканымны хәтерлим.

**Икенчесе:** Хәсән Туфан белән очрашу. Бу очрашу бик тә сәер булды. Безнең мәктәп китапханәсе бик зур иде. Киштә-киштә томлыклардан алып, биш-алты гына битле рәсемле китапларга кадәр. Ни генә юк!.. Аңлап та, аңламыйча да барысын тоташ укып бетергәннән соң, почта аша кайта торган китап бәйләмнәрен көтеп ала торган идем. Көннәрдән бер көнне бәйләмнән яшел тышлы ике китап килеп чыкты. Төрле елларда чыгуларына карамастан — бертуганнар кебек. Икесе бергә. Икесе дә яшел тышлы. Язучыларының исемнәрен генә кара: Туфан, Бабич. Ничектер, ирексездән, рәттән санап китәсе килә: Пуш-кин, Ту-кай, Так-таш, Җә-лил, Ту-фан, Ба-бич...

Бүген килеп сиңа баш иям.
Тукай биргән эстафетаны
Югалтмаган хәлдә, Русиям.

Соңыннан Хәсән ага Туфанның җылы кулын да күп тоярга, чыбыгының очын да байтак татырга туры килде. Еш очраштык та, янәшә дә яшәдек. Әмма авылда мәктәп китапханәсендәге шул беренче очрашудан да истәлеклесе булмагандыр. Беренче очрашу һәрвакыт иң кадерлесе бит. Соңыннан аңладым: Хәсән ага үзе — шигърият, шигърияте — үзе икән. Шуңа күрәдер дә беренче китабын уку, аның үзе белән очрашу булып күңелгә сеңеп калган.

**Өченчесе:** Казанга килеп яшьтәшем, каләмдәшем, якын дустым Зөлфәт белән очрашу. Әдәбият кешесенә бөтен җаныңны әйләндереп сала алырлык бер кеше кирәк. Әдәби һәм дөньяви ваклыкларны яки зурлыкларны бер генә кеше белән ачыктан-ачык сөйләшеп була. Фикердәш булсаң гына! Уртак омтылышың булса гына! Шундый иптәше булмаган язучының максаты ваклана. Язучы өчен иң куркынычы: максатының ваклануы.

2. Бу сорауга җавап бирер алдыннан үземнең әдәбиятка килүемнең шәхсән үзенчәлекләрен әйтеп китмичә булмый. Алтмышынчы еллар башында бер гаҗәп шаукым кузгалды. Ул да булса, гасырлар буе формалашып килгән шигърияттебездән ваз кичеп, татар сүзләре белән башка телдә язу хәрәкәте. Бу хәрәкәт минем киләчәк язмышымны, тормышымда гомер буе өстерәп барачак «чыбыркы» — «үз башыма төшәчәк чыбыркы» мәсьәләсен хәл итте.

Кол Гали, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Ясәви, Кандалый... Тукай, Бабич, Такташ, Туфан, Җәлил, Хәким...

Шуларның кайсын укып, кайсын әбиемнең укуы аша белгән, үз телемнең куәтенә инанган бер малайга бу хәрәкәт шулкадәр чит булып тоелды ки, мин каныма сеңгәннең мәңгелек икәнен исбат итәргә теләп каләмгә тотындым. «Еракка китеп кара» дип аталган шигырьләр бәйләме шуңа бәйле рәвештә язылган иде. Бу шигърияткә кагыла. Үзем алган юлга. Журнал биргән сорауда «Җитмешенче еллар әдәбияты» диелгән. Мине нәрсә белән куандырды ул? Шәриф Хөсәеновның «Әни килде»се, «Зөбәйдә адәм баласы» белән. Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗевнең яңа әсәрләре белән, С. Хәким, Н. Арслан, Р. Фәйзуллин, Зөлфәтнең яңа иҗади уңышлары белән.

Нәрсәсе белән канәгатьләндермәде? Нәкъ менә мин атаган исемнәр биеклегенә кайберәүләрнең азрак омтылышы белән, шул биеклекне максат итеп алмаулары белән. Бәлки ул кешенең мөмкинлегеннән киләдер?!

3. Шигъриятнең сиксәненче еллардагы хәрәкәтен мин бүген барган агымда барыр дип беләм. Шунда бер «әмма» бар. Безнең алтмышынчы еллардагы шигърият шулкадәр биеклеккә иреште ки, без аны бөтен ил күләменә горурланып чыгара алабыз. Башка халыкларның поэзиясе белән чагыштырып карый алу дәрәҗәсендәге кеше моны бик тиз сизәчәк. Сиксәненче еллар безнең шул байлыгыбызның гомуми илебез байлыгына әвереләчәк еллары булыр дип уйлыйм. Күңел шуны тели.

Яхъя Абдуллин,

философия фәннәре докторы

# РУХИ АСЫЛЫБЫЗ

Гасырлар дәвамында тупланган фәлсәфи, этик һәм эстетик идеяләр һәм иҗтимагый-политик карашлар татар халкы рухи культурасының зур бер әһәмиятле өлешен тәшкил итә. Яңа, социалистик культура төзүнең башында ук бу өлкәдәге кыйммәтле мирасны тирәнтен өйрәнүгә һәм тәнкыйтьчел үзләштерүгә аерым игътибар бирелде. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы игълан ителгәч тә, халкыбызның иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихы проблемаларына караган беренче хезмәтләр күренә башлый.

Беренче кыйммәтле тәҗрибәне күренекле әдип галим-марксист Галимҗан Ибраһимов ясый. Аның «Насыйриларның тарихи урыннары» дигән хезмәте аеруча игътибарга лаек. Ул анда татар мәгърифәтчеләренең иҗаты һәм эшчәнлегенең халыкны урта гасыр караңгылыгыннан азат итүдәге, дини хорафатны фаш итүдәге, фәнни белемнәргә һәм культура казанышларына әйдәүдәге әһәмиятен ача. Болар белән бергә, ул мәгърифәтчеләр эшчәнлегенә гомуми тасвирлама бирә, аларның иҗтимагый-политик, фәлсәфи, этик һәм эстетик идеяләренең нинди социаль-экономик шартларда барлыкка килүен күрсәтергә омтыла. Г. Ибраһимов «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүендә марксизм ысулы» (1922), «Татарның соңгы тарихында өч дәвер» (1922), «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар» (1924), «1905 ел революциясендә татарлар» (1926), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1925) һ. б. хезмәтләрендә дә иҗтимагый-тарихи проблемаларына кагыла.

Егерменче елларда иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүгә әдәбият белгече Г. Сәгъди шактый өлеш кертә. Дөрес, ул элекке мирасны бәяләүдә төгәлсезлекләр дә эшли, ялгыш нәтиҗәләр дә чыгара. Шул ук вакытта ул күпкырлы тикшеренүче була, халыкның тарихын һәм культурасын яхшы белә. Бу аның хезмәтләрендә яхшы чагылыш таба, һәм аларда иҗтимагый фикер тарихына кагылышлы байтак кыйммәтле материал тупланган. Бу җәһәттән аның «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 1926) дигән хезмәте уңышлы. Аталышыннан күренгәнчә, бу китап әдәбият тарихына багышланган. Алай да аның эчтәлеге, җиселе исеменнән шактый киң. Әдәбият белән бергә, анда культура һәм иҗтимагый фикернең гомуми проблемалары да җентекләп карала.

Бу елларда Җ. Вәлидов, Г. Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим дә татар культурасы эшлеклеләренең иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи проблемалар өлкәсендәге мирасларын тикшеренүдә мәгълүм эз калдырды. Әмма алар марксизм-ленинизмның фәнни баскычларына баса һәм аны үзләренең тикшеренү эшләрендә куллана алмадылар. Аларның хезмәтләрендә буржуаз объективизм юшкыны сизелә. Шунысы да хак: аларда, Г. Сәгъди хезмәтләрендәге кебек, фактларның бай материалы бар. Бигрәк тә Җ. Вәлидовның 1923 елда рус телендә нәшер ителгән «Идел буе татарларының белемлелеге һәм әдәбиятының тарихи очерклары» дигән хезмәте җәлеп итәрлек дәрәҗәдә бай. Автор, язучылар иҗатының һәм эшчәнлегенең татар халкы рухи тормышындагы әһәмиятенә гомуми тасвирлама бирү белән бергә, аларның дөньяга карашлары проблемаларын да күтәрә һәм татар фикер ияләренең аны хәл итүгә ни рәвешле якын килүләрен дә күрсәтеп үтә.

Сугыштан соңгы елларда иҗтимагый фикер тарихы проблемалары киңрәк тикшерелә башлый. Мәгърифәтчелек һәм революцион-демократик идеология мәсьәләләре бигрәк тә күп һәм тиз өйрәнелә. Л. Җәләйнең «Татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри»[1] дигән мәкаләсе басылып чыккач, күп кенә тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә төрле рәвештә татар мәгърифәтчелеге мәсьәләләре дә яктыртыла. Бу юнәлештә М. Х. Гайнуллин уңышлы эшли. Аның 1955 елда басылган «Каюм Насыйри һәм татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте» дигән хезмәтендә Каюм Насыйри һәм башка мәгърифәтчеләрнең эшчәнлеге сурәтләнә һәм татар мәгърифәтчелегенең әһәмияте ачы-

[1] «Совет әдәбияты», 1945, № 2.

ла. Мондагы эзләнү нәтиҗәләрен ул «XX гасыр башында татар әдәбияты һәм публицистикасы» (Казан, 1966) дигән китабында үстерә һәм тирәнәйтә төшә. Автор яңа исемнәр дә атый, мәгърифәтчеләр тарафыннан әйтелгән идеяләрнең үсешен дә күзәтә. М. Х. Гайнуллин «XIX гасырда татар әдәбияты» (Казан, 1968) китабында һәм соңгы дистә елларда язган мәкаләләрендә дә мәгърифәтчеләр мирасын эзлекле пропагандалый.

К. Ф. Фасеевның «Алдынгы татар иҗтимагый фикере тарихыннан» (Казан, 1955) китабында мәгърифәтчелек һәм революцион-демократик идеология мәсьәләләре үзәк урыннарның берсен били. Анда татарлар арасында бу прогрессив идеяләр хәрәкәте барлыкка килгән тарихи шартларга, аларны формалаштыруда рус иҗтимагый фикеренең әһәмиятенә җентекле тасвирлама бирелә һәм кайбер фикер ияләренең иҗаты һәм эшчәнлегенең эчтәлеге ачыла. Аның «Туганлык һәм дуслык көче» (Казан, 1966) һәм «Пролетар интернационализм юлыннан» (Казан, 1971) китаплары прогрессив татар җәмәгатьчелек фикере вәкилләренең идея мирасын өйрәнүдә алга зур адым булып тора. Бу хезмәтләрдә прогрессив татар фикер ияләренең, ягъни мәгърифәтчеләр һәм революцион демократларның милләт һәм милли мөнәсәбәтләр проблемаларына карашлары һәрьяклап анализлана һәм алар мирасының халыклар дуслыгы идеологиясен ныгытудагы әһәмияте ачыла.

Ә менә Р. И. Нәфигов «Алдынгы татар иҗтимагый-политик фикере формалашуы һәм үсүе» дигән китабында (Казан, 1964) татар иҗтимагый фикерен өйрәнү тарихын шактый яңача рәвештә күз алдыннан кичерә. Ул моңарчы идея мирасына бәя бирүдәге кайбер утрак, үсешсез карашлардан читләшә: татар культурасының байтак вәкилләре иҗатын һәм эшчәнлеген яңача, төрле яктан килеп бәяли. Р. И. Нәфигов татарлар арасындагы җәдитчелек хәрәкәтенең социаль табигатенә, андагы мәгърифәтчелек-демократик һәм буржуаз-либераль тенденцияләр нисбәтенә карата байтак кызыклы фикерләр әйтә.

С. М. Михайлованың «Идел буе татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең формалашуы һәм үсүе» дигән китабында (Казан университеты нәшрияты, 1972) бу хәрәкәтнең социаль-экономик һәм культура-идеология шартларына, татар мәгърифәтчеләренең эшчәнлегенә җентекле характеристика бирелә. Анда Казан университеты һәм аның галимнәренең татарлар, шулай ук Идел буендагы башка халыклар өчен уйнаган мәгърифәтчелек роле һәрьяклап күрсәтелгән; Петербург һәм Казан университетлары укытучылары И. Хәлфин һәм Х. Фәйзхановның мәгърифәтчелек характерындагы эшчәнлеге ышандырырлык итеп ачып салынган. Бу хезмәт XVIII гасыр ахырында һәм XIX гасырның беренче яртысындагы чорда татарларның культура тормышын, татарларга карата патша самодержавиесенең колониаль политикасын, алар тормышында мөселман руханилары һәм православие миссионерларының тискәре эшчәнлеген фаш итә торган материалга бай.

Татар мәгърифәтчеләренең иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи карашлары, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәйзханов, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов иҗатларының төп рухы һәм эчтәлеге турында соңгы елларда «Казан утлары» журналында басылып чыккан мәкаләләр дә татар иҗтимагый фикере тарихы проблемаларын өйрәнүдә җитди әһәмияткә ия. 1976 елда Татарстан китап нәшрияты «Татар мәгърифәтчелек фикере» дигән хезмәт чыгарды. Анда мәгърифәтчеләрнең иҗат мирасы турындагы тикшеренүләргә йомгак ясала һәм аларның фәлсәфи, иҗтимагый-политик карашларына проблемалы анализ бирелә.

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты нәшер иткән «Татар иҗтимагый фикере тарихыннан» дигән җыентыгы иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын тикшеренүне киңәйтү юнәлешендә яңа адым сыйфатында каралырга бик хаклы. Бу хезмәттә элекке заманнардан алып бүгенге көнгәчә татарлар арасында иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи фикер үсеше тарихының аерым сәхифәләре тикшерелә.

Татар иҗтимагый фикеренең иң күренекле вәкилләренең иҗат мирасын туплап яктыртуда мәгълүм нәтиҗәләргә ирешелде. «Каюм Насыйри — күренекле мәгърифәтче-демократ» (1976) дигән җыентык — К. Насыйри иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнүдә яңа бер этап. Былтыр «Габдулла Тукай» җыентыгы дөнья күрде. Анда шагыйрьнең тууына 90 ел тулуга багышланган фәнни конференция һәм юбилей тантаналары материаллары тупланган. Бу җыентыкта шагыйрьнең фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик мәсьәләләргә мөнәсәбәте һәрьяклап тикшерелә һәм аның татар иҗтимагый фикере тарихында тоткан урыны ачыла. Ч. Айтматов, Р. Гамзатов, И. Брагинский, Ш. Турдыев, К. Васин һәм башка эшлекләрнең мәкаләләрендә Г. Тукайның тугандаш халыклар әдәбиятына шифалы йогынтысы раслана. Галимҗан Ибраһимов турында да шушындый җыентык әзерләнде.

Фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик фикер тарихын тикшеренүдәге шушы рәвештәге мәгълүм казанышлар янәшәсендә кимчелекләр дә күзгә ташлана, тарихи мирасны өйрәнү һәм йомгаклауның кичектергесез проблемалары өскә калка. Татар иҗтимагый фикерендә марксистик-ленинчыл философик һәм иҗтимагый-политик идеяләр таралуын һәм ныгуын тирәнтен дә, һәрьяклап та тикшеренү — төп бурычларның берсе. Бу мәсьәләне хәл итүгә профессорлар К. Ф. Фасеев, Р. И. Нәфигов һәм доцент М. Ф. Фасеев тикшеренүләре сизелерлек өлеш кертте инде.

Тарихчылар һәм әдәбият белгечләре дә бу юнәлештә байтак эш башкарды. Профессор М. К. Мөхәррәмов, тарих фәннәре докторы Х. Х. Хәсәнов, филология фәннәре

докторлары М. Х. Хәсәновның, И. З. Нуруллин, Г. Халитов һәм башка иптәшләрнең «Татарстан АССР тарихы», «Татарстан партия оешмасы тарихы очерклары» җыентыкларындагы кыйммәтле гомумиләштерүләрне беренче нәүбәттә күрсәтеп үтү мәгъкуль булыр. Алай да бу проблеманың дөньяви-фәлсәфи аспекты тиешенчә өйрәнелмәгән әле. Инде XX гасыр башында ук татар иҗтимагый фикеренең алдынгы карашлы вәкилләренә марксистик-ленинчыл идеяләр йогынты ясый. Әйтик, Г. Тукай иҗатын җентекле тикшерү аңа башта ук социалистик идеяләр һәм социал-демократик әдәбиятның көчле тәэсир итүе турында сөйли. Татар культурасының башка прогрессив эшлеклеләренең, аерым алганда Г. Ибраһимовның иҗат юлы мәгърифәтчелектән һәм революцион демократизмнан марксизмга үсештән торган иҗат юлын шушы нисбәттә тикшерү кызыклы нәтиҗә бирер иде.

Хәзер Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикерне өйрәнү секторы «XX гасыр башында марксизм һәм татар иҗтимагый фикере» дигән теманы тикшерә. Бурыч Татарстанда марксистик-ленинчыл философия һәм иҗтимагый-политик идеяләр таралуын өйрәнүдән гыйбарәт. Татар телендә чыккан социаль-демократик әдәбият һәм анда күтәрелгән проблемалар турындагы мәсьәләне карау аеруча әһәмиятле. Киләчәктә бу теманы татар иҗтимагый фикерендә Октябрь революциясеннән соңгы чорда чагылган буржуаз-милли идеологиягә каршы көрәш алып бару һәм марксистик-ленинчыл идеяләрнең ахыргача ныгуын раслау рәвешендә дәвам иттерү зарур.

Социалистик үзгәртеп корулар халкыбызның рухи дөньясын шифалы рухы белән яңартып җибәрде, җәмәгатьчелек аңында революция ясады. Илебездә социализм җиңүе нәтиҗәсендә совет иҗтимагый фикере үзенең яңарыш фәне иканен дәлилле раслады. Мәгълүм булганча, бу шома гына түгел, ә бәлки кискен идеологик көрәш шартларында барды. Кешеләрнең аңын тамырдан үзгәртүгә һәм совет иҗтимагый фикере тантанасына китергән бу көрәшнең барлык сыйфатын, рәвешен ачып күрсәтү бик мөһим. Бу дөньяга фәлсәфи караш социаль-политик, шул исәптән милли һәм интернациональ, шулай ук гаилә-көнкүреш аспектларын да тирәнтен өйрәнүне сорый. Кыскасы, Татарстанда совет иҗтимагый фикере ныгып урнашуның дәвамлы юлын җентекле тикшерү — тарихи-фәлсәфи проблемаларның иң әһәмиятлеләреннән берсе.

Татар иҗтимагый фикерендә атеистик идеяләр таралуы һәм ныгуы мәсьәләләрен өйрәнү — шушы тикшеренүләрнең бер өлешен тәшкил итә. Бу яктан бездә, аерым алганда, Г. Тукайның атеистик мирасын гомумиләштерү буенча мәгълүм тәҗрибә тупланды. Бу тәҗрибәне үстерү, ныгыту сорала. Югыйсә, татар культурасының башка вәкилләре дә бу мәсьәләдә прогрессив карашта торганнар. Ф. Әмирхан, Г. Чагатай (Гафуров), Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев һәм башка эшлеклеләрнең мирасы — бу процессның закончалыгын һәръяклап ачыклау өчен кызыклы җирлек. Культурабызның күп кенә эшлеклеләренеке кебек үк, Тукай атеизмы да өстәмә анык-лык кертүне таләп итә. Бу эш иҗтимагый фикердә фәнни атеизмның нык тамыр җәюе өчен көрәшне һәм аның ныгып урнашуын теоретик-методологик яктан чыгып тикшерену, анализлау рәвешендә дәвам иттерелергә тиеш.

Әгәр без татар иҗтимагый фикеренең марксизм таралуга кадәрге чорына мөрәҗәгать итсәк, аның бары тик XIX гасырдагы һәм XX гасыр башындагы торышы гына чагыштырмача яхшырак өйрәнелгәнен күрербез. Бу барыннан да элек мәгърифәтчеләр һәм революцион демократлар мирасына кагыла. Монда да нокта куярга иртә сыман. Каюм Насыйрины гына алыйк. Аның әле тик басма әсәрләре генә җентекләп анализланган. Татар мәгърифәтчелек фикеренең күренекле бу вәкиле бик зур кульязма мирас та калдырган бит! Аны тиешенчә өйрәнү К. Насыйри эшчәнлегенең яңа якларын ачарга булышлык итүе дә ихтимал.

Соңгы вакытта зур философ һәм фикер иясе һәм тарихчы-галим Ш. Мәрҗанинең иҗат йөзе тагын да ачыклана төште. Алай да әлегә без аның мирасын өйрәнә генә башладык, бу юнәлештә беренче адымнар гына ясалды дисәк тә, һич хата булмас. Ш. Мәрҗанинең күпчелек әсәрләре гарәп телендә язылган. Шуңа күрә аннан күпләр файдалана алмый. Тел, әдәбият һәм тарих институтында бер кадәр эш эшләнми түгел: «Мәрҗани тарихчы» дигән монография әзерләнде, «Мәрҗанинең мөселман дине тәгълиматын һәм суфыйчылыкны тәнкыйтьләвенең төп принциплары һәм юнәлешләре» дигән тема буенча эш алып барыла, аның җиде томлык «Вафиятел әсләф вә тәхиятел әхләф» хезмәтеннән сайланма җыентык әзерләнә башлады.

Үзенең радикальлеге белән аерылып торган татар мәгърифәтчелеге вәкиле Ш. Көлтәси исеме соңгы елларда гына матбугатта телгә алына башлады. Күптән түгел Ф. Г. Газизуллинның «Хакыйкатькә юл. 1880—1917 елларда сыйныфларның социаль-экономик интереслары һәм татар экономик әдәбияты» дигән китабы чыкты. Без бу хезмәттән татарларның экономик тәгълимат өлкәсендә дә бай мираслары булуын белдек. XIX гасырның икенче яртысында экономика фәненең Г. Фәйзханов кебек зур һәм оригиналь вәкиле эшләгәнлеге күпләр өчен ачыш булды. Әгәр дә без XIX гасыр һәм XX гасыр башы хезмәтләрен җентекләп тикшеренү белән шөгыльләнсәк, Ш. Көлтәси һәм Г. Фәйзханов кебек шәхесләрнең яңаларын тагын ачуыбыз ихтимал.

Революцион демократларга мөрәҗәгать иткәндә, аларның дөньяга караш позицияләрен, фәлсәфи һәм социологик идеяләрен, алар аеруча югары күтәргән халыклар дуслыгы идеяләрен тикшеренүгә тирәнтен игътибар итү зарурлыгын басым ясап күрсәтеп үтми булмый. Ләкин игътибарга лаеклысы шул — без мәгърифәтчеләрнең дә, революцион демократларның да дошман-

нарын начар беләбез. Әсәрләренә анализ ясау белән мәшәкатьләнмичә, мәгълүм схема буенча, һаман Ишми ишан янсә Исмәгыйль Кышгарины тукмый бирәбез. Югыйсә, XIX гасыр һәм XX гасыр башы прогрессив фикер йөртүчеләрнең зуррак түбәтәйле дошманнары да булган. Алар турында без бөтенләй белмибез. Әмма, либераль һәм консерватив идеологияне яхшы белми торып, алдынгы иҗтимагый фикер үсешенең һәм татар иҗтимагый фикеренең марксистик-ленинчыл идеяләрне үзенә кабул итү хәрәкәтен дөрес сурәтләргә мөмкин түгел.

XIX гасырга кадәрге татар культурасы эшлеклеләренең мирасы аларның дөньяга караш позицияләрен һәм иҗтимагый-политик карашларын ачыклап бетерәсе бар. Татар халкының рухи культурасы бай тарихлы. Татарларның борынгы бабалары булган Идел-Кама болгарлары X—XI йөзләрдә үк бай идеяле тормыш белән яшәгәннәр. Тарих безгә Идел-Кама Булгариясендәге күп кенә галимнәрнең исемнәрен саклап калдырган. XIII гасырдан башлап, болгар-татар культурасының язма истәлекләре дә сакланган. Аларда гаделлек һәм гуманизм идеяләре кызыл җеп булып сузыла, изелү һәм тигезсезлекне кире кагу тавышы яңгырый. Аерым әсәрләрдә шулай ук социаль утопизмга авазлаш идеяләр дә чагыла. Урта гасырдагы кайбер татар фикер ияләре дөньяга карашның зур мәсьәләләрен дә күтәргәннәр. Мисал итеп Котбине һәм аның «Хөсрәү вә Ширин хикәяте» (XIV гасыр) китабын гына китерү дә җитә. Урта гасырның бу фикер иясен кеше һәм аның дөньяга мөнәсәбәте дулкынландыра. Ул кешене бер үк вакытта зур галәм киңлегендә карый. С. Сараиның «Гөлстан битторки» дигән китабында Җирнең Кояш тирәсендә әйләнү идеясе әйтелә. Ә бу Коперниктан 150 ел элегрәк була. Ләкин бу бай мирас безнең тарафтан фәлсәфи дөньяга караш планында өйрәнелмәгән. Шуңа күрә без, татар культурасы һәм җәмәгатьчелек фикере тарихы турында сөйләгәндә, күп очракта өстән-өстән генә, кайвакыт дәлилсез фикер йөртүләр белән чикләнергә мәҗбүр булабыз. Моның белән без үзебез утырган ботакны үзебез кисәбез түгелме?

Татар иҗтимагый фикерендә һәм аларның үсешендә эстетик идеяләр турындагы мәсьәлә дә йомшак өйрәнелгән. Бу проблема турында сүз чыкканда, без «ислам дине сәнгатьне тыйган һәм шуңа күрә эстетик фикер тоткарланган» дияргә ашыгабыз. Ләкин хакыйкать хакына шуны әйтергә кирәк: ислам дине сәнгатьнең барлык төрен дә түгел, ә бәлки кеше портретын ясауны, полотно янсә ташта кеше һәм хайваннар образын сурәтләүне генә тыйган. Музыка янсә җырга килгәндә, бу кысрыклаулар аеруча фанатик һәм консерватив «изге»ләрнең чамадан тыш көчәнүләре нәтиҗәсе генә. Кайбер дини руханилар музыка белән җырны бер дә гөнаһ дип санамыйлар, үзләре үк музыка һәм җыр белән мавыгалар. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, бер ишанның үз фикердәшләре белән ел саен Идел буе һәм Урал яны авылларында йөрүе, анда музыка коралларында уйнаулары, җырлау һәм биюләре, ягъни күңел күтәрү чаралары оештырулары турында язып калдырган.

Билгеле, татар руханилары арасында сәнгать белән шөгыльләнергә ярамаганлыгын теоретик яктан нигезләргә маташучылар да булган. Әйтик, Петербург мәчете имамы Гатаулла Баязитовны шулар*рәтенә кертергә мөмкин. Ул сәнгатьне порнография һәм әхлак бозаулары дип кенә күргән. Аңа капма-каршы рәвештә музыкада гына түгел, сынлы сәнгатьтә дә бернинди гөнаһлы нәрсә юк дип исбатлаучы Ш. Мәрҗани кебекләр дә булган.

Шуның өстенә татарлар арасында шигъри иҗатның, графика, милли нәкышнең, төзелеш сәнгатенең, нәфислеге белән аерылып торган ювелир әйберләр ясауның, тире һәм тукымаларга чигү сәнгатенең дәвамлы үсеше тарихын онытырга хакыбыз юк. Боларның һәммәсе дә халыкның эстетик зәвыгына йогынты ясый һәм мәгълүм эстетик критерийлар булдыруга этәрергә тиеш. Алар язма истәлекләрдә чагылыш таба һәм үзенең тикшеренүчесен көтә. Татар мәгърифәтчеләренең иҗаты белән танышу, мәсәлән, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм башкаларның эстетик идеал, аның этик идеал белән нисбәте, сәнгатьтәге форма һәм эчтәлек, сәнгатьнең җәмгыять тормышындагы урынына, әһәмиятенә кагылышлы мәсьәләләрне күтәреп чыгулары турында сөйли. Татар культурасы тарихын тирәнтенрәк өйрәнү мондый мисалларны безгә күп бирәчәк.

Татар иҗтимагый фикере тарихы проблемаларын өйрәнү бурычлары турында сөйләгәндә җәдитчелек мәсьәләсен читләтеп үтү дә хилаф булыр. Бу хәрәкәт турында бездә бик күп каршылыклы фикерләр яшәп килә. Кайбер тикшеренүчеләр җәдитчелекне феодаль тәртипләргә һәм реакцион мөселманнарга каршы юнәлдерелгән алдынгы идеология дип саныйлар, башкалары аны реакцион көч сыйфатында күз алларына китерәләр һәм тулысынча революциягә чит нәрсә дигән тасвирлама бирәләр. Җәдитчелек турында кабынган бәхәсләрдә проблеманың асылын тирән белү урынына схемага бирелү йогынтысы сизелә. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башының кискен идея көрәшендә татар халкы тормышында шактый әһәмиятле, уңай роль уйнаган әлеге хәрәкәткә чын фәнни, марксистик-ленинчыл бәя бирү өчен безгә шушы чор әдәбиятын, газета-журналлар, китаплар, архивларын, мәктәпләр һәм татар интеллигенциясенең аерым вәкилләре эшчәнлеген, татарларның культура тормышын җентекләп өйрәнергә кирәк.

Үткән заман фикер ияләре һәм культура эшлеклеләренең әсәрләрен бастырып чыгару җәмәгатьчелек фикере тарихын өйрәнүдә гаять зур таяныч булачак. Шуңа күрә элекке прогрессив фикер ияләре мирасын нәшер итәргә әзерләү һәм дөньяга чыгару кичектергесез бурыч сыйфатында кала. Дөрес, бездә бу юнәлештә мәгълүм тәҗ-

рибә бар. 1975—1976 елларда, тууына 150 ел тулу уңае белән, К. Насыйриның ике томлык Сайланма әсәрләренең тулыландырылган басмасы, аннары рус телендә бер томлыгы чыгарылды. Габдулла Тукай Әсәрләренең дүрт томлык яңа басмасын нәшер итү тәгалләнде. Галимҗан Ибраһимовның сигез томлык әсәрләренең бишенчесе чыкты. Г. Камалның тууына 100 ел тулу көнендә китап укучылар өч томлыкның инде икенчесен алдылар. М. Гафури Сайланма әсәрләренең дүрт томлыгы әзерләнә.

Биредә дә хәл ителмәгән проблемалар күп. Әйтик, К. Насыйри әсәрләренә аның мирасының бик кечкенә өлеше генә керде. Мәсәлән, аның энциклопедик «Фәвакиһел-җөләсә» дигән хезмәтенең гакыл турындагы бүлекләрендә аның дөньяга карашлары ачыла. Заман укучысына бу җиткерелми калды. Ш. Мәрҗани мирасын бастырып чыгаруга әзерләү юнәлешендә дә бары тик беренче адымнар гына ясалып килә. Кызганычка каршы, прогрессив иҗтимагый фикернең башка кайбер вәкилләренә карата хәтта болар да эшләнми әле. Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм башка культура эшлеклеләренең тулы, Академик басмаларын әзерләү турында да уйлый, уйлый гына түгел, эшлекле адымнар башларга бик вакыт.

Кыскасы, безнең алда бу өлкәдә зур, хәерхаһлы бурычлар торуы шактый ачык күренәдер.

Болар белән беррәттән, аеруча күренекле фикер ияләренең фәнни биографияләрен әзерләү һәм бастырып чыгаруны да кайгыртырга кирәк. Без К. Насыйри турында барысыннан да күбрәк беләбез. Тик татар иҗтимагый фикеренең шушы иң зур вәкиленең дә фәнни биографиясе язылмаган әле. Башкаларныкын әйткән дә юк. Күптән түгел укучылар игътибарына «Күренекле кешеләр тормышы» сериясендә чыккан «Габдулла Тукай» китабы (татар һәм рус телләрендә) тәкъдим ителде. Укучы башка язучылар һәм культура эшлеклеләре турында да шундый рухтагы һәм рәвештәге китаплар көтә. Үзәктә булмаса, һич югы, үзебездә.

Бу яктан Казанда, гомумән Татарстанда ниләр эшләнгән? Татарстаннан иҗтимагый фәлсәфи фикер тарихы турында сүз алып барганда, бу шулай ук үзәк мәсьәлә сыйфатында алга килеп баса. Чөнки Казан XVIII гасыр ахырыннан башлап гомумән Россия күләмендә зур иҗтимагый-политик, шулай ук культура үзәкләренең берсе булып яши. XIX гасырда биредә идея-политик дәртләр чаткысы кабына, фәнни һәм фәлсәфи проблемалар турында бәхәсләр бара, дөньяга фәлсәфи карашның әһәмиятле проблемалары күтәрелә. Казан университеты фән һәм алдынгы иҗтимагый-политик фикер үзәге була. Биредә Н. И. Лобачевский һәм А. М. Бутлеров кебек фәлсәфи фикер үсешенә гаять зур йогынты ясаган күренекле галимнәр эшләгән. Университет профессорлары А. П. Щапов, П. Ф. Лесгафт һ. б. азатлык идеяләре тарату белән шөгыльләнгән. Бу мирас та үз тикшеренүчеләрен көтә. Ул гомумроссия идея көрәшендә һәм гомумроссия иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи фикер тарихын эшкәртүдә Казанның тоткан урынын һәм әһәмиятен ачыклау өчен генә түгел, татарлар һәм шушы төбәктәге башка халыклар арасында иҗтимагый фикер үсешенең барлык якларын һәм үзенчәлекләрен ачыклау өчен дә әһәмиятле.

Октябрь революциясеннән соң Татарстанда, барыннан да бигрәк, Казанда механик төстә, вульгар тенденцияләргә һәм ачыктан-ачык идеалистик булган карашларга каршы барган кискен көрәшне генә алыйк. Аны һәрьяклап өйрәнми торып, без татар иҗтимагый фикерендәге тамырдан үзгәрешләрне һәм Татарстанда совет иҗтимагый фикеренең ныгып урнашуы процессы дәвамын тиешле тирәнлектә яктырта алмабыз.

Татар культурасын һәм иҗтимагый фикеренә алдынгы рус культурасы, фәннифәлсәфи һәм иҗтимагый фикере шифалы тәэсир итә. Моңа басым ясап, Г. Ибраһимов, татарларның Россиягә башка халыклардан элегрәк кушылуы, руслар чолганышында һәм аларның үзәк шәһәрләренә якын яшәүләре, шуңа күрә, самодержавиенең кара политикасына, тел һәм гореф-гадәтләрдәге үзгәрешләргә карамастан, татарлар һәм руслар тормышында күп охшашлыклар барлыкка килүе турында яза. («Биш ел эчендә» җыентыгы. Казан, 1925, 107—108 б. б.) XIX гасырда һәм XX гасыр башында — илдә демократик һәм азатлык хәрәкәте көчәйгән чорда алдынгы рус культурасының татар культурасына тәэсире аеруча арта. XX гасыр башында татар иҗтимагый фикеренә рус һәм бөтендөнья фәнни-фәлсәфи фикеренең иң зур казанышы булган ленинизм гаять көчле йогынты ясый башлый. Бу чорда интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләре дә тарала. Культураларның бер-берсенә, барыннан да элек, алдынгы рус культурасының татар культурасына уңай йогынтысы һаман әле тирәнтен өйрәнүчене көтә. Дөрес, соңгы вакытта бу нисбәттә дә кызыклы тикшеренүләр күренә башлады. С. М. Михайлованың телгә алынган «Идел буе татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең формалашуы һәм үсүе» дигән хезмәте шулар арасына керә. 1978 елда «Н. Г. Чернышевский һәм татар иҗтимагый фикере» дигән китап басылып чыкты. Мондый тикшеренүләрне дәвам иттерергә, архив материалларын өйрәнергә, газета-журналларны һәм башка чыганакларны җентекләп карарга һәм гомумиләштерергә кирәк.

Кыска бу күзәтүдә дә Татарстандагы иҗтимагый фикер тарихын тикшерену мәсьәләләренең шактый катлаулы һәм киң характерда икәнлеген күрдек. Кирәкле һәм игътибарга лаек эш күп әле. Чөнки тарихи материалларны яхшы белү хәзерге заманның идеологик проблемаларын, шул исәптән, киләчәк коммунистик җәмгыять кешесенең рухи дөньясын формалаштыру бурычларын тормышка ашы-

руга булышлык итәчәк. Аларда җәмгыять членнарында югары әхлак-политик һәм гражданлык сыйфатлары тәрбияләү максатларына файдаланырлык бай материал табарга мөмкин. Ватан тарихы, дип язды «Правда» газетасы 1975 елның 17 октябрендә басылган баш мәкаләсендә, бик күп киләчәк буыннар өчен патриотизм һәм интернационализмның рухландыргыч үрнәге булырлык һәм үрнәк булып калачак мисалларга бай. Рухи культура тарихының аерылгысыз өлеше булган үткән заман фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик фикере бу мәсьәләләрне хәл итү өчен кыйммәтле җирлек бирә.

Иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын тикшеренүнең актуальлеге турында сүз алып барганда, без шулай ук үткән заман идея мирасы мәсьәләсендә кискен көрәш барганын да онытмаска тиешбез. Марксист-ленинчылар алардагы барлык алдынгы һәм демократик юнәлешләрне үзләренең көрәш, дәлилләү коралы итеп алсалар, империалистик буржуазия идеологлары үткән заман фикер ияләренең йомшак якларын өскә күтәрәләр, аларның фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик мәсьәләләрдәге тоткан юнәлешләрен бозып күрсәтәләр. Идея мирасындагы иң кыйммәтле һәм тормышчан байлыкны безнең хәзерге заман империалистик буржуазиясеннән тартартырырга хакыбыз юк. Бу мирас — корал безнең, аны һәрьяклап без өйрәнергә һәм эшкәртергә тиешбез.

Тагын бер нәрсәне басым ясап күрсәтеп үтик. Иҗтимагый фикер тарихы проблемаларын тирәнтен өйрәнү милли хәрәкәтләрне дөрес бәяләү өчен дә зур әһәмияткә ия. Әйтик, буржуаз француз тарихчылары А. Беннигсен һәм К. Келкеже татар милли хәрәкәтен Оренбург диния нәзараты, аның мөфтие һәм указлы имамнар эшчәнлеге белән бәйлиләр. Бу һич тә болай түгел. Татар милли хәрәкәтенең башы Пугачев восстаниесе, татар һәм рус хезмәт ияләренең башка тугандаш халыклар белән уртак дошманга — алпавыт-крепостниклар строена каршы бердәм көрәше белән бәйләнгән. Нәкъ менә крестьяннар сугышында катнашучылар арасында, социаль азатлыкка омтылу таләпләре белән берләттән, милли азатлык таләпләре дә формалаша. Бу милли азатлыкка һәм тигезлеккә омтылу таләпләре татар мәгърифәтчелегендә идея-теоретик гәүдәләнеш таба.

Татар халкы — илебезнең күп санлы халыкларыннан берсе. Аның рухи культурасы үсешенең бай һәм күп гасырлы тарихы бар, һәм бу мираска без көндәлек җитди, көрәшүчән рухлы игътибар белән карарга тиешбез. Чөнки ул мирас — Татарстан АССР төзелүнең иҗтимагый-политик асылын, 60 ел буе үткән данлы юлыбызның, тыныч тормышыбызның җирлеген әзерләүгә күп өлеш кертте. Ул үткәнебез белән киләчәгебезнең дәвамлылыгын тоташтыручы көчләрнең берсе.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Калмык мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Кечкенә таш белән бәреп зур ташларны ваталар.*
*Чатаннар иләндә чакта бер аякка аксап йөр.*
*Кара төндә юл озын, саран затка дус ерак.*

**Даргин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Су савыты ватылса да, су янында ватылыр.*
*Су агып уза, таш ятып кала.*
*Куркусыз башлау — үзе бер җиңү.*
*Ялгыз агачны җил тизрәк ега.*
*Канат эзләргә дип китеп, койрыгын өздереп кайткан.*
*Сикерүченең аягын «сикер!» дигән сындыра.*



# МӘСКӘҮ. 80 нче ЕЛ ОЛИМПИАДАСЫ

## ЛЕНИН һӘМ ФИЗИК КУЛЬТУРА

Илебез һәм социалистик илләр тарихында беренче тапкыр Мәскәүдә 80 нче ел Олимпия уеннары үткәрелә. Совет Ватаны спорттагы казанышлары белән хаклы горурлана. Көчле тән, чыныккан рух — сәламәтлек бәхете. Ул бәхет совет властеның беренче көннәреннән үк өстәлә-арта барды.

Бу эшнең башы Ленин исеме белән бәйле. Даһи, галим, Коммунистлар партиясенә нигез салучы, дөньядагы беренче социалистик дәүләтне төзүче буларак, ул физик культура мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә, К. Маркс һәм Ф. Энгельсның шәхесне һәрьяклап, гармонияле тәрбияләү турындагы карашларын үстерә. Ленин физик тәрбияне гомуми тәрбиянең аерылгысыз бер өлеше итеп саный. «Карл Маркс» дигән мәкаләсендә, Марксның гакыл белемен физик тәрбия һәм хезмәт җитештерүчәнлеге белән кушуны хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү чарасы итеп кенә түгел, шулай ук һәрьяклап үскән шәхес тәрбияләүнең нәтиҗәле чарасы итеп тә карарга кирәклеге турындагы фикерен аерып алып күрсәтә.

В. И. Ленин физик тәрбияне эшчеләр сыйныфының революцион отрядларына сугышчан әзерлек бирүнең бер ягы итеп тә карый. Маркс белән Энгельс кебек үк, ул революционерларның үзләренең физик ныклыгына җитди игътибар иткән. Хатларында яки әңгәмәләр вакытында ул революцион көрәштәшләренә сәламәтлекләрен ныгытырга, организмнарын чыныктырырга, катгый режим сакларга, көн дә гимнастика белән шөгыльләнергә, җәяү яисә чаңгыда йөрергә, тимераякта шуарга, йөзәргә тәкъдим итә. 1898 елны әнкәсенә язган хатында кулга алынган энесе Дмитрий турында болай дип сорый: беренчедән, ул диета саклыймы? Минемчә, анда бу бик кирәк. Икенчедән, гимнастика белән шөгыльләнәме? Владимир Ильич энесенә бернichә гимнастик күнегү тәкъдим итә.

Ә 1901 елны төрмәдәге кече сеңелесе М. И. Ульяновага: син ничек яшисең, дөрес режим урнаштыргансыңдыр дип ышанам, ялгызың утырганда бу бик мөһим, дип яза, китап укуны гимнастика белән аралаштырырга куша: иң әһәмиятлесе, көн дә үзеңне гимнастика ясарга мәҗбүр ит, дигән киңәш бирә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң фәнни коммунизмга нигез салучыларның шәхесне рухи һәм физик яктан гармонияле үстерү турындагы идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлекләре булдырылды. Ленин илдә физик культура үсешен хезмәт иямләренә коммунистик тәрбия бирү бурычлары белән тыгыз бәйләде. Ул, безнең хезмәтчел илебезгә физик яктан көчле ихтыярлы, ир йөрәкле, дәртле һәм чыдам кешеләрнең миллионлы армиясе кирәк, диде, киләчәк аларныкы булачагын, кешелек җәмгыяте нигезләрен төзү хокукы шундый кешеләр кулы белән яуланачагын күрсәтте.

В. И. Ленин яшьләрне коммунистик әхлак нигезендә һәрьяклап тәрбияләү, белемле итү һәм чыныктыру турында аеруча зур кайгыртучанлык күрсәтте, киләчәктә

коммунизм өчен көрәшергә туры киләчәген, яшьләрнең бу сугышларны нык сәламәт хәлдә, корыч нерв һәм көчле мускуллар белән каршыларга тиешлеген әйтеп калдырды, яшьләрнең физик һәм акыл сәләтләренең тәңгәл үсешен зарури дип саналы.

Совет физик культурасын формалаштыру һәм үстерү нигезе Ленин идеяләре белән сугарылган. Совет хөкүмәтенең физик культура өлкәсендәге беренче чаралары В. И. Ленинның турыдан-туры катнашы белән үткәрелде. Ул коммунистик идеология нигезендә тормышка ашырылган культура революциясенең аерылгысыз өлеше булды.

В. И. Ленин кул куйган декретлар, аның шәхси күрсәтмәләре белән илебездә физкультура эшен оештыру һәм аңа җитәкчелек итүнең мөһим мәсьәләләре хәл ителде: җитәкче органнар төзелде, яңа, совет белгечләре әзерләнде, матди база булдырылды, мәгарифкә физкультура кертелде, Кызыл Армия сугышчыларын һәм армиянең резервларын әзерләүдә физкультура һәм спорт кулланыла башлады.

Гражданнар сугышы елларында бу эшне оештыру 1918 елның 8 апрелендә В. И. Ленин кул куйган декрет нигезендә төзелгән хәрби эш комиссариатларга (военкоматларга) йөкләнә. Декретта күрсәтелгәнчә, хәрби комиссариатлар илдәге физкультура хәрәкәтенә җитәкчелек итүче беренче совет органнары вазифасын үти. Соңгарак, 1920 елда, В. И. Ленин мәгъкуль күргән Югары Физкультура Советы төзелә.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының 1918 ел, 22 апрель декреты белән хезмәт ияләрен гомуми хәрби эшкә өйрәтү (всевообуч) кертелә. Кыр гимнастикасы, штык сугышы һәм спортның байтак төрләре (чаңгы, ату, йөзү, җиңел атлетика) хәрби өйрәнүләрнең төп өлешен тәшкил итә. В. И. Ленин хәрби өйрәтүләрне, физик күнегүләрне камилләштерүгә һәм булачак сугышчыларны коммунистик идеяләргә бирелгәнлек рухында тәрбияләүгә нык дикъкать итә.

Мәскәүдә 1919 ел апрелендә физик культура һәм призывка хәзерлекнең Бөтенроссия съезды үткәрелә. Әлеге киңәшмә Ленин һәм Коммунистлар партиясе күрсәтмәләрен җитәкче кулланма итеп алып, совет физик культурасы хәрәкәтенең үсеш юлларын, зур бурычлар билгеләде.

Хәрби өйрәнүләрнең берьеллыгы көнендә — 1919 елның 25 маенда — сугышчылар һәм физкультурачылар парады була. Парадны В. И. Ленин кабул итә һәм үз чыгышында хезмәт ияләре белән сугышчыларның хәрби-физик әзерлектә ирешкән уңышларына югары бәя бирә.

Ә шушы елның сентябрендә В. И. Ленин Эшче-Крестьян Оборона Советының «Хезмәт ияләрен гомуми хәрби укытуны оештыру турында»гы карарына кул куя. Анда Кызыл Армиянең сугышчан резервларын әзерләүне тагын да камилләштерү карала. Ул илдә яңа патриотик күтәренкелек китереп чыгарды. 1919 елның декабрендә Казанда Беренче губерна спорт конференциясе үткәрелә, анда Совет хөкүмәтенең бу карары тулысынча яхшы дип табыла.

Хезмәт ияләренә хәрби әзерлек бирү белән бергә, В. И. Ленин үсеп килүче яшь буынны һәрьяклап тәрбияләүгә нык игътибар итте. Ул Мәгариф халык комиссарына гомуми белем мәктәпләрендәге физик тәрбия дәресләрен мәҗбүри итү турында күрсәтмә бирә. Шулай итеп, яшь буынны физик тәрбияләү аңа белем бирү һәм коммунистик әхлак рухында тәрбияләүнең аерылгысыз өлешенә әверелде. Бер үк вакытта партия оешмалары һәм халык мәгарифе органнары җитәкчелегендә мәктәпләр эшен үзгәртеп корулар башланды.

Казан губернасында да эш алып барылды. 1919 елның гыйнварында Мамадыш өязе укучы-мөселманнары үзләренең III съездында В. И. Ленинга хат белән мөрәҗәгать итәләр. «Без, Казан губернасының Мамадыш өязе укучы-мөселманнары, — дип яза делегатлар, — тәрбия һәм белем бирүдәге идеяләребезне тормышка ашыру өчен бөтен тырышлыгын куйган Совет власте политикасының дөреслеген таныйбыз. Сезне кайнар котлыйбыз, яшь революционерлар хәзерләүне үзебезнең бурыч итеп саныйбыз. Әгәр капиталистлар белән аларның ялчылары безнең фронтны өзәргә теләсә һәм безнең революциягә җиңелү белән янасалар, без, укучылар, кулга корал алып, явыз дошманга каршы фронтка китәрбез һәм актык тамчы каныбызга кадәр аның белән көрәшергә тантаналы вәгъдә бирәбез. Яшәсен иптәш Ленин!» [1]

[1] Товарищу Ленину. М. Политиздат, 1969. 109 бит.

Совет кешеләренең яңа буыны — яшьләр — Бөек Ватан сугышы фронтларында батырларча сугыштылар һәм мәкерле дошманны җиңүгә ирештеләр.

В. И. Ленин физик культура белгечләрен хәзерләү турында күп кайгыртты. Совет хөкүмәте карары белән 1918 елның җәеннән физкультура уку йортлары ачыла башлый. Гражданнар сугышы елларында 20 дән артык курс яки мәктәп, ә Петроград белән Мәскәүдә физкультура институтлары ачыла, Халык Комиссарлары Советының 1920 елның 1 декабрендә В. И. Ленин кул куйган декрет нигезендә Мәскәү үзәк физик культура институты югары гыйльми-уку йорты итела.

Ленинның шәхси күрсәтмәсе белән җирле партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары катнашында 1927 елның язына илебездә 2000 гә якын спорт мәйданчыгы төзелә. Ленин бу вакыйганы культура фронтындагы казанышларның бер өлеше буларак бәяли.

Шулай итеп, Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәтенең кайгыртучанлыгы В. И. Ленинның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, Октябрь революциясе җиңүенең беренче көннәрендә үк физик культура хезмәт ияләренә тәрбия һәм белем бирү системасына киң кертелә, шулай ук Кызыл Армиянең сугышчан куәтен ныгыту максатларында файдаланыла.

Хезмәт ияләрен һәрьяклап гармонияле үстерү һәм физик тәрбияләү турындагы Ленин идеяләре КПСС Программасында, партия съездлары һәм физик культура мәсьәләләренә карата кабул ителгән карарларда тагын да баетылды. «Кече яшьтән үк физик һәм рухи көчләре гармонияле, физик яктан нык булган яшь буын тәрбияләүне партия мөһим бурычларыннан берсе дип саный»[1] диелә Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Программасында.

Нык үскән социализм физик культура өлкәсендә Ленин билгеләгән бурычларны һәм КПССның программа-положениеләрен тормышка ашыру өчен зур мөмкинлекләр бирә. СССР Конституциясе физик культура, спорт һәм туризмны, хезмәт ияләренең ялын оештыру, сәламәтлеген ныгыту чаралары буларак, закон белән беркетте.

Совет физкультура хәрәкәте бөтен халык хәрәкәтенә әверелә, спорт киң мәйданга чыга. Ватаныбыз башкаласы Мәскәүнең XXII Олимпиада уеннарын үткәрү урыны итеп сайлануы дөнья җәмәгатьчелегенең Советлар илендәге физкультура һәм спортны үстерүнең гаять зур казанышларын тануы булды. Совет кешеләре 1980 ел Олимпиадасы тиешле дәрәҗәдә узсын, дуслык һәм тынычлык идеяләренең яңа импульсын тудырсын өчен бөтенесен дә эшләделәр. Бу илебездә физик культура һәм спортның чәчәк атуы, үлемсез Ленин идеяләренең тормышка ашуы турында сөйли.

**ӘНВӘР БУЛАТОВ,**
**педагогия фәннәре кандидаты.**

[1] КПСС программасы. Казан, 1965, 115 б.

# БАТЫР ЯКТАШЛАРЫБЫЗ

1976 елның беренче августы — Монреаль вакыты белән 21 сәгать 45 минут — Канада башкаласында Олимпиада-76 уты сүнү мизгеленнән башлап спорт дөньясы үз сәгатен Мәскәү вакытына күчерде. Монреаль Уеннар эстафетасын Советлар Союзының башкаласына тапшырды. Хәзер Олимпиада уты илебезнең иң зур спорт аренасы булган В. И. Ленин исемендәге Үзәк стадионның иң югары ноктасына куелган чынаякка юл тота. Ул борынгы Грециянең Олимп тавында кояш нурларыннан көчле линзалар ярдәмендә кабызылды. Йөгерешчеләр эстафетасы, ялкынланып янучы факелны Болгария һәм Румыния аша Молдавия, Украина һәм РСФСР территорияләреннән 5 мең чакрымга якын юл үтеп, 18 июльдә Мәскәүгә китереп җиткерә. Олимпия уты шул чынаякта 3 августка — Уеннар тәмамланганчы халыкара туганлык, төрле илләр, төрле милләт кешеләре арасында тынычлык һәм дуслык мәгънәсе сыйфатында балкып торачак.

Дүрт ел буена Мәскәү Олимпиада мәшәкатьләре белән яшәде, олимпиячеләргә ярышу өчен өр-яңа корылмалар салынды, аларның көнкүреше, ялы, күнегүләре турында кайгырттылар. Башкалабызда 78 яңа спорт комплексы салынды һәм элеккеләре үзгәртеп корылды.

Мәскәүдә спорт үзәкләренең мондый кызу рәвештә һәм киң җирлектә төзелгәнен тарих белми-хәтерләми әле. Тынычлык проспектындагы түбәсе ябылган стадион һәм йөзү бассейны, Крылатскоедагы велосипедчы трегы, Лужникидагы универсаль спорт залы кебек искиткеч корылмалар Җир шарында беренче тапкыр төзелде. Биналарның архитектура сурәте дә бик үзенчәлекле. Спортның 12 төреннән — теннис, гимнастика, волейбол, баскетбол, көрәш, бокс һәм башкалардан ярышлар үткәреләчәк бу залга өстән карасаң, ул гаять зур көнбагыш табагын хәтерләтер. Төсе дә төрледән төрле. Ярышларның үзенчәлегеннән чыгып, зал трибуналарына мең ярымнан 4 меңгә якын тамашачы җыела ала.

Түбәсе ябык стадионга күз салыйк. Монысы озынча түгәрәк рәвешендә өскә күтәртелеп эшләнгән. Озынлыгы — 224, киңлеге 184 метр. Анда спорт чыгышларын берьюлы 45 мең кеше тамаша кыла ала. Мондый үзенчәлекле корылма әлегә дөньяның бер генә илендә дә юк!

Йөзү бассейнының түбәсе ияргә охшатып ябылган. Аның ике залы бар. Берсендә йөзүчеләр ярыша, икенчесе — трамплиннан суга сикерүчеләр һәм ватерполо уйнаучылар өчен. Олимпиада таләпләре нигезендә һәр корылмада мунча, медицина бүлмәләре булдырылган. Велотрекның зурлыгын күз алдына китерү өчен аның түбәсе астына ике футбол кыры сыя алуын әйтү җитә. Трекның узышу юллары — 333,3 метр. Аларга Себер наратларыннан ярылган такта идән җәелгән.

Измайловодагы Олимпия авылы үзе ни тора! Биредә 30 катлы кунак йорты салынды. Ресторан-кафелары, кино-концерт заллары да үзендә. Мондагы кунак йортары комплексында 10 мең кеше яши.

Останкинодагы Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Бөтенсоюз телевидениесе үзәге дә үсеп, яшәреп, матураеп китте. Спорт ярышларын трансляцияләү өчен Олимпиада телерадио ансамбле барлыкка килде. Чит илләр өчен берьюлы 20 урында төсле телевидение һәм йөзгә якын радиотапшыру алып барылачак.

78 корылманың барысы турында да сөйләп бетерү мөмкин түгел. Аларның һәркайсы башкалабызны бизәде, яшәртеп җибәрде, аның архитектура йөзен матурлады.

80 нче елгы Олимпиадада катнашучыларның һәм кунакларның туклануын хәл иткәндә күп кенә катлаулы бурычларны хәл итәргә туры килде. Планетабызның 5 континентыннан килгән кешеләрнең ашау-эчү үзенчәлекләрен өйрәнергә, аларны үзенчә канәгатьләндерергә кирәк иде. Олимпия менюсын галимнәр һәм врачлар, тренерлар һәм спортчылар, атаклы аш-су осталары төзеде. Аларның күмәк иҗаты белән азык-төлекнең 400 төре расланды. Ә гарнирлар 100 дән артык. Безнең илебез кухнясыннан тыш, башка күп кенә халыкларның аш-су пешерү үзенчәлекләре дә өйрәнелде. Ярышлар барганда һәр спортчы көн саен уртача 5 мең килокалорий



*Универсаль спорт залының тышкы күренеше.*

кадәр энергия сарыф итә. Аны тулыландыру өчен Олимпия авылы ашханәләрендә һәр аш-суның күпме калорий энергия бирүен күрсәткән махсус язмалар эленгән. Бу бигрәк тә боксчылар, штангачылар һәм көрәшчеләр өчен кирәк. Чөнки аларга беренче көнгә авырлыкларын арттырырга да, киметергә дә ярамый: үлчәүләре үзгәрсә, икенче категория атлетлары сафына күчерәләр. Спортчы үз авырлыгын хәтта 100 граммга гына арттырган очракта да медальдән колак кагуы мөмкин.

XXII Җәйге уеннарны оештыру комитетында җиңүчеләрне инде хәзер медальләр көтә. Катнашучылар һәм кунаклар өчен истәлек медальләре дә булдырылды. Аларның үрнәкләре моннан ике ел элек Афинада Халыкара Олимпия комитетының 80 нче сессиясендә расланган иде. Яшь совет скульпторы Илья Постол берничә медаль ясады. Советлар Союзы һәм Америка Кушма Штатлары космонавтларына, ССР Союзының Зур театрына 200 ел тулуга багышланганнары һәм чемпионнарга тапшырыла торганнары — аның иҗаты. Олимпия хартиясе законнарында язылганча, аларның калынлыгы — 3, диаметры — 60 миллиметр. Кырларына призерларга тапшырыла торган спорт төре рәсеме төшерелгән. Өске ягына, башка Олимпиадаларныкы кебек, Уеннарның гадәттәге эмблемасы ясалган. Икенче ягы бүгенге көн таләпләре рухында: стадионның йөгерү юллары, Олимпия уты яна торган чынаяк һәм 80 нче ел Уеннарының эмблемасы. Мәскәүнең икенче бер танылган скульпторы Ангелина Леонова — Уеннарда катнашучылар һәм рәсми кешеләрнең барчасына бүләк ителә торган медальләрне ясаучы. Алтын төсендәге бронзадан коелган бу бүләкләрдә Кызыл мәйдан сурәтләнгән, «XXII Олимпиада. Мәскәү. 1980» дип язылган. Ангелина Леонованың истәлек медальләре Краков, Варшава, Венеция, Будапешт, Росток, Дюссельдорфта булган халыкара күргәзмәләргә куелып югары бәя алдылар.

Менә шушы бүләкләр өчен көрәш аренасына чыгучы атлетлар башта берберләре белән кул кысышалар. Бу — гадәти бер әдәплелек галәмәте генә түгел, бәлки көндәшләрнең бер-берсенә иң изге хисләр, яхшы уен хисләре белдерү билгесе дә. Шуңа күрә башкалабыз Мәскәүдә булачак 80 нче ел Олимпиадасының төп өндәве итеп «Спорт — тынычлык илчесе» дигән канатлы сүзләр алынган. Алар Уеннарга 130 илдән килгән 12 меңләп спортчыны, меңнән артык хөрмәтле кунакны, 3500 судьяны, Халыкара спорт конференцияләренең 3 мең делегатын һәм чит дәүләтләрнең 7 меңнән артык журналистын татулыкка, дуслыкка, үзара тыныч яшәүгә өндәү булып яңгырый һәм Олимпиаданың килеп чыгу тарихына туры килә.

Борынгы легендаларда Уеннарның килеп чыгышы турында болай дип сөйләнә:

Урта диңгез буйларында вак-вак дәүләтләргә бүленеп яшәгән греклар борын-борыннан җир бүлү, мал-мөлкәт туплау өчен һәрвакыт бер-берсе белән сугышып торганнар. Кан койгыч бу бәрелешләрдә Элита дәүләте зур зыян күргән. Бервакыт, Спарта дәүләте Элитаны басып алырга гына торганда, җиңелүчеләрнең патшасы Ифит күршеләренә китә. Ул көчле дәүләт булган Спартаның патшасы Ликург белән очраша. Ифит, курәсең, әйбәт дипломат булган: күршесенә кылычларын һәм пычакларын читкә ташлап, тынычлык турында солых төзергә һәм бу вакыйга хөрмәтенә аллалар күңеленә хуш килерлек уеннар оештырырга тәкъдим ясаган. Көчне корал һәм кан белән түгел, бәлки кешеләрнең көче һәм җитезлеге белән күрсәтергә кирәк. Ликург, Ифит фикере белән килешеп, Элитаны нейтраль дәүләт дип игълан иткән. Ике патша арасындагы килешү тексты бакыр тәлинкәгә чокып язып куелган. Грекларның башка дәүләтләре дә моны таныган. Ифит, сугышларсыз яшәргә омтылуны мәңгеләштерергә теләп, үз дәүләтендәге Олимпия дигән урында «Атлетлар уены» (грек сүзе атлетикосның мәгънәсе көрәш дигәнне аңлата) оештырып җибәргән. Олимпия уеннарының исеме менә шушыннан килеп чыккан. Бу безнең эрага кадәр 776 нчы елда була. Греклар җиңүчеләрнең исемнәрен Алфей елгасы буендагы мәрмәр колонналарга чокып язып барганнар. Анда беренче җиңүченең дә исеме билгеле. Ул — Элита дәүләтенең пешекчесе Корэб атлы кеше.

Шуннан соң безнең эраның 394 нче елына кадәр Олимпиадалар аллалар һәм легендар батырлар хөрмәтенә дүрт елга бер мәртәбә үткәрелеп килгән. Халык Олимпия бәйрәмен түземсезлек белән көтеп ала торган була. Иртә таңнан, кояш җирне яктырта башлауга, кешеләр, үзләрен чәчәкләр һәм агач яфраклары белән бизәп, Олимпиягә агылган. Алар иң элек ярышларда катнашу бәхетенә ирешкән атлетларның исемлеге белән танышканнар. Моңа һәр кеше лаек була алмаган. Ярышларның кагыйдәсе бик гадел һәм катгый: караклар, алдакчылар, җинаятьчеләргә анда катнашырга рөхсәт ителмәгән. Ярышучылар һәм судьялар, аллаларның алласы Зевска хөрмәтләшмәскә ант иткәннән соң, кичен кешеләр сәнгать бәйрәмендә күңел ачкан, иртәгесен ярышлар башланган.

Күрәсез, Уеннар, беренче көннәреннән үк, гаделлек, намуслылык, дуслык фикерләрен алга сөргән, кешеләрне татулыкка өндәгән. Олимпиягә юл тотучыларны берәү дә тоткарламаган, аларга кул күтәрмәгән. 103 нче Олимпиадага баручы тамашачыларны, мәсәлән, аркадиецлар тотып ала. Греклар, моңа үч итеп, аларны озак вакытка Уеннарда катнашудан мәхрүм иткәннәр.

Уеннар баштарак бер көн барган. Аннары биш көнгә, соңрак ай буена сузылган һәм урак өсте тәмамланып, йөзем җимеше җыю вакыты килеп җиткәндә үткәрелгән. Беренче уеннарның 13 е Зевсның 600 аяк табанына тигез булган бер стадиягә (190 метр 27 сантиметр) йөгерүдән торган. Бу араны Геракл үзе үлчәп биргән.

Соңга таба программа байый барган. Ераграк араларга йөгерүләр, сикерү, диск һәм сөңге ыргыту, көрәш, йодрык сугышы, җигүле атларда узышулар, панкратион (кул белән теләсә ничек сугып, аяк белән тибеп һәм башка алымнар кулланып көрәшү. Аңарда тик бармак белән күзгә төртү генә тыелган) кертелгән.

Эллиннарның Атлетлар уены башка илләргә, төрле халыкларга күчкән. Этруслар, римлылар да шундый Уеннар үткәрә башлаганнар. Римда алар цирк тамашасына әйләнеп киткән, гладиаторларның үлгәнче сугышыннан соң гына тәмамланган. Безнең эраның 394 нче елында Рим императоры Федосий I аларны тыйган. Олимпиядәге корылмалар бер генә ел төзек хәлдә сакланган: 395 нче елда Алфей елгасы буена византиялеләр һәм готлар килеп чыккач, кан коюлы сугышта аларны ваталар. Йөз елдан күбрәк вакыт үткәч, көчле ике җир тетрәүдән алар тәмам җимерелә. Алфей һәм Кладей елгалары ташыганда ком астында кала. Мең елдан артык Олимпия белән кызыксынучы булмый. 1824 елда инглиз археологы лорд Станхов казу эшләре алып бара һәм борынгы Олимпиянең планын сыза.

1502 ел үткәч, француз педагогы барон Пьер де Кубэртен дөнья күләмендә шундый спорт Уеннарын үткәрү мәсьәләсен күтәреп чыга һәм ул Халыкара олимпия комитетының беренче президенты итеп сайлана. Аның тырышлыгы белән 1896 елда Афинада хәзерге заманның I Олимпия уеннары үткәрелә. Уеннарның эмблемасы — бер-беренә үрелгән биш боҗра сурәте дә Кубэртен исеме белән бәйле. Ул Олимпия хәрәкәтенә кушылган биш континентның бердәмлеген һәм дуслыгын күрсәтә.



*Крылатское велотрегында ярышлар бара.*

Зәңгәр бөҗра — Европа, сарысы — Азия, карасы — Африка, яшеле — Австралия, кызылы — Америка символы. Беренче Олимпиададан соң аның флагы икешәр тапкыр Париж һәм Лондон, берәр мәртәбә Сент-Луис, Антверпен, Стокгольм, Амстердам, Лос-Анджелос, Берлин, Хельсинки, Мельбурн, Рим, Токио, Мехико, Мюнхен, Монреаль шәһәрләре күгендә җилфердәде. Җәйге Олимпиаданың алтынчысы — Беренче, XII һәм XIII Уеннар Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә үткәрелми калды.

Хәзерге заман Олимпиадаларының традицион анты беренче мәртәбә 1920 елда Антверпенда (Бельгия) VII уеннарда яңгырый. Аны Бельгия фехтовальчысы Виктор Буан укый, һәм шуннан башлап ант кабул итү һәр Олимпиаданың тантаналы горефгадәтенә керә.

Совет спортчыларының Олимпиада биографиясе 1952 елда Хельсинкида башлана. Моңа кадәр уеннарның бәхәссез җиңүчеләре АКШ спортчылары була иде. Финляндия башкаласында күкрәкләренә «СССР» дип язылган егетләребез һәм кызларыбыз спорт дөньясын шаккаттырды. Алар, 22 алтын, 30 көмеш, 19 бронза медаль отып, рәсми булмаган команда зачетында америкалылар белән 1—2 нче урыннарны бүлешәләр. Бу АКШ спортчылары өчен аяз көндә яшен суккандай була. Безнекеләр тик Мехикода гына икенче урынны алалар. Мельбурн, Рим, Токио, Мюнхен, Монреаль Уеннарыннан америкалыларны отып кайталар. XXI Олимпиадада Германия Демократик Республикасы спортчылары АКШ командасын өченче урынга кысрыклап чыгардылар. Гомумән, Канада башкаласындагы Уеннар социалистик илләр олимпиячеләренең триумфаль җиңүе белән тәмамланды. Алар программага кертелгән 24 төрнең 14 ендә беренче урыннарны яулап алдылар. Социалистик илләр вәкилләре өлешенә өч төрле дәрәҗәдәге 613 медальнең 344 е туры килә.

Ватаныбызның иң көчле, иң җитез, иң оста уллары һәм кызлары күтәрелгән Олимпиада биеклекләрендә безнең республика вәкилләренең дә өлеше аз түгел. Якташларыбыз төрле милләт вәкилләреннән төзелгән һәм бер гаиләдәй дус, җиңүгә омтылыш белән яшәүче СССР җыелма командасы составында Хельсинкига баралар. Ике кешелек байдарка көймәләрендә ярышучылар арасында Казан ишкәкчеләре Николай Тетеркин һәм Игорь Феоктистов та була. Алар ун километрлы стартка чыгалар һәм Җир шарының иң күренекле ишкәкчеләре белән киеренке көрәштә финишка җиденче булып киләләр. Әле бер мәртәбә дә халыкара аренага чыкмаган Казан егетләре өчен бу зур җиңү була, әлбәттә.

Малай чакларын Тәтештә үткәргән баһадир Аркадий Воробьев та үзен данга күмгән юлны Финляндия башкаласының штанга күтәрү күперчегеннән башлый. Бөек Ватан сугышында якташыбыз диңгез пехотасында хезмәт итә. Румынияне һәм Болгарияне фашистлардан азат итүдә катнаша, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Фронттан кайткач, водолаз сыйфатында Одесса диңгез портын торгызуда эшли. Нәкъ менә шушында, 23 яшендә ул «тимер уен» белән кызыксынып китә. Язмыш аны Свердловскига алып килә. Егет эштән соң бөтен буш вакытын диярлек штанга күтәреп күнегүләргә бирә. Көн саен 10—15 тонна чамасы авырлык күтәрә. 1950 елда СССР җыелма командасы составында Франциягә дөнья чемпионатына бара һәм күкрәгенә көмеш медаль тагып кайта. Хельсинкида аның төп көндәше Америка Кушма Штатларыннан Олимпия чемпионы Стенли Стенчук иде. Судьяларның хәрәмләшүе аркасында гына Аркадий Воробьев өченче урынга чыга.

Аркадий Воробьевның корычтай нык ихтыярын судьяларның намуссызлыгы сындыра алмый. Ул үзенең көчен Мельбурн һәм Рим Олимпиадаларында таныта, хаклылыгын ярышта җиңеп раслый. Мельбурнда Идел баһадирларына каршы Америка тренерлары Дэвид Шеппардны куялар. Беренче хәрәкәттә үк совет атлеты аннан 7 ярым килограммга артыграк күтәрә. Өченчесендә А. Воробьев 177,5 килограммны һавага чөя, Д. Шеппард 165 килограмм белән генә чикләнә. А. Воробьев Олимпиададагы беренче зур алтын медален менә шулай ала.

Римга, А. Воробьев белән бергә, Казан авиация институты студенты Александр Курынов та бара. Штангачылар турнирын күзәтүче тамашачыларның карашы ярым урта үлчәүдәге атлетлардан америкалы Томми Коно һәм Александр Курынов очрашуына төбәлә. Беренчесе — алты мәртәбә дөнья чемпионы, ике Олимпиадада алтын медаль откан. Штангачылар арасында Томминың икенче исеме бар. Ул — җиңелмәс Коно. Италия башкаласында оттырырга туры килә үзенә. Казан штангачысы, аны өч төрдә 437,5 килограмм күтәреп, Олимпиаданың яңа рекордын куеп җиңә. Воробьев өченче Олимпиадасында да алтын медаль өчен АКШ атлеты белән ярыша. Бу юлы да көндәше Джон Пульскэмп аның белән юкка гына тартыша. Турнирны А. Воробьев Уеннар рекорды куеп һәм алтын медаль яулап тәмамлый.

Ике Олимпиадада җиңгәннән соң журналистлар А. Воробьев турында: «Титаннар токымыннан туган кеше», — дип язалар. Аның Олимпиадалар һәм дөнья чемпионатларында ирешкән уңышларын хөкүмәтебез Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары белән билгеләп үтә.

Унбер ел дәвамында илебез җыелма командасы составында чыгыш ясаган Тәтеш батыры фәнни эш белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Ул, Свердловск медицина институтын тәмамлагач, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен уңышлы яклый. Профессор Аркадий Никитич Воробьев — хәзер Мәскәү өлкәсе физик культура институты ректоры. Аның җитәкчелегендә безнең баһадирлар дружинабыз Токио һәм Мехико уеннарында җиңеп кайтты.

Совет штангачылары А. Воробьевның Хельсинкида атлаган беренче адымнарын уңышлы дәвам иттерәләр. Иң авыр үлчәүдәге Василий Алексеев ярышларда 80 тапкыр Олимпия һәм дөнья рекорды куйды. Халыкара аренада без республикабызның бүгенге штангачыларыннан Бөгелмә егете Николай Колесниковны күрәбез. Атказанган спорт мастеры, авыр атлетиканың Халыкара федерациясе башкарма комитеты члены А. Медведев Н. Колесниковның Монреальдәге чыгышы турында болай сөйли: — Монреальгә чаклы дөнья һәм Европа чемпионатларында төп көрәш Болгария һәм Советлар Союзы командалары арасында бара иде. Канадада ике көнлек ярыш нәтиҗәләре буенча бу көндәшләр очрашуының исәбе тигезләнде — 7:7. Чираттагы ярым җиңел үлчәүдәге атлетларга җитте. Безнең командадан Европа чемпионы һәм этәреп күтәрүдә дөнья рекордчысы Николай Колесников чыгыш ясый. Болгарлар берничә тапкыр дөнья чемпионы һәм рекордчысы Георгий Тодоровны куйдылар. Ыргымда Тодоров — 122,5, Колесников һәм япон Хираи 125 әр килограмм күтәрде. Беренчелек Николайда. Чөнки ул Япония атлетыннан җиңелрәк. Этәреп күтәрүне Тодоров 152,5 килограммнан башлады. Николай — 2 ярым килограммга артык! Колесников искиткеч осталык белән авырлыкны баш өстенә күтәреп куйды. Болгар 157,5 килограмм күтәрде һәм Николайны куып җитте. Әмма Колесниковның тагын ике тапкыр күперчеккә чыгу мөмкинлеге бар иде. Аларның берсен ул уңышлы файдаланды — 160 кило-

грамм күтәрә алды. Бу бигрәк тә шатлыклы вакыйга иде. Чөнки ярым җиңел үлчәүдәге штангачыларыбыздан берәү дә Рим Олимпиадасыннан соң халыкара ярышларда почет пьедесталының югары баскычына күтәрелә алмады. Уеннар чемпионы булгач, Колесников күперчеккә тагын бер мәртәбә чыкты һәм дөнья рекордын яңартты — 161,5 килограмм!

Николай Колесников Мәскәү Олимпиадасына да үз үлчәвендә беренче булып катнаша.

Җәйге Олимпиадаларда (1956 елдан башлап Кышкы уеннар да үткәрелә) чыгыш ясаучы республикабыз спортчылары арасында бер «тимер уен» вәкилләре генә түгел. Мельбурнда Балык бистәсе районында туып үскән Геннадий Бухарин СССР җыелма командасының медальләр коллегиясен үзе яулаган бүләкләр белән баета. Ул каноэ көймәсендә бер һәм ун километрлы узышларда финишка өченче булып килә һәм ике бронза медальгә ия була. Хөкүмәтебез ишкәкче егетне «Почет билгесе» ордены белән бүләкли.

Рим Уеннарында ишкәкчеләр ярышы совет спортчыларының алтын финишы белән башланып китә. Ярыш серләренең әлифбасын Кабан күлендә өйрәнә башлаган Казан медицина институты студенты Мария Шубина Антонина Середина белән бер байдаркага утыра. Безнең экипаж, финалда катнашучы 8 көймәнең 7 сен артта калдырып, алтын медаль алуга ирешә. Италиядә диск ыргытучылардан Буа егете Владимир Трусенов, 42 километр 195 метрлы арада марафон йөгерүендә Зеленодольскидан Константин Воробьев чыгыш ясый.

Казан Суворов училищесында укыган боксчы Вадим Емельянов Токиода ярым финалга барып җитте. АКШтан килгән негр егете Джо Фрэзерга гына оттырып, ул бронза медаль яулый. Соңыннан Фрэзер атаклы боксчы Мөхәммәт Алига каршы чыга һәм берничә ел профессионаллар арасында дөнья чемпионы булып тора.

Мюнхен Уеннарында иң зур бүләк — алтын медаль Чүпрәле районының Каракитә авылында туган классик көрәш остасы Шамил Хисаметдинов күкрәгенә тагылды. Минзәләдән Виталий Кузнецов дзю-до көрәшеннән чемпион исемен абсолют беренчелектә дәгъвалады. Келәмгә 29 көрәшче чыккан иде. Спортның бу төре турнирын үткәрү бик үзенчәлекле: японча көрәшүчеләр бер ярышта үзара берничә тапкыр очраша алалар. Европаның абсолют чемпионы Виталий Кузнецов башта Голландиянең 120 килограммлы көрәшчесе Вим Рюсканы откан иде. Рюска, калган очрашуларны җиңү белән тәмамлап, ярым финалда француз Бронданьны бирелергә мәҗбүр итте. Финалда Рюска һәм Кузнецов яңадан көрәште. Бу юлы өстенлек Голландия спортчысы ягында булды. Аңа — алтын, В. Кузнецовка көмеш медаль тапшырдылар. Футболчыларыбыз Виктор Колотов һәм Геннадий Еврюжихин Германия Федератив Республикасыннан бронза медальләр белән кайттылар. Виктор Колотов Монреальдә дә шундый ук бүләккә лаек булды. Соңгы уеннарның икесендә дә ул илебез футбол командасының капитаны сыйфатында катнашты.

XXI Олимпиадада фехтование осталарыбыз Наилә Гыйләҗева, Ольга Князева һәм Валентина Никоновага рапирачыларның команда турниры алтын медальләр китерде. Олимпиада бүләкләре янында кызларыбыз күкрәгендә хөкүмәтебезнең «Хезмәттәге батырлык өчен» медальләре балкыды.

Уеннар — спортчылардан тыш, судьялар өчен дә җитди имтихан. Соңгы өч Олимпиадада баскетболчылар турнирын Казан химия-технология институтыннан техник фәннәр докторы, профессор Габделнур Мөхәммәтҗанов зур осталык белән үткәрде. Ул иң гадел арбитр буларак билгеләп үтелде.

Җыеп кына әйткәндә, республикабызның данлы уллары һәм кызлары, җәйге Олимпиадаларда 11 алтын, 1 көмеш һәм 8 бронза медаль отып, Ватаныбызның спорт данын арттыруга үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр.


Хәзер без аларның иң лаеклыларын дүрт ел көтеп алган Мәскәү Уеннарында күрербез.

Уңышлар сезгә, якташларыбыз!

**ХӘНИФ МОРТАЗИН,**
В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан
дәүләт университеты укытучысы,
Бөтенсоюз категорияле судья.

# ЯЗГЫ ТАШУЛАР ЯКТЫСЫ

*Иҗат портретына эскизлар*



Ул үзенең шигырьләренә охшаган. Алар кебек үк ярсу-кайнар, эчкерсез-хыялый, җор һәм моңлы... Һәр сүзе-ымы, һәр ишарәсе белән шуны раслап тора. Яшьлегендә бик гаярь, кыз-кыркынның һушын китәрерлек чибәр һәм мут егет булгандыр, дип уйлыйсың.

Без аның белән якташлар гына түгел, тумышыбыз белән дә бер авылдан ук икәнбез, ә менә беренче тапкыр күрешкән җиребез — Казан, танышкан урыныбыз — язучыларның Тукай исемендәге клубы булды. Әле дә хәтердә: әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш бара, болай да зур булмаган залда алма төшәрлек урын юк, әмма без — студентларга шул эшлекле ыгы-зыгыда Нәби Дәүлине күрми калырга мөмкин түгел иде. Юк, киеме, килеш-килбәте белән бүтәннәр арасында әллә ни аерылып тормый ул, урындыгы да күзгә ташланырлык төшкә туры килмәгән. Хикмәт бөтенләй башка нәрсәдә: трибунадан поэзия турында доклад укыйлар. Нәби ага исә, аның һәрбер сүзен үз учыннан очырып җибәргәндәй, бик әсәрләнеп, ашкынып, дәрт биреп утыра иде. Таләпчән-катгый фикерләр әйтелгәндә, ул уң кулының имән бармагы белән һавада кискен хәрәкәт ясап «нокта куя», докладчының сүзе нәкъ менә шул «нокта»да расланып кала сыман. Дусларча чеметү-шаярту ишетелеп китсә, залдагы җанланып алуны чал чәчле язучының ихлас күңелдән кычкырып көлүе көчәйтеп җибәрә. Бу мәлдә аның йөзендәге сыр-җыерчыклар челтәре шундый язылa, — ул әбиләр чуагы чорындагы пәрәвез җепләренә әверелер дә, очып китәр төсле...

Әйе, шактый үткен, таләпчән, әле күпме бәхәсләр уятачак сүзләр әйтелде трибунадан. Һәм бу җыелышта үзе катнашмаган кешегә шактый сәер тоелырга мөмкин нәрсә — әлеге докладның «дирижеры» гына түгел, авторы да Нәби Дәүли булуы (бары авырыбрак торганлыктан гына аны башка берәүдән укытуы) — залдагыларның һәркайсына билгеле иде. Сүз үзенең иясеннән аерылмаган булып чыкты. Бәлки, шуңа күрә дә ул икеләтелгән тәэсиргә — үзенә күрә «стереофоник» яңгырашка ирешкәндер.

Ул очрашудан соң инде дистә еллап гомер үтте. Вакыт күп күренешләрне хәтердән юа, күңелдә калганнарына яңа күз белән карарга өйрәтә. Язучыны якыннанрак белгән саен, аның һәрвакыт хәрәкәткә омтылучан, тынгысыз бер җан булуы

ачыла бара. Тынгысыз кешегә дөньяда яшәү җиңел түгел. Бу — иҗат утында януның бер рәвеше булганда, — бигрәк тә. Хәтерлисездер, ул үзенең бер китабын да «Тынгысыз йорт» дип атаган иде. Гәрчә әлеге җыентыкта шундый исемдәге шигырь очрамаса да, автор «тынгысыз йорт» итеп үзенең күңелен һәм иҗат дөньясын күз алдына китергәндер... «Юл башы» исемле поэмадагы Такташ һәм Туфаннар «мине бу тынгысыз йортка дәштеләр» дигән юллар да шул фикерне раслап тора.

Каләмдәшләре әдипнең һичбер риясыз, туры сүзле, ә кайчакта уяу янартау кебек кайнап-күкрәп алучы холкын яхшы беләләр. Ләкин ул янартау күкрәгендә нинди давыллар кайный?... Язучының язмышы шундый: соңгы исәптә иҗатының киң катлау укучылар, халык тарафыннан кабул ителгән өлеше генә уртак хәзинәгә кушыласын белә ул. Кемнеңдер калын-калын томнары тотылган кәгазь өеменә әверелгәндә, икенче берәүнең сүзен-хәрефен архивлардан эзләп алалар... Бу кырыс һәм ачык хакыйкать белән һәр аерым очракта килешү җиңел түгел. Шуңа күрә дә ялгыш фикер — гөман тудырмасын: Нәби Дәүлигә чын мәгънәсендә танылу, шиңмн торган язучылык даны шактый соңарып, әмма көтмәгәндә, дәррәү килде. Көннәрнең берендә укучы бу исемне «Яшәү белән үлем арасында» дигән повесть белән бергә, иң беренче чиратта әнә шул китап авторы буларак күтәреп алды. Әлеге әсәр әдәби җәмәгатьчелектә дә, кырмыска оясына таяк белән орынган кебек, актив бер җанлану тудырды, төрле фикерләр ташкыны уятты. «Яшәү белән үлем арасында» — бүген дә яратып укыла торган китапларның берсе. Әмма вакыт елгасы ага тора, инде хәрәкәттәге тәнкыйтьнең игътибар үзәгенә башка, яңа әсәрләр килеп керүе табигый хәл. һәм нәкъ менә хәзер, шау-шу басылгач, таныш сәхифәләргә кабат әйләнеп кайту, тәэсир-кичерешләрне янарту язучының иҗади йөзен тулырак күз алдына китерү максатында кызыклы булыр иде.

*
* *

Тормыш язучыны утлы сиратлардан еш кичәргә, кырыс сынауларда сынатмаскасыкранмаска өйрәткән. Дәһшәтле һәм фаҗигале сугыш елларының кайтавазы гына да бәгырьләрдән кан саудырып, җаннарны тетрәндерерлек. Ә аның өлешенә тагын да имәнечрәк, хәтәррәк борылмалар язган икән әле... Изге туфрагыбызга мәкерле дошман аяк басканның икенче көнендә үк яу кырына киткән Нәби Дәүли авыр бәрелешләрнең берсендә йөзләгән иптәшләре белән чолганышта кала һәм тоткынлыкка төшә. Бу инде икеләтә авыр: язмышының бөтенләй билгесез сукмакларга кереп китүе белән дә, илдәгеләр өчен «хәбәрсез» югалуы белән дә. Ләкин язучы — гади солдат, гади әсир түгел, ул — яшенне үзенә тарткан имән кебек — тормышның драматик катлаулылыгын бөтен тулылыгы белән үз йөрәге аша үткәрү мөмкинлеге ала. Язучы күңеле башкалар бер кичергәнне мең кичерә, кайта-кайта телгәләнә. Хис-кичерешләр чынлыгы, мең күзгә аша үткәреп бер ноктага тупланнгандай, аерым шәхеснең генә түгел, бөтен бер буынның фаҗигасен күз алдына бастыра. Менә ни өчен ул безнең бөтен күзәнәкләргә үтеп керә, көйдереп ала, тетрәндерә.

Теге яки бу әсәрне язарга этәргән сәбәпләр, аларның «чынлыгы» турындагы сорауларга язучы халкы күнеккән инде. «Яшәү белән үлем арасында» повесте уңаеннан исә, бу сорау, мөгаен, аның әхлакый нигезе белән бәйле рәвештә генә булырга мөмкиндер. Йомылып килүче яраларны яңадан кузгату кирәкме? Кешеләрне генә түгел, тормыш һәм сугыш чынбарлыгын да гадел тасвирларга көч җитәрме? Әсирлекнең күзгә күренмәс фронт сызыгын, «алгы сызыктан да алдарак булган окоплар»ын күрсәтә, ышандыра алырсыңмы? — Н. Дәүли әлеге сорауларга әсәрен язарга керешкәнче үк җавап бирергә тиеш булган. Инде повестьны укыганда без язучының шул хакта дулкынланып сөйләвен, кинәт кенә тонкыланып киткән күкрәк тавышын ишеткәндәй булабыз. Кешеләр, сез бу сүзләрне кабат-кабат «әйләндереп» тыңлагыз һәм тыңлагыз, ди сыман ул.

*«Сугыштан соң Казанга кайткач, мин һәр көнне диярлек вокзалга барып йөри идем. Ул көннәрдә демобилизацияләнгән солдатлар белән шыгрым тулы эшелоннар бер-бер артлы килеп кенә тора. Вокзалда туганнарын, дусларын каршыларга төшүчеләр хәтсез күп... Кичкә таба перрон бушап кала. Шул вакытта мин бер карт кына хатынны күрә торган идем. Ул да, мескенем, кемнедер каршылар-*

*га килә иде, күрәсең... Шулай беркөнне без тагын буш перронда икәүдән-икәү генә калдык. Менә ул хатын миңа якын ук килде дә: «Кайтмадымы?» — дип сорады. «Юк, кайтмады шул», — дидем мин. «Кемне көтәсез?» — «Дусларымны». Хатын яшь тулы күзләре белән миңа карады да: «Мин дә улымны көтәм, ә ул бик сагындырып кына кайтырга уйлый, ахрысы,— диде авыр сулап».*

Язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирән уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән кемнедер әче җилдән ышыкларга тели төсле, алга таба талпынып куя. «Ялгыз ананың бердәнбер улы сугышның башында ук фронтка киткән,— дип сүзен дәвам итә ул.— Бары бер генә хаты килеп калган. Ә инде өч айдан соң аның хәбәрсез югалуы турында военкоматтан язу китергәннәр... «Хәбәрсез югалды дисәләр дә, йөрәгем ышанмый, — диде хатын. — Я бүген, я иртәгә кайтып төшәр шикелле»...

Мин өйгә кайтып барам. Ә башымда уйлар кайный. Күпме алар ялгыз аналар, ятим калган балалар?!. Тукта, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ны белмимме икән? Мин аларны күрмәдемме? Бәлки алар минем белән янәшә булганнардыр!.. Әйе, мин ул «хәбәрсез югалганнар»ның адресларын беләм. Ләкин ул адрес буенча хат бармый, аннан хат та килми. Ул адресны аналар, балалар белсеннәр иде, дидем мин. Аларның язмышларын, көрәшләрен күрсеннәр иде. Шул теләк белән мин шушы повестьны яздым сезгә, яшь дусларым!..»

«Яшәү белән үлем арасында» әсәренең үзенчәлекле стиле нинди укучыга йөз тотып һәм нинди ният белән язылуыннан башлана. «Мин хәбәрсез югалган идем» дигән кереш өлештә төп максат ачыктан-ачык күрсәтелә: «Кем иде соң ул фашист? Мин сиңа шул турыда сөйләргә телим», — ди язучы. Мондый конкретлык безне ике юл чатына куеп, бераз сагаерга мәҗбүр итә: сурәтләр чынлыгы һәм аналитик фикер тирәнлеге белән җәлеп итәрме ул, әзер схемалар буенча алып китмәсме?

Н. Дәүли беренче юлны сайлый һәм немец халкының фаҗигасен реалистик буяулар белән ачуга ирешә («Германия нинди матур ил икән!.. Чәчәк аткан гүзәл табигать эчендә фашистлар да яши дип ышанасы килми иде»). Ул, кайбер әсәрләрдәге кебек, фашистларны ахмак һәм ерткыч табигатьле юлбасар итеп кенә сурәтләсә, аларның «барыннан да элек кешегә охшаган булулары белән куркынычлы» икәнлекләренә ышандыра алмас иде. Иң мөһиме шунда: укучыга фашизмның кара йөзе якты фонда — тәннәре әсирлеккә төшсә дә, рухлары белән хөр булып кала алган кешеләрнең тормышка мәхәббәте фонында күрсәтелә. Әсәрдә югалту-әрнү хисе өстенлек алыр төсле. Әмма язучының иң хәсрәтле уйлануларында да солдатларча горур, киләчәккә ышаныч белән тулы рух калкып чыга һәм ул көчәйгәннән-көчәя бара. Лагерьда «парикмахерская», «лазарет», төрле «мастерскойлар» ачылу күренешләрен генә искә төшерик. Безнең алда — чын мәгънәсендә оптимистик трагедия, совет солдатының күңел сафлыгына, рухи ныклыгына сокланып дан җырлаучы героик баллада. Теткәләнгән киемнәрдә калган йолдызлы төймәләр котылгысыз үлемнән куркып-каушап калмаслык көч бирә. Әнә шуңа күрә фашистларга үз өннәрендә дә тынычлык юк, әсирләрнең яшәүгә, җиңүгә омтылышын нинди рәхимсез шартлар да сүндерә алмый. Язучы бу көрәшнең драматизмын нечкә тоеп, тантаналы финалын зур гомумиләштерүләр нигезендәге фәлсәфи сөземтә рәвешендә тәкъдим итә: «Без Германия җиренә үзебез белән немец армиясенең җиңелү хәбәрен алып килдек», — ди ул.

Шушы лейтмотивның «Җимерелгән бастион» романында да саклануын күрергә мөмкин. Иң хәлиткеч минутларда роман геройларыннан берсе — Наҗия, мәсәлән, турыдан-туры: «Сүз яшәү белән үлем турында бара», — ди. Билгеле, «Җимерелгән бастион»ның әдәби «ачкычы» бөтенләй башка, ул катлаулы язмышлар төене булып күз алдына килә. Ләкин язучы тормышның «яшәү өчен генә түгел, барыннан да элек, явызлыкка каршы көрәш» булуы турындагы сүзен дәвам итә. Үз гомерен куркыныч астына куеп, меңләгән әсирләрнең азатлыгы өчен көрәш юлын сайлаган Иван Потапов, сугыш чынбарлыгында күзләре ачылган яшь лейтенант Франц һәм башка образлар ярдәмендә ул «коммунизм белән фашизм кылычка кылыч килгән» иң кискен бәрелешләрне сурәтли, шул көрәштә «бер Германиянең ике Германиягә» аерылуын күрсәтә... Укучы игътибар иткәндер: сүз «Җимерелгән бастион» турында бар-

ганда да мин үземтәләрне «Яшәү белән үлем арасында» повестеннан китердем. Һәм менә ни өчен. Безнең кайбер тәнкыйть мәкаләләрендә әлеге ике әсәрне бер-берсенә каршы куеп, повестьта фашист концлагерьларындагы авыр тормыш кына тасвирлана, әсирләрнең дошманга каршы көрәше күрсәтелми, дигәнрәк фикерләр ишетелгән иде. Сүзне озынга сузмыйча, бу бер аңлашылмаучылык кына булгандыр, дип әйтәсе килә. Әсирлектә «шырпы кебек янып сүнгән» ир-егетләрнең: «Ничек тә исән каласы иде», — дип өзгәләнүләрен генә хәтерләгән кеше дә, яшәү өчен көрәш гадирәк, җиңелрәк, дип уйлый алмас. «Бу сәгать осталары, бу тимерчеләр, бу игенчеләр, бу инженерлар, врачлар, балта осталары әле дөньяга күпме байлык, күпме матурлык бүләк итәрләр иде... Кешелек дөньясы иртәгә туарга тиешле бәхеттән аерылды. Моңа бары тик, бары тик фашизм гына гаепле». Без биредә шәрә фәлсәфә, коры риторика белән түгел, әдәбиятның могҗизалы көче ярдәмендә бер шәхес хатирәләреннән буыннар хәтеренә күчү күренеше белән очрашабыз. Әсәрдәге бер куш уч якты сагышның меңнәрчә күңелләрдә тәкрарланып искиткеч олы масштабларга ирешүен күрәбез. Ул, һәр таңда чыккан кояш кебек, безне тормыш-яшәеш кадерен белергә өйрәтә. Вакыйгалар моннан утыз биш-кырык ел элек һәм бер үк вакытта безнең күз алдында бара. Хикәяләүнең үзенчәлекле стиле ачык билгеләнгән: әсирлек көндәлеге, хатирә-репортаж! Язучы үзе тасвирлаган вакыйгаларны бүгенге көн биеклегеннән торып күздән кичерә, кирәк урында ачыктан-ачык аңлатып шәрехләп ала, кичерешләреннән оялмый, мөнәсәбәтен яшерми. Әмма ул, башыннан кичкән хәлләрне генә сөйләсә дә, үзен игътибар үзәгенә куймый, киресенчә, хәбәрсез югалган дусларын күбрәк күрсәтергә тырыша, аларның аманәтләрен тапшырырга ашыга. Чөнки хәбәрсез югалганнар һәм яу кырында һәлак булганнар җирдә фашизм яңадан баш калкытмасын өчен көрәш сафында калалар.

Кыскасы, зур ышаныч белән әйтергә була: еллар үткәч тә «Яшәү белән үлем арасында» кебек китапларның дулкынландыру көче кимемәячәк. Алар үткәнгә түгел, бүгенге көнгә, киләчәккә төбәлгән һәм яңа буыннарны ватандарлык рухында тәрбияләүгә хезмәт итәләр.

*
* *

«Яшәү белән үлем арасында» повестеның язучы иҗатындагы иң биек нокталардан берсе булуы ачык. Мәгәр шунысы да бар: аның һәр әсәренең чын кыйммәте әлеге биеклеккә нисбәтле бәһаланачак.

Нәби Дәүлинең шигъри дөньясы соңгы елларда яңа төсләргә, яңа интонацияләргә баеды. Язучының хәтта үткәндәге иҗатын да яңа мәгънәләре белән ачкан төсле булды повесть. Мәсәлән, әсирлек йөгөн үз иңнәрендә күтәргән автор шәхесенең, әсәрдә лирик «мин» дәрәҗәсендә генә калмыйча, сүз һәм хәрәкәт активлыгына ия булуына игътибар итик. Аның «мин»е — шәхси дөньясына кереп бикләнү чарасы түгел, ә тормыш чынбарлыгын үз күңеле аша үткәреп, укучыга якынайтырга сәләтле тәрәзә. Бу тылсымлы «тәрәзә» төп игътибарны, вакыйганың үзен хәбәр итүдән бигрәк, аның турында уйлануга, аны кичерүгә юнәлтә:

Сугышларда орден алмадым дип,
Кайгырасым булмас үкенеп:
Киләчәктә туар фашистларны
Мин бүген дә йөрим үтереп.

Шагыйрьнең тирән гомумиләштерүләре нигезенә тормыш тәҗрибәсе һәм яшәү принциплары салынган. Аңа язмышның беренче һәм авыр сынауларын нарасый бала чагында ук кичерергә туры килә. Бер-бер артлы әтисе белән әнисе дөнья куя. Бу дөньяда ач-ялангач һәм, барыннан да бигрәк, япа-ялгызы калу ачысын татыган малайның күңеле, бәлки, туган җирләреннән еракта, тамак ялы өчен көтү көтеп йөргән заманнарда ук мөлдерәп торган моң чишмәсенә әверелгәндер. Булачак шагыйрьнең холкы-фигыле Донбасстагы зур заводларның берсендә тимерче булып эшләгән

чакларында ныгый, формалаша башлагандыр. Аның иҗатка омтылышы да шунда уяна, беренче шигырьләре, мәкаләләре татар шахтерлары өчен чыгарылган «Пролетар» газетасында басыла. Бик күп еллар үткәч, Н. Дәүли: «тирән шахталарда кап-караңгы юллар узган бар», тормыш юлларында адашып калмаска шунда өйрәндем, дип язар.

Туган якларына шактый сулар аккач кына кайтырга насыйп була аңа. Ә шагыйрьнең туган җире — кечкенә генә Мәүләшә авылы. Телгә-җырга кермичә, тыйнак гомер сөргән, игелекле төбәк, нигезе — борынгы Болгар туфрагында, биегрәк үргә менеп карасаң, Туфанның Кармәте күренер төсле. Язмышларында да ниндидер уртаклык сизелә: тамырлары белән туган җирдән аерылмаганнар, әдәбиятка берсе Уралдан, икенчесе Донбасстан килгән...

Нәби Дәүлинең катлаулы иҗат юлы турында уйланганда төрле чор шигырьләре күз алдыннан үтә. Башлангыч чорда ук язылган самими сурәтләргә, хыялга бай юллар... Җырга әверелгән «Чулпан», «Татарстан — минем республикам» шигырьләре... Хис-моңлы, зур фәлсәфәле соңгы еллар лирикасы... Шулай да, иң яраткан шигырене сайла, дисәләр, мин «Өч тамчы су турында баллада»га тукталыр идем. Сугыш юлы узган җирдә, чишмәләр дә кипкән бер мәлдә яралы солдат бер йотым суга тилмереп ята. Командир үз флягасында калган суны аңа бирмәкче: «Эч, туганым, һәм уйлама аерылам дип дуслардан». Җылы сүз дә үлем белән көрәшкән сугышчыга хәл керткәндәй була, ул инде суны эчми, башка яралыларга суза... Солдат флягасы кулдан кулга күчеп, сусауны һәм йөрәкләр сызлавын басып, комбатның үзенә кире кайта. Ә анда бары... өч кенә тамчы су булган!

Муса Җәлилнең җыр булып яңгыраган батырлыгы турындагы «Берлинда окоп» поэмасы, шагыйрь-солдат Фатих Кәрим истәлегенә багышланган «Госпитальдән хат» шигыре һәм башка бик күп әсәрләрнең дә нигезендә куәтле фикер-хис потенциясе ята. Укучыны алардагы аерым сурәтләр, чагыштырулар түгел, ә язучы тудырган эстетик чынбарлык һәм тормыш фәлсәфәсе җәлеп итә.

Гомумән, Нәби Дәүли шигърияте ике төп сыйфатка — зур гомумиләштерүләргә һәм ачык гражданлык пафосына омтылуы белән аерылып тора. Аның сайланма әсәрләренә язган кереш мәкаләсендә шагыйрь Зәки Нури да әнә шуңа игътибар итә һәм: «Күрәсең, «гражданлык» төшенчәсен әсәрнең укучы йөрәгенә тәэсир итә торган көче буларак та, художестволылыкның бер шарты итеп тә, ниһаять, шагыйрьнең халык тормышы белән бәйләнеше шунда икәнен раслый торган факторларның берсе дип тә аңлау дөрестер», — дигән нәтиҗә ясый. Нәби Дәүли иҗатының заманча һәм халыкчан яңгырашы кайдан килә дигән сорауга моннан да төгәлрәк итеп җавап бирергә мөмкин түгел. Нинди генә газаплар кичерсә дә, шагыйрьнең күңеле суынмаган, хисләре тупасланмаган. Ул үзенең төп принципларына, тематик юнәлешенә һәрвакыт тугрылыклы кала. Аның әсәрләрендә иркәләп-шаяртып, ә кайчак шактый усал һәм ачы итеп көлү дә, нечкә психологизм һәм кыю публицистика да, «поэзиядә географик чикләр юк, анда идея чикләре генә бар», дип, ил-көн, җир язмышы өчен борчылу да урынлы яңгырый.

Шигырь формасы, техникасы мәсьәләләренә килгәндә, Н. Дәүлинең бу өлкәдәге үзенчәлекле карашы — һәртөрле яңалыкка шикләнебрәк каравы билгеле. Кискен полемик рух аның фикерләрен, әлбәттә, икенче чиккә дә алып киткәли. Әмма «новаторлык» дип куштырнаклар эченә алып язудан башлап, «төннәр буе хәреф эзләүчеләрне» тәртипкә чакыруга кадәр барып җитсә дә, бу — шигырьнең мәгънәви тирәнлеген һәм образлы яңгырашын көчәйтү юнәлешендәге иҗади эзләнүләргә каршы чыгу түгел иде. Моңа язучының үз әсәрләре үк шаһит. Иң традицион алымнар белән дә ул шигъри сурәт бөтенлегенә ирешә. Гап-гади кабатлаулар ярдәмендә, әнә, Хатынь авылындагы кыңгырауның тирбәлүен генә күрсәтеп калмыйча, моңын да ишеттерә. Яшьлегендә рәссамлыкка әзерләнгән әдип иҗатындагы төсләр төгәллеге, интонацияләр байлыгы игътибарны җәлеп итә. Прозасыннан, хәтта мәкаләләреннән моңа күп мисаллар китереп булыр иде. «Яшәү белән үлем арасында»гы доктор Васили Петровичның күзләрен хәтерлисезме? «Шырпы сүнгәч тә, ул күзләр һаман янып торалар иде кебек». Сатлыкҗан полицайның күзләре исә «буш тартмага уелган ярыклар кебек» кенә... Фрау Эльзабетның күзләре «ояларына ут төшкән чыпчык

балалары кебек сискәнеп китә». Кыю татар кызы Нәҗия «кар суының тамчысы кебек саф» күзле булып истә кала.

Нәби Дәүли сүзләрне үзенчә сайлап ала, үзенчә тезә: алар алдагы җөмләләрнең логик дәвамы булудан бигрәк, яңа фикер учаклары булып кабыналар. Образ-сүз, чак кына кыры белән куюга, кристалл кебек яктырып, балкып китә:

Кеше гомере олы бер тау,
Вакыт аны ватып ала,
Һәм кабергә куяр өчен
Бер кечкенә ташы кала.

Шигырь ялтыравык таңкәләре белән күзне чагылдырмый, сукырайтмый. Киресенчә, сугышчан юлын разведчик булып башлаган шагыйрь күңел күзләребезне ачыбрак карарга, күбрәкне күрергә чакыра.

*
* *

Безнең якларда язгы ташуларга мөнәсәбәтле «сыза» дигән матур бер сүз бар. Күңел сызуларын хәтерләтә торган сүз.. Бәлки, борынгы төрки-болгар бабаларыбыздан ук калган төшенчәдер ул, әмма сызасыз ташу — кайсы заманда да ташу булмый инде. Күз алдыгызга китерегез: язның сәгатьләп түгел, минутлап килгән чагы. Яр битләрендәге кар юеш-соры чабуын боз өстенә җәелгән судан ала алмый башлый. Мәгәр елга-инешләр кузгалырга уйламый да әле.. Менә, ниһаять, таң алдыннан авылны ниндидер гөрелте уята. «Һай, сыза төшкән!» — диләр картлар. Әйе, урманкыр суларының — сызаларның килеп әйдәвен генә көткән икән Чирмешән бозы! Шашкын-дәһшәтле, шул ук вакытта үзенең көче-куәте белән дә, бозыннан бушанукотылу шатлыгы алып килүе белән дә гаҗәеп матур күренеш ачыла.

Сүзне болай ерактанрак урап килүнең сәбәбе шул: сызалы язлар белән Нәби ага Дәүли иҗаты арасында әчке бер уртаклык бар сыман. Аның яшенләп-күкрәп килгән шигъри ташкыннары да шулай, әлегәчә сызыла алмый торган күңелеңне кузгата, авыр уйларыңны төбе-тамыры белән куптарып алып китә, җаныңда рәхәт-аяз иркенлек, киңлек кенә кала.

Җил тирбәтә көмеш башакларны,
Бөртек йоклый ефәк бишектә.
Тургай сайрый, кояш көлеп тора,
Яз җырларын ул да ишетә...

...Якташлар соңгы елларда язларыбызның яме китебрәк тора: кар-боз үзалдына сызылып бетә, шуңа күрә ташу аккан төсле дә түгел, диләр. Күңел сызаларга, сызалар уяткач ярсып аккан ташуларга сусый... Һәм алда әле шигърияте язларның күп булачагына ышаныч зур. Язучының «тынгысыз йорты» тәрәзәләреннән төшкән яктылык безне шуңа өметләндерә.

**САЛИХ МАННАПОВ.**

# ЗУР БАКЧАНЫҢ БЕР ГӨЛЕ

Татар совет балалар әдәбиятының күренекле вәкиле Җәвад Тәрҗеманов утызынчы елларда Казан шәһәренең 13 мәктәбендәге иҗат атмосферасында тәрбияләнеп үсә. Мехчы балалары укыган бу мәктәпнең ул елларда чынчыннан мәдәният бакчасы дип аталырга хакы була. Биредә татар телен һәм әдәбиятын чын күңелдән яраткан, шул мәхәббәтне балаларга да бирә белгән укытучылар эшли, әдәбият түгәрәгенә Һади Такташ һәм Фатих Кәрим кебек атаклы шагыйрьләр җитәкчелек итә, драмтүгәрәкне режиссер һәм драматург Риза Ишморат алып бара, республикабыз рәссамнары тарафыннан исеме әле дә хөрмәт белән искә алынган Габдрахман ага Свиргузин яшь рәссамнар белән эшли. Әнә шундый осталар ярдәмендә танылган рәссамнар (Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттах), галимнәр (Габделхак Галиуллин), язучылар (Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Җәвад Тәрҗеманов, Гарәфи Хәсәнов), журналистлар, укытучылар, врачлар, җәмәгать эшлеклеләренең үсеп чыгуы гаҗәп түгел.

Илебез халыкларының илһамланып, дәртләнеп яңа тормыш корган еллары була ул. Өлкәннәрдәге ашкыну, омтылыш балаларда да зур. Шау-шулы пионер сборларында чыгышлар ясау, стена газеталарына язышу, түгәрәк утырышларындагы сүзләр Җәвад Тәрҗемановта бик кечкенәдән гражданлык сыйфатлары тәрбияләүгә булышалар. Карап торуга юаш кына күренгән бу малай җиденчедә укыган чагында ук:

Без көрәштек, без җиңүче булдык
Илне төзүчеләр сафында,
Илдә әле көрәш тукталмаган,
Соңгы җиңү безне чакыра,

— дип шигырь яза. Киләчәктә балаларның яраткан язучысы булып танылачак Җәвад Тәрҗемановның беренче шигыре була ул һәм Галимҗан Мөхәммәтшин фатихасы белән 1935 елның февралендә «Яшь ленинчы» газетасында басылып та чыга.

Шуннан бирле татар һәм рус телләрендә аның кырыктан артык китабы дөнья күрә. «Тукран малае Шуктуган» әкияте Европа телләренә дә тәрҗемә ителә.

Җәвад Тәрҗемановның иҗаты күп төрле. Ул шигырьләр, җырлар, әкиятләр, проза һәм сәхнә әсәрләре, каләмдәшләренең иҗаты турында мәкаләләр яза. Соңгы елларда аның «Көмеш дага» исемле күләмле тарихи романы чыкты. Шулай да әдәбиятка ул балалар язучысы булып килде һәм шул өлкәдә эшләвен күп еллар дәвам итте.

Әле үзе дә мәктәп яшеннән чыгып өлгермәгән яшь шагыйрьнең беренче шигырьләре балалар күңеле кебек үк сафә, аларда катлаулы образлар, бизәкләр, чагыштырулар да аз була. Бу шигырьләрдә баланың көндәлек тормышындагы вакыйгалар, тирә-юньдәге предметлар турында сүз бара. Хәерле иртә теләп аваз биргән әтәч, песи баласы, өй буярга килгән мастер, атны алты аяклы итеп рәсем ясаган сабый, чаңгы шуарга чыккан пионерлар, дәресен сөйли алмаган ялкау бала һ. б. турында язуның әллә ни авырлыгы юктыр да сыман. Әмма бик үк хикмәтле булмаган бу шигырьләрнең сөйләшергә әле яңа өйрәнгән, я булмаса, беренче — икенче классларда гына укучы балалар өчен язылуын искә алсак, алар күңелен җәлеп итәрлек итеп әйтеп бирүнең бик үк ансат түгеллеген дә аңларга мөмкин.

Бу турыда сүз чыкканда Җ. Тәрҗеманов үзе: «Нәниләр күңеленә барып җитә алырлык шигырьләр язучы кеше ул — гаять катлаулы махсус профессия кешесе», — ди.

Утызынчы елларда балалар өчен информация чыганаклары артык күп түгел иде әле. Газета-журналлар барып җитмәгән, радио кермәгән өйләр дә аз булмагандыр. Ә телевизор дигән тылсымлы тартма турында ул вакытта ишетүче булдымы икән? Ул вакытта балаларның бар белгәне укытучылардан һәм китаплардан килде. Әнә шул «катлаулы махсус профессия кешеләре»нең берсе булган Җәвад Тәрҗеманов та тормышның төрле тармакларыннан балаларга информация бирүне беренче чираттагы бурычы итеп куя. Аның беренче шигырьләре балаларны пөхтәлеккә, тырышлыкка өндәсә, матурлыкны күрергә өйрәтсә, утыз сигез-утыз тугызынчы еллардагы иҗатында инде ул күбрәк туган ил, анда барган вакыйгаларны тасвирлауга урын бирә.

Балалар инде аның шигырендә фабрика эшчеләре булып уйнаучы яшьтәшләрен, урындыкны машина иткән нәни «шоферны», Ленин рәсемен үзе үстергән гөлләр белән бизәүче кыз баланы, Папанинга хат язучы хыялый малайны һ. б. күрәләр. Шул вакытта ук Тәрҗеманов поэзиясенә тынычлык темасы килеп керә. «Илебез чигендә» дигән шигырендә ул, бала исеменнән:

> Һәркем тынычлыкны яклый
> Безнең Совет илендә.
> Аны минем абыем да
> Саклый илнең чигендә,

— дип яза. Бу юлларны укыгач, башына йолдызлы шлем кигән, биленә агачтан ясалган кылыч таккан кыска чалбарлы малайның тырыша-тырыша шигырь сөйләве күз алдына килә. Тынычлык... Бүгенге көн балаларының да теленнән төшмәгән изге сүз. Бу теманы шагыйрь тагын да дәвам итеп, «Яшәсен тынычлык» (физкультурачылар бәйрәмендәге самолетларның төрле фигуралар ясап шул сүзләрне язулары турында), «Бөек дуслык» (чит ил балалары белән хәбәрләшүче пионерларның хатында «Яшәсен бөек Дуслык һәм Тынычлык!» диелгән), «Фестиваль чәчәкләре» (төрле илләрдән килгән яшьләр Кызыл Мәйданда) һ. б. күп кенә шигырьләр иҗат итә.

Утызынчы еллар азагында татар балалар әдәбиятында илебезнең эчке һәм тышкы дошманнарына каршы көрәш темасы уңышлы чагылыш тапты. Чик сакчыларының батырлыгы, кулакларга каршы көрәш, капитал илләрендәге балаларның авыр хәлләре турында повестьлар, пьесалар, поэмалар, шигырьләр иҗат ителде. Аларның географияләре киң иде. Казанда, Агыйдел буенда, Кузбасста, Кавказ тауларында, Монголиядә, Берлинда, Америкада, Шотландиядә һ. б. җирләрдә барган вакыйгалар сурәтләнде. Шул елларда Җәвад Тәрҗеманов та «Негр малае Том» дигән озын шигырь яза һәм бу традицияне дәвам итеп, соңга таба «Судан табылган хат», «Шотландия малае» дип исемләнгән күп кенә шигырьләр иҗат итә.

Мондый әсәрләрне укыганда ирексездән соңгы еллардагы статистик материаллар хәтергә килә. Бер минут эчендә дөньяда бер миллион сумлык корал эшләнә икән. Американың хәзерге заман авианосецы 12—13 миллион доллар тора, ә ул сумма мең мәктәпне бер ел буе эшләтергә җитәрлек, ди. Шул ук вакытта күп кенә илләрдәге балалар Тәрҗеманов әсәрләрендәге Том, Мэри, Джесси, Гемфриләр кебек мәктәп күрми үсәләр.

«Шотландия малае» дигән хикәя темасы, чишелеше белән генә түгел, алынган материалы белән дә кызыклы. Дөньяга фәнни һәм техник ачышларны зур гыйлемиеләре генә ясый дип уйларга күнеккән булсак та, яңа йолдызлар тапкан, машиналар уйлап чыгарган балаларны да беләбез. Мәсәлән, Ленинградтагы Нева аша атаклы күперне механик юл белән ачу һәм ябу ысулын әле соңгы елларда гына уйлап тапкан яшьлек малайның уйлап табуы, күлләрдә йөзә торган яссы төпле көймәнең беренче моделен яшь техниклар түгәрәгенә йөргән пионерка ясавы билгеле.

Безнең илдә мондый эшләр эшләгән балаларны мактап газета-журналларга язалар, бүләкләр бирәләр, тагын да ныграк укыталар, өйрәтәләр. Ә менә Җ. Тәрҗеманов хикәясендәге Шотландия малае Гемфрины, инде кирәге калмагач, эштән куып чыгаралар. Ике тормыш, ике язмыш. Боларның берсен балалар китаплардан укып белсә, икенчесен үзләре күрәләр.

Җ. Тәрҗеманов иҗатында үзгә урын тоткан жанр — әкиятләр. Әйтерсең лә Абдулла Алиш үзе сугышка киткәндә Җәвадка васыять әйтеп калдырган: «Менә сиңа

каләмем, менә сиңа кәгазьләрем. Мин кайта алмасам, үлеп калсам да, әкиятләр үлмәсен. Син аларны күп итеп яз. Минем әкиятләрне укыган кебек үк, аларны да балалар яратып укысыннар».

Һәм Җәвад, яуда егылган батырның коралын алып алга ыргылган сугышчы кебек, остазы Алиш традицияләрен дәвам итеп, гаҗәп матур әкиятләр яза. Ул әкиятләрнең геройлары тырыш бал кортлары, шаян күбәләкләр, мактанчык чебеннәр, аңгыра ишәкләр һәм бөек акыл иясе Кеше. Шигырь белән язылмый, әллә прозага салынмый — аларда камил эшләнгән форма, кызык эчтәлек, үткен юмор була. Иҗатының беренче елларындагы кебек, автор акны ак, караны кара дип тәртеп әйтми, ә фикерне образларның кылган гамәле аша ачык сиздерә яки күрсәтә.

«Казан утлары» журналының 1978 елдагы 9 нчы санында, Абдулла Алишның 70 еллыгына карата мәкаләсендә тәнкыйтьче Равил Кукушкин: «А. Алиш әкиятләрен функцияләре ягыннан шартлы төстә өч төргә аерып карарга мөмкин: беришесе балага табигатьне танып белү чарасы буларак кызыклы; икенчеләре исә — мавыктыргыч һәм гыйбрәтле мөнәсәбәтләргә корылганнары тәрбияви характер алулары белән әһәмиятле; өченчеләре, башлыча, эстетик үзенчәлекләре белән игътибарга лаек»,— дип язды. Җ. Тәрҗеманов әкият формасының мөмкинлекләрен тагын да киңәйтә, аны сәяхәтләр жанрында да кулланып, баланы илебезнең уңышлары белән таныштыру өчен файдалана. «Көмеш койрык маҗаралары» дигән әкиятендә ул реаль булмаган вакыйгалар аша тормышыбызның бик реаль күренешләрен тасвирлый. Очерк жанрын кабул итәргә әзерлеге булмаган бала шул ук материалны әкият итеп сөйләп биргәч — тиз һәм җиңел үзләштерә. Моңар әкиятнең теле дә ярдәм итә. Аның прозадан да, шигырьдән дә аерылып торган үзенә хас стиле бар. Җөмләләр җиңел әйтелә торган яңгыравыклы сүзләрдән төзелә, бер үк сүзләрнең кат-кат кабатлануы, яисә төрле сүз җилемнәре куллану әкият теленең сыгылмалыгына китерә. Борынгы халык әкиятләренең шул үзенчәлегенә таянып Абдулла Алиш, татар балалар әдәбиятында беренче буларак, рифмалы проза белән яза башлады. Аның бу алымын Җәвад Тәрҗеманов уңышлы дәвам итте. Янәшә килгән ике җөмләнең ахыр сүзләрен рифмалау, җөмләдәге сүзләрне билгеле бер ритм саклап төзү әкият теленең музыкальлеген тагын да көчәйтте.

Казан химия-технология институты доценты, техник фәннәр кандидаты Җәвад Тәрҗеманов үз фәне буенча балаларга күп нәрсәләр сөйли ала. Аның «Көмеш дага» исемле тарихи романы математикада революция ясаган бөек Лобачевскийның фәнни батырлыгын сурәтләве белән әһәмиятле. Казан гимназиясендә укыган елларында ук булачак математикның фән белән тирәнтен кызыксынуы, борынгы язмаларны уку өчен бик күп телләр өйрәнүе, төрле кыенлыклар белән көрәшә-көрәшә үз максатына баруы, Румовский, Карташевский, Нигъмәт Ибраһимов кебек прогрессив галимнәр белән дуслыгы һәм, ниһаять, бөтен гомере буе эзләнгән ачышын — неэвклидовая геометрияне иҗат итүен җанлы картиналар ярдәмендә, тәэсирле итеп яза.

Романның гыйльми мәсьәләләргә кагылышлы урыннары авыррак, фәнни әдәбият теле белән язылган булса да, Казан университеты ачылу, студентлар тормышы, башка тарихи вакыйгалар, геройларның шәхси тормышлары әсәрне җанландыра, унтугызынчы гасырның иҗтимагый политик атмосферасын шактый тулы күзалларга ярдәм итә.

Роман Җ. Тәрҗемановның зур уңышы. Бу теманы тагын да дәвам итеп, мәсәлән, Ибраһим Хәлфин, я булмаса Каюм Насыйри турында шундый ук күләмле, төрле проблемаларны эченә алган әсәр язсын иде ул.

Җәвад Тәрҗемановның унынчы класста укыган вакытында «Кызыл галстук» исемле беренче җыентыгы чыгуга кырык елдан артык вакыт үтте. Шул еллар эчендә ул татар балалар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Бала вакытында Һади Такташ, Фатих Кәримнәрнең шигъри мәктәбен үткән, «Октябрь баласы» журналы аша Муса Җәлилдән, «Яшь ленинчы» белән «Пионер каләме»ндә Абдулла Алиш һәм Ләбиб Гыйльмиләрдән матур әдәбият дигән сихри бакчаның ямен тоярга өйрәнгән язучы үз остазларының өметен аклады һәм киләчәктә дә аклар, дип әйтәсе килә.

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА.**

# ТӘНКЫЙТЬЧЕ һӘМ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ



„Кайбер чишмәләр агач вә таш араларында чыга да, адәм балалары файдалана алырлык бер елга булып, үзенең табигый юлы белән зураеп, киңәеп агып китә алганчы, әллә нинди җирләрдән, таш асларыннан, файдасыз юллардан борылып йөри, соңра гына тигез җиргә чыгып, файдалы рәвештә агып китә. Адәмнәргә бирелгән бик күп кабилиятләр дә, табигый юлларына төшеп, яратылышлары буенча барыр ноктаны таба алмыйча, күп вакыт адашып чит юлларда йөридер», — дип язган Галимҗан Ибраһимов мәкаләләренең берсендә. Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Мансур Хәсәнов турында сүз башлаганда бу юллар искә төшә гыйбрәтле. Беренчедән, ул үзенең әдәбиятта, культура тормышындагы урынын таба алмый адашып йөрүләрдән тулысынча азат иде. Икенчедән, М. Хәсәновның эзләнү һәм үз-үзен табуына, безгә калса, бар нәрсәдән бигрәк, Г. Ибраһимов мирасы юнәлеш бирде.

Күренекле язучы һәм ялкынлы революционер, олы галим һәм фикер иясе, тәнкыйтьче һәм тынгысыз җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов эшчәнлегенең кайсы гына өлкәсенә мөрәҗәгать итмә — ул үзе аерым бер дөнья. Татар совет әдәбиятын, татар совет әдәбияты белемен һәм әдәби тәнкыйтебезне нигезләүче әдипләрнең дә иң күренеклесе Г. Ибраһимов. Халык әкиятләрендәгедәй юллар чатына килеп чыккач — фәндә һәм әдәбиятта аерым бер тема, юнәлеш сайлар вакыт җиткәч Мансур Хәсәнов икеләнеп тормаган булса кирәк. Чөнки Г. Ибраһимов иҗаты һәм аның данлы тормыш юлының олылыгы, алмаздай күпкырлылыгы эзләнү һәм табышларга ашкынып торган, җегәрле һәм хәзерлекле яшь тикшеренүчегә үз-үзен сынау һәм үз-үзен билгеләү өчен гаять җитди мәйдан була.

Г. Ибраһимовның роман һәм хикәяләре инде бер татар халкының гына түгел, күп милләтле совет әдәбияты укучыларының уртак рухи казанышы булып тора. Әдипнең әсәрләре татар һәм рус телләреннән тыш күп кенә башка тугандаш халык телләренә тәрҗемә ителде һәм зур тиражда басыла киләләр. Бу барыннан да элек, әлбәттә, партия һәм хөкүмәтебезнең әдәбият, сәнгать турында даими кайгыр-

тучанлыгы, ленинчыл милли политиканың чәчәк атуы нәтиҗәсе. Шунда ук Г. Ибраһимов әдәби-эстетик мирасының күп милләтле совет әдәбияты казанышы дәрәҗәсенә күтәрелүендә әдипнең олы иҗатын үзенә бер фидакарьлек белән озак еллар дәвамында өйрәнә, туплый һәм актив рәвештә пропагандалый килгән галим һәм әдәбият белгече Мансур Хәсәнов хезмәтләренең дә әһәмияте зур икәнлеге бәхәссез булса кирәк. «Галимҗан Ибраһимов» дип исемләнгән күләмле монографияләрнең рус һәм татар телләрендә кабат-кабат басылып чыгуы һәркайсы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бер вакыйга сыман билгеләп узылды. Чөнки алар бер үк хезмәтнең төрле басмалары гына түгел, ә галимнең марксистик-ленинчыл методологиягә нигезләнгән өзлексез эзләнүләре һәм күренекле әдип мирасын өйрәнүдә яңа табышлары һәм ачышлары, әдәби-эстетик гомумиләштерүләре нәтиҗәсе булып килделәр. Вакыт белән бергә әдәбият фәне генә түгел, әдәби мирас үзе дә хәрәкәттә икән, еллар үткән саен Ибраһимов таланты әдәбият сөючеләрне яңа яклары белән сокландыра килә, аның яңадан-яңа үзенчәлекләре ачыла бара — әлеге монографияләрдә М. Хәсәнов әнә шул хакыйкатьне дәлилле рәвештә исбат итә.

Әдәбият сөючеләр һәм язучылар филология фәннәре докторы Мансур Хәсәновны Галимҗан Ибраһимов турындагы фундаменталь хезмәт, күп санлы мәкалә, чыгышлардан тыш, татар әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе хакындагы колачлы җитди мәкаләләр авторы буларак та яхшы беләләр. Әйтик, классик мирас турында, татар әдәбиятында социалистик реализм иҗат методының нигезләнүе һәм үсеше, күп милләтле совет әдәбиятлары гаиләсендә бүгенге татар әдәбиятының урыны турындагы дистәләгән мәкаләләр аның иҗат диапазонының киңлеге турында ачык сөйлиләр булса кирәк.

Олы юбилейлар елында, бу истәлекле көннәрдә СССР Язучылар союзы члены, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Мансур Хәсән улы Хәсәновка 50 яшь тула. Татарстан язучылары һәм «Казан утлары» журналы күп меңләгән укучылары исеменнән әдипне әлеге дата белән ихластан тәбрик итә, иҗатында һәм иҗтимагый эшчәнлегендә яңадан-яңа уңышлар теләп кала.

# МӘРЗИЯ ФӘЙЗУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ



*Мәрзия Низам кызы Фәйзуллина 1930 елда Татарстанның Арча районы Шушмабаш авылында туа. 1964 елда М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый.*

*Ул әдәбиятка 50 нче еллар башында килә. 1955 елда «Салават күпере» исемле нәниләр өчен шигырьләр җыентыгын чыгара. Хәзер Мәрзия Фәйзуллина — татар һәм рус телләрендә чыккан унбиш шигырь китабы авторы: «Салават күпере», «Чәчәкләр сәгате», «Ике көрәк», «Гөлнар мәктәпкә бара», «Шаян ай», «Энҗе чәчәк», «Уенчыклар иртәсе», «Саф мәхәббәт», «Цветочные часы», «Стихи», «Пропала кошка», «Только для тебя» һ. б. Шагыйрәнең аерым әсәрләре, рус теленнән тыш, башкорт, үзбәк, чуваш, украин һ. б. халыклар телләренә дә тәрҗемә ителгән.*

*Хәзерге көндә М. Фәйзуллина Бөек Ватан сугышы каһарманнарына багышлап «Кече җирдән хатлар» исемле зур шигъри бәйләм өстендә эшли.*

## Мәрзия Фәйзуллина

# СОЛДАТ ХАТЛАРЫ

*Кече җирдә уйланулар*

●

Төн. Яп-якты. Өстән бертуктамый
Утның явып торган чаклары...
Джанхотадан Кече җиргә хәтле
Саллар йөртә сугыш картлары.

Снарядлар оча уңга, сулга,
Су өсләре китә каралып.
Менә берсе салга килеп төшә,
Бүрәнәләр китә таралып.

Сапер дуслар бер-бер артлы кубып
Салкын суга сикереп төшәләр —
Йөзгән мәлгә салны җыя-җыя,
Хәлдән таеп тирләп-пешәләр.

Тик «картлачлар» гына аңлый торган
Моңнары бар утлы төннәрнең...
Улым, бәгърем, ябышып бүрәнәгә
Аталары йөзә кемнәрнең?!

●

Туфрак янды, ташлар төтенләде,
Күпме солдат каны коелды.
Металл эреде... Бетон җимерелде...
Ахыр заман булып тоелды.

Күпме солдат шулай шәһит китте,
Шулай барды көн дә бездә эш...
Ә фронтта, улым, телгә алып
Әйтерлек юк, диләр, үзгәреш.

## Чөеш уены

Мина кыры булган иңкел җирдә
Мәетләргә йөрим күз төбәп...
Берсеауган әнә күккә карап,
Икенчесе ята йөзтүбән.

Ирексездән күңел дулкынлана
Башка килгән сәер уйлардан:
Әйтерсең лә, үлем кеше белән
Акча чөеш уены уйнаган.

Бу уеннан уймак шул: мәетләр
Ята «иләк» яки «күн» булып.
Аяныч бу... Җиңү даулап алгач,
Үлем килгән соңгы көн булып.

## Дуслар китте... калдым колын белән

Дуслар китте... Калдым колын белән.
Күз тиюдән куркам мин аңа.
Сугышны ул бар диеп тә белми,
Уйнар өчен килгән дөньяга.

Канатланган дуслар — акбүз атлар
Эределәр кичке томанда.
Тынып калды тояк тавышы да,
Шпорлардан чыккан чыңнар да.

Әйе, улым, каты сугышларда
Җанын биргән атлар азмы соң?
Шуңадыр мин күрәм ат күзендә
Халкым моңын, илем язмышын.

Сугыш узар, исән калган дуслар
Сугарырлар талган атларын...
Җибәрерләр туган якларына
Минем кебек сагыну хатларын.

Дуслар китте... Калдым колын белән,
Күз тиюдән куркам мин аңа.
Сугышны ул бар диеп тә белми,
Уйнар өчен килгән дөньяга.

## Телемемне бүләм икегә

Бу хатымнан шуны белегез сез:
Атна инде... Кече җирдә мин.
Бару белән каты сугыштан соң
Иң якын бер дусны җирләдем.

Бер савыттан ашап-эчкәнгәме,
Бигрәк авыр булды күңелгә.
Өзгәләнә йөрәк, теткәләнә
Онытуы һич мөмкин түгелгә.

Бергә чакта булган гадәтемчә,
Кулларымны сузсам ипигә,
Беләм: дустым шәһит, тик барыбер
Телемемне бүләм икегә.

## Дагалар да бәхет китермәде

Көнбатыштан искән җилгә каршы
Дулкын ярып ашыга бер кораб.
Капитаны аны алып бара,
Суга, ярга, күккә гел карап.

Ә трюмда биш йөз сугыш аты
һәм ике мең данә дага бар.
Зәңгәр күктә ап-ак, саф күңелле
Акчарлаклар канат кагалар.

Акчарлаклар нигә моңаялар?
Күңелләре бәлки сизәдер:
Сагышлары бәлки урынлыдыр,
Соңгы кабат кораб йөзәдер...

Чыйнак мина кинәт шул минутта
Палубага килеп кадалды.
Дулкыннарның көмеш чырайлары
Шомлы төскә кереп каралды.

Кешеләр һәм атлар гүя очып
Берәм-берәм суга төштеләр.
Атлар йөзде бер-беренә сыенып,
Көймәләрдә йөзде кешеләр.

Кайсы якка караш төшерсәң дә
Яр күренми — һаман, һаман су.
Ничек ярдәм итик диеп оча
Акчарлаклар, бигрәк ямансу.

Йөрәк өзгеч кешнәп, бата-калка
Хәл беткәнче атлар йөзделәр...
Дагалар да бәхет китермәде,
Малкайлар әй өмет өзделәр.

Әнә инде соңгы ике атның
Тик күренеп калды яллары.
Соңгы тапкыр яулык селкегәндәй
Алары да тынды аннары.

Ландыш кебек ап-ак акчарлаклар
Дулкыннарга утырып елады.
...Истән чыкмас шәһит киткән атлар,
Җан тетрәткеч сугыш еллары.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Коми мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Ут белән уйнауны ташла — үзең утта янарсың.*
*Елга ермактан туа.*
*Аккан сулар кире кайтмый.*
*Сунарчы узган сукмактан эзер җәнлек җыймакчы.*
*Кипкән каеннан су агызмыйлар.*
*Җиләнсез булса, һәр сарык — тәкә.*
*Үткән елгы чаңгы эзе быел узар өчен түгел.*

**Комык мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Яшәү көче — дуслыкта.*
*Көтүдән куылган терлек үләнне тәмләп утлый.*
*Көтүчеләр күп җирдә — сарыклар күпләп үлә.*
*Аксак карга куккә тизрәк менә.*

# НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

*Балалар өчен кызыклы шигырьләр язучы, аларга аталган берничә китап чыгарган шагыйрә Заһирә Гомәровага 50 яшь тулды. Ул Саба районының Эзмә авылында яши, укытучы булып эшли. Актив иҗат дәрте белән янган шагыйрә — безнең журналның да күптәнге авторы.*

*Укучыларыбыз исеменнән иҗат бәйрәме белән дә кайнар котлап, аның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Заһирә Гомәрова

### Бер өйдән сигез кеше

Физкультурачылар көне...
Ярыш бара һәрьякта.
Бу бәйрәмдә безнең өйдән —
Сигез кеше парадта.

Велосипедта чабучы
Күпме оста җыйналган!
Ак сакалын җилфердәтеп
Бабай бара иң алдан.

Район чемпионы булган,
Күп алган бүләген дә.
Ул бүген дә иң беренче
Семьябыз куләмендә.

Бик узмакчы була әти,
Бик узмакчы абыйлар.
Узып китәр иделәр дә,
Куып җитә алмыйлар.

Мин — иң артта. Тик шулай да
Яклап бара гел әнкәй.
— Борчылма,— ди,— син бабаңнан
Илле яшькә бәләкәй!

### Монда без хуҗа

Балта пычкысыз
Килеп чыга да,
Боз күпер сала кыш
Һәр бер елгага.

Җәй көне йөрдек
Йөзәргә шүрләп,
Чөнки үртиләр
Каз белән үрдәк.

Ә менә бүген
Монда без хуҗа.
Узса да безне
Җил генә уза.

Ә яр читендә
Каз белән үрдәк
Боегып тора,
Атларга шүрләп.

# ҮСЕШТӘГЕ ИҖАТ

Язучы Вакыйф Нуруллинның яңа китабы «Аккан су юлын табар»[1] дип атала. Бу җыентыкка авторның шул исемдәге һәм укучыларга яхшы таныш булган «Күпер чыкканда» повесте кертелгән. Соңгысы үз вакытында укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан шактый җылы каршыланган иде. Яраткан әсәр белән тагын бер кабат очрашу ялыктырмый. Бу юлы да шулай булды.

Җитмешенче еллар эчендә Вакыйф Нуруллин дүрт повесть иҗат итте. Әйтергә кирәк, һәрберсе яратып укыла, укучылар күңелен кузгата алырлык осталык белән язылган.

«Әгәр син булмасаң» әсәре, Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте кебек, яшьләрнең аерылмас күңел хәзинәсе булып әверелде дисәк тә һич хата булмас. Рухиянең Равилгә язган хатын, яки әсәрнең башка өзекләрен үзешчән сәхнәләрдән, әдәби кичәләрдә еш ишетергә туры килә, яшьләр аларны күңелләрендә йөртәләр. «Яшьнәп үткән яшьлек» повесте исә безне үткән буыннарның каһарманлыгы, ялкынлы көрәшче Миңнуллалар белән таныштыра, шул елларның данлы сәхифәләрен җанландыра.

«Икмәк булса, җыры да була... Тикмәгә генә шулай диелми. Икмәк һәрвакыт төп ризык, барлык кыйммәтләрнең үлчәгече булды»[2]. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный Секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның бу сүзләре авыл хуҗалыгы эшчәннәре хезмәтенең төп мәгънәсен никадәр тирән ачып сала. В. Нуруллин повестьларының геройлары әнә шундый игелекле хезмәт кешеләре.

Язучы авыл тормышын, аның үткәнен, бүгенгесен әйбәт белә, колхоз председателе эшнең бөтен нечкәлекләре белән яхшы таныш, авыл эшчәннәре характерларын сурәтләүдә кыенлык кичерми. Әсәре өчен сайлап алган тормыш материалы белән иркен эш итү, андагы ситуацияләр, Ф. Хәсни әйтмешли, «үз җыры, үз моңы» булып әверелү автор уңышының яртысын тәшкил итә.

Повестьның язылу тарихын, максатын аңлатып, автор, укучыга мөрәҗәгать итеп, болай ди: «...мена тагын колхоз председателенә әйләнеп кайттым. Кирәк идеме икән болай эшләү? Минемчә, кирәк иде. «Күпер чыкканда» басылганнан соң, колхозлар һәм авыл халкы тормышында зур үсеш-үзгәрешләр булды. Колхозлар гына түгел, колхоз председательләре дә үзгәрде. Элеккеге җиде-ун класс белемле җитәкчеләр урынына махсус югары белем алган, яшь, энергияле иптәшләр килде. Монысы—бер. Икенчедән, без—язучылар авылларда йөргән чагында, авыл халкы да, колхоз председательләре дә: «Авыл турында шактый күп язасыз, әмма күбрәк аның үткәнен язасыз, ә безнең бүгенге тормышыбызны, бүгенге эшләребезне тиешенчә күрсәтеп бирә алганыгыз юк әле», — дип бик хаклы рәвештә үпкә дә белдерәләр. «Аккан су юлын табар»ны мин, әнә шул иптәшләрнең теләкләрен истә тотып, шуларга җавап йөзеннән яздым».

Бу юллар кайбер фикерләргә этәрә. «Кирәк идеме болай эшләү?»—дип сорый автор. Без дә, авторга кушылып, кирәк иде, дибез. Ләкин бу яңа әсәрдә язучы үзе әйткән «зур үсеш-үзгәрешләр» чоры колхоз председателен күрәсе килә иде. Әмма, кызганычка каршы, Булат та, Әлфәт кебек, бер үк чор — сугыштан соңгы һәм илленче еллар колхоз җитәкчесе булып кала. Дөрес, алар бүген дә шул постта, ләкин аларның характерлары, нигездә, кырыгынчы еллар ахыры, илленче еллар проблемаларын хәл иткәндә ачыла, чөнки алар күбрәк шул ситуацияләр эчендә сурәтләнә. Димәк, бүгенге чорның проблемалары, аларны чишүдәге каршылыклар эчендә сурәтләнгән председательне күрү теләгебез әле канәгатьләндерелмәде. Вәгъдә яртылаш кына үтәлгән. Бәлки, алдагы иҗатында В. Нуруллин бу темага бөтенләй үк якын килер, бүгенге тормыш материалының эченә үк үтеп керер.

«Элекке җиде-ун класс белемле җитәкчеләр урынына махсус югары белем алган, яшь, энергияле иптәшләр килде»,— ди язучы. Бу да дөрес. Күрүебезчә, повесть геройлары да читтән торып махсус югары белем алган авыл хуҗалыгы белгечләре, ләкин шулай да яшьләре белән шактый олы кешеләр. Бүгенге яшь кадрлар, авыл хуҗалыгы җитәкчеләренең күп-

[1] Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.
[2] Брежнев Л. И. Чирәм җир. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979, 3 бит.

челеген тәшкил итүчеләр характерын художестволы өйрәнү заман язучыларының төп бурычларыннан берсе булып кала бирә әле.

Бу турыда сүз чыккан икән, әйтеп үтәсе килә: авыл хуҗалыгыбыздагы уңышларны колхоз председательләренә генә кайтарып калдыру берьяклылыкка илтә. Авылда уннарча белгечләр, күп төрле механизатор кадрлар, намуслы колхозчылар эшли. Алар барысы да әсәр герое булырга лаеклылар. М. Җәлил «Хат ташучы» поэмасында, Г. Бәширов «Намус» романында бригадир образларын әнә ничек калку итеп сурәтләп бирделәр иң! Аннан соң авыл хуҗалыгыбызның үсешендә партиянең Сентябрь (1953) һәм Март (1965) Пленумнары карарларының хәлиткеч әһәмияте дә һәрвакыт истә тотылырга тиеш.

«Аккан су юлын табар» әсәренә килгәндә, ул укучыны үз артыннан ияртә, сурәтләнгән вакыйгаларга ышандыра. Авторның йөгерек, үткен, образлы теле дә әсәрнең үзенә тарту көчен арттыра. Әсәр В. Нуруллин иҗатының үсештә икәнлеген күрсәтә. Ләкин шулай да әсәрне кызыклы иткән, аның җегәрен арттырган әйбер ул конфликт үткенлеге, характерның шул бәрелешләрдә табигый ачылышы.

Әсәр кешегә бер урында туктап калмаска, яткан таш мүкләнә, йөргән таш шомара дигәндәй, хәрәкәт итәргә, су кебек томырылып агарга кирәклекне әйтү өчен язылган. Ләкин агу белән агу арасында аерма бар, сулар үрләргә акмаса да, кешегә үргә таба да барырга, каршылыкларга туры карап атларга туры килә. Шулай итмәсәң, суның, үз агымына ияртеп, син теләмәгән якларга илтеп адаштыруы бар.

Булат та башта су уңаена агып карый. Әнисе кушуы буенча фельдшер-акушерлык мәктәбенә керә, әнисенең энесе Нәкыйп абыйсы киңәше белән хисапчылар курсында укый. Ләкин хисапчылык эшен яратмыйча, ирексездән башкара. Тормыш аның алдына бер-бер артлы каршылыклар куя, аларның берәүләрен ул урап үтә, ә кайберләреннән алай әйләнеп үтеп кенә котылып булмый. Менә шул каршылыклар Булат характерын укучыга ачып күрсәтүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Ул каршылыклар, нигездә, әхлакый планда, шул сәбәпле геройның шәхси тормышындагы сикәлтәләрен тасвирлауга өстенлек бирелгән дә.

Конфликт иң баштан ук шәхси планда оеша. Булат та, Шәйхи дә нәсел-нәсәпләре буенча ярлы катлаудан. Әле бала чакта ук, әтиләре бер-берсе белән гаугалашып йөргәндә, малайлар арасында дуслык булмый. Егет булгач, икесе дә Айсылу исемле кызга гашыйк була. Әмма кыз үзенә гомерлек юлдаш итеп Булатны сайлый, нәтиҗәдә үзара мөнәсәбәтләрдәге каршылыклар тагын да кискенләшә. Булат тагын бераз су агымына бирелеп ала — Кузбасс шахталарын урап кайта.

Автор конфликтны кора белә, анысы бәхәссез, ләкин характерның шул коллизия эчендә ничек хәрәкәт итүенә артык әһәмият бирми кебек. Конфликт кискенләшү белән бергә характерның логик үсеше янәшә барырга тиеш. Конфликт иң югары ноктасына җиткәч тә характерның үсешен дәвам иттерү әсәрне салмакландыруга илтә. Бу очракта шулайрак булган. Булат гомере буе Шәйхинең усаллыгыннан, эчкерлелегеннән зарлана. Бактың исә, Шәйхине үз башы өстендә янап торган куәк итеп үстерүгә ул үзе үк булышкан икән. Әсәрнең иң кискен ситуацияле урыны — Шәйхинең законсыз рәвештә колхоз икмәген сатуы, шул турыдагы ялган документның Булат кулына килеп керүе. Әтисе Вәлиуллалардан килә торган турылык, гаделлек Булатка бу очракта үз адымнарын иҗтимагый мәнфәгатьләр белән үлчәүгә китерергә тиеш иде. Икмәкнең килограммы да гаять югары бәяләнгән ул заманда машина белән ашлык урлауга үз мөнәсәбәтеңне белдерү шәхси эш кенә түгел. Ләкин Булат Шәйхине, үз бакчасындагы бер ботак алманы сындырып алган малайны әрләгән кебек кенә, куркытып кала. Авыл Советына гаделлек эзләп килгән колхозчы алдында Булатның — ул вакытта җирле Совет җитәкчесенең — нинди авторитеты калды икән? Димәк, бу очракта ул үзе дә күпмедер дәрәҗәдә Шәйхинең җинаятен бүлешә. Гариф Ахуновның «Чиклəвек төше» әсәрендәге Халик Саматов болай эшли алмас иде. Булатның, Шәйхигә иркенләп каракланырга мөмкинлек биреп, күрше колхозга председатель булып күчүе дә шул ук су агымы белән китүе түгелме икән?

Ярый, Шәйхине фаш итүче кәгазь яндырылган да булсын ди, әмма шушы җинаятьне күреп торган кешеләр бар бит. Теләсә, Булат үз сүзенең дөреслеген раслый алмас иде микәнни? Шәйхине председательлектән төшерүгә ирешсә, гади колхозчы буларак, ул дәүләткә андый зур зыян китерә алмас иде. Шушы күзлектән уйлаганда Булат характерының логик үсеше эзлекле үк бармый диясе килә.

Шәйхи характерының да логикасы бераз аксаган. Шундый горур, үзен генә кешегә исәпләүче, үзенең саткайлыгына (Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасындагы гайбәт таратучы кулак малае) үкенеп, кайчандыр үзе өйләнергә йөргән Айсылу алдына килеп гафу үтенәме соң ул? Автор аны бу очракта иелмәс-бөгелмәс итеп калдырса, конфликт тагын да үсеш кенә алыр иде. Шәйхинең райкомга Булат өстеннән шикаять белән баруы да, бу гадәттән тыш фактка райком секретареның җитди карамавы да әллә ни ышандырмый. Гәрчә, Булат кулында фаш ителерлек документ калмаса да, үз шәхесе турында шундый күңелсез эчтәлекле сөйләшүне оештыруның үзе өчен кирәкле эш булмавын гына аңламаслык ахмак түгел ул Шәйхи.

Булат белән Шәйхи арасындагы конфликт «Күпер чыкканда» повестендагы Әлфәт белән Рәдиф арасында булганга караганда шактый кискен. Чөнки Шәйхи үзенең тоткан урыны, хәзерлеге, хәтта кайбер физик сыйфатлары белән Булаттан өстенрәк. Аны, Рәдиф кебек иттереп, күпер астына тотып атып кына котылып булмый. Менә ни өчен Булат, шәхес буларак, шактый тулы ачылган, чөнки шушы катлаулы шартларда җиңеп чыгу, өстенлекне раслау Булатка җиңел генә бирелми. Әмма ул моңа ирешә, ныклык, ихтыяр көче күрсәтә. Ләкин Шәйхинең соңгы үсеше читтә булу, укучының аны күздән югалтуы әсәр динамикасын бераз йомшартуга китергән дип әйтәсе килә.

Әсәр көндәлекләр формасында язылган. Булат егерме дүрт ел колхоз председателе булып эшли. Әсәр дә шул ук сандагы бүлектән тора. Бүлекләрдә (автор аларны дәфтәрләр дип атый) вакыйгалар эзлекле үстерелсәләр дә, алар ел исәбе түгел. Автор дәфтәрдән-дәфтәргә кеше күңеленең тирбәлешләрен тирәнрәк ача бара, укучыны да шул сәхифәләр белән кызыксындыра. Һәм, әйтергә кирәк, шактый кызыклы күңел дөньясы ачыла. Акыллы, аналитик фикерле белүче, тирәюньдәгеләргә үз мөнәсәбәтен белдереп баручы Булатның көндәлекләре белән танышу укучыны ялыктырмый. В. Нуруллин иҗатына ачыктан-ачык публицистлык гомумән хас. Ул вакыйгаларны сурәтләп кенә калмый, укучы белән фикер дә уртаклаша. Объектив һәм субъектив башлангычларның мондый синтезы шулай ук художестволы әдәбиятта үзенчәлекле алым. Аның герое колхозларның бүгенге экономик хәле, авыл кешеләренең мул, рәхәт тормышы, шушы биеклекләргә күтәрелүдә үзенең катнашы булуы белән горурланып сөйли, шул ук вакытта күп кенә хәл итәсе проблемаларны да хәтердән чыгармый.

Бүгенге җитәкче нинди булырга тиеш? Бу сорауга җавап бирү җиңел түгел. Колхоз — кумәк хуҗалык, ләкин шулай да аның уңышлы, ритмлы һәм рентабельле эшләвендә иң элек председатель җаваплы. Укучы күз алдыннан ике председательнең эш стиле үтә.

Шәйхи колхозчы белән председатель арасында дистанция булырга тиеш дип карый, эшне боерык биреп кенә эшләтергә ярата. Юл уңае туры килгәндә дә үз колхозчылары белән бер атта утырып йөрүне үзе өчен түбәнлек саный.

Булат исә гади булып, колхозчыны тиң күреп эш итә. Бу исә эшнең нәтиҗәлелегенә уңай тәэсир итә, кешеләр белән уртак тел табуга, теләктәш булуга китерә. Шул сәбәпле Булат койрыкта өстерәлгән «Трактор» колхозын тернәкләндерүгә ирешә, аннан соң берләштерелгән «Уңыш» колхозын алгы сафка чыгара.

Үз эшенә бирелгәнлек, җитәкченең намуслылыгы, әхлакый тотнаклык мәсьәләләренә мөнәсәбәтләре дә диаметраль капма-каршы аларның. Шәйхи колхоз турында рәтләп кайгыртмый, дәүләт планнарын гадел булмаган юллар белән үти, кумәк байлыкны әрлән кебек үз оясына ташый. «Намус» романындагы Сәйфидән ким түгел ул. Ләкин Сәйфи үз җәзасын ала. «Шәйхинең ул кыланышлары барыбер бер фаш ителер әле» дип әйтелсә дә, ул әсәрнең азагына кадәр шома килеш йөри бирә. Дөрес, ахырда Шәйхи кабаттан райком секретаре булып сайлана алмый, әмма бу әле аның җитәкчелек эшеннән китүе дигән сүз түгел, ул әле бик күпләрнең канына тоз салачак кеше. Әхлакый яктан да шактый таушалган кеше ул. Ә үзе тормыш баскычларының берсеннән икенчесенә күтәрелә бара. Шәйхи кебек җитәкчеләрнең булуы җәмгыятебезгә никадәр мораль һәм материаль зыян китерергә мөмкин икән! Автор бу мәсьәләне бөтен кискенлеге белән күтәреп бик дөрес эшләгән. Бүгенге җитәкче иң элек үзенә тапшырылган производствоны буйсындыра белергә тиеш, шул сыйфат юк икән, ул кешеләр белән дә идарә итә алмый.

Булат нәкъ шундый мәгънәдәге җитәкче. Үз эшен әйбәт белә, укый, эзләнә, кешеләрне ярата, хөрмәт итә, алар белән дөрес мөнәсәбәт урнаштыра ала. Аның агроном Фәгыйтькә булган мөнәсәбәтеннән моны бик ачык күрергә була. Булат колхоз өчен иң кирәкле белгечләрнең берсе булган агрономга бөтен тиешле шартларны тудыра, эшендә ярдәм итеп тора. М. Хәбибуллинның «Чоңгылар» романындагы председатель Талип Бикмуллин һәм яшь агроном Мидхәт Бәдретдинов арасында булган кебек низаглар китереп чыгармый ул, үз өлкәсендәге эшләрдә агрономга тулысынча ышана. Шулай да колхоз производствосы мәсьәләләрен хәл иткәндә Булат җил уңаена ята дигән сүз түгел. Ул төп җитәкчелекне үз кулында нык тота. Моны кул астындагыларның шәхесен кимсетмичә, алар белән киңәшеп эшли. Булат тормышта үз урынын таба, юлын таба.

Элегрәк чорларда әдәбиятта «җанлы кеше» теориясе бар иде, һәм ул нигездә имеш, беркем дә фәрештә түгел, уңай кешенең дә чатаклы яклары була, характерны бернинди дә кимчелексез итеп тасвирлау хакыйкатькә каршы килә дигән карашны эченә ала иде. Без дә җанлы кеше урынына идеаль курчак ясап чыгару ягында тормыйбыз. Андый образлар, реаль кешене гәүдәләндерүдән бигрәк, аяклы плакатны хәтерләтә башлыйлар. Әмма заманыбызның райком секретаре, колхоз председателе кебек төп фигуралары турында сүз барганда андый образларда йөз аклыгы, тотнаклылык кебек уңай сыйфатларның тотрыклырак булуын таләп итәргә дә хакыйбыз бар.

Шәйхине инде әйтеп тә тормыйбыз, автор аны мөмкин кадәр карарак буяулар белән бирә. Бу хәтта бераз ясалмалылык төсе дә ала кебек. Шәйхи белән Булатның төрле характер иялəре булулары на-

селдән килә дип аңлауга да юл кала. Шәйхинең әтисе Шәрифулла, ярлы нәселдән булуына карамастан, колхозны таркату политикасы алып барган кулаклар рупоры булып килгән.

Ә Булатның үз әтисе Әхмәтша, үги әтисе Вәлиулла (алар ата ягыннан бертуганнар) көч-гайрәт ягыннан тирә-якта бер. Пычракка баткан йөкле арбаны тартып чыгару, дәү бер үгезне «мөгезеннән каерып алып, җиргә егып салу», үзенә һөҗүм иткән берничә кешене һушсыз итү боларга берни дә тормый. Булат та, өлкән яшьтә булуына карамастан, берничә егетнең арт сабагын укыта. Булат әтиләре кебек намуслы булырга омтыла, үги әтисенең васыятен үтәү аның тормышта төп максаты булып әверелә.

Халкыбызның «оясында ни күрсә, очканда шуны күрер» дип бик белеп әйткән сүзе дә бар. Шулай да характерның болай алдан ук билгеләнеп куелуы художестволылыкны киметә. Укучы әсәрнең соңгы бите ябылганчы нәрсә булып бетәчәген сизмәли алмаган очракта гына әсәр җегәрле була. Ә мондый җегәр бары тик конфликтның оригиналь булуы һәм көтелмәгәнчә кискенләшүе белән генә тәэмин ителә.

Булатта да бар кимчелекле яклар. Булатның су агымына бик нык каршы тора алмавы әйтелде инде. Бу як тагын бер нәрсәдә — аның хатын-кызлар белән мөнәсәбәтендә күренә. Күреп торабыз, ул Айсылуга яратып өйләнә, берсеннән-берсе уңган өч бала үстерәләр. Семьяның бер-береңне яратуга нигезләнүе социалистик җәмгыятьнең иң зур казанышларыннан берсе, бу әхлак сафлыгының алшарты булып тора. Ә Булат исә хатын-кыз алдында җеби дә төшә. Үз сүзләре белән әйтсәк, Кәбирә исемле чибәр тол хатын бик җиңел генә аның «уразасын ычкындыра». Яки икенче эпизодны алыйк. Санаторийда ял иткәндә моның номерына Диләрә исемле бер хатын килеп керә көче тапмый, ярым-йорты каршы килгән һәм биредә куныл калачагын белдерә. Булат шуны чыгарып җибәрергә ихтыяр булып, өзеп кенә җавап бирми. Нәтиҗәдә җиңел холыклы бу хатын бүлмәдә йоклап кала һәм Булатның кесәсен чистартып кача. Ныклы характер иясе булса, ул, әлбәттә, тормыш төбенә төшкән мондый шикле затлар белән ике уйларга урын калдырмаслык итеп сөйләшә алыр иде.

Укучы хәтерлидер, шуңа охшашлы эпизод Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар...» романында да бар. Варис яньна яшь чагында таныш булган Васил исемле кыз килеп чыга. Ләкин күңелен башка берәүгә ныклап беркетергә карар иткән Варис бу кыз белән бер бүлмәдә калудан катгый рәвештә баш тарта. Моның белән Варис характерының бөтенлеге саклаңып калына. Кеше — акыллы җан иясе, ул тиешле вакытта үз-үзенә хуҗа булуы белән күркәм калырга тиеш. Инстинктлар колы булу кешене кимсетә. Хәер, андыйлар тиешле җәзаларын да алалар. Без моның шулай икәнен В. Нуруллин повестеннан да ачык күрәбез. Теге Диләрә дигән хатын Булатны гына түгел, яшелчә кибете директоры азгын Фәсәхи агайны да, чибәр хатын күргәч дөньясын оныткан Нодарны да ничек итеп акылга утырта!

Эпизодик персонаж гына булса да, шактый колоритлы фигура булып күз алдына килеп баса Диләрә. Ирләр психологиясен бик оста белеп эш йөртә ул. Аларны алдау юлларын бөтен нечкәлекләренә кадәр белә. Укучы, Диләрәдән бигрәк, әнә шул Фәсәхиләрне күрә алмый башлый. Дөрес, автор тегеләрен дә, боларын да камчылый. Андыйларга каршы кискен сүзен әйтеп, язучы бик дөрес эшләгән. Әхлак проблемасы һәр чорда актуаль булды һәм шулай булып кала, тормыш китереп чыгарган кайбер күңелсез якларны фаш итү, матурлыкның өстенлеген раслау социалистик реализм әдәбиятының әһәмиятле бурычы.

Күреп үткәнебезчә, В. Нуруллинның яңа повесте укучыны күп яклап уйландыра, фикерләүгә этәрә. Димәк, әсәр замандашларны борчыган сорауларны күтәргән. Югарыда әйтелгән аерым кимчелекләре булуга карамастан, кирәкле әсәр бу.

Язучы бер урында үзәк герой Булаттан болай дип әйттерә: «...журналистның (шулай ук язучының да — Ф. Г.) язган әйберсе укучыларны ышандырырлык, укучыларны дулкынландырырлык, хисләндерерлек булырга тиеш дип уйлыйм мин. Ә алай итеп язар өчен журналист кеше үзе күтәреп чыгарга тиешле мәсьәләне җентекләп өйрәнергә, үзе язарга алынган кешеләрнең холыкларын һәм аларның эшләрен биш бармагы шикелле белергә тиеш» (227 бит).

В. Нуруллин социалистик реализм язучысы эшенең төп хасиятен дөрес аңлый, бу аңа алдагы иҗатында тагын да үткенрәк проблемалар күтәрергә, аларны кабатланмас характерларда, тормышчанрак ситуацияләрдә сурәтләү өчен тайпылмас юл күрсәткеч булыр дип ышанасы килә.

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН.**

# ПОЭЗИЯДӘ ЗАМАН СУЛЫШЫ

Бүгенге татар совет әдәбиятының үсеш проблемалары өстендә эшләүче һәм туктаусыз эзләнүче әдәбият галимнәре арасында Тәлгат Галиуллин аерым урын алып тора. «Еллар юлга чакыра» (1975), «Социалистик реализм юлыннан» (1977) дигән китаплары һәм күп санлы мәкаләләре белән ул үзен хәзерге совет поэзиясе проблемалары буенча киң эрудицияле белгеч итеп таныта.

Галимнең «Заман сулышы»[1] исемле яңа китабы аның бу өлкәдә озак еллар буе алып барган тикшеренү һәм эзләнүләренең дәвамы буларак кабул ителә.

Үзенең бу хезмәтендә Т. Галиуллин егерменче-утызынчы еллардагы татар поэзиясендә социалистик реализмның үсешен, яңа төр әдәбиятның эчтәлеген, эстетик күпъяклылыгын, шагыйрьләрнең индивидуаль үзенчәлекләрен, стиль агымнарының хәрәкәтен яктыртуны, образлы фикерләү һәм сурәтләү чараларының үсеш диалектикасына типологик анализ ясауны максат итеп куйган. Һәм, әйтергә кирәк, бу олы максатка шактый тулы ирешә алган.

Илебез халыклары әдәбиятларының тарихын өйрәнү өлкәсендә моңа кадәр егерменче-утызынчы еллар әдәбиятына тиешенчә игътибар биреп җиткерелмәде, дисәк, һич тә ялгыш булмас. Бу бик катлаулы һәм ифрат кызыклы чор әдәбияты буенча гыйльми тикшеренүләр, чыннан да, бик аз. Утызынчы еллар әдәбиятын егерменче яки алтмышынчы еллар әдәбияты белән чагыштырганда соңгыларына зур өстенлек бирү үзен нык сиздерә килде. Ә асылда бу чор әдәбияты һәм аның поэзиясе искиткеч бай һәм күп төрле бит. Әдәбиятыбыз үсешендә аның бик әһәмиятле урыны бар. Т. Галиуллин хезмәте дә бу фикерне ачык раслый.

Автор кайчандыр татар әдәби тәнкыйтендә бу дәверне әдәби кризис чоры дип бәяләргә маташуларны кискен рәвештә кире кага. Ул чорның гаять катлаулы булуына, анда вульгар социалогизм, формализм, конфликтсызлык күренешләренең билгеле дәрәҗәдә зарарына да карамастан, утызынчы еллар поэзиясе социалистик реализм әдәбиятының үсешендә хәлиткеч роль уйнавы.

Соңгы елларда сугышка кадәрге әдәби мирасны җыю, туплау һәм бастырып чыгару буенча шактый эш эшләнде. М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Н. Дәүли, С. Хәким, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, М. Садри кебек шагыйрьләрнең әсәрләре яңадан тупланып, басылып чыкты. Әдәбиятның йөзен билгеләгән, егерменче-утызынчы еллар әдәби хәрәкәтенең үзәгендә торган күренекле язучылар һәм тәнкыйтьчеләрдән Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, М. Галәү, Г. Мөхәммәтшин, Г. Нигъмәти, Г. Гали, К. Нәҗми һ. б. ларның әдәби мирасы басылып чыгу бу чор әдәби хәрәкәтенең күпьяклы һәм бай булуын ачарга мөмкинлек бирде. Т. Галиуллин үзенең монографик хезмәтендә әнә шул зур байлыкка таянып эш итә.

«Заман сулышы» китабының тагын бер уңай ягы — авторның күп милләтле совет әдәбияты тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итеп, татар поэзиясен әдәбиятларның үзара бәйләнеше, бер-берләренә йогынтысы сферасында күрсәтә белүдә. Татар әдәбиятының рус совет поэзиясе, шулай ук тугандаш башкорт, казакъ, үзбәк, әзербәйҗан, кыргыз, төрекмән һәм башка халыклар әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә үсүен автор бик күп мисалларда чагылдыра.

Т. Галиуллин хезмәтенең структурасы анда куелган үзәк проблемаларны мөмкин кадәр тулырак ачу максатына буйсындырылган. Китап дүрт зур бүлектән тора. Ул бүлекләр эчендә аерым мәсьәләләргә багышланган махсус бүлекчәләр бар.

«Иҗат методы — иҗатның нигезе» дип аталган беренче бүлек совет әдәби тәнкыйтендә һәм татар әдәбияты гыйлемендә иҗат методы хакындагы тикшеренү һәм бәхәсләргә, бу өлкәдәге кайбер тенденцияләргә багышланган. Егерменче еллар тәнкыйтендә булып узган «диалектик материализм методы», «ультрареализм», «дубльреализм», «экстрареализм» кебек терминологик бәхәсләргә һәм аерым буталчыкларга шактый киң туктала, әдәби үсешкә зур зарар китергән вульгар социологизмның тәнкыйтьтә чагылышына ышандырырлык дәлилләр китерә.

Иҗат методы турындагы эзләнүләр Т. Галиуллин хезмәтендә традиция һәм новаторлык проблемасы белән эзлекле бәйләнештә карала. Бу өлкәдә, шулай ук форма белән эчтәлекнең үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсендә дә тәнкыйтьтә кызу бәхәсләр булганлыгы билгеле. Ул бәхәсләр турында Т. Галиуллин хезмәтендә дә телгә алына Г. Ибраһимов, һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Ф. Бурнаш кебек Октябрь революциясенә кадәр үк әдәбиятка килгән язучыларның вульгар социологизм позицияләреннән торып тәнкыйть ителүләре, Ф. Мөсәгыйть, Х. Вәли, С. Каратай, Х. Нәүм кебек тәнкыйтьчеләрнең әдәбият күренешләренә вульгар карашлары хакында китапта кызыклы күзәтүләр бар. Бигрәк тә Такташ иҗатына кагылышлы бәхәсләр хакындагы материаллар гыйбрәтле.

[1] Галиуллин Т. Н. Заман сулышы (1941 елгача татар совет поэзиясендә социалистик реализмның тууы һәм үсеше мәсьәләләре). Казан дәүләт университеты нәшрияты, 1979 (рус телендә). 304 бит.

Т. Галиуллин татар әдәбиятының алга үсешендә Коммунистлар партиясенең көндәлек кайгыртучанлыгы, әдәбият өлкәсендәге мәгълүм карарлары ролен дә ачык чагылдырган.

Социалистик реализм методы термин буларак әдәби хәрәкәттә киң кулланыла башлагач татар совет әдәби тәнкыйтендә аны үзләштерү турындагы күзәтүләргә китапта аерым бүлекчә бирелгән. Яңа иҗат методының, Г. Ибраһимов әйткәнчә, әдип йөрәген халык йөрәге белән бәйләргә мөмкинлек бирүен автор күп санлы мисаллар белән нигезли. Әдәбиятта тел, формализм, тәнкыйть, иҗади процесс турында барган кызу бәхәсләрне чишүдә рус совет әдәбиятында М. Горкийның, татар әдәби хәрәкәтендә Г. Ибраһимовның егерменче еллардагы иҗади эшчәнлеге, аның тәнкыйть мәкаләләре һәм теоретик хезмәтләре, әдәбият белгече М. Хәсәнов әйткәнчә, татар әдәбиятының социалистик реализм юнәлеше буенча үсеп китүендә хәлиткеч роль уйнады.

«Заман сулышы» китабында утызынчы елларда әдәби тәнкыйтькә М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Хәйри, Я. Агишев, Г. Кашшаф, М. Мамин кебек яңа буын әдәбият галимнәре килүнең әһәмияте хакында да әйтеп үтелә. Дәрдмәнд, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич кебек катлаулы иҗат юлы үткән шагыйрьләрнең иҗатын өйрәнә башлау да әдәбият фәнендә алга таба бер адым булды. Татар әдәбиятының бай тарихын өйрәнү, Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һәм башка язучыларның иҗатлары турында җитди гыйльми хезмәтләр язылу шулай ук әдәби хәрәкәтнең тагын да җанлануына китерде.

Хезмәттә татар совет әдәбиятының тугандаш әдәбиятлар белән тыгыз бәйләнештә үсүенә дә зур игътибар бирелә. Татар телендә Горький, Пушкин, Маяковский, Лермонтов, Некрасов, Толстой, Байрон, Гюго, Шиллер, Гейне әсәрләре басылып чыгу Татарстанда рус һәм дөнья әдәбияты классикларының СССР халыклары әдәбиятлары вәкилләренең юбилейлары үткәрелү, төрле милләт язучыларының үзара аралашулары әдәбиятның интернациональлек рухын көчәйтте. Әдәбият фәнендә дә әдәби бәйләнешләрне өйрәнүгә керешү нәкъ менә шушы чорга — утызынчы елларга туры килә.

Монографик хезмәтнең «Революция һәм поэзия» дип аталган икенче бүлегендә автор егерменче еллар татар совет поэзиясендә иҗат методы өлкәсендәге эзләнүләргә махсус туктала. Бирелә романтизм традицияләре турында кызыклы гына күзәтүләр бар.

Революциягә кадәрге татар әдәбияты үзенең проблематикасы, гуманистик пафосы, халыкчанлыгы белән критик реализм методына якын килде, анда шулай ук прогрессив романтизм тенденцияләре дә көчле иде. Т. Галиуллин татар әдәбияты тарихында күренекле урын тоткан мәгърифәтчелек реализмын һәм XX йөз башы әдәбиятына хас булган «романтик реализм» дигән күренешне дә телгә алып уза. Китапта егерменче еллар поэзиясендәге эзләнүләр, «сул агымнар», романтик гыйсьянчылык поэзиясе турындагы күзәтүләргә шактый киң урын бирелгән.

Октябрь революциясенең поэзия үсешенә хәлиткеч йогынтысы, шигърияттә яңа төр революцион романтизм туу «Заман сулышы» китабында аеруча тулы чагылдырылган. Яңа типтагы романтик герой, революция солдаты образын яңа поэтик алымнар белән гәүдәләндерү — революцион чынбарлыкка хас күренеш. Яңа заман югары эстетик идеалга туры килә торган геройны тудырды. Әлеге хезмәттә һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләрнең яңа дәвер героен сурәтләүдәге иҗади эшчәнлеге, бигрәк тә Такташның новаторлыгы, татар поэзиясендә Маяковский традицияләрен үзләштерүе һәм тормышка ашыруы киң тасвирлана, аның Ленин образын тудыруы бөтен татар совет поэзиясенең зур казанышы буларак күрсәтелә. Х. Туфан иҗатындагы философик уйланууларның лиризм һәм сәнгатьчә фикерләүнең, кеше тойгылары тирәнлегенең масштаблы образларда чагылуын автор шулай ук отышлы мисаллар белән раслый.

Монографик хезмәтнең иң зур өлеше— «Заман сулышы» дигән өченче бүлеге утызынчы еллардагы татар поэзиясенең үсеш проблемаларына багышланган. Бу дәвер — илдә тарихи үзгәрешләр чоры — әдәбиятның, шул җөмләдән поэзиянең, олы казанышлары белән характерлана. Революция героикасы бу елларда хезмәт батырлыгы белән кушыла.

Хезмәтенең бу өлешендә автор поэзиядәге романтик пафоска, бишьеллыкларның хезмәт героикасына зур урын бирә. Элеккеге бунтарь-гыйсьянчы герой урынына татар совет поэзиясенә реаль көрәштә, яңа көн конфликтларына чыныккан яңа герой килә. Поэзиядә халыкчанлык принцибы, шул чор кешесенең җанлы образы бик хаклы рәвештә үз урынын ала. Заманның йөзе хезмәт батырлыгын, бөек төзелешләр пафосын гәүдәләндерүдә чагыла. Бишьеллыклар темасы — Донбасс, Днепрдагы төзелешләр, Котыпны яулау поэзиянең үзәк темаларына әйләнү, М. Сөндекле, Ш. Маннур, Н. Баян, Д. Фәтхи һ. б. ларның төзелешләрдән язган шигъри әсәрләре монография авторының игътибар үзәгендә тора. Ул аеруча М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Х. Туфан кебек күренекле шагыйрьләр иҗатына киң туктала. Бер үк вакытта Т. Галиуллин үзе тикшергән чор поэзиясенең кимчелекләренә дә күз йоммый: фактлар белән мавыгу, рапортлар, маршлар шавы астында кеше хисләренең күмелеп калу очракларын тәнкыйтьли.

Монографиянең лирикага багышланган бүлекләре күңелдә җылы тәэсир калдыра. Аерым шигырьләрне, лирик миниатюраларны тикшерү ансат нәрсә түгел. Т. Га-

лиуллин бу өлкәдә, һичшиксез, иркен эш итә һәм сизелерлек уңышларга ирешә. Лириканың тематикасы, андагы синтетик башлангыч турындагы фикерләрне автор Г. Тукай, С. Рәмиев һәм совет чоры шагыйрьләренең иҗат практикасыннан алынган мисаллар белән ныгыта. Еш кына очракларда автор тугандаш казакъ, башкорт, үзбәк поэзиясе мисалларына да мөрәҗәгать итеп бик дөрес эшли.

Х. Туфан, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Ф. Кәрим, С. Хәким кебек шагыйрьләрнең лирик циклларына таянып ул шагыйрьнең шәхесе һәм лирик герой, лириканың «синтетик» характеры һәм «синтетик формалар» хакында уйлана. Хезмәттә С. Баттал, Ш. Маннур кебек шагыйрьләрнең лирик эзләнүләренә урын бирелгән. Җыр жанрында халык иҗаты традицияләрен дәвам итү, бу өлкәдә М. Җәлил, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, С. Хәким, Г. Хуҗи, М. Садри һ. б. шагыйрьләрнең эшчәнлеге дә монографиядә киң чагылыш тапкан.

Поэзиядә лиризмның тирәнлеге, табигать, пейзаж лирикасы хакындагы бүлекчәдә автор, лирик поэзиянең эчке асыл сыйфатларына тукталып, Х. Туфан шигъриятен аерым бер нечкәлек һәм тирәнлек белән анализлый, М. Җәлил, С. Хәким, Ә. Фәйзи лирикасының үзенчәлекләрен ача.

Китапның «Эпос һәм заман» дип исемләнгән соңгы, дүртенче кисәгендә поэзиянең эпик жанры булган поэмаларга киң характеристика бирелә һәм Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, М. Җәлил, Ш. Маннур, С. Хәким, Г. Хуҗи поэмалары җентекле анализлана.

Йомгаклап шуны әйтергә була, Т. Галиуллин татар совет поэзиясенең сугышка кадәрге чорда социалистик реализм методын үзләштерү процессын чагылдырган бик кирәкле гыйльми хезмәт язган. Бу хезмәт әдәбият тарихы белән кызыксынган һәр кеше өчен көтеп алынган бүләк. Татар әдәбияты үсешенең алты томлык тарихы язылган көннәрдә шушындый монографиянең дөньяга чыгуы аеруча куанычлы.

**ГЫЙЛЕМДАР РАМАЗАНОВ,**
филология фәннәре докторы.

# Укучының күңел дәфтәренә

**Кыргыз мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Халык дигән зур нәрсә — изге булып калачак,*
*халыктан аерылучы — мәңгегә югалачак.*
*Таныш дошманга төзрәк атасың.*
*Ир какканны мир каккан.*
*Су кизләүдән башлап болгана.*
*Эчең авыртса — авызыңны яп, күзең авыртса — кулларыңны тый.*
*Ике дөя бәрелешсә, чебеннәр кысылып үлә.*
*Баш таза булса, чәч үсми калмый.*
*Былтыр булган янгыннан көек исе быел чыга.*
*Тинтәкне үз илендә дә әсир итәргә мөмкин.*
*Эт ачуланса — койрыгын болгый, ат ачуланса — колак торгыза.*
*Каты тукмак белән суксаң, йон казык та җиргә керә.*
*Үз өендә артыкны ят җирләр дә үз итми.*
*Әгәр дә саф икәнсең — су бул да пычракны ю.*
*Күңелем яхшы дип белсәң — җир бул да шытым үстер.*
*Акыллыдан алда бар, ахмактан артта атла.*
*Үз колыныи типсә дә, бия аны имгәтми.*
*Кымыз кешегә кан булса, ит — кешегә җан булыр.*
*Ялган сүз — җан дошманы.*
*Зур савытыңны бирәнгә күрсәтмичә саклый бел.*
*Җан бирәсе килгән карга бөркет белән шаярыр.*
*Берсе елга кичмәкче, берсе эчәргә су эзли.*
*Алдан барганның хатасын арттан килүче белә.*
*Егылсаң да дәү дөядән егыл.*
*Телдән агу да һәм бал да тама.*
*Уйламый сөйләү — авырмый үлү.*
*Әйткән сүз — җеп шикелле ул: төрлечә тартып була.*
*Тинтәк җанга әйткән сүз — агып уза торган су,*
*акыллыга әйткән сүз — кулга ияләшкән кош.*
*Яхшы теккән итек тиз тузмый.*
*Күп эшлим дисәң — начар эшләмә.*

## ТАТАРСТАН ХУДОЖНИКЛАРЫНЫҢ III СЪЕЗДЫ

Март аенда Татарстан художникларының III съезды булып узды. Татарстан АССР Художниклар союзы идарәсе отчеты турындагы докладны идарә председателе Ә. И. Тумашев, ревизия комиссиясе отчетын ревизия комиссиясе председателе Г. А. Рахманкулова ясады.

Докладлар буенча фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнашты: РСФСРның атказанган художнигы В. И. Куделькин, ТАССРның халык художнигы В. М. Маликов, художник Э. Я. Зарипов, художник А. Ә. Абзгильдин, скульптор В. И. Рогожин, Куйбышев районының 57 нче ат заводы директоры урынбасары В. И. Макаров, ТАССРның халык художнигы М. Х. Хәйретдинов, РСФСР Художество фондының Татарстан художество-производство мастерскойлары директоры Е. А. Макаров, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Е. А. Симбирин, «Союзспортпроект» институтының зона мастерское баш архитекторы А. А. Спориус, скульптор Р. Х. Нигъмәтуллина.

Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча резолюция кабул итте. Аннары ТАССР Художниклар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составлары сайланды. Яңа сайланган идарәнең һәм ревизия комиссиясенең беренче утырышында Татарстан Художниклар союзы идарәсе председателе итеп Ә. И. Тумашев, председатель урынбасарлары итеп А. Ә. Абзгильдин, Е. А. Симбирин, җаваплы секретарь итеп В. П. Аршинов, ревизия комиссиясе председателе итеп Р. В. Нурмөхәммәтов иптәшләр сайланды.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, КПСС шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре А. В. Моторин катнаштылар.

## ИЛҺАМЫБЫЗ — БӨЕК ЛЕНИНГА!

Даһи юлбашчыбыз хөрмәтенә һәр ел саен башкалабыз Казанда музыкаль фестиваль уздыру матур традициягә әйләнде. Быелгы фестиваль аеруча тантаналы шартларда үтте. В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу уңае белән уздырылган бәйрәмгә Мәскәүдән, Киев, Алма-Ата һәм башка бик күп шәһәрләрдән сәнгать осталары Казанга җыелдылар. Фестиваль 10 апрель көнне М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Ленин яшәде, Ленин яши, Ленин яшәр!» дигән тантаналы концерт белән башланып китте. Концертта СССРның халык артистлары А. Ейзен, Т. Синявская, Казагыстан ССРның атказанган артисты А. Днишев, пианистларның халыкара конкурслары лауреаты М. Плетнев, СССР Зур театрының балет солистлары, халыкара конкурслар лауреатлары М. Михальченко һәм А. Фадеечев, Мәскәү һәм Казан артистлары чыгыш ясады.

Фестивальдә барлыгы 900 ләп сәхнә остасы катнашты. Алар арасында Бородин исемендәге дәүләт квартеты, Пятницкий исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Дәүләт академия рус халык хоры, «Гусляры» дәүләт инструменталь ансамбле, РСФСРның халык артисты Александр Ворошило, БССРның халык артисты Виктор Вуячич, РСФСРның атказанган артистлары С. Снитковский, Н. Петров һәм башка күренекле артистлар бар иде.

Фестиваль Татарстан сәнгать осталары катнашлыгында «Ленин Татарстаны» дигән зур концерт белән тәмамланды.

## ЛЕНИНЧА, КОММУНИСТЛАРЧА ЯШӘРГӘ!

Татарстан язучыларының В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышланган партия җыелышы әнә шул девиз астында узды. «Ленинча, коммунистларча яшәргә!» исемле доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. Ахунов чыкты.

Фикер алышуларда язучылардан С. Хәким, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Н. Дәүли, Л. Ихсанова һәм башка иптәшләр катнашты.

## ЮЛЛАРНЫҢ БЕРЛЕГЕ, ЭЗЛӘНҮЛӘРНЕҢ ТӨРЛЕЛЕГЕ

Ташкентта «Литературная газета» һәм Үзбәкстан Язучылар союзы «түгәрәк өстәл» янында сөйләшү уздырды. «Юлларның берлеге, эзләнүләрнең төрлелеге» дигән темага үткәрелгән бу сөйләшү күп милләтле совет әдәбиятының үсеш юлларына багышланган иде. Илебезнең күренекле язучылары, шагыйрьләре, тәнкыйтьчеләре җыелган әлеге әдәбият форумында Казаннан драматург К. Станиславский исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Туфан Миңнуллин да катнашты.

«Түгәрәк өстәл» янындагы сөйләшүдә катнашкан бер төркем әдипләрне КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членылыгына

кандидат Үзбәкстан Компартиясе Үзәк Комитеты беренче секретаре Ш. Р. Рәшидов кабул итте.

### ЛЕНИНИАНА ҺӘМ БАЛАЛАРНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ

СССР Язучылар союзының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча советының чираттагы пленумы булып узды. Ул В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга багышланды. Пленумны СССР Язучылар союзы секретаре, совет председателе С. Михалков ачып җибәрде. Кереш сүзне язучы М. Прилежаева сөйләде. Чыгыш ясаучылар бөек юлабшчыбызга багышланган әсәрләр турында, ул әсәрләрнең яшь буынны тәрбияләүдәге роле турында сөйләделәр.

Пленумында совет члены, балалар язучысы Ләбибә Ихсанова да катнашты.

### ХИКӘЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Псковщинадагы Пушкин Тауларында бүгенге көн хикәяләренең үсеш юлларына багышланган Бөтенсоюз киңәшмәсе узды-рылды. Илебезнең төрле почмакларыннан җыелган прозаиклар, әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр, нәшриятлар, газета һәм журнал редакцияләре вәкилләре бүгенге совет хикәясенең үсеш тенденцияләре һәм актуаль проблемалары турында сөйләштеләр.

Киңәшмәдә Казаннан күренекле хикәя остасы Әмирхан Еники дә чыгыш ясады.

### МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Ташкентның республика Белем йортында Муса Җәлилгә багышланган зур кичә булды. Герой-шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлы турында филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров сөйләде. Кичәдә Муса Җәлилнең, Абдулла Алишның һәм Әхмәт Симаевның шигырьләре яңгырады. Аларны И. Зәбиров һәм Асия Асланова укыды.

Соңыннан «Яшьлек» исемле татар-башкорт халык ансамбленең концерты булды.

* * *

Ош шәһәренең (Кыргыз ССРы) С. М. Киров исемендәге урта мәктәбе укучылары Бөек Җиңүнең 35 еллыгы уңае белән пионер учаклары кабызалар. Һәрбер учак Ватан сугышының бер героена багышлана. Шундый учакларның берсе Советлар Союзы Герое Муса Җәлилгә атап яндырылды. Аңа багышланган кичәдә пионерлар татар, рус, кыргыз телләрендә шигырьләр укыдылар, М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган газета чыгардылар, китап күргәзмәсе оештырдылар.

### ӘДИП ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

Күренекле язучы һәм галим Нәкый Исәнбәтнең тууына 80 ел тулу уңае белән СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының, Татарстан Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, киңәйтелгән утырышы булды.

Н. Исәнбәтнең гыйльми эшчәнлеге турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Назыйм Ханзафаров сөйләде. Ул әдипнең егерменче еллардан алып бүгенге көнгә кадәрге фәнни эшләренә күзәтү ясады, аның фундаменталь хезмәтләренең дөньякүләм әһәмиятен күрсәтте, әдип архивында бик күп гыйльми хезмәтләр барлыгын әйтеп узды, аларга кыскача характеристика бирде.

Фикер алышуларда филология фәннәре докторы Фоат Ганиев, филология фәннәре кандидаты Илбарис Надиров, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Шириаздан Сарымсаков, сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллин, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми катнашты. Соңыннан Н. Исәнбәт үзе дә чыгыш ясады, иҗат планнары белән уртаклашты, яшьләрне иҗади активлыкка чакырды.

### ДРАМАТУРГИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсендә соңгы ике елдагы драматургиябезнең торышы турында сөйләшү булды. Аны кереш сүз белән идарә председателе Р. Җиһаншина ачып җибәрде.

Татарстан Язучылар союзы каршындагы драматурглар секциясе җитәкчесе А. Гыйләҗев докладыннан соң фикер алышуларда театр тәнкыйтьчеләреннән А. Әхмәдуллин, Х. Гобәйдуллин, Һ. Мәхмүтов, И. Илялова, драматург Т. Миңнуллин иптәшләр катнашты.

* * *

Март аенда Әлмәт дәүләт драма театрының Чаллы шәһәрендә гастрольләре булып узды. Шул уңай белән анда драматурглар Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Батулла, Р. Хәмид, театр белгечләре И. Илялова, Д. Гыймранова, И. Гатова да катнашты. Алар Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә», А. Гыйләҗевнең «Әгәр бик сагынсаң», Р. Хәмиднең «Иске йорт кешеләре», Ю. Сафиуллинның «Без дә үсеп җиттек» һәм Ю. Әминовның «Очрашырбыз, Гөлсылу» спектакльләрен карадылар, фикер алышуларда катнаштылар. Мөслимнән килгән яшь драматург Ф. Садриевның «Кондырлы кодачалар» исемле комедиясен укып тикшерделәр. Шушы ук группа Минзәлә дәүләт драма театры күрсәткән Р. Хәмиднең «Язмышлар хәл ителгәндә», Ә. Гаффарның «Соңгы ләкләк» исемле ике яңа спектаклен дә карады. Анна́ры Минзәлә Культура йортында студентлар, яшьләр, җәмәгатьчелек вәкилләре белән очрашу үткәрелде. Минзәләдәге очрашуларда драматург Әхәт Гаффар, ТАССР культура министры урынбасары, шагыйрь Ренат Харис та катнашты.

## ҮТКЕН ПУБЛИЦИСТИКА ӨЧЕН

Пресса йортында ТАССР Журналистлар союзы, ТАССР Язучылар союзының очерк-публицистика буенча иҗат секциясе белән берлектә, вакытлы матбугатта публицистиканың торышы турында сөйләшү уздырды. Сөйләшүне ТАССР Журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов башлап җибәрде.

Утырышта ТАССР Язучылар союзының очерк-публицистика секциясе җитәкчесе Марсель Зарипов, язучылар Мөхәммәт Мәһдиев, Самат Шакир, Мөнир Мазунов бүгенге публицистика һәм алда торган бурычлар турында сөйләделәр.

## СОЮЗГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ

ТАССР Язучылар союзы каршындагы балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышында балалар язучысы Җәүдәт Дәрзамановның иҗат отчеты тыңланды. Кереш сүз белән секция җитәкчесе Адлер Тимергалин чыкты. Ул Җ. Дәрзамановның балалар әдәбиятында актив эшләп килүен, туктаусыз эзләнүен, балалар әдәбиятын пропагандалауда актив катнашуын билгеләп үтте.

Язучы иҗаты турында Ләбибә Ихсанова сөйләде. Фикер алышуларда Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов, Нур Гайсин, Равил Кукушкин, Резеда Вәлиева, Ринат Мөхәммәдиев, Мөдәррис Әгъләмов иптәшләр катнашты.

Секция утырышы Җәүдәт Дәрзамановны бертавыштан СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итте.

## ЯШЬЛӘР КОМИССИЯСЕНДӘ

Яшь авторлар белән эшләү комиссиясенең чираттагы утырышында Казан дәүләт университетында озак еллар эшләп килүче «Әллүки» әдәбият түгәрәгенең отчеты тыңланды. Түгәрәкнең эше турында университет укытучысы, түгәрәк җитәкчесе Флера Ганиева сөйләде. Утырышта шулай ук Чаллыдагы «Ләйсән» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, язучы Газиз Кашапов та катнашты. Ул түгәрәкнең эш планнары белән таныштырды.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ТҮГӘРӘГЕНДӘ

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенең чираттагы утырышы яшьләр прозасы мәсьәләләренә багышланды. Кызыклы сөйләшүдә Ә. Закирҗанов, З. Хөснетдинов, Р. Бикчуров һәм башка яшь тәнкыйтьчеләр катнашты. Алар «Идел» альманахында басылган проза әсәрләренә хас үзенчәлекләр турында фикер алыштылар.

## ӘДӘБИ КОНКУРС

ВЛКСМ Үзәк Комитеты, СССР Госкомиздаты һәм СССР Язучылар союзы идарәсе быел 1 марттан башлап яшь авторның иң яхшы беренче китабына даими Бөтенсоюз конкурсы игълан итте.

Бу әдәби конкурста 35 яшькә кадәрге әдипләр катнаша ала. Китапларны республика һәм өлкә нәшриятлары, союздаш республикалар, крайлар һәм өлкәләрнең комсомол комитетлары, язучылар оешмалары тәкъдим итә. 1981 елдан башлап конкурска ике елга бер йомгак ясалачак. Җюриның карары Максим Горькийның туган көненда—28 мартта игълан ителәчәк. Җиңүчеләр төрле жанрлар: проза, тәнкыйть, әдәбият гыйлеме, публицистика һәм очерклар буенча акчалата премияләр һәм Максим Горький исемендәге конкурс дипломы белән бүләкләнәчәкләр.

## ӘДӘБИ АТНАЛЫК

Баулы районы авылларында В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстанның 60 еллык юбилее, Бөек Җиңүгә 35 ел тулу уңае белән әдәбият һәм сәнгать атналыгы уздырылды. Атналык Исергәп авылы Культура йортында башланып китте. Очрашу кичәсен «Урал» колхозының партком секретаре Ф. Хәбипов ачты. Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре, прозаик Мөсәгыйт Хәбибуллин үз чыгышында республикабыз әдипләре башкарган эшләр турында сөйләде. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, шагыйрь Роберт Миңнуллин, прозаик Рәфкать Карами тамашачыларны үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар. Җырчы Миңгол Галиевнең җырларын да залдагылар яратып тыңладылар.

Шушындый ук очрашулар Баулы эшчеләр поселогында, Каракашле, Кече Урыссу, Бәйрәкә авылларында да җанлы үтте. Язучылар Ильич исемендәге, «Байкал» колхозларында, Урыссу эшчеләр поселогында да хезмәт ияләре белән очраштылар, мәктәпләрдә укучылар белән әдәби кичәләр оештырдылар.

## «КАЗАН ЯЗЫ»

Татарстан Язучылар союзы тарафыннан даими үткәрелә торган шигъри бәйрәм— «Казан язы» быел зур юбилейларга— В. И. Ленинның тууына 110 ел тулуга, Татарстан АССРның 60 еллыгына, Бөек Җиңүгә 35 ел тулуга багышлап үткәрелде.

Беренче кичә сәүдә работникларының Культура йортында үтте. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Аннары Илдар Юзеев, Роберт Батулла, Рәфкать Карами, Флюра Гыйззәтуллина үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

Соңыннан Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов, Татарстанның атказанган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина, артистлар Миңгол Галиев, Рәгъде Халитов, Зөһрә Сәхәбиева, Клара Хәйретдинова һәм Искәндәр Биктаһиров катнашында зур концерт булды.

Шундый ук кичәләр мехчылар Культура сараенда, «Комсомолец» клубында, В. И. Ленин исемендәге, С. Сәетгалиев

исемендәге Культура сарайларында да уздырылды. Анда язучылар Вакыйф Нуруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәфкать Кәрами, шагыйрьләр Галимҗан Латыйп, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Фаил Шәфигуллин, Разил Вәлив, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Фәннур Сафин, Хәйдәр Гайнетдинов һәм башка әдипләр катнашты.

* * *

Шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев Казанның 35 нче мәктәбендә, шулай ук Казан авыл хуҗалыгы институтында укучылар, студентлар һәм укытучылар белән очрашу уздырды. Ул сорауларга җаваплар бирде, үзенең шигырьләрен укыды, бүгенге әдәбият яңалыклары белән таныштырды. Очрашулар җанлы һәм кызыклы узды.

* * *

Казанның 5 нче китап кибетендә язучылар белән очрашу үткәрелде. Китап сөючеләр белән очрашуга өлкән шагыйрь Мөхәммәт Садри, язучы Рәисә Ишморатова, «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре, язучы Мәдинә Маликова килде.

Ул көнне кибеттә татар язучыларының В. И. Ленинга багышланган әсәрләреннән торган китап күргәзмәсе эшләде.

## ЯЗУЧЫГА — БАМ ПРЕМИЯСЕ

«Якутуглестрой» комбинаты һәм «Литературное обозрение» журналы редакциясе Кече БАМ һәм Көньяк Якутиядәге территориаль-промышленность комплексы төзүчеләре һәм эшчеләре хезмәтен һәм көнкүрешен яктырткан иң яхшы әсәрләргә иҗат конкурсы үткәргән иде. Күптән түгел бу конкурска йомгак ясалды. Җиңүчеләр арасында татар язучысы Рафаэль Мостафин да бар. Әлеге конкурс премиясенә ул «Дружба народов» журналында (1 нче сан) басылып чыккан «Нерюнгрига кайту» исемле очеркы өчен лаек булды.

## ДИПЛОМ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ

СССР Язучылар союзы һәм СССР Композиторлар союзы Бөек Октябрьга багышланган җыр конкурсы уздырганнар иде. Шушы арада конкурсның йомгаклары билгеле булды. Анда композитор Рөстәм Яхинның «Иң матур җырым синә, Октябрь» исемле җыры (Р. Байтимиров сүзләре) диплом белән бүләкләнде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешма утырышында язучы Шамил Бикчуринның «Тирән катлам» исемле яңа романы тикшерелде. Әсәр Татарстан һәм Себер нефтьчеләренең иҗади элемтәсен, дуслыгын, яңа нефть ятмаларын ачу өчен барган киеренке көрәшне чагылдыра.

Чыгып сөйләүчеләрдән Җәмит Рәхимов, Гамил Афзал, Юныс Әминов, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов «Казан утлары» журналының проза бүлеге редакторы Марсель Галиев, Азат Ганиев, Альберт Хәсәнов, Роберт Рәкыйпов, Нур Әхмәдиев һәм башка иптәшләр романның уңышлы якларын күрсәтү белән бергә, аның масштаблы фикер көрәшенең җитенкерәмәвен дә күрсәтеп үттеләр. Авторга әсәрен тагын да камилләштерү юнәлешендә күп кенә файдалы киңәшләр әйтелде.

* * *

Нефть районнарында яшәүче язучылар һәм яшь авторлар алдында Шамил Бикчурин белән Җәмит Рәхимов «Язучының иҗат командировкасы» дигән темага чыгыш ясадылар. Алар Советлар Союзының төрле почмакларында иҗат командировкаларында булган чакта алган тәэсирләре турында сөйләделәр, тәҗрибә уртаклаштылар.

* * *

Әлмәт язучылар оешмасы нефть якларында яшәүче яшь авторлар белән эшләүгә зур игътибар бирә, үзенең төп тырышлыгын әдәби берләшмәләрнең эшен тагын да җанландыруга юнәлтә. Лениногорскидагы «Чишмә», быел үзенең 25 еллыгын билгеләп үтәчәк. «Әлмәт» әдәбият берләшмәләре яшь талантларга аеруча бай. Беренче адымнарын шушы берләшмәләрдән башлап җибәргән әдипләр дә аз түгел. Әдәби алмаш тәрбияләүдәге уңышлары өчен Әлмәт язучылар оешмасы ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Әлмәттәге рус әдәбият берләшмәсе утырышында яшь язучы Адел Алиуловның яңа повесте тикшерелде. Әсәрдә яшьләрне тәрбияләү, әхлак проблемалары күтәрелә. Тикшерүдә катнашкан язучы Владимир Мальцев, шагыйрьләр Иван Винокуров, Дмитрий Матвеев һәм башка чыгыш ясаучылар әсәргә нигездә уңай бәя бирделәр. Адел Алиулов ул әсәре белән Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтында диплом эше яклаган иде.

* * *

Әлмәттәге 15 нче эшчеләр тулай торагында Татарстанның 60 еллыгына багышланган әдәби кичә уздырылды. Анда татар язучыларының китапларыннан күргәзмә оештырылды. Кичәдә шагыйрә Клара Булатова үзенең шигырьләрен укыды, әдәбиятка кагылышлы сорауларга җаваплар бирде.

# ТАТАРСТАН

**МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИН**
**музыкасы**

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
**сүзләре**




Яшьлекнең таңында мин күпме
Хыялый сарайлар кормадым!
Хыялны канатлы кош итте,
Туган җир, тик синең җырларың.

Кушымта:


Без — дусларга ак күгәрчен,
Дошманнарга — арыслан,
Безгә шундый иман бирдең,
Көч бирдең, Татарстан.

Йөрәктә син булган чагында,
Ялгыз да, ятим дә булмамын!
Мәңгелек көч алам Иделдән,
Җаныма коя күк Чулманың.

Кушымта.

Безгә бит бергәләп кичәсе
Дөньяның давыллы елларын...
Тик бәхет ягына илтсеннәр,
Илтсеннәр Ватаным юллары!

Кушымта.


Con moto (marciale)
Без- дус- лар- га ак ку- гәр- чен,
дош-ман-нар-га а- рыс- лан.
Без- гә шун-дый и-ман бир- дең, көч бир-
дең, та- тар- стан
Көч бир-дең,
та- тар- стан.
стан
стан

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Менә сез журналның ярты ел буе чыгып килгән байлыгы белән таныштыгыз. Инде киләчәк айда, 7 нче санда нинди
рәк әсәрләр басылачагы белән кызыксынасыздыр. Рәхим итегез!

Журналның 7 нче саны Г. Ахуновның сез ике айдан бирле укыган яңа повесте белән ачылачак. Шуның белән «Йолдызлар калка» повесте бу айда тәмамлана. Шулай ук язучы А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән...» исемле повестеның да 7 нче санда ахыры басылачак.

Монда шигырьләр бик мул итеп бирелгән. Укучы Р. Гатауллинның «Феникс — бәхет кошы» дигән баш астына тупланган яңа шигырьләр циклын һәм Ф. Гыйззәтуллинаның күп санлы шигырьләрен укый алачак.

Поэзия бүлеге моннан тыш «Дуслар иҗаты» рубрикасында Каракалпак АССР шагыйрьләренең иҗат үрнәкләрен дә тәкъдим итә. Бу сәхифәләр — ике республика арасындагы дуслык билгесе. Быел август аенда Каракалпак республикасында татар әдәбияты һәм сәнгатенә багышлап үткәреләчәк бәйрәмгә Татарстанның күп санлы сәнгать эшлеклеләре, әдипләре барачаклар. Журналның 7 нче санындагы «Дуслар иҗаты» рубрикасы да шул сәфәргә әзерлек төсендә бирелә.

Очерклардан М. Зариповның Түбән Кама шәһәре кешеләренә багышланган язмасын күрсәтергә була. Очерк зур күләмле. Бу санда аның беренче өлеше генә басыла.

Тәнкыйть бүлеге бу юлы яңа рубрика ачып җибәргән. «Яшь тәнкыйтьче сүз сорый» дип исемләнгән бу рубрика дүрт яшь тәнкыйтьченең чыгышын сыйдырган.

Болардан тыш журналда «Китап күзәтү», «Безнең календарь», «Әдәбият-сәнгать яңалыклары» рубрикалары бар. Аларга кергән һәр язма укучыны кызыксындырыр дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ